# КАЗАН УТЛАРЫ

www.kazanutlary.ru

ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ЖУРНАЛ

1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА


## Бу санда


ШИГЪРИЯТ ҺӘМ ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР

Ренат ХАРИС. Уба. *Поэма.* ....3
Фәтхулла АБДУЛЛИН. Күрәсен күрде... *Бәян.* ....10
Мөхәммәт МИРЗА. Сабырлык сорыйм ялварып... *Шигырьләр.* ....37
Альберт ХӘСӘНОВ. Өстемдәге затлы җиләнем... Хикәя. ....42
Әхмәт САТТАР. Шигърияткә бирдем гомеремне. *Робагыйлар (Фирдәвес Хуҗинның кереш сүзе белән).* ....56
Рөстәм ЗАРИПОВ. Әниләр. *Бәян.* ....60
Рәмис АЙМӘТ. Кыяларсыз калган дөньялар. *Шигырьләр.* ....78
Луиза ЯНСУАР. Тузганак таҗларын көрибез. *Шигырьләр.* ....96
*100нче бит:* Фирдәвес ХУҖИН. Туган телем. *Шигырь.* ....100

«ИҢ ШӘП ХИКӘЯ» КОНКУРСЫНА

Нурания ТӨХБӘТУЛЛИНА. Сөйли, жырлый, сагына торган материя. *Хикәя.* ....101

ЯҢА ИСЕМНӘР

Айгөл ХӨСНУЛЛИНА. Язмыш кайтавазы. *Бәян.* ....82
Сәгыйть ӘХМӘТҖАНОВ. Ул хакыйкатьне белгән... *Шигырьләр.* ....113

ГАМЬЛЕ ӘҢГӘМӘ

Бер гасыр милләт сагында *(Казанның Г.Тукай исемендәге 1нче татар гимназиясе директоры Г.ШӘМСИЕВА белән Р.ХАННАНОВ әңгәмәсе).* ....118

ЮБИЛЕЙЛАР

Фоат ГАЛИМУЛЛИН. Бүгенгедән – тарихка таба *(Мөсәгыйт Хәбибуллинга 90 яшь).* ....122
Камил КӘРИМОВ. Һәркем яшьлеген эзли *(Әхсән Баянның тууына 90 ел).* ....128
Ләбиб ЛЕРОН. Әнвәр эзи *(Әнвәр Хәйринең тууына 70 ел).* ....131

ФӘН

Зиннур МАНСУРОВ. Каләм бергәлектә көчле. ....134

ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

Дания ЗАҺИДУЛЛИНА. Кем ул – Нобель бүләге лауреаты Һенрик Сенкевич? ....144
*Әдипнең төүге китабыннан:* Мәхмүт ХӘСӘНОВ. Герой. *Хикәя.* . ....150
*Тукай һәм татар әдәбияты:* Рифә РАХМАН. Уй буеның уйлы урамнары. ....155
*Әдәби хәзинәләребез:* Зәки ВӘЛИДИ ТУГАН. *Хатирәләр.* ....157
*Фикер:* Айрат ЧАНЫШЕВ. Карлы тауда – Карачун. ....173
*Табигать һәм мин:* Лилия ГАТАУЛЛИНА. Хушлашып китте... ....181
2017 елда «Казан утлары» журналында басылган әсәрләр исемлеге. ....184
Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан. ....190

Гамәлгә куючы –
«Татмедиа»
акционерлык
җәмгыяте

*БАШ МӨХӘРРИР –*
**Илфак Мирза улы**
**ИБРАҺИМОВ**

*ИДАРӘ:*

**Рабит Батулла**
**Мөдәррис Вәлиев**
**Разил Вәлиев**
**Рәдиф Гаташ**
**Рәдиф Җамалетдинов**
**Айрат Зарипов**
**Дания Заһидуллина**
**Дамир Исхаков**
**Зиннур Мансуров**
**Хатыйп Миңнегулов**
**Вакыйф Нуриев**
*(җаваплы сәркатип)*
**Данил Салихов**
**Айрат Сибагатуллин**
**Энгель Фәттахов**
**Равил Фәйзуллин**
**Рамил Ханнанов**
*(баш мөхәррир урынбасары)*
**Рәфикъ Юныс**

---

*Мөхәррирләр:* **Айгөл Әхмәтгалиева, Гөлзадә Бәйрәмова, Фәнил Гыйләҗев, Камил Кәримов, Ләйсән Солтанова, Рәфикъ Юныс.**

*Гамәли хезмәткәрләр:* **Лилия Гатауллина, Элеонора Җамалиева, Наил Кадыйров.**

*Сайт мөхәррире:* **Рәзилә Хәйретдинова.**

*Исәп-хисап бүлеге:* **Люция Сөләйманова** (баш бухгалтер).

---

✉✉: Редакция һәм нәшер адресы: *420066, Казан, Декабристлар урамы, 2.*
☎☎: *Баш мөхәррир – 222-05-50 (өст. 1618).*
*Баш мөхәррир урынбасары – 222-09-83 (өст.1612).*
*Шигърият, сәнгать һәм хатлар бүлеге – 222-09-83 (өст.1616).*
*Исәп-хисап бүлеге – 222-09-80 (өст.1266).*
: **Факс** – (843) *222-09-83 (өст.1612).*

: **E-mail:** kazanutlari@yandex.ru

---

★Авторлар фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.
★Редакциягә килгән кульязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
★Басмаханә гаебе белән киткән җитешсезлекләр өчен редакция җавап бирми, брак журналларны алыштыру мөмкинлеге юк. Алар хакында 519-44-61 телефоны белән басмаханәнең техник контроль бүлегенә хәбәр итәргә кирәк.

---

Журнал редакциянең компьютер үзәгендә җыелды һәм битләргә салынды. Айга бер тапкыр чыга.
Басарга кул куелды 30.11.2017, график буенча 30.11.2017.
Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы 70Х108 $^{1}/_{16}$.
Нәшер-хисап табагы 14,2. Басма табак 12 (16,8). Заказ А-3042. Тираж 4030.
Журнал Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм гаммәви коммуникацияләрне күзәтү буенча федераль хезмәтнең Татарстан Республикасы идарәсендә 2011 елның 23 мартында теркәлде.
Теркәлү таныклыгы ПИ № ФС77-44362.
Индекслар: 73210 (Татарстаннан читтә яшәүче физик затлар өчен), П2365 (Татарстанда яшәүче физик затлар өчен), 16262 (Татарстаннан читтәге юридик затлар өчен), П2368 (Татарстандагы юридик затлар өчен). Бәясе ирекле.

---

Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы ярдәме белән чыгарыла.
«ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды.
Казан, Декабристлар урамы, 2

© «Казан утлары», 2017 ел



Ренат
Харис

# УБА

ПОЭМА

– Сталинистмы, әллә түгелме? – дип
сорап куйды дустым нигәдер.
Нинди фикер аның күңеленә
сәяси ук булып тигәндер,
юкса баллы сүзләр генә иде,
рюмка да юк иде табында...
Россиядә рюмка «девонынннан»
төрле сорау, җавап табыла...

Сорау сискәндерде йөрәгемне
һәм сагайтты тыныч аңымны –
әйтерсең лә миңа кәй кушамат
йә бик хәтәр ярлык тагылды.
«...ист»лар, «...изм»нарны күп ишеттек,
без шуларсыз яши белмәдек...
Ярлык үзе медаль дискы булса,
«...ист»ы булды аның элмәге...

Җавап бирергә мин ашыкмадым...
Ул да аңлатмады соравын...
Әлегәчә минем күңелемдә
канлы ыргак булып тора ул.
Мал түшкәсен шундый ыргак белән
өчаякка асып туныйлар...
Әмма шулчак бу дәһшәтле сүздә
Җиңү байрагының тыны бар.

Ренат ХАРИС (1941) – *Татарстанның халык шагыйре; Россиянең Дәүләт, Татарстанның Г.Тукай исемендәге Дәүләт премияләре лауреаты. Җиде томлык «Сайланма әсәрләр» һәм төрле телләрдә басылган күпсанлы китаплар авторы. Казанда яши.*

Дустым минем – күренекле кеше!
Бөтен Әлмәт белә дустымны.
Ничә еллар без курсташ булдык...
Сагынуның тансык сусыны
мине, Казан казанынннан алып,
Әлмәт табынына китерде –
студентлык чоры мизгелләрен
без сихәтле шәраб иттердек...

Ул гаҗәеп төгәл – бер сүзне дә
әйтмәс болай гына – сәбәпсез.
Ул көттерә... Мин дә көтә беләм...
Бер ритмда йөргән сәгать без...
Аңның бер яртысы табын тота –
сөйли, көлә, мактый, мактана;
икенчесе – «сталинист»лыкның
эзен эзләп җанда таптана...

Хәтер сызгалана яшен кебек,
гомер мизгелләре кабына...
...Җыр дәресе беренче сыйныфта –
генералиссимус ягына
сөеп карап, бирелеп җырлыйбыз:
(итенергә генә оста мин –
җырлый белмим) чын көчкә кычкырам:
– Яшә, даһи Ста-а-а-а-а-а-лин![1]

Ә ул үлде. Бөтен мәктәп белән,
авыл белән үксеп еладык...
Шул көннәрдә, ахры, күңелемдә
нидер туды, нидер югалды.
Шул вакыттан бирле мин, чыннан да,
«сталинист» булып яшимдер?..
Күңел үлчәвемнең төрле якка
һаман чайкалуын яшермим:

шәхес культы кайчак баса төшә
һәм кузгата нәфрәт буранын...
Ә һәрвакыт Җиңү байрагын мин
«эверест»та тотып торамын.
Җиңүгә бит кемдер алып бара,
көчле генә яулый Җиңүне!
Кемнең күргәне бар берәр илгә
көч-куәтнең күктән иңүен?!.

Үлчәүне дә алмаштырып карыйм...
Баланс таба алмыйм һаман да...
Нишлисең бит, яшим, эшлим, язам
шундый илдә, шундый заманда.

---

[1] «Гөрләсен безнең җыр» – Җәүдәт Фәйзи музыкасы.

Дөреслекне казып чыгарабыз,
ә ул шартлый безнең кулларда –
ябылып бетә язган яраларның
каткан кутырларын кубара.

Ике тәлинкәсен дә үлчәүнең
авырайта тамып яңа кан.
Ил-халыклар шул ук Дөреслектән
плюс-минус эзли яңадан.
Дөреслекнең бармы бөтен Җирне
канәгатьләндерә алырлык
үлчәгече?.. Юктыр!.. Әгәр булса –
ул, мөгаен, фәкать – Сабырлык...

Шундый уйлар яшен тизлегендә
«Сталинистмы?» дигән сорауга
җавап эзләделәр, хәтеремнең
карст[2] бушлыкларын бораулап.
Җавап табылмады... Сәер сорау,
кызыксынуымның култыгын,
кети-кети иткән кебек капшап,
түзеп булмас итте кытыгын.

Көлә-көлә үзем әйтә куйдым:
– Ну, Хәсәныч[3], синең соравың –
әлегәчә төбен күрә алмыйм:
әллә туры, әллә урау ул?!.
– Ул туры да, ул урау да түгел, –
диде дусым, ихлас елмаеп, –
яңа әсәреңә азык бирәм...
Бүген – август, көне уңайлы...

Чәйле чынаякны читкә этеп,
балкашыгын балда онытып,
мин дустымның көттем хикәятен –
илһам азык җыяр минутны.
Ә ул мине урамга чакырды:
– Йөреп керик, аяк оеды...
Коттеджның капкасы төбендә
көтеп тора иде «Toyota»...

Без кузгалдык һәм каядыр киттек...
Дустымның да теле ачылды –
чишеп җибәрде ул әсәремә
азык хәстәрләнгән янчыгын.
Мең тугыз йөз җитмешенче елда
каты гына чирләп алган ул.
Аны Әлмәт хастаханәсенә
кичекмәстән илтеп салганнар.

[2] Карст – известь юылып, җир астында барлыкка килгән куыш.
[3] Ф.Х.Закиров – җәмәгать эшлеклесе, пенсионер.

Палатада, күрше караватта
яткан агай белән танышкан...
Әсәремне мин язарга тиеш
икән шул агайга багышлап:
үз чорының типик кешесе ул,
язмышы да шактый гыйбрәтле.
(Әдәбият укытучысы бит –
дустым белә нәрсә кирәген!)

Теге ерак, ГУЛАГлы елларда
тракторчы булган икән ул –
экиятләрдә женне җигүчедәй –
көчле «чытызы»ны[4] җиккән ул.
Район ярышларында катнашкан,
Мактау тактасыннан төшмәгән,
социализм тизрәк җиңсен, диеп,
бөтен көчен биреп эшләгән.

Төрле-төрле бүләкләр дә алган,
гәзитләр дә мактап язганнар –
колхоз күләмендә генә түгел,
районда да ул дан казанган.
Ә дан тирәсендә һәрвакытта
бөтерелә бер көч – көнләшү:
күзен җиргә төбәп сине котлар,
сине мактый-мактый сөйләшер...

Дусты булган моның – авылдашы,
ярышташы колхоз кырында.
Бик тырышкан, ләкин меналмаган
Мактау тактасына, урынга...
Һәм беркөнне өр-яңа «сытызы»[5]
кайтып төшкән ярышташына...
Шушы тракторлар, ни кызганыч,
ике дусның җитә башына.

Бәхәсләшеп китә ике егет,
берсен берсе яман чагалар:
– «Чытызы»лар ташбакалар кебек,
«сытызы»лар аттай чабалар...
Ярышташлар китә онытылып,
түбәләшә алар пыр тузып...
– Орып бәрә «Сталинец»ыңны
Түштән[6] батыр кебек «чытызым»...

Яшьлек тилелеге чама белми –
ычкынгандыр башка сүзләр дә...
Өч-дүрт көннән «чытызы»ныкының
тормыш юлы кинәт үзгәрә...

[4] ЧТЗ – Чиләбе трактор заводында чыккан трактор.
[5] СТЗ – Сталинград трактор заводында чыккан трактор.
[6] Түштән (Тюштян) – мордва халык экиятләрендә сукачы батыр.

Ун ел Колымада була егет...
Кайта... Иң беренче соравы
мондый була: «Теге исән-саумы,
нәрсә эшли, кайда тора ул?»

«Җир йотты бит аны, – дип әйтәләр, –
шул ук елны, август башында»...
«Кайтыр әле... Туган җире тартса...
Мин дә кайттым көткән ашыма...»
Әйтемнәргә без күнегеп беткән –
алар меңәрләгән ләбаса –
«җир йотты» дип кенә җибәрәбез,
әйбер эзләп таба алмасак.

Ә тегене җир чын-чынлап йоткан –
әйтерсең лә көтеп торган ул –
йөгереп барган тракторы белән...
Чуртан йоткан кебек корбанын...
Көпә-көндез... Тигез, такыр кырда...
Ышанмас та хәтта беришең –
җир өстендә тик ыржаеп калган
«Сталинец» зурлык бер тишек.

Төне буе, имеш, җир астыннан
ишетелеп торган гөрелте
кеше аңындагы йоклап яткан
төрле хорафатны терелтеп.
Халык курка калган... Бу тишеккә
бер кеше дә якынлашмаган,
төбе бармы, тирән микән, диеп,
тик ерактан ташлар ташлаган...

Шул урынга[7] икән сәфәребез,
шунда икән илһам азыгы!
Хәсәнычның хикәяте миндә
түземсезлек уты кабызды.
Тизрәк барып күз саласы килде
әләкчене йоткан авызга –
кечкенә бер чокырчыктыр әле,
бәлки, камыш баскан саз гына?!.

Барып җиттек... Теге хәтәр тишек,
җиде дистә еллар ишелеп,
зур бүрәнкә булган – йота ала
бер кабуда йөзләп кешене...
Ә бугазы әле тыгылмаган
меңләп тонна ак таш йотса да...
Төбендәге шымган кара суы
йөрәкләргә һаман шом сала.

[7] Әлмәт районы Кәләй авылы янындагы «Акташ упкыны» («Акташский провал») – табигать истәлеге.

Бер очраклы туры килү микән
яки хаклы хөкем эшеме –
шушы җиргә төбәп алып килгән
шул мизгелдә теге кешене?
Юлбашчыга тел-теш тидерү дә,
дустын батырырлык әләк тә
чара күрелмичә калмаганнар –
берсе төрмә, берсе һәлакәт...

Ишеткән бар: куллары кипкән, дип,
югалткан, дип, акыл-аңнарын
мәчет манарасы кисүчеләр,
ватучылар чиркәү чаңнарын.
Алары да шундый очрак кына,
хорафаттан калган уйдырма,
берәр ялган түгел микән дигән
сорау янә сорау тудыра.

Мәҗүсилек тере әле бездә...
Кемдер аны тирән яшерә,
ә кемнәрдер (хәтта язучылар)
шуны язып рәхәт яшиләр...
Мәҗүсилек беркайчан да үлмәс
җирдә, суда, тауда, урманда
(безнең Әлмәт янындагы кебек)
серле хәлләр була торганда.

Теге агай инде дөнья куйган...
Аңа биреләсе сораулар
күңелдәге карст бушлыкларын
тирәнәйтә бара бораулап.
Сорауларның гади өслегеннән
ераккарак киткән саен мин
якынлашам иң-иң тирәненә:
гафу иткәнме ул хаинны?

Гафу иткән булса, кайчан иткән?
Бу адымга нәрсә этәргән?
Кичермәсә, нигә кичермәгән?
Үч-ачуын ничек күтәргән?
Каргаганмы тракторы исмен?
Юлбашчыга нәгърә органмы?
Әллә гомер буе үз вөҗданын
тозлы кыргыч белән кырганмы?..

Ул агайны үзем күргән булсам,
бер сөйләшкән булсам әгәр дә,
җаваплары «азык» булыр иде
дустым миннән көткән әсәргә...
Ә мәхәббәт? Шунсыз булмый әсәр –
сораштырыр идем ипләп мин...
Сөю хисе безнең җанны ача,
сер ишеген хәтта бикләтми...

Безне көчле итә сөю хисе –
кешегәме, эшкә, илгәме –
туендыра шәхес горурлыгын
һәм сугарып тора илһамны.
Ә хәзергә минем күз алдында
гап-гади бер карст тишеге –
бәгъзе аңда – тәмуг яки җәннәт,
яки риваятьләр ишеге...

Сәясәтнең монда эзе дә юк...
Тукта, тукта! Бәлки, бардыр да!..
Кеше аны «Халыклар атасы»
исме белән истә калдырган.
Юлбашчыны яклаган өченме,
дустын саткангамы бер юкка
ул мескенне шулай, ап-аязда
яшен суккан кебек, җир йоткан?!.

Һәр заманның яхшы ягы да бар!
Гаепмени шуны сагынсак?..
Әйе, бездә заманабыз яши –
аң да уяу һаман, тел дә сак.
Ләкин үткәннәрне сагынудан
бүгенгемә зарар киләме?..
«Сталинист»мы, әллә «анти...»мы мин?
Кем үлчәгән шулар күләмен?..

«Мәтәләсең!..» диеп, йолкып алып,
уйларымны дустым бүлдерде...
Мин убаның кара көзгесендә
хәтер утын күреп өлгердем...
Убалар күп... Алар төрле-төрле...
Өстәлеңдә... Аяк астында...
Хәтта сүздә... Шундук убыласың,
авыр гөнаһ асып бас кына!..

Ә бу уба, бер карасаң – чокыр,
бер карасаң – серле тирәнлек...
Басып торам авызына карап,
үз җанымны үзем өйрәнеп.
Әллә анда, әллә шомлы җанда,
эшли кебек теге трактор...
Төсе качкан дустым пышылдады:
«Уба авызыннан ерак тор!..»



# Фәтхулла Абдуллин

## КҮРӘСЕН КҮРДЕ...

БӘЯН

Августның эссе, тынга каплана торган бөркү көннәре. Туктаусыз тамак кибә. Чыдар әмәл юк. Берәр чынаяк чәй эчеп, сусынны басарга заманча шәһәрдә чәйханә юк та юк инде ул. Ә менә рестораннар, кафелар, сыраханәләр адым саен – буа буарлык. Мин, ничарадан-бичара дигәндәй, элмә тактасына күбекләре ташып чыккан сыра кружкасы төшерелгән бинага кердем.Чибәр генә сатучы ханым, мактый-мактый, миңа төрледән-төрле сыра тәкъдим итәргә тотынды.

– Абый, сезгә нинди пиво кирәк? Жигулёвскимы, чувашскимы? Менә, әле генә яңа мичкәне ачтык. Теләсәгез, рижскиен, чешскиен да салып бирә алам, ну алары бераз кыйбатрак инде.

– Рәхмәт, сеңлем! Миңа берәр чынаяк чәй ясап бирсәгез, шул җитә.

Сатучы ханым, билгеле инде, мондый заказ көтмәгән иде, сәерсенеп калды.

– Бары шул гынамы?

– Әйе.

Ханымның чыраенда ризасызлык галәмәте ярылып ятса да, «клиент всегда прав» дигән гыйбарәне исенә төшереп булса кирәк, теләмичәрәк кенә минем заказны кабул итте.

– Хәзер куям.

Мин дә сатучының күңеле булсын дип өстәдем:

– Чәегез кайнап чыкканчы эчә торырга бер стакан томат согы бирегез алайса.

Мин, соклы стаканымны күтәреп, буш өстәл артына барып утырдым. Тирәякка күз төшереп алдым. Ни гаҗәп, сыраханәдә кеше күп түгел иде. Йөзләрен сакал-мыек баскан өч ир-ат, караңгырак почмакка посканнар да, кызып-кызып, ни турындадыр гәпләшәләр. Үзләре, угрылар шикелле, як-якларына каранып алалар иде.

Икенче яктагы өстәл тирәсендә дә берничә кеше утыра. Ак күлмәкле, ярыйсы ук бүксәле ир-ат бер кулы белән өстәлгә таянып, икенчесе белән калын пыяла бокалдан сыра чөмерә. Янындагыларның йөзендә ялагай елмаю чалымнары шәйләнә. Күрәсең, «бүксә» алар өчен авторитет иде булса кирәк, ул ым кагу белән, берсе шундук сикереп торды, стойка янына килеп, бушаган кружкаларын сатучыга сузды:

---

Фәтхулла АБДУЛЛИН (1937) – *язучы, «Еракка китеп кара», «Тормышка юл ярганда», «Чүл бүресе» һ.б. күпсанлы китаплар авторы; Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе. Түбән Кама шәһәрендә яши.*

– Повторить!

Ул арада сыраханәгә чама белән утыз биш яшьләр тирәсендәге тагын бер ир килеп керде. Стойка янына килеп басты. Сатучы белән исәп-хисап ясаганнан соң, ул сыралы кружкасын күтәргән килеш, «кунакларга» урын эзләп, як-ягына каранып алды. Аннары (гәрчә буш урыннар күп булса да), ни өчендер, мин утырган өстәлгә якынлашты.

– Бу урыннар бушмы?

– Әйе. Рәхим итеп утырыгыз! Күңелең киң булса, тар җиргә дә сыясың, диләр. Ә биредә урын барыбызга да җитәрлек.

Егет сыралы кружкасын өстәлгә куйды да урындыгын якынрак шудырды, аннары миңа кулын сузды.

– Әйдә, таныш булыйк. Камил.

Монда тәртип шулайдыр дип, мин дә эти-әни кушкан исемемне атадым.

Камил кружкасын иреннәренә якын китерде. Күрәсең, ул да минем кебек сусаган иде бугай, күбекләрен өреп, бер сулышта эчеп бетерә дә язды.

Мин, сүз юктан сүз булсын дигәндәй:

– Бүген көн ничек, ә! Чүлдәге шикелле кыздыра! – дидем.

Ул, исе китмәгән кыяфәттә:

– Игеннәр өлгергән чак бит. Шулай булырга тиеш инде ул, – дип кенә куйды.

Мин, эчемнән генә, күр, игеннәр өчен борчыла, авыл кешесе ахры, дип уйлап алдым. Бу егетнең нindirәк бәндә икәнен фаразларга тырышып, йөзенә карадым. Ярыйсы ук киң маңгай. Эш кешесенә хас гадилек һәм эчкерсезлек бөркелеп торган ирнең чигә чәчләре дә бераз гына агара башлаган. Ә күзләре... Уйчан коңгырт күзләр... Ул күзләрнең төпкелендә ниндидер серләр бардыр сыман тоелды миңа.

Камил тагын берничә йотым сыра уртлап куйды.

Инде кул бирешеп тә танышкач, балтасы суга төшкән кешедәй борын салындырып утыру килешмәс дип, мин тагын сүз каттым:

– Энем, үзең кайсы як егете буласың?

Ул тагын өнәмичәрәк кенә җавап кайтарды:

– Шушы якныкы.

– Шушы яктан, шушы туфрактан икән алайса.

Ул җиңелчә генә баш кагып алды.

– Әйе, шулайрак.

Аның җавабы тагын да төксерәк килеп чыкты. Мин, ни дияргә белми нәүмизләнеп, гаҗәпсенеп калдым. Менә сиңа мә! Үзе чакыра, үзе кача, чыкмый чакырган җиргә, дигән җырдагы шикелле икән алайса. Сәер, үзе башлап танышырга кул суза, үзенең сөйләшәсе килми. Бу егет, берәр кыйммәтле әйберен югалтканмы, әллә ярамаган эш эшләгәнме дип, үземчә фаразлап алдым.

Ул арада минем заказны – пары күзгә күренеп торган кайнар чәйне алдыма китереп куйдылар.

Шулчак Камил, көтмәгәндә, әллә каян, күкрәк түреннән, ыңгырашкан сыманрак авазлар чыгарды, кружкасына үрелде. Бу юлы савытында калган сырасын эчеп бетерде. Һәм тагын да үкенечлерәк уфылдап, башын аска иде. Бу минутларда аның кыяфәте тукмалган кешенеке шикелле иде. Нигә шулкадәр уфылдый бу бала? Бәлки, аңа берәр төрле ярдәм кирәктер?

– Энем, авырыйсызмы әллә?

Камил башын күтәрде, бертын күзләремә текәлеп торганнан соң, ниһаять, телгә килде.

– Абзыкаем, мин бик начар кеше бит. Үз гомеремдә бик зур хата ясадым бит мин, абзыкаем, гафу итеп булмастай гөнаһ алдым. – Ул, кискен хәрәкәтләр белән, изүләрен ычкындырды, башын миңа таба иде. – Абзыкаем, эт итеп сүк! Үтергәнче тукма син мине! Бәлки, миңа җиңелрәк булыр!

– Син ни сөйлисең, энем? Нишләп мин сиңа кул күтәрим ди? Синең миңа тамчы да начарлык эшләгәнең юк. Сер булмаса, әйт инде. Нинди хата ясадың? Нинди гөнаһ кылдың? Алай-болай ялгышып, кеше үтермәгәнсеңдер бит?

– Юк-югын да. Барыбер дә гафу итеп булмастай хата ясадым.

– Нишлисең, адәм баласы хаталардан хали түгел шул. Әгәр уйласаң, бу фани дөньяда яшәгәндә барыбызның да хаталарыбыз бардыр. Алай гына да түгел, баштан ашкандыр. Җан ияләрен рәнҗетсәң, вакытында гафу үтенеп, гаебеңне ничек тә юарга кирәк.

Камил йодрыгы белән өстәлгә сугып алды. Чәй тәлинкәсе, аның хәленә кергәндәй, җиңелчә генә зеңгелдәп җавап бирде.

– Соң шул инде. Соң... Бәлки, аның бер йотым суга тилмереп яткан чагы булгандыр...

Мин ни дияргә белми аптырап торган арада, ул, бушаган савытын тотып, урыныннан кузгалды.

– Абый, сезгә дә алыйммы?

– Рәхмәт, энем! Кирәкми!

Камил, кабат өстәл янына килеп утыргач, мин, шикләнеп кенә:

– Энем, һәркемнең үз дөньясы, үз кайгысы, борчу-мәшәкатьләре. Эч серләреңне дә теләсә кемгә сөйләп булмый, шулай да барыбер кайгы-хәсрәтләреңне сер сыя торган кешегә сөйләп, эчеңне бушатырга кирәк. Теләсәң, сөйлә, күңелең бушасын... Минем вакытым бар, – дидем.

Ул, ихластан әйтәме бу абзый дигәндәй, бертын миңа текәлеп, дөресрәге, сынап карап торды. Фәкать шуннан соң гына, тәвәккәлләп, телгә килде...

***

...Авылда туып-үскән Камил, солдат хезмәтеннән соң да, бәлки, кабат авылына кайтыр, туган колхозында терлекчеме, механизатормы булып эшләр, өйләнеп, балалар үстерер, һәм, әлбәттә инде, үзенә яңа йорт җиткергән булыр иде. Әмма республикада купкан галәмәт зур төзелешләр күпләрнең, шул исәптән аның да, язмышын бөтенләй икенче якка борып җибәрде. Аларның гасырлар кичкән авылы промышленность зонасына эләкте дә, сала халкын шәһәргә күчерәчәкләр, дигән хәбәр таралды.

Яшерен-батырын түгел, гомер бакый иген иккән, терлек асраган җир кешеләре арасында шәһәргә күчәргә теләмәүчеләр дә күп булды. Чөнки үзләре генә аңлый торган сәбәбе бар иде: биредәге кара туфрак катламы туксан сантиметр! Урыны-урыны белән бер метрга җитә! Бу төбәктә гомер-гомергә уңыш мул булды. Колхоз рәисе, Социалистик Хезмәт Герое Зыятдин ага шушы, кем әйтмешли, ипигә май урынына ягып ашарлык уңдырышлы кара туфракны пыран-заран китергәннәрен күргәч: «Көлсу туфраклы җирдә төзеп булмады микәнни соң бу заводны?» – дип, утырып елаган, диделәр.

Кала тормышын өнәмәүчеләр, күрше-күләннән, туган-тумачадан аерылабызмыни инде, дип зарланды. Ярый әле җитәкчеләр аларны күз күреме җитмәстәй шәһәрнең төрле почмагына чәчмәделәр. Гәрдәле халкы панельдән төзелгән бишкатлы йортка сыйды да бетте. Бер яктан, шунысы рәхәт: хәзер хәл белергә түбән очтан югары очка менәсе, югары очтан түбән очка төшәсе

юк. Күрше-күлән бер ишектән кереп йөри яисә күрше подъездда гына яши. Бу вакытта инде Камилнең әтисе вафат булган, әнисе белән генә калганнар иде. Шулай да аларга өч бүлмәле фатир бирделәр.

Колхозда бригадир булып эшләүче әтисенең үлеме бигрәкләр дә үкенечле булды. Урып-җыю чорында колхозга ярдәмләшергә килгән йөк машинасы белән аракы эзләп, күрше авылга барышлый, коеп яуган яңгырда күпердән очканнар. Асты өскә килгән йөк машинасының кабинасы яньчелеп беткән. Ни кызганыч, анда булган кешеләр дә сытылганнар иде...

«Г» хәрефенә охшатып төзелгән йортның бер башында Камилләрнең фатиры булса, икенче башында аның сөеклесе Миләүшә яши. Аның белән бер партада утырып, мәктәпне тәмамладылар. Кая барсалар да, агылый белән тагылый шикелле, гел бергә йөрделәр. Аларның бәхәсләшүләре дә мәхәббәт белән тулган була. Әле дә, «көнче күбәләкләр»нең йөрәген яндырып, һаман бергә! Әгәр Миләүшәләрдә ут бер кабынып, бер сүнеп ала икән, димәк, аның сөеклесе урамга чыгарга әзерләнә: Камилгә дә киенә башларга вакыт!

Ике елдан артык төзелештә эшләп кавырсыны каткан Камилне дә, вакыты җиткәч, солдат хезмәтенә алдылар.

Эшләп үскән авыл баласы ике елга сузылган солдат хезмәтенең әллә ни авырлыгын күрмәде. Дөрес, баштагы чорда казарма тормышының язылмаган законнары нигезендә, беренче елны ул «салага» буларак үткәрергә, аннан соң гына «дед»лар рәтенә күтәрелергә тиеш иде. Әмма депутатлар, сенаторлар, тәҗрибәле юристлар язган законнарның да искәрмәләре булган кебек, солдат хезмәтендә дә шундыйрак хәлләр була икән. Баштагы чорда Камил, авыл баласына хас киң күңеллелек күрсәтеп, «бары – бергә, югы – уртак» принцибы буенча кесәсендә булган соңгы тиеннәренә кадәр иптәшләре белән уртаклашты. Әнисе салган посылкалар эчендәге тәм-томнарның да кайберләрен үзе авыз итә алмыйча калган чаклары булды. Әмма «дед»ларга болар гына аз икән.

Шулай беркөнне битен тоташ бетчә баскан җирән чәчле «дед», отбойдан соң, аягындагы оекбашларын салып:

– Эй салага, на, держи! Чтобы к утру они были чистыми и сухими! – дип, ике ярусны караватның өске катында яткан Камилгә ыргытты.

Йомарланган носки туп-туры егетнең битенә килеп төште, сасысы борынны ярып керде. Носкига ябышып каткан чүп аның күзенә эләкте. Камил, ихтыярсыздан, бер кулы белән күзен уарга кереште, икенчесе белән носкиларны кире хуҗасына томырды.

– Ты что делаешь? Глаз попал бит! – диде ул, ярым русча, ярым татарча.

Җирән чәч, сасыган оекбашлар кире үзенә килеп төшкәч, үз телендә йомры гына сүгенү сүзе ычкындырды.

– Я что, твоя жена чтоли? Стирай сам! – диде егет, аңа каршы.

– Ещё хуже! Ты ведь ещё только «салага»!

Камил дә бурычлы булып калмады.

– А ты – рыжий пёс!

Егетнең сүзләре җирән чәчнең үтенә барып кадалды. Ул яткан җиреннән сикереп торды.

– Что ты сказал? А ну-ка, повтори! – диде ул, әтәчләнеп.

Дөнья син дигәнчә генә бармый шул. Нахакка рәнҗетә башласалар, басынкы кешеләрдә дә мин-минлек калкып чыга. Адәми зат кына түгел, хайваннар да, хәтта куркак дип даны чыккан куян да яшәү өчен көрәшергә мәҗбүр. Ахыр чиктә кыерсытылган куян да, чалкан ятып, тыпырчына-тыпырчына, тәпи

тырнаклары белән бөркетнең бүксәсен ярырга мөмкин, диләр. Гәрдәле егете алай мескен түгел бит әле.

– Рыжий пёс! –дип кабатлады ул. – Вдобавок, глухой! Ты что, когда в армию брали, комиссию не проходил чтоли?

Җирән чәч, гайрәтләнеп, Камилгә якынлашты, үрелеп, сугарга селтәнде. Камил кискен генә читкә тайпылып өлгерде. Алай да «дед»ның бармак очлары аның битен сыдырып өлгерде. Сыдырылган ярадан чыккан кан егетнең майкасына тамды. Ул койкасыннан сикереп төште, чырае явызланып өлгергән җирән чәчнең биленнән кысып күтәреп алды да (Камил – мәйдан тоткан батыр булмаса да, малайлар белән чирәмдә бил алышып үскән егет), татарча көрәш алымы кулланып, тегене аркасы белән казарма идәненә китереп салды. Мондый хәлне көтмәгән җирән чәч җайсызрак килеп төште ахры – лепкәсеннән кан саркып чыкты. Еланның койрыгын өзсәң, сиңа «җизни» дип әйтер ди. Шуннан соң Камилне «салага» дип кыерсыткан кеше булмады.

Миләүшәдән килгән мәхәббәт хатлары егетне кышкы салкыннарда җылытты, авырлыкларны җиңәргә көч бирде. Гашыйклар өчен ике ел гасырга тиң булгандыр. Ике ел эчендә алар күпме хат алышканнардыр, сорасаң, төгәл санын үзләре дә әйтеп бирә алмаслар иде. Сөеклесеннән хат алган көн – егет өчен, һич арттырусыз, бәйрәмгә тиң булды. Кызның йөрәк җылысы белән сугарылган хатларын ул кат-кат укып ләззәтләнде, бәхетле мизгелләр кичерде. Андый көнне Камил, сабый баладай очынып, канатланып йөрде. Мәхәббәт ул таулар күчерә, диләр! Хактыр! Юкса башын югалтыр дәрәҗәдә гашыйк булганнар сөйгәненә алтын таулары вәгъдә итмәс, «җаным-бәгърем, синең өчен күктән йолдызлар чүпләп алып төшәргә дә риза!» дип, антлар эчмәс иде.

Камил икенче елын хезмәт иткәндә, нишләптер, кинәт кенә Миләүшәдән хат килми башлады. Егетнең күңеленә шик корты кереп «оялады». Ятса да, торса да, ул аңа тынгылык бирмәде, болай да кан саркып торган йөрәк итен талады да талады. Ут йотып йөргән егет бу хәлне төрлечә фаразлады. Нәрсә булды икән аның сөеклесенә? Авырып киттеме? Әллә инде... Әллә? Азмы, егете кайтырга өч ай кала, башка егеткә кияүгә чыккан кызлар... Аптырагач, сәбәбен сорап язарга булды. Хатының ахырында: «Нишләп хат язмыйсың, Миләүшә? Завод төзергә килгән берәр тел бистәсе зиһененңне чуалттымы әллә?» – дип үпкә белдергән һәм үзешчән сәнгать түгәрәгендә өйрәнгән җырның:

Ай яктысы якты, диеп,
Тар басмадан су алма;
Сөйгән ярым янда юк дип,
Ятлар белән чуалма, –

дигән бер куплетын да өстәгән иде.

Шуннан соң, көттереп-зарыктырып кына, җор телле Миләүшә аның дәгъвасына каршы:

Кара урманнарны таптадым,
Таяныргa таяк тапмадым.
Атна саен хатлар яздым,
Җибәрергә юлаучы тапмадым, –

дип, җыр тексты белән җавап кайтарды. Менә ишетмәсәң ишет, колагың булса тишек... Иң сәере: кызның хатында сәлам дә юк, хәл-әхвәл сорау да юк. Фәкать шул бер куплет җыр тексты! Егет сөйгәненең бу табышмак хатын нәрсәгә юрарга да белмәде, башын кашып, озак кына уйланып утырса да,

очына чыга алмады. Хезмәт итү срогы да тагын ярты ел бар бит әле. Их, бу вакыт дигәннәрен кирәк чакта туктатып та, тизләтеп тә булсын иде ул! Ни хәл итәсең, адәм баласына андый кодрәт бирелмәгән шул. Әбиләр шикелле, сабыр канатларың сынмасын да, сугышлар чыкмасын дип теләргә генә кала инде...

***

Солдат хезмәтенең санаулы көннәре үтсә дә, тормышның сынаулы көннәре үтмәгән икән шул әле. Ул җәзага тиң газаплы көннәр, әйтерсең, Камилнең кайтуын сагалап торганнар иде...

Нәкъ ярты елдан, көзге, җелекләргә кадәр үтә торган салкын яңгыр пыскаклап торган болытлы көннәрнең берсендә, Камил утырган очкыч Бигеш аэропортына килеп кунды. Егет траптан төшкәндә, түземсезләнеп, пассажирларның үкчәләренә баса-баса атлады. Алдагыларның җылы салоннан чыгасылары килми идеме, ташбака шикелле әкрен кыймылдыйлар. Камил түзмәде, трапның тоткасыз ягыннан җиргә сикерде. Ниһаять! Менә ул туган-үскән җир! Һавасы гына да ни тора! Егет, күкрәген киереп, салкынча һаваны сулады. Аңа әйтеп бетергесез рәхәт булып китте. Тирә-якка күз төшереп алды. Кемнәрдер көзге салкыннан бөрешеп, якасын күтәрде, хатын-кызлар җылы шәлләренә төренде. Көзге ачы җил Камилнең дә чәчләрен тузгытты, битен чеметеп алмакчы булды. Ни гаҗәп, салкын җил аңа, битләрдән сыйпап, иркәләп исә торган җылы саба җиле сыман тоелды! Салкын яңгыр аның битләрен юар өчен, әйтерсең, күкләр тарафыннан иңдерелгән шифалы тамчылар иде. Ә исе! Исе! Егет моңарчы башына килмәгән ачыш ясады: карале, яңгырның да исе була икән бит, әй!

Шәһәргә кайтучы автобус килергә байтак вакыт бар иде әле. Каккан казык кебек урамда кагаеп тормас өчен, ул аэропортның пассажирлар залына керде. Болытлы көн булганга, кайбер юнәлешләргә очу тоткарланган иде булса кирәк, зал халык белән шыгрым тулы. Утыргычка тиенгәннәр рәхәт чигә, урын җитмәгәннәр сырганак шикелле стена буйларын сырып алган. Диварга сөялгән килеш аягын чалыштырып баскан егет, дөньяда гаме булмаган кешедәй, китапка текәлгән. Мөгаен, студенттыр. Камил дә егет янына килеп басты, аннары саклык белән генә катыргы чемоданы өстенә чүмәште. Зал умарта күче кебек гөжләп тора. Кемдер иптәшенә кычкыра. Кемнәрдер тыныч кына күршесе белән гәпләшә. «Монда без дә бар бит әле», дигән шикелле, юк-юкта репродукторлар да «телгә» килә. Арырак эскәмияләрнең берсендә Камилгә аркасы белән утырган хатынның баласы елый. Ул аны ничек туктатырга белми изалана. Шул тирәдә утырган ике әби, балалы хатынга карый-карый, үзара нидер сөйләшәләр, ни өчендер мескен хатын ягына кулларын да селтәп алалар иде. Нигә алай кыланалар? Балалы хатын ни өчен әбиләрнең ачуын чыгарган – шайтан белсен! Камилгә аларның сүзе өзек-төтек кенә булып ишетелә. Алай да колагыңны торгызып тыңласаң, ни сөйләгәннәрен чамаларга була иде.

– И-и, әйтмә дә инде, җаный, хәзерге яшьләрне! Ходай биргән шул бер баласын да карый алмыйлар.

– Иреннән карата инде ул аны. Ирен җигә! – ди башындагы француз яулыгы өстенә җылы шәл япканы.

– Шулайдыр. Әнә бит ничек бизәнгән. Баласыннан бигрәк үзен караган. Буялган тырнаклар белән ничек бала чүпрәге юмак кирәк.

– Иреннән юдырта инде ул аны.

– Карале, ахирәт, карале, баласы белән ничек тупас кылана. Утын түмәре күтәрәмени? Бала күргән хатынга охшамаган бу.

– Кыланышыннан ук сизелә шул. Кычкырып та ала. Сабый балага тәмле тел белән генә эндәшергә кирәк югыйсә.

– Дөрес әйтәсең, ахирәт. Яратканны кырык көнлек сабый да аңлый.

Теге хатын әбиләрнең ризасызлыгына игътибар иттеме, көтмәгәндә баласын күтәреп торып басты. Борылып, сабыен үзенең урынына утыртты, каршына чүгәләп, авызына имезлекме, нидер каптырмакчы булып азапланды. Сабый, үҗәтләнеп, авызындагы сыен гел кире чыгарды.

Камил, хатынның йөзен күрүгә, ни уйларга белми, тораташ кебек катты да калды. Бала күтәргән хатын... аның сөеклесе Миләүшә иде! Нәрсә бу? Өнемме, төшемме?! Әллә күземә генә күренәме? Егет, үз күзләренә үзе ышанмагандай, торып басты. Кабат кызга текәлде. Юк! Төш кенәдер бу! Чемоданы өстендә йокымсырап киткәндер дә уяна алмый интегәдер. Ул, шулай нишләргә, ни уйларга белми аңгы-миңге торган арада, репродуктор телгә килде. Каядыр очачак рейска хәбәр бирделәр ахры, зал умарта күчедәй тагын да көчлерәк гөжләргә тотынды. Кемнәрдер алагаем зур чемоданнары белән аның балтырына бәрелеп үттеләр. Аягөсте китапка «кадалып» торган студент егет тә каударланып китеп барды.

«Юк! Төш түгел, өн бу, Камил! Өн!» – дип пышылдады ул үзалдына.

Хәзер аңа нишләргә? Барып исәнләшергәме? Котларгамы? Әллә танымаган булып кыланырга, күрмәмешкә сабышыргамы? Егет, тәгаен бер карарга килә алмый, икеләнеп басып тора бирде. Миләүшә берара хат язмый башлагач, ул әнисе аркылы аның институтка керергә әзерләнеп йөрүен ишеткән иде. Кыз, Камилнең әнисенә сер итеп кенә, имтиханга әзерләнәм бит әле мин, Хатирә апа, Камилнең кайтуына сюрприз әзерләп торам, дип аңлаткан.

Институтка кергәндерме-юкмы, анысы караңгы. Сөеклесе аңа тагын да кәттәрәк сюрприз әзерләгән икән бит! Ә мин – тинтәк. Аны тәүлегенә туксан тапкыр уйлап, дивана була яздым. Ә ул?! Вәгъдә – иман, диләр, биргән вәгъдәңә хыянәт иманыңа хыянәт белән бер. Иманына хыянәт иткән кешеләрнең исеме дә чиркангыч – мөртәт! Бу сүз янында сукрану да, катлы-катлы итеп сүгенү дә чүп кенә. Татар телендә мөртәттән дә имәнеч, җан биздергеч нәфрәт сүзе, мөгаен, юктыр. Әллә соң биргән вәгъдәсендә тормаган Миләүшәгә кул селтәргә дә, саубуллашмыйча китеп барыргамы?

Камил бер мизгелгә генә туктап, уйланып калды. Бу минутларда аның күңелендә, Такташ әйтмешли, ике «мин» көрәшә иде. «Тукта, тукта! Кызма!» – дип киңәш итте аның икенчесе... – Тормыш – колагыңны бормыш, ди. Тормышта төрле хәлләр булырга мөмкин ич. Бәлки, аның сөйгәне кемнеңдер тасма теленә алданып, кияүгә чыкмыйча гына бала тапкандыр? Миләүшәнең соңгы вакытта хат язмавы да бер сәбәпсез генә булмагандыр?»

Күңелендә икеләнү, шикләнү, өметләнү кебек мең төрле фараз кайнаган Камилнең аяклары ихтыярсыздан әле һаман сабыен елавыннан туктата алмаган Миләүшәгә таба атлады. Ул кызга җитәрәк ике-өч адым кала туктады. Гәрчә тагын да якынаясы, сөеклесен кочагына алып сөясе, күпереп-дулкынланып торган чәчләреннән иркәләп сыйпыйсы килсә дә, тыелып калды. Бәлки инде ул кемнеңдер никахлы хатыныдыр?

Миләүшә дә аны күреп алды. Кызның елак сабый белән әвәрә килгәндәге борчулы йөзе мизгел эчендә май кояшыдай яктырып китте. Ул инде кулындагы сабыен да онытты бугай.

– Камил! Кайчан кайттың?

Камилнең күңелен бимазалаган беренче «мин» тагын өскә калкып чыкты. Хәзер егетнең карашы да битараф. Әле генә кичергән хисләре дә юып алгандай югалган иде.

– Синең хат язмавыңның сере менә кайда икән. Әни булуың белән котлыйм, – диде ул, салкын гына.

Миләүшә егетнең тавышы да, кыланышы да ни өчен төксе икәнен чамалап алды. Әйтерсең, шайтан котыртты, ул бу «уен»ны дәвам итәргә булды.

– Ә нигә? Гаеп эшмени? Хатын-кыз үз гомерендә һич югы бер бала тәрбияләп үстерергә тиеш. Ул – аның Аллаһы Тәгалә каршындагы бурычы.

Егет белән кызның төртмә телләнеп сөйләшүе кызык тоелдымы, сабый елавыннан туктады. Миләүшә, биләүдәге сабыйга ымлап:

– Карале, Камил, ул сине күргәч, елавыннан туктады, – диде, елмая төшеп.

Сабый, чыннан да, Камилгә карап, ачылмаган теле белән «ыгы-ыгы» килеп, үзенчә нидер сөйләнеп, елмаеп тора иде.

– Сизәсеңме, Камил, ул сине бер күрүдә үк яратты. Гаҗәп бит, әйеме? Әллә кулыңа алып, «үчтеки-үчтеки» итеп, сикертеп аласыңмы? Әйдә, сабыйның күңеле булсын инде. Мә!

Алай да Камилнең күңеле эремәде.

– Рәхмәт! Мөгаен, аның үз әтисе бардыр. Ул сикертсен инде.

– Ә булмаса? Үксез баланың күңелен күтәрү тагын да саваплырак ич, – диде кыз, уенын дәвам итеп.

– Әтисез генә бала табарга син Мәрьям анамыни? Һәм ул, Миләүшәнең җавабын көтеп тормастан, өстәде: – Ятим балалар белән детдом шөгыльләнә. Мин түгел!

Кызның ярату, сагыну, очрашу шатлыгы белән мөлдерәмә тулган күңелен рәнжү хисе телеп узды. Менә аның сөйгәне нинди икән, ә?! Миләүшә кулындагы сабыйны аның уйнаштан тапкан баласы дип уйларга өлгергән. Кызның егеткә ачуы килә башлады.

– Камил, моңа кадәр мин сине мәрхәмәтле, әйбәт егет дип белә идем. Хәзер ни уйларга да белмим инде.

– Теләсәң ни уйла! Очраган бер күке баласының башыннан сыйпап йөрергә мине кем дип беләсең?

Аның тавышы тагын да кырысланган иде. Ул, минем сүзем бетте дигәндәй, кул сәгатенә карап алды. Автобус китәр вакыт җитеп килә иде. Егет, чемоданын кулына алып, Миләүшә белән саубуллашмыйча да китеп барды.

Сабыйның кайсыдыр төше авырта иде бугай, ул тагын ачыргаланып еларга тотынды. Миләүшә, сабыйны кулына алып, тирбәтә-тирбәтә йөренә башлады. Бу минутларда булган хәлләр чын-чынлап аны борчуга салган иде. Сөйгәне белән мондый очрашу көткән идемени соң ул? Уеннан уймак чыгарганы өчен берара үзен дә битәрләп алды. Егетнең нервысында уйнап, шаяртып ала, имеш. Камилне дә әйтерең бармы? Бала күтәргән Миләүшәне күрүгә, коелды да төште. Ә бәлки әле шулай яхшырактыр да. Моңа кадәр ул аны яхшы беләм дип йөрде, һәрчак аны якын күрде. Кешенең нинди икәнен белер өчен аның белән бер пот тоз ашарга кирәк, диләр шул. Гомер буе бергә яшәгән иреңне дә белеп бетереп булмый, димәс иде тормыш иткән хатыннар да.

Әнисен юксына башлады ахры, күтәреп йөрткәч, берара тынычланып торган сабый тагын еларга тотынды. Озаклады шул. Сабый гына түгел, Миләүшә дә бертуган апасының килүен түземсезлек белән көтә. Иртәгә эш көне. Аның да кайтасы бар. Соңгы автобуска булса да өлгерергә кирәк иде.

Ниһаять, касса янындагы кешеләрне ерып, тирләп-пешеп беткән, шулай да кош тоткан сабыйдай шатланган апасы Сәвия килеп чыкты.

– Уф, көчкә алдым! Бу рейска эләкмәсәм, бала белән иртәгә кадәр аэропорт

саклап ятарга туры киләдерие, – диде ул, өс-башын тәртипкә китереп. Аннары өзек-төтек кенә булса да, сеңлесенә касса янындагы мажараларны сөйләп алды. – Бер әрмән, чиратсыз кереп, миннән алда билет алмакчы булган иде, кертмәдем. Үзе юньләп русча да белми. «Ереван! Ереван!» дип, кассага акча суза. Сиңа Ереван булса, миңа Казан, дип кертмәдем. Әгәр аңа юл куйган булсам, билетсыз кала идем.

Озак сөйләшеп тора алмадылар. Ул арада репродуктор телгә килде. Миләүшәнең апасы очачак рейска теркәү башланды. Шулай да кыз апасына Камилне очратуы, аның солдат хезмәтен үтәп кайтуы турында әйтергә өлгерде.

– Туйга кайтасы була икән алайса, – диде апасы, сеңлесе өчен ихластан куанып.

– Белмим инде, белмим.

– Ничек инде белмисең?

Миләүшә бүтән сүз куертмады. Апасының соравы да җавапсыз калды.

Ул апасын озатып җибәргәндә, көн кичкә авышкан иде, шәһәргә кайтасы соңгы автобуска да чак-чак өлгерде.

***

Камилне аэропортта сөйгәне белән очрашу тетрәндергән иде. Аның тизрәк мондагы яңалыкларны беләсе килә. Ә әнисенең ике ел күрмәгән улына сораулары җыелган. Бердәнбере бит. Исән-сау кайткан улына бер-бер артлы сораулар яудырып кына тора.

– Солдат хезмәте авыр булмадымы? Кыерсытмадыылармы? Әрмиядә тәртип юк, диләр бит. Бигрәк тә яшь солдатларны рәнҗетәләр, дип сөйлиләр. Хакмы шул сүзләр?

– Җебеп торсаң, кыерсытырга маташучылар кайда да җитәрлек ул, әнкәй. Барысы да кешенең үзеннән тора.

– Анысы шулай инде. Кырык ата баласында кырык төрле холык. Әтиең, мәрхүмкәй, үзенә тырнак белән дә чирттермәде. Аңа охшасаң, син дә төшеп калганнардан булмассың, боерган булса.

– Алдагысын Алла гына белә инде.

Чуан тулып тишелгән шикелле, кайтып кергәннән бирле Камилнең йөрәген тырнап торган сорау тышка бәреп чыкты.

– Әнкәй, нәрсә, Миләүшә кияүгә чыктымыни?

Камилнең әнисенә бу сорау аяз көнне яшен суккандай тәэсир итте. Ул берара ни дияргә белми торды. Менә, үзеңдәге хәлне күршеңнән сора дигәннәре хактыр. Әллә кайда, ачуым килмәгәе, кошлар очып җитмәс җирдә хезмәт иткән улы нинди яңалык алып кайткан!

– Ю-ук! Сорап килүчеләр булды бугай. Тик ул, төрле сылтау табып, барысын да кире какты.

– Детдомнан бала алдымыни?

– Нишләп алсын! Институтта укый бит ул хәзер.

– Мин аны әле ике сәгать элек кенә аэропортта бала белән күрдем. Елак баласын туктата алмый изалана иде. Каршысында утырган әбиләр сүктеләр дә әле үзен.

Әнисенең һич кенә дә ышанасы килми иде.

– Булмас! Шаярткандыр әле.

– Нинди шаярту ди? Кеше әйтсә, ышанмас та идем. Мин үз күзләрем белән күрдем бит, әнкәй! Әзрәк сөйләшеп тә тордык әле.

– Нәрсә диде соң үзе?

– Хатын-кыз үз гомерендә һич югы бер бала үстерергә тиеш, ди.

Камилнең сүзләре әнисен тагын да ныграк аптыраштa калдырды. Ул инде икеләнә дә башлады.

– Һәй, эттәгенәсе! Менә яңалык?! Кичә үлгән булсам, ишетми каласы булганмын икән, ә!

Ул арада, монда мин дә бар бит әле, дигән шикелле, кухняда чәйнек сызгырганы ишетелде. Әңгәмә өзелде. Ана белән улы аш бүлмәсенә уздылар. Камил үзенең яраткан урынына утырды. Ике ел үтсә дә, берни үзгәрмәгән. Тәрәзә төбендә – әнисенең яраткан яран гөлләре. Алар Камилнең кайтуына әзерләнгәннәр диярсең – шау чәчәктә утыралар! Стенада – авылдан ук алып килгән түгәрәк сәгать. Вакыттан кала бар нәрсәгә битараф сәгать, өйдәге тынлыкны бозып, бер көйгә текелди. Юк, текелдәми, ә Камилнең йөрәк януын тагын да көчәйтеп, бер үк сүзләрне кабатлый кебек: «...көт-мәгән, көт-мәгән, көт-мәгән...» Зал белән кухня арасында тәм-томнар әзерләп йөргәндә, улы китергән яңалык берара басылып торса да, өстәл әзер булгач, Хатирәнең йөрәк итен кабат талый башлады. Ул өзелгән әңгәмәне дәвам итмәкче иде... Кинәт кенә Миләүшәнең апасы кунакка кайтканы исенә төште.

– Менә баш диген инде, ә! – Әнисе уч төбе белән җиңелчә генә маңгаена чәпелдәтеп алды. – Әле шушы арада гына Миләүшәнең кияүгә чыккан апасы баласы белән кунакка кайткан иде бит. Бәлки, шуның баласы булгандыр... Үткән ел Казан егетенә кияүгә чыкты бит ул.

– Апасын күрмәдем мин аның.

Ана белән ул, ни дияргә белми, бер-берсенә карашып, тынып калдылар. Ана кеше юлдан кайткан улына ял итәргә кирәклеген шәйләп алды.

– Ярар, улым, борчылма. Юлда талчыккансыңдыр. Бар, ял ит. Бүлмәңә урын әзерләдем. Иртәгә Миләүшә белән үзегез сөйләшерсез. Нибуч, аңлашырсыз әле...

***

Әнисе: «Нибуч, аңлашырсыз әле», дисә дә, икенче көнне дә, аннан соң да алар аңлаша алмадылар.

Миләүшә Камилнең аэропорттагы кыланышыннан баштарак көлгән булса, соңыннан бик нык рәнҗегән иде. Шуңа күрә ул җылы караш күрсәтмәде, егетнең ишек шакуына «кәефем юк» яисә «температурам күтәрелде», дип, өйләренә кертмәде.

Әнә бит, ул бүген дә:

– Семестр ахыры. Имтиханга әзерләнәм, – дип, бик җайлы гына кире борды. Икенче, өченче көнне дә, аннан соң да шундый хәл кабатлангач, Камилнең тәмам сөмсере коелды. Сөйләшмәс булды. Ул үз эченә бикләнде. Ә бит ул сөйгәнен үлеп сагынган иде. Солдат хезмәтенең дә ике елына караганда, соңгы ике көнен үткәрү аңа җәза кебек тоелган иде. Кайткач та иң беренче эше итеп, икәүдән-икәү генә калып, сөеклесенең чәчләрен сыйпап иркәләмәкче, пешкән чия төсле иреннәреннән үпмәкче, серле күзләренә карап, бик озак сокланып тормакчы иде...

Соңыннан ул Миләүшәнең апасы турында ишетте ишетүен. Подъезд төбендә кызның кайтуын сагалап торып, гафу да үтенде. Әмма... Ни аяныч, сөеклесенең күңеле һаман эремәгән иде шул әле. Ул Камилгә, чит кешене күргәндәй, хиссез, битараф караш ташлап:

– Яратуың шуның кадәр генә булган икән, Камил, – дип, подъезд ишеген шапылдатып ябып кереп китте.

Шулай да Камил кызның карашында кызгану, үкенү чалымнарын шәйләп алды. Миләүшә егетне кызгана идеме, үзенме – шунысы гына аңлашылмады.

***

Алты яшьлек сәфәрдән кайтса, алтмыш яшьлек аның хәлен белергә килер, дигәннәр. Камилнең кайтканын ишетеп, әнисенең энесе Сәфәргали килде. Иллесен тутырган абзый, басса бакыр, типсә тимер өзәрдәй чагын «күтәренке күңел» белән яшәп, вакытында өйләнә алмыйча да калды. Хәер, «Коммунизмга юл» дигән салага барып, бер ялгыз хатынга йортка кергән иде дә, ул мескеннең сукыр эчәге шартлап, гомере өзелде. Бала-чагалары булмагач, Сәфәргали тол хатынның йортында яшәп калды. Гәрдәле халкын шәһәргә күчергәндә, аңа өлеш тимәде. Хәзер дуадак каз кебек ялгызы яши. Колхозлар таркалгач, күпләр шикелле ул да эшсез калды. Булдыклы егетләр күмәк хуҗалык таркалды дип, борын салындырып утырмады, пай җирләрендә иген икте, абзар тутырып мал асрады, хуҗалыгын гөл кебек итте. Сәфәргали кебек «көпшәкләр», кибет тирәсенә җыелып, өстәгеләрне сүкте. Янган йөрәкләрен (бурычка алып булса да) хәмер белән басарга тырышты. Аларның, төкерекләрен чәчә-чәчә, бугаз киерүен өстәгеләр ишетмәде, түбәндәрәк утырганнар ишетсә дә, колагына да элмәде яисә «безгә югарыдан шулай куштылар» дип кенә җавап бирде. Вакытында кеше төсле гаилә корган булса, ул да берәр чарасына керешер иде. Ә хәзер аның «гуты узган, чабатасы тузган». Кибеткә килгән-киткәннән тиеннәр өмет итеп көн күрә. Шулай булса да, әнисенең энесе бит, Камил кибеткә чыгып йөгерде.

Абзасы белән чәйләп-мәйләп утыру да егетнең янган йөрәген басмады. Киресенчә, хәмер тәэсире аны әллә нинди яман уйларга этәрде. Аның күңелендә, «мөгаен, Миләүшәнең егете бардыр, саклап торырга кирәк», кебек берсеннән-берсе күңелсез уйлар чуалды.

Улының, балтасы суга төшкәндәй, пошаманда йөрүенә әнисе дә борчыла, сәбәбен дә белә, ярдәм генә итә алмый иде. Аптырагач, улының хәленә керергә тырышып, ул:

– Улым, бер болганмый, су да тынмый, диләр. Миләүшә начар кыз түгел. Үпкәләп йөрер-йөрер дә акылына килер. Ул кадәр борчылма. Бар, урамга чык. Иптәшләреңне күр. Шәһәр белән таныш. Күрәсеңме, ничек зурайды! Әнә, бездән ике тукталыш кына яңа кинотеатр төзеп куйдылар. Кинога бар! – диде.

Ә шәһәр, чыннан да, зурайган иде. Ике ел элек кенә бураннар уйнап торган япан кырда ничаклы йортлар калкып чыккан. Йорт тирәли утырткан агачлар калкынып килә. Алар яшәгән өй янында гына автобус тукталышы ясап куйганнар. Тукталышка бәләкәй генә сәүдә павильоны килеп сыенган.

Көн аяз. Кояш, солдаттан кайткан егетне күрүенә шатлангандай, нурын җәлләми мул сибә. Тукталышта җим эзләп, чыпчыклар чыркылдаша, күгәрченнәр, гөр-гөр килеп, кешеләрнең аяк астында бөтерелә. Камил кошларның кыланышына хәйран калып карап торды. Күгәрченнәр кешеләр сипкән көнбагышны кабыгы-ние белән бергә йотып җибәрәләр. Ә чыпчыклар (ничек башлары җитә диген!) җәһәт кенә томшыкларына эләктерәләр дә, башларын кыегайта-кыегайта, берничә мәртәбә асфальтка бәргәләп алалар. Шулай иткәч, көнбагышның кабыгы ярылып китә дә читкә чәчри. Хәйләкәр чыпчыклар аның төшен генә ашыйлар. Менә кайда ул гаҗәп хәйран тамаша! Камилнең моңа кадәр аларга игътибар иткәне юк иде. Аның күңеле күтәрелеп китте.

Тукталышта кеше күп түгел. Егет читтәрәк басып торучы кызга игътибар итте. Кыз әледән-әле сәгатенә карап ала, аптырагач, тукталыш тирәли утырткан һәм инде ярыйсы ук тернәкләнеп килүче юкә агачларының яфракларын өзеп ала. Түземсезләнеп-кыбырсып, аларны бөтергәли. Мотлак, ул шулай сабырсызланып, кемнедер көтә иде. Ә кыз теләсә нинди асыл егетләрне дә үзенә каратырлык

чибәр булуы өстенә, кигән киемнәре дә соңгы мода белән тегелгән. Әйтерсең, ул чибәрләр конкурсында катнашып, әле генә Парижның үзеннән кайтып төшкән.

Кызның көткән кешесе, ә Камилгә кирәкле маршрут автобусы юк та юк. Егет, бар кыюлыгын җыеп, кызга якынлашты.

– Кемне көтәсез, чибәркәй?

Кыз, Камилне баштанаяк күздән кичергәннән соң, саран гына елмайды. Күңеленнән генә, ярыйсы егет күренә бу, таушалмаган, дип уйлап алды.

– Менә, сезне көтәм.

– Соң, нигә аны әйтми торасыз?

– Кызлар үзләре сүз башлар дип уйлыйсызмы әллә? Не дождётесь!

– Соң, әйдәгез алайса, минем белән кинога!

Кыз тагын бер мәртәбә Камилгә сынап карап алды.

– Нәрсә, кызың килмәдемени?

– Миңа андый бәхет тәтемәде шул әле.

– Үпкәләткәнсеңдер. Шуңа килмәгәндер.

Камилнең йөрәге сыкрап куйды. Шулай да чыраена чыгармады. Кыз тагын телгә килде:

– Нинди фильмга чакырмакчы буласыз инде?

– Ә сез ниндирәк фильмнар карарга яратасыз? Сугыш турындамы? Детективмы?

Кыз, якын килмә, дигән кыяфәттә ике кулын берьюлы күкрәк турысына күтәрде. Әйтерсең, бу минутларда аңа кемнәрдер сугарга кизәнә. Ул, шулардан саклану өчен, кулларын калкан итеп куйган иде.

– Ой, юк! Ул сугыш-үтереш турындагы фильмнардан болай да туйган инде. Телевизорны кабызсаң да, шул – аккан каннары экраннан чайпалып чыгардай. Карап торуы чирканыч!

– Әйдәгез, алайса мин сезне «Ватан»га алып барам. Элек анда Һиндстан фильмнары күрсәтәләр иде. Аларда мәхәббәт маҗаралары җыр-музыка белән үрелеп бара ичмаса.

– Ә нишләп иде дип үткән заманда сөйлисез әле? Утырып чыктыгызмы әллә дияр идем, андый егеткә охшамагансыз.

Чая кыз икән бу, сүзгә кесәгә керә торганнардан түгел, дип уйлап алды Камил күңеленнән генә.

– Ике ел хезмәт итеп кайттым мин.

– О-о, Ватан алдындагы бурычыгызны үтәгәнсез икән алайса. Димәк, хәзер дүрт ягыгыз кыйбла!

– Хәзерге минутта безнең кыйбла «Ватан» кинотеатрына юнәлгән булырга тиеш. Сез риза булсагыз, әлбәттә.

Кыз (бу юлы елмаеп) Камилне тагын бер мәртәбә күздән кичерде.

– Солдаттан кайткан егеткә ничек каршы киләсең инде. Сезнең кебек полковник каршында мин рядовой солдат кына.

Камил кычкырып көлеп җибәрде.

– Ике ел эчендә полковник чыкса, безнең ил генераллар белән тулыр иде. Мин бары өлкән сержант кына.

– Барыбер командир инде.

– Сержантларны младший комсостав, диләр.

Кыз буялган тырнаклы нәфис кулларын җиңелчә генә селтәп алды.

– Барыбер командир бит инде.

Камил бәхәсләшеп тормады.

***

Чибәр кызның исеме дә үзе шикелле матур иде – Лиана! Тропик урманнарда колмак шикелле үрмәләп-уралып үсә торган үсемлек. Кинога чакыргансың икән, аны озатып куярга да кирәк. Камил анысын белә белүен. Ә менә бу чибәр кызның да алар белән бер йортта яшәвен уена да китермәгән иде. Миләүшәләрнең фатиры йортның бер башында, Камилләрнеке икенче башында булса, Лиана, Камил белән Миләүшә арасына килеп кергән чөй шикелле, уртадагы подъездларның берсендә яшәп ята икән! Гәрдәле кызы булса, егет аны, һичшиксез, белер иде. Ул хезмәт иткән арада кыз булып җитешсә дә, үсмер чагын хәтерләр, һич югы, чамалар иде. Ә Лиананы юк, хәтерләми!

– Лиана, сер булмаса, әйт әле, ничек килеп эләктең син бу йортка? Монда яшәүчеләрнең барысы да бер авыл кешеләре. Кул чугының биш бармагы кебек бер-берсен белә. Бары да таныш. Ә мин сезне, нишләптер, хәтерләмим.

– Ә син Гыйльмеямал әбине беләсеңме?

– Ә-ә, беләм. Ире сугышта һәлак булган ялгыз карчык иде ул. Мин солдатка киткәндә исән иде әле.

– Менә шул Гыйльмеямал әбинең Фәрхиямал дигән сеңлесенең оныгы булам инде мин.

– Ул апа, ялгышмасам, кайдадыр Урал якларында яши иде түгелме соң?

– Өстенә бастың – туры китердең! Башлы егет икәнсең!

Камил, ихтыярсыздан, ай-һай теле, тел очында безе, дип уйлап алды.

– Ярар, аңлат инде алайса бу «башлы егет»кә, син монда ничек килеп чыктың соң?

– Менә шул Гыйльмеямал әби үлгәч, хосусыйлаштырылган фатир кемгә калырга тиеш?

– Балалары булмагач, дәүләткәдер инде.

– Түгел шул! – кыз, башыңны эшләт, дигән шикелле, җиңелчә генә Камилнең маңгаена чиртеп алды. – Наследство мирас буларак якын туганнарының берсенә күчәргә тиеш. Димәк, Пермь өлкәсендә яшәп ятучы Фәрхиямал әбигә. Ә ул әбинең бер аягы җирдә булса, икенчесе инде гүрдә. Әби ул фатирны менә миңа – оныгына подарить итте. Төшендеңме инде?

Камил, әйе, дигәнне аңлатып, җиңелчә генә баш кагып алды.

– Юкәдә икән чикләвек!

– Ә син ничәнче фатирда торасың?

Курчак кебек чибәр кыз сорагач, ничек әйтмисең инде. Подъездына, этажына кадәр әйтте Камил.

– Ә кем белән яшисең?

– Әни белән икәү генә.

– Фатирыгыз зурмы соң?

– Зур.

– Ничә бүлмәле?

– Өч.

– Бай яшисез икән.

– Ә безнең авылдагы йорт та иркен иде...

***

Лиана тәвәккәл кыз булып чыкты, икенче көнне Камилләрнең ишеген шакыды. Әнисе белән итагатьле генә исәнләшкәннән соң, аптырабрак калган егеткә дәште:

– Камил, син электричествоны әйбәт беләсеңме?

Шундый чибәр, кем әйтмешли, бер кашык су белән йотардай кыз алдында ничек белмим дип торасың инде.

– Трансформаторга керергә булса, минем доступ юк... Ну, вак-төяген, хуҗалыкта кирәген генә беләм инде.

Лиана керәч кебек ап-ак тешләрен күрсәтеп елмайды.

– Юк, солдат хезмәтеннән исән-сау кайткан егетне алты мең көчәнешле трансформатор будкасына илтеп тыгарга минем башыма тай типмәгән. Аны гына беләм инде. Гыйльмеямал әбинең саргаеп беткән, хан заманыннан калган бер рожоклы люстрасын алыштырмакчы идем. Миңа ярдәм итә алмассыңмы икән? Бәхилләтер идем.

Камил анысын гына булдыра, билгеле. Әллә ни катлаулы эш түгел. Люстрадагы чыбык очларын ялгап, изолента белән урыйсың да түшәмгә элеп куясың.

– Ә ничә куыклы люстра куймакчы соң?

– Биш.

Егет, күңеленнән генә, бераз катлаулырак икән, дип уйлап алды. Шулай да үзләрендә өч куыклы шәмдәл куйганын исенә төшереп ризалашты.

– Отвёртка, пассатижы кебек инструментларың бармы соң? Изолента...

– Нинди инструмент? Гыйльмеямал әбинең дисбесеннән башка нәрсәсе булсын инде?!

Нишлисең, юк икән юк алайса. Үз коралларыңны алырга туры килә.

Көтмәгәндә Лиананың килеп керүе егетнең әнисен дә аптырашта калдырган иде. Шулай да караңгы чырай күрсәтмәде.

– Ишек төбендә генә торма, кызым. Әйдә, түрдән уз! Синең безгә беренче мәртәбә генә керүең бит әле.

Ул арада кухня ягыннан чәйнекнең ярсып сызгырганы ишетелде.

– Әнә, ишетәсеңме, кунак кергәнен сизгәндәй, «самавырым» да кайнап чыкты.

Камил, кирәкле эш коралларын табып, бүлмәгә кергәндә, Лиана белән әнисе чөкердәшеп, чәйләп утыралар иде инде.

Ә биш куыклы шәмдәл бер куыклы кебек җайлы түгел икән шул. Камил тегеләй дә, болай да тоташтырып карады. Кабызгач, йә икесе, йә өчесе генә яна. Калган икесе юк. Егет эченнән генә, ялгыз башына нигә кирәк булгандыр биш куыклы люстра, дип, кызны битәрләп тә алды. Биш тапкыр сүтеп, биш тапкыр җыйды, калган икесендә барыбер лампочкалар кабынмады. Ахыр чиктә кыз да кулын селтәде. Ул монысына да риза иде. Чөнки ике көн элек кенә люстра куярга егете Андрейны чакырган иде, ул хәтта ике куыгын да кабыза алмады. Фазаларны бутап бетерде, ахыр чиктә сыңар куыкны гына эшләтеп җибәрә алды. Егет кеше бит, шулай да сер бирәсе килмичә, ул:

– А зачем нам свет? Я и в темноте тебя хорошо вижу, – дип, Лиананы кочмакчы булган иде дә, кыз аны якын җибәрмәде.

Ни дисәң дә, Камил шәмдәлнең өч куыгын кабызды бит әле. Болары да җитеп торыр. Әлегә...

***

Аралаша-сөйләшә торгач, Камил Лиананың шәһәрдәге затлы салоннарның берсендә парикмахер булып эшләвен белде. Алар, билгеле, клиентлар өчен тырышалар, әмма үзләренең кыяфәтләре турында да онытмыйлар инде. Егеткә кызның һәрчак курчак кебек пөхтә күренүенең сере ачыкланды. Нишләтәсең, хатын-кызның һәрчак матур буласы килә. Сөйкемле затлар өчен бу табигый хәл. Ир-ат халкы беренче чиратта хатын-кызның тышкы кыяфәтенә игътибар итә, аның холкы-фигыле, эчке дөньясы турында уйлап та карамый.

Камил, эш коралларын култык астына кыстырып, Лианаларның подъездыннан чыгуга, кулына ярыйсы гына авыр сумка күтәргән Миләүшә очрады. Кыз кибеттәнме, каяндыр кайтып килә иде булса кирәк, сумка авырлыгыннан аның гәүдәсе дә бер якка янтайган иде. Камил, йөгереп диярлек, аның каршына килеп басты.

– Кая, бир әле сумкаңны!

Кыз егетнең култык астындагы инструментларына күз сирпеп алды.

– Ә син каяндыр шабашкадан кайтып киләсең бугай. Арыгансыңдыр. Рәхмәт!

Миләүшә сумкасын икенче кулына күчерде һәм (әйтерсең, кемдер аны куып килә) адымын кызулатты.

Кызның төртмә телләнеп әйткән сүзләре Камилнең йөрәгенә ук булып кадалды. Ул, нишләргә белмәгән кешедәй, нәүмизләнеп, берара баскан урынында таптанып алды. Аннары, каккан казык кебек ялгызың серәеп торуның ярамаганын аңлап, фатирларына таба атлады.

Бу минутларда егетнең күңелендә давыл купты. Димәк, аның Лиана белән кинога баруы турында кемдер Миләүшәгә җиткергән! Башын иеп, уйланып бара торгач, ул үз подъездларын үтеп киткән икән, таныш түгел ишек төбенә җиткәч кенә, ялгышуын аңлап алды.

***

Камил, берара тегендә барып, монда сугылып йөрде дә армиягә алынганчы эшләгән төзү-монтаж идарәсенә барып урнашты. Бригадада ГПТУ тәмамлап килгән берничә яшь җилкенчәктән кала күбесе элек бергә эшләгән кешеләр иде. Алар:

– Вәт, солдат шулпасы килешкән сиңа, Камил! – дип, ирләрчә үз итеп, аның җилкәләренә шапылдатып сугып алдылар. Бригадирлары Петрович (өлкән яшьтәге агай) хәтта:

– Һо, Камильчик, бөркет булгансың бит! Когда обмоем? – дип, аны үз улыдай күреп, кочаклап ук алды. Ни хикмәттер, агайның авызыннан аракы исе аңкый иде. Шәһәр төзелешендә данлыклы үрләр яулаган бригада җитәкчесе (уңышлардан башы әйләндеме?) соңгы вакытта шайтан суы белән дуслашкан.

Җитәкчеләр, инде атказанган төзүче исеменә кәгазьләр әзерләнгән агайның яман гадәтен сизеп, тиз арада лаеклы ялга озаттылар да аның урынына солдаттан кайткан Камилне куйдылар. Аның:

– Мин бит әле генә... Миннән башка да... – дигән ай-ваена да колак салмадылар.

***

Лиана вак-төяк йомыш белән дә күршеләренә түгел, Камилләргә керә башлады. Хәзер егет аны ишек шакуыннан ук таный. Бүген дә. көтмәгәндә, ишектәге кыңгырау кискен генә өч тапкыр чылтырап куйды. Егет бу кызның тагын миңа берәр йомышы төшкәндер дип уйлап алды. Чөнки ул әле күптән түгел генә аның фатирындагы идәнгә җәйгән линолеумны яңага алыштырган иде. Әмма кыз бу юлы Камилгә түгел, әнисе янына кергән:

– Хатирә апа, мине бәлеш пешерергә өйрәтегез әле?

Өйрәтегез әле дип әйтү, гәрчә, таләп итү кебегрәк тоелса да, барыбер үтенеч бит. Гозер белән кергән кешене ничек кире борасың инде. Кешесе ул түгел. Үзенең авызыннан өзеп булса да, йомыш белән килгән кешенең хәленә керми калганы юк әнисенең. Ул фәкать:

– Нәрсә, кунак көтәсеңме әллә, кызым? – дип кенә куйды.

– Гыйльмеямал әбинең вафатына бер ел тула бит. Әбиләр җыеп, елын үткәрмәкче идем.

Кызның сүзләре хатынның йөрәгенә сары май булып ятты. Ул, күңеленнән генә: «И-и, Алланың рәхмәте! Яшь булса да, тәүфыйклы, мәнле икән бу бала», – дип уйлап алды. Ул, соклану катыш:

– Ай-һай, кызым! Бик изге эшкә тотынгансың икән бит. Гүр иясе булганнарның рухына дога ирештерү – саваплы гамәл. Әбиеңнең елы икәнен онытмавың өчен рәхмәт! Тик, балам, алай кешеләр җыеп аш үткәргәндә, бер бәлеш белән генә булмас шул. Анда аш-су да, чәй ризыклары да, башка тәгамнәр дә кирәк булачак бит әле. Аларын йә үзеңә пешерергә, йә сатып алырга кирәк була инде. Барыбер дә бу мәшәкатьле эшне башкарып чыгарга үзеңә генә авыр булыр, берәр аш-суга оста ярдәмче кирәк булачак сиңа, кызым.

Моңа кадәр хатын-кызларның әңгәмәсен тыныч кына тыңлап торган Камил, елмаебрак:

– Якын-тирәдә аш-суга синнән дә остарак кеше юк инде ул, әнкәй, – дип сүз кыстырды. Аның бу ат дагалаганда бака ботын кыстырган кебегрәк тоелган сүзләре Лианага ярап куйды.

– Хатирә апа, алайса миңа ярдәмләшергә вакытыгыз юкмы соң? Бәхилләтер идем.

– Һи кызым, андый изге эшкә акча алу гөнаһ булыр. Алай үтенеч белән кергәнсең икән инде, башка кешегә әйтмәгән булсаң, кулдан килгәнчә ярдәм итәргә тырышырмын, Алла боерса.

Шуннан соң алар, килен белән каенана шикелле, берничә көн рәттән Гыйльмеямал карчыкның елын үткәрү мәшәкате белән мәш килделәр: ике фатир арасын таптадылар. Пәнҗешәмбе – әрвахлар дога өмет итеп кайта торган көн, дип, якын-тирәдәге карчыкларны җыеп, Коръән укыттылар.

Гыйльмеямал әбинең елын бергәләп үткәрү Лиананы Камилләр гаиләсенә тагын да якынайтты.

***

Миләүшә Лиананың Камилләрдә үз кеше булып китүен күреп-белеп торды. Тышка чыгармаса да, күңеленнән ут йотты. Үзенә урын таба алмаган көннәре дә, мендәрен күз яшьләре белән юган төннәре дә аз булмады. Хәзер аның бар шөгыле – эш тә уку. Бар юанычы: уку әсбаплары, дәреслекләр, китаплар... Гыйлем эстәүне энә белән кое казуга тиң дип белеп әйткәннәр икән. Ул «Высшая математика», «Начертательная геометрия» фәннәрен Миләүшәнең җене сөйми. Тормышта аларның бер кирәге дә юк югыйсә. «Сопротивление материалов» дигәне дә катлаулы. Математика белән физиканы белмәсәң, тешең үтмәячәк. Студентлар җор халык бит. Алар арасында, уенын-чынын кушып, «Сопромат сдал – можно жениться» дигән әйтем-гыйбарә дә таралган. Ә «Начертательная геометрия» фәне турында алар «Ничертательная не понимательная геометрия» дип кенә җиффәрәләр. Шулай булса да, барыбер имтихан яисә зачёт тапшырырга кирәк. Тапшыра алмасаң, көзгә калдыралар. Көзгә кадәр «койрык» сөйрәп йөрисе килми Миләүшәнең. Төн йокыларын калдырып булса да, шул сөймәгән фәннәрне үзләштерә. Зачётын да үз вакытында тапшыра, имтиханда да уңай бәя алып чыга. Шулай бер семестр икенчесенә ялгана. Көннәр аккан су кебек сизелми генә ага да ага. Көннәр айларга, айлар елларга әйләнә...

Утыз көнлек уразаның да бәйрәме булган шикелле, биш елга сузылган укуның бәйрәме Миләүшә өчен кулына диплом алган көн булгандыр. Кыз ул көнне, кош тоткан сабыйдай, әйтеп бетергесез шатлыклы мизгелләр кичерде. Камил-Лианалар турында да уйламаска тырышты. Алар икенче планга күчте. Хәер, уйлаудан ни мәгънә. Буласы булган, туннар тузган. Миләүшә укып йөргән

арада инде алар гаилә корып яшиләр. Яннарында тупырдап торган уллары бар. Аларның тормышы түгәрәк. Тормышларына кырау гына төшмәсен – бәхетле яшәсеннәр. Очрашканда да, алар, гаепле кеше сыман, бер-берсенең йөзенә туры карамаска тырышалар. Исәнләшүләренең дә ата-анасы юк. «Исәнмесез!» сүзе дә «Исә...» дигән иҗекләр белән генә төгәлләнә дә һәркем үз юлына китә. Киләчәктә бу «Исә...» торган юллар очрашырмы? Тәгаен генә беркем дә әйтә алмас... Барысы да Кодрәт иясенең ихтыярында...

Тик менә соңгы вакытларда Камилнең әнисе генә авырып тора икән. Урамга да кеше ярдәменнән башка чыга алмый мескенкәй, гел ятып тора, диләр. Авылда ялгызы мал-туар асрап, төзелештә дистә еллар дәвамында соскы көрәк белән бетон ыргыткач, ничек сәламәтлегең какшамасын инде.

***

Ә Камил белән Лиананың кавышу тарихы...

Лиананың һич кенә дә сазаган кызлар рәтенә керәсе килми иде. Моңа кадәр дә ул егетләр белән аралашты, дуслашты. Әмма тормыш корырдай җитди ир-егетне генә очрата алмады. Күбесенең максаты: уен-көлке, кәеф-сафа кору... Аннары бик җиңел генә ятакта ауный-тәгәри... кавышу булды. Соңгы вакытта танышкан Андрейның да максаты шул тирәдән артмады. Хәер, рәтләп люстра да куя алмаган ир аңа нигә кирәк? Ә Камилнең, тормыш кору турында сүз кушмаса да, эшкә кулы ятып тора. Ул аның осталыгын линолеум алыштырганда ничек тәфсилләп, һәр җөйне бөртекләп, җеген җеккә китереп эшләвен күзәтеп торганда ук күрде. Кызның күңелендә «Эх, тормыш көткәндә шундый ирең булса...» дигән уй күптән бөреләнгән иде инде. Кешесен генә очрата алмый йөри иде. Ә егеттә өйләнү кайгысы юк: авызыннан өйләнү сүзенең «ө»се дә чыкмый. Бар сөйләгәне эш тә эш...

Дәрт иткән – морадына җиткән ди. Танышканнарына ике ел чамасы үттеме икән, Лиана Камилне туган көнгә кунакка чакырды. Билгеле инде, ул үзе теләгән, җан яраткан, күңел тарткан кешеләрен генә дәшкән. Күбесе – бергә эшләгән, берсеннән-берсе чибәр яшь кенә ханымнар. Арада бер ала карга – Камил генә. Шуңамы, ул көнне бөтен игътибар Лианадан бигрәк Камилгә булды. Җырлаган җырлары да дәртле, ымсындыргыч иде.

Яле, иркәм, карап кара,
Кара күземә генә,
Карасаң күземә генә,
Булам үзеңә генә...

– Безнең арада «для запаха» бердәнбер егет! – дип, ханымнарның кара чәчлесе дә, сары чәчлесе дә Камил белән бокалларын чәкештерде.

Аракы, әллә нинди пәһлеван егетләрне дә тез астына бөкләп сала торган явыз, үз эшен эшләде. Камил исерде... Һәм икенче көнне иртән генә уянып китте! Иң сәере: алар Лиана белән бер түшәктә яталар иде?!!

Лиана, аның уянганын сизеп:

– Әнә, күр, мине елата-елата кичә ниләр кыланганыңны! – диде, ятакка күрсәтеп. Аннары торып, эчке күлмәктән килеш кенә көзге каршында чәчен-башын төзәтергә тотынды.

Камил, юрганны бер якка селтәп, ятакка күз төшереп алды һәм... имәнеп китте!!! Ни диярга белми, телсез калды.

– Икенең берсен сайла, – диде Лиана, төксе генә. – Йә ЗАГСка барабыз, йә мине көчләде дип, милициягә барам!

Камил шунда гына үзенең капкынга эләгүен аңлап алды. Тик соң иде шул инде. Соң иде...

Ә Лиана – исеменә күрә җисеме! Үсмер чакта ук инде подъезд төбендәге эскәмиядә утыручы мут хатыннарның, ничек итеп айлык вакытына туры китереп, егетләрне кармакка эләктерүләре хакында көлешкәннәрен ишеткәли иде. Дөнья булгач, елгыр хатыннарның хәйләсе Лианага да ярап куйды...

Әмма тормыш – колагыңны бормыш.

***

Камил авыру әнисен төрле табибларга күрсәтеп карады, республика дәваханәсенә алып барды, аптыраган үрдәк арты белән күлгә чума дигәндәй, өшкереп-төкереп дәвалаучы әбиләрнең ишеген дә күп шакыды. Нәтиҗәсе генә булмады. Ахыр чиктә әнисенең аяк-куллары йөрми башлады – паралич сукты. Урын-җир өстендә калган, бер хәрәкәтсез яткан кешене тәрбияләү бигрәкләр дә авыр икән. Ул мескен торып утырып ашый алмый, ризыкны кашык белән авызына салсаң гына әвәләп йота. Көндез Лиана белән Камил эштә, уллары Азат балалар бакчасында. Авыру әниләре өйдә ялгызы кала. Ярый әле Камилнең эш урыны ерак түгел. Аларның бригадасы күрше урамда яңа йорт җиткерә. Әбәт вакытында ул тиз-тиз генә капкалый да әнисен карап килә. Тугыз катлы йорт төзелеп беткәч, аларның бригадасын шәһәрнең икенче башына күчерсәләр, нишләр? Ашату-эчертү бер нәрсә. Торып йөри алмагач, ул мескеннең йомышлары да яткан килеш кенә...

Лиана, әниләре янына килгәнче, башта борынына чүпрәк бәйли. Аннары, озын тырнакларына зыян салмаслык итеп, әкрен генә резин перчатка кия. Шуннан соң гына караватка якын килә.

Соңгы вакытларда Лиана каенанасын карарга җирәнә башлады. Ул яткан урын-җирне чистартканнан соң, исе тәнемә сеңгән дип, ванна бүлмәсенә бикләнә дә сәгатьләр буе юына.

Өйдә сүз гел шул турыда бара: Лиана зарланудан башканы белми.

– Беркөн кызлар, синнән нинди дер ис килә, дип аптыраттылар. Хәлне сөйләп биргән идем, «аһ» иттеләр. Безнең сөйләшкәнне мөдир дә тыңлап торган икән. Болай булса, клиентларыбызны бездән биздерәсең бит син. Нигә ул кортканы картлар яисә инвалидлар йортына илтеп тапшырмыйсыз, ди.

Камил хатынының йөзенә текәлде.

– Нәрсә, бу синең миңа киңәшеңме инде?

– Әнә, безнең постоянный клиент – эшмәкәр Сан Санычның хатыны тётя Лизалар да шундый хәлгә тарыганнар икән. Өметсез булгач, инвалидлар йортына урнаштырып котылдык, ди.

– Ә хәзер әниләре яшәгән бүлмә яныннан үткәндә, йөрәкләре әрнеми микән соң аларның?

– Хәзерме?! Ул бүлмәдә бозау кадәр овчарка яши икән. Нәселле, лабрадор токымлы эт, шулкадәр акыллы – хуҗаларының әйткәнен ярты сүздән аңлый, ди.

– Аңлы этләре өй эшендә булышамы икән инде? Идәннәрен себереп чыгарамы, керләрен юамы?

– Идән себерү генәмени? Урамга алып чыккач, таяк ыргыталар да: «Иди, принеси!» дип, команда бирәләр икән. Ушлы овчарка, чабып барып, ыргыткан таякны шундук авызына кабып, хуҗаларына китереп бирә, ди.

Камил, чыраена мыскыллау галәмәте чыгарып, йөзен җыерды.

– Бала-чага уены ич бу. Йә, шуннан кемгә файда?

– Кызык бит.

Бу юлы ирнең чыраенда нәфрәт чалымнары чагылды.

– Нәрсәсе кызык? Кызганыч бу! Алар эт белән мәрәкә килгәндә, вакытлыча, әниләрен онытып та торсыннар ди. Ә ул әрәмтамакны кабат әниләре яткан бүлмәгә кайтарып япканда, нинди хисләр кичерәләр икән? Сорамадыңмы?

– Юк.

– Юк шул менә! Юк!

– Кеше тормышына тыкшынырга минем ни хакым бар?

– Ни кызганыч, хәзер күп кеше «моя хата с краю» дип яши. Үзенә килеп тисәләр генә «Каравыл!» кычкыра...

Лиана – елгыр хатын, беркөнне каяндыр табып, үзе белән ниндидер бер әби ияртеп кайтып керде.

– Менә, әнигә иптәш. Без эштә чакта аңа күз-колак булыр. Ашатыр-эчертер, сораган әйберсен китереп бирер.

Камил хатынының бу гамәленә каршы килмәде. Ни дисәң дә, хатын хаклы иде. Күңеленнән генә ул аңа рәхмәт тә укыды. Башыңа төшмәсә, каян беләсең, «сиделка» дип исем алган замана әбиләре дә хәзер бушка эшләми икән. Ул сораган бәягә килештеләр. Хәзер ир белән хатын тыныч күңел белән икесе ике якка эшкә китә. Эшләр бераз җайланды шикелле. Әмма бу да озакка бармады. Биш ай чамасы үтте микән, тәрбияче әби, кинәт кенә, чыгымчы ат кебек көйсезләнде дә куйды. Әллә башка, кыйммәтрәк түли торган клиент тапты, әллә, чыннан да, сәламәтлеге какшады.

Урын өстендә яткан авыруны карарга атлыгып торучы кешене тиз генә каян табасың. Авыру ана тагын Камилләрнең үзләренә калды.

Адәм баласы барысына да күнегә, диләр. Камил белән Лиана да дистә елга якын бер түбә астында яшәп, бер ятакта йоклагач, бер-берсенә күнеккәннәр иде инде. Мәхәббәт хисе Таһир-Зөһрәнеке кебек булмаса да, хәзер күп нәрсәләр уртак. Җитди мәсьәләләрне хәл иткәндә, барыбер тәмле телләнә.

Камил дә:

– Лиана, җанкисәгем, әллә вакытлыча эшеңнән китеп торсыңмы? – дип тә карады.

Хатынының бу турыда ишетәсе дә килмәде. Сүзен сүз итәр өчен, кайнарланып, саллы-саллы дәлилләр китерде.

– Камил, башың белән уйлап кара әле син әзрәк. Мин бу эшемнән китсәм, андый төшемле урынны каян табармын соң? Машинаны яңартасы бар. Көзгә улыбыз Азат беренче сыйныфка укырга керә. Киләчәктә аны укытасы, кеше итәсе бар. Хәзер бит уку кая барсаң да түләүле. Хәзердән үк мая тупламасаң, киләчәктә аны ничек укытасың?

– Лиана, җанкисәгем, мин дә эшләп йөрим бит әле. Өйдә йокы симертеп ятканым юк.

– Камил, акыллым, әйтсәм әйтим инде, без бу хәлдән әнине психоневрологический диспансерга тапшырып кына котыла алабыз, белдеңме?

– Ә нигә картлар йортына яисә инвалидлар йортына түгел, нәкъ менә ахмаклар йортына?

Хатын, картлар йортына – балалары әти-әнисеннән ваз кичсә генә, инвалид-гариләр йортына – чират белән генә урнаштырганнарын, аларга фәкать бер генә юл – әниләрен психо-неврология диспансерына гына илтеп тапшырырга

мөмкин икәнлеген күптән белешкән иде. Билгеле, бу турыда ул Камилгә әйтеп тормады.

– Ә син әнинең үзалдына лыбыр-лыбыр сөйләнә башлаганын сизмисеңмени, Камил?

– Паралич суккан кешегә сөйләшүе авырдыр, теле көрмәкләнә торгандыр. Шуңа күрә әйтәсе килгән сүзләре дә авызыннан тукмалып-имгәнеп чыга торгандыр. Хәзер нәрсә, шуңа карап, без әнине тилеләр йортына илтеп тапшырыйкмыни инде?!

Лиана бүтән сүз куертмады, кухняга кереп китте. Урындыкларның дөбер-шатыр килүеннән, савыт-сабаларның челпәрәмә килердәй булып шылтыравыннан аның эчендә давыл купканын чамаларга була иде. Алар тугыз ел инде бергә яшиләр. Камил әле һаман хатынының холкын аңлый алмый. Лиананың холкы бөтерчек өермә кебек: уйламаганда-көтмәгәндә куба. Кайсы яктан исәсен, кай тарафка илтәсен шайтан белсен!

***

Атна-ун көн үтте микән, Камил эштән кайтуга фатирлары тып-тын. Урын-җир җыештырылмаган, кухня ягыннан пешкән аш исе дә килми, савыт-саба юылмаган килеш өелеп ята. Чәйнектән, әйтерсең, котып салкыны килә. Өстәлдә фәкать бер бит кәгазь ята. Анда бәгырьләрне өтеп алырдай дүрт-биш сүздән торган җөмлә: «Камил, гафу ит, түзәрлегем калмады!»

Камил иртәме-соңмы нидер буласын сизенгән иде инде. Чөнки бу арада өйдә тәртип бетте. Ул, беркавем башын иеп, терсәге белән буш өстәлгә таянган килеш чигәләрен учлап, уйга калды. Хәзер аңа нишләргә? Нишләргә? Шушы сорауга җавап таба алмый күпме утыргандыр, хәтерләми, бераздан торып, бүлмә буйлап йөренде. Ни өчен икәнен үзе дә белмәстән, кием шкафларын ачып япты. Анда Лиананың күлмәкләре юк. Күрәсең, ул барын да алдан ук уйлаган, чарасын күргән иде.

Ир, балтасы суга төшкән кешедәй, чарасыз, диванга барып сеңде. Өй эче мәет чыккан шикелле тып-тын. Сөйләшер-киңәшләшер кеше юк. Хатынының каты-каты басып йөргән аяк тавышлары да, уллары Азатның юк кына әйбердән кызык табып, бүлмә яңгыратып көлгән авазы да юк. Фәкать стенадагы тышкы кыртышына тузан кунган түгәрәк сәгать кенә бернигә дә карамый, секундларны минутларга тезеп, берөзлексез текелди...

Әллә чыннан да, Лиана киңәш иткәнчә, әнисен акылга зәгыйфьләр йортына илтеп тапшырыргамы? Уйласаң, бер алар гынамыни? Машинаң белән фырылдап килеп туктыйсың да, яраксыз әйберне чүплеккә чыгарып ташлаган кебек, илтәсең дә ыргытасың. «Мәгез, карагыз! Шуның өчен дәүләт сезгә акча түли», – дисең. Алай итсәң, авыруны карап мәшәкатьләнәсе юк. Өйдә бернинди ис тә, кос та юк. Рәхәт бит! Алай эшләсәң, улын алып, Лианасы да кайтыр. Элеккечә яшәрләр. Элеккечә?! Ә элеккечә ихлас, элеккечә эчкерсез булырмы соң ул тормыш?.. Күңеленә килгән бу ямьсез уйлардан Камил үзе үк чирканып куйды. Кеше-кара сизмәсен дигәндәй, янында беркем булмаса да, як-ягына каранып алды. Бүлмәдә кеше заты юк. Алар икәү генә: Камил дә сәгать кенә. Сәгать телләре «Ялгыша күрмә!», «Ялгыша күрмә!» дигәндәй, берөзлексез текелдәп, минутларны саный... эчке бүлмәдә газизләрдән газиз әнкәсе!!! Камилне үстергәндә, аңа җиңел булгандыр дисеңме? Башта тугыз ай карынында күтәреп йөрткән, еласа юаткан, төн йокыларын калдырып, бишектә тирбәткән; авызыннан өзеп, иң тәмле, иң татлы ризыкларны аңа биргән, чылаткан чүпрәкләрен юган... Һә-әй! Санап кына бетерерлекмени?!

Ә хәзер аның шул игелекләренә лач итеп төкереп, бик җиңел генә ахмаклар, акылы зәгыйфьләр йортына илтеп тапшыр инде, ә?! Ю-ук! Алай эшләсәң, юлда кайтканда ук үзеңне аяз көнне яшен сугар! Аллам сакласын! Ю-ук! Булмый! Камил үлсә дә алай эшли алмый! Эшләмәячәк тә! Ул бит Ана! Әнкәй! Сине бу якты дөньяга китергән, синең өчен ут йоткан бердәнбер изге зат!!!

...Камилгә өч-дүрт яшь булды микән, әтисе аны үзе белән алачыкка алып барды. Ул тимерче белән сөйләшкән арада шук малай алачыктан чыгып китте. Шулчак ул, бер як читтәрәк, балчык өеменнән сизелер-сизелмәс кенә төтен чыгып торганын күреп алды. Нәрсә бар икән анда? Читтән генә карап торып буламыни? Өемнең түбәсенә менеп карарга кирәк! Тиктормас малай менүен менде... Аягын нидер өтеп алгач, тыпырчынган иде, гөбердәп, ике аягы берьюлы күмер базына чумды! Әтисе аның ачыргаланып кычкыруына алачыктан йөгереп чыкканда, соң иде инде. Мизгел эчендә малайның тездән түбән аяк тиреләре куык кебек кабарып чыкты. Әтисе, аны күтәреп, якындагы Афзал буасына йөгерде. Улын яр буена утыртып, аякларын суга тыкты. Аннары, тиз генә үлән йолкып, Камилнең астына салды да: «Шунда гына утырып тор!» – дип китеп барды.

Улының аяклары пешкәнен ишетеп, әллә кайдагы Кызыл Саз басуыннан йөгереп кайта торгач, чәчәп беткән әнисенең кыяфәте Камилнең әле дә күз алдында...

...Әтисе үлгәч, әнисен кияүгә сорап килгәннәрен дә хәтерли әле Камил. Ярыйсы гына ыспай киенгән мыеклы абзый иде ул.

Ипле генә сөйләшеп утырганда, «кияү егете»:

– Малаеңны детдомга илтеп тапшырсаң да була инде, Хатирә. Анда ятим балаларны әйбәтләп тәрбиялиләр, укыталар, – дип куйган иде. Аннары, өлкәннәрнең сүзен шым гына тыңлап утырган сабыйга борылып. – Детдомга барасыңмы, улым? Анда балаларны тәмле-тәмле ризыклар белән сыйлыйлар, – дип, юмалап, башыннан сыйпап алганын да хәтерли әле Камил.

Улы турында, ятимнәр йорты турында сүз чыккач, әнисенең кыяфәте дә, сүз сөреше дә кискен генә үзгәргән иде.

– Сез ни сөйлисез, Фәтхерахман абзый? Нишләп мин бердәнбер улымны ятимнәр йортына тапшырыйм ди? Булмаганны! Мин нәрсә, бер бала да карап үстермәслекмени?

Ялгыз башына кыен булса да, шул чагында әнисе аны ятимнәр йортына илтмәгән, кияүгә дә чыкмаган. Ә хәзер, нәрсә, шушы әнисен акылы зәгыйфьләр йортына илтеп тапшырсынмы?!

Уйласаң, бәлки әле, әнисен рәнҗеткән, сүзен тыңламаган чаклары да булгандыр. Исән чагында аның бәхиллеген алып калырга кирәк.

...Малай чакта уенга һәвәс булды Камил. Әнисе иртән басуга киткәндә, аңа эш кушып калдыра, ә аның, малайлар белән уенга мавыгып, әнисе әйткәннәре онытыла. Исенә төшсә дә, ярар, малайлар белән тагын азрак уйныйм да кайтам дип күңеленә беркетеп куя. Юк! Көтелмәгән берәр хәл килеп чыга да аның уйларын челпәрәмә китерә.

Бу юлы да шулай килеп чыкты. Малайлар җәйге челләдә урамда уйнап туйгач, коенырга ындыр артындагы буага киттеләр. Өс-башларын чишенеп, суга кергәннәр генә иде, болыннан кайтып килүче Миргаяз абзый күпергә керде. Кулындагы ике җәпле таякка елан уралган. Гади тузбаш кына түгел, агулы кара елан. Гәүдәсенең бер өлеше таякка уралган, койрыгы асылынып торса да, як-якка боргалана: ычкынырга омтыла. Миргаяз абзый җәмки шикелле ике чатлы таягына еланның башын кыстырган: җибәрми! Буада

чупырдашкан малайлар, сайрак җиргә басып, тамаша кылырга тотындылар. Тамаша кылуга тиз арада кызыксыну да өстәлде:

– Миргаяз абый, ничек тоттың?

– Ничек эләктердең?

– Ничек чакмады?

Абзыйның әбәткә генә кайткан чагы. Малай-шалай белән сүз куертып торырга арасы юк. Ул кулындагы таягын еланы белән бергә тотты да буага ыргытты.

– Мәгез! Үзе белән сөйләшегез!

Күкрәктән суда басып торган малайлар, куркышып, як-якка сибелделәр. Күбесе тизрәк судан чыгарга ярга ыргылды. Арадан бер Габдрахман гына, нишләптер, каршы як ярга таба йөзәргә тотынды. Коры җирдә камчы кебек яткан елан суда батмады, гәүдәсен бик җайлы гына як-якка боргалап йөзеп китте! Юк, йөзеп түгел, су өстеннән шуып кына бара шайтан! Ул, тизрәк кая да булса качып котылу өченме, Миргаяз абзыйга үч итепме, Габдрахман артыннан куып китте! Ә Габдрахман әле буаның яртысына гына җиткән. Куркудан, каушаудан йөзүенең дә рәте-чираты юк. Куллары белән чәбәләнә, авызына кергән суны бертуктаусыз пошкыра. Болай булса, елан мескен Габдрахманны куып җитәчәк иде. Хәлнең мөшкеллеген абайлап, Миргаяз абзый да кире борылды. Киңәш биреп кычкырышкан малайларны аралап, кабат күпергә керде. Ирләрчә саллы тавыш белән малайга кычкырды.

– Курыкма, Габдрахман, курыкма! Елан куып җитә башласа, суга чум! Суга чум да кире борыл! Курыкма, кабат суга керми ул. Еланның да яшисе килә. Тизрәк ярга чыгып, кая да булса качасы килә. Мин әйткәнчә эшлә!

Шулай да Миргаяз абзый яр буендагы куактан пеше тал чыбыгы (елан өчен Газраил!) сындырып алды, тиз генә чишенеп тә ташлады. Аның тәне шалкан кебек ап-ак иде. (Арка кыздырып ятарга авыл кешесенең вакыты бармыни?) Безнең халык җор телле бит инде ул. Кешенең холык-фигыленә ятышлы яисә берәр кимчелегенә бәйле кушамат чәпи дә куя. Миргаяз абзыйга, шул тәненең аклыгына ишарәләптер инде, «Кыргаяк» кушаматы такканнар. Әмма ул бу минутларда һич кенә дә кыргаяк түгел, ә киек ауларга чыккан сунарчыны хәтерләтә иде. Ул тагын малайга кычкырды:

– Габдрахман, елан чакса да курыкма! Аның агуы синең тәнеңә эләкми, суга ага. Мин әйткәнчә эшлә!

Бар көчен җыеп йөзгән Габдрахман, елан аңа якынлашуга, тирә-якка су тамчылары чәчрәтеп, төпкә чумды. Абзый әйткәнчә, су астыннан кирегә борылды. Елан Габдрахманның башы судан калыкканын көтеп тормады – яр буендагы куаклар арасына кереп, күздән югалды.

Миргаяз абзый шуннан соң гына кулындагы чыбыгын читкә ыргытты. Курку катыш каушаудан хәлсезләнә башлаган Габдрахманны судан сөйрәп чыгаргач, үз юлына китеп барды.

Ул көнне малайларның авызында елан белән булган хәлләр иде.

Камил өйгә кайтып кергәндә, инде кич җиткән. Өйдә бернәрсә дә эшләнмәгән. Табак-савыт юылмаган. Кош-корт каралмаган. Әнисе иртән табакка салып калдырган бәрәңге дә әрчелмәгән килеш кояшта шиңеп ята иде. Эштән кайткан әнисе әле тегендә, әле монда чабып, хуҗалыктагы кичке эшләрне тәртипкә китереп бетергәч, улы Камилне каршысына утыртты. Кычкырмыйча, салмак-сабыр гына (шулай булса да ярыйсы ук үтемле итеп!) сөйләргә кереште:

– Улым, син үзеңнең малайлыктан чыгып килгәнеңне сизмисеңмени? Әтиең синең кебек чакта инде ат белән җир сукалаган, җир тырмалаган. Ә син һаман җил куып йөрисең. Безнең хуҗалыктагы эшләрне күрше кереп эшләмәс бит. Күпме әйтергә була сиңа. Колагыңа да элмисең: һаман уен да уен. Аның бер чиге булырга тиештер бит инде. Акыл утыртырга вакыт. Әгәр тагын бер тапкыр шулай кыланасың икән, урманга керәм дә югалам.

Шуннан соң ул, кайнаган чәен дә эчмичә, урынына барып ауды.

Әнисенең рәнҗү катыш инәлеп әйткән сүзләреннән соң гына, «Әнисез калсаң, нишләрсең? Кая барырсың?» кебек куркыныч уйлар Камилнең аңына барып иреште. Әтисез калса да, ул ятим булмады. Әнисе аны һәрчак җилдавылдан саклады. Әгәр ул да үлсә?! Аннары бит аны, чыннан да, ятимнәр йортына илтеп тапшырачаклар! Ю-ук! Ул анда мәңге дә аяк басмаячак!

Икенче көнне әнисе эштән кайтуга, каралты-кура ялт иткән иде инде...

Шушы вакыйга Камилнең исенә төшсә, әле дә тетрәндерә. Әнисе алдында үзен гаепле саный. Уйласаң, ата-ана алдындагы бурычыңны гомерең буе түләсәң дә, түләп бетерә торган түгел. Пәйгамбәребез дә оҗмахка юл – әниләрнең аяк астында, дип, юкка гына әйтмәгән. Исән чагында аның бәхиллеген алып калырга кирәк.

Күрше бүлмәдән әнисенең, нәрсәдер сорап булса кирәк, ыңгырашкан авазы ишетелде. Камил, кабаланып, ул яткан бүлмәгә кереп китте.

***

Кайчагында Камилнең күңелендә әгәр Миләүшә белән тормыш корган булсам, бәлки, бу хәлгә тарымас идем, дигән үкенү хисләре баш калкытып ала. Кем белә... Ә бәлки... Тик үткәнне кайтару – буш хыял гына шул. Ул турыда уйладың ни дә уйламадың ни!.. Ялгышны төзәтергә инде соң. Язмышны үзгәртү дә икеле. Күрәсең, бу аның тәкъдиредер...

***

Камил ике кулына ике сумка күтәреп кибеттән кайтып килә иде, көтмәгәндә аңа Миләүшә очрады. Гадәтенчә исәнләшергә дә китәргә иде исәбе. Әмма бүген Миләүшә аның юлына үзе аркылы төште.

– Тукта, Камил, тукта! Яулыкка йөгергән апалар кебек кая шулкадәр ашыгасың?

Камил эченнән генә, апалар хәленә калгач, нишлисең, йөгерәсең инде, дип сыкрап алды. Шулай да туктарга мәҗбүр булды. Сумкаларын җиргә куйды.

– Хатирә апаның хәле ничек соң? Әз генә булса да алга китеш юкмы?

Камил җиңелчә генә башын чайкап алды.

– Юк. Шул элеккечә инде. Ятып кына тора.

– Камил, бәлки сиңа берәр төрле ярдәм кирәктер? Кер юаргамы йә башкачамы? Тарсынып, уңайсызланып торма, әйт. Мин кереп ярдәмләшермен.

– Рәхмәт! Хатын-кыз эшенә өйрәнеп беттем инде мин. Керләнгән киемнәрне машинада гына юабыз бит хәзер. – Ул бер тын гына туктап алды. – Аннары, ни... киявең бик көнче, диләр. Безнең сөйләшеп торганны күрсә, сүзе булыр. Ярар, мин китим инде.

Миләүшә кайбер кешеләр сыман «юк, юк, гайбәт кенә ул» дип, акланып тормады, чарасыз калган кешедәй, кулларын җиңелчә генә як-якка җәеп алды.

– Нишләтәсең инде, ярып карарга кеше карбыз түгел шул. Өйләнешкәндә, күтәреп кенә йөртермен, өрмәгән җиргә дә утыртмам, дип ант иткән иде югыйсә.

Миләүшә үкенечле, теләсә кемгә сөйләргә ярамаган күңел серләрен нәкъ менә аңа чишкәч, Камил моңа кадәр битараф күзләрен Миләүшәгә төбәде һәм... хатынның күз төпләре күгәргәнен абайлап алды. Дөрес, ул сөрмә тартып аларны капларга тырышкан. Әмма иннек-кершән генә явызлык эзләрен яшереп бетерә алмаган. Әле бит аның зур гына предприятиенең бүлек җитәкчесе буларак кеше арасында йөрисе бар?!

Камил – тормышның ачысын-төчесен татыган кеше, ул белә: көнче ир белән гомер итүче хатыннарның күбесе балалары хакына иренең җәберләүләренә түзеп яши, түзәр хәле калмаса гына аерыла. Миләүшә шул икенең кайсын сайлар?

Камил ихтыярсыздан тагын беренче мәхәббәтенең күзләренә карады. Ул күзләрдән якты нур, әйтеп кенә аңлатып булмый торган җылы хисләр бөркелә иде... Камилнең күптән инде мондый – ихлас караш күргәне юк. Ир-ат дигәч тә... аның да йөрәге таш түгел. Ул да хатын-кызның җылы карашына мохтаҗ.

Миләүшә саубуллашканда тагын бер кат: «Камил, ярдәм кирәк булса, уңайсызланып торма, әйт», – дип өстәде.

***

Әнисен өч елга якын авырыксынмыйча тәрбияләгәннән соң булды бу көтелмәгән хәл.

...Камилне эшендә эшчеләр дә, җитәкчеләр дә яратты, хөрмәт итте. Аның бригадасы алдынгы булды, һәрчак телдән төшмәде. Советлар чоры булса, күчмә Кызыл Байрак озак еллар аларның бытовкасын бизәп торыр иде. Шулай булгач, традициягә кергән төзүчеләр көнен ничек бәйрәм итмисең инде? Алдынгы бригада ич! Эш сәгате беткән иде инде. Билгеле, алар кәттә ресторанга барып тормадылар, юлда очраган беренче «мәйханә»гә кереп тулдылар. Камилнең берничә эшчесе генә, «уважительный сәбәп» табып, өйләренә кайтып китте. Егетләр ипле генә сөйләшеп утырдылар: бригаданың оешу тарихын, вафат булган ветераннарны искә алдылар. Шулай матур гына таралышмакчы булып, сыраханәдән чыктылар. Арада «тәмәшникләр» була бит инде:

– Таралышканчы, әйдә, бер көйрәтеп алыйк әле, – дип, бер як читкәрәк чыгып басканнар гына иде, көтмәгәндә (сагалап торганнар диярсең), әллә каян гына әзмәвердәй биш-алты милиционер килеп чыкты. Арадан берсе:

– Әһә, пивнушка завсегдатайлары! Повеселились, да?! – дип, егетләргә бәйләнә дә башлады.

Төзүче егетләр, бу ни хәл, дип, ни әйтергә белми торган арада, төркем янына айныткыч машинасы килеп туктады. Шуны гына көтеп, әзерләнеп торганнар икән, милиционерлар эшчеләрне берәм-берәм төрткәләп, каршы торганнарның кулларына сугып, машинага кертеп тутырдылар.

– Сез нишлисез? Без бит – төзүчеләр! Бүген безнең бәйрәм! – дип, эшчеләрен яклап, арага кергән Камилне дә аяп тормадылар, кулларын каерып төрткәләделәр. Эшчеләрне яклап, нидер әйтеп калган агайга да эләкте.

– Абзый, күп сөйләшсәң, хәзер үзеңне дә алып китәбез!

– Ничек алып китәсез? Мин тамчы да аракы капкан кеше түгел. Егетләр дә буталып, болагайланып йөрмәделәр, сөйләшеп кенә тордылар.

– Кычкырып сөйләшәләр. Авызларыннан аракы исе килә. Тагын ни кирәк?

– Нәрсә, сөйләшергә дә ярамыймыни? Сталин заманы түгел ич.

Чандыр гәүдәле сержант, абзый янына якын килде дә, кызыл каймалы фуражка козырёгын, кисеп керердәй итеп, аның маңгаена терәп, елан ысылдаган шикелле, теш арасыннан берничә сүз сыгып чыгарды:

– Абзый, сез эштә план артыннан куасызмы? Куасыз. Безгә дә план үтәргә кирәк. Белдеңме? – Һәм саубуллашу билгесе итеп, агайның маңгаена чиртеп алды.

Әйкенче көнне... икенче көнне подъезд төбендә Камилне Сәфәргали абзасы көтеп тора иде.

– Нихәл, энекәш? Эшләр барамы?

– Бара гына түгел, чаба. Артыннан куып җитәр хәл юк.

– Алдынгы булгач, шулай тиештер инде ул. Төзүчеләр көне ничек, әйбәт үттеме?

– Әйбәтнең теге ягында булды... (Бригадабыз белән айныткычта булдык, димәс бит инде!)

– Мин дә элегрәк төзелештә эшләп алган кеше бит. Шул искә төште дә, тукта, мин әйтәм, энекәшне бәйрәмнәре белән котлап кайтыйм әле дип килдем.

– Рәхмәт!

Камил, абыйсының кыяфәтенә күз төшереп алу белән, килүенең сәбәбен аңлап алды.

– Сәфәргали абый, тукта, мин әнинең хәлен белеп чыгыйм инде. Аннан соң...

– Мин әле генә апаны карап чыктым. (Сәфәргалинең сәфәре ешайгач, Камил фатир ачкычының берсен аңа биргән иде.) Ул тыныч кына йоклап ята. Уятмыйк инде. Йокласын.

Абый кешенең сүзенә ничек ышанмыйсың?! Алдашкан, хәйләләгән, дип уеңа да китермисең... Камил кибеткә китте. Ял көн, бәйрәм көн булгач, кибеттә халык күп иде. Кассасына да су буе чират.

Подъезд төбендә түземсезләнеп, таптанып торган Сәфәргали (эскәмия буш югыйсә):

– Әллә заводына барып килдең инде. Озакладың! – дип, Камилне шелтәләп алды.

– Бер генә касса эшли. Ял көне югыйсә, – диде Камил, аңа каршы.

Ул, абыйсына кирәк «әҗәл даруы» – ике шешә шайтан суын, ризыклар белән тулы сумкасын кухняга илтеп куйды да тизрәк әнисе яткан бүлмәгә керде һәм... тораташ кебек катып калды! Бер кулы караваттан салынып төшкән, күзләре ярымйомык, авызы ачык халәттә әнисе тынсыз калган иде...

Әнисенә әзерләп киткән чәй шул килеш тора. Кайнаган су салган банка идәндә аунап ята. Суы идәнгә түгелгән. Әнисе, калтыраган куллары белән үрелгәндә, ялгыш аударганмы, кулыннан төшереп җибәргәнме – хәзер аны каян беләсең?..

Бүлмәгә Сәфәргали килеп керде. Ул бу хәлгә әллә ни борчылмады бугай. Камилнең әнисенең салынып төшкән кулларын күкрәгенә күтәреп куйганын, мәетнең өстен ак җәймә белән каплаганын тавышсыз гына күзәтеп торды. Аннары, нәрсәдер әйтергә әзерләнгәндәй, тамак кырып алды. Камил, абыйсы кайгы уртаклашып, нәрсәдер әйтмәкче бугай, сүз генә таба алмый, ахры, дип уйлап алды.

– Камил, энем... ни... апаның алтын алкалары, көмеш беләзекләре бар иде бугай. Хәзер алар аңа кирәк түгел бит инде...

Әнисен югалтудан тетрәнеп исәнгерәгән Камил, бер мизгелгә ни әйтергә белми, телсез калды.

– Ә?! Ни дидең?!

Бер урында таптанып торган Сәфәргали тагын телгә килде:

– Хатын-кызның бизәнү әйберләре сиңа да кирәк түгел бит инде...

Ничек кенә булмасын, моңа кадәр Камил Сәфәргалине (әнисенең бертуган энесе бит) һәрчак кунак итте. Бервакытта да караңгы чырай күрсәтмәде,

җәлләде. Әмма бүген аның сабыр савыты тулып ташты. Шулай да мәет өстендә кычкырырга, тавыш күтәрергә ярамаганын абайлап өлгерде.

– Бар, чыгып кит! – диде ул абыйсына, тыенкы гына.

Сәфәргали (әллә аңа әйттеләр, әллә бүтәнгә), берни булмагандай, каккан казык кебек, һаман бер урында басып тора бирде. Әле җитмәсә, бур кешедәй, астыртын гына, як-ягына каранып та алды. Аның бу кадәр сөмсез кыланышына ахыр чиктә Камилнең сабырлыгы тәмам төкәнде. Ул түзмәде, авызыннан аракы исе аңкып торган абзасын якасыннан эләктереп алды да, ачу белән, җилтерәтеп, ишектән төртеп чыгарды.

– Моннан соң эзең дә булмасын! Ишеттеңме? Тагын килсәң, баскычтан тәгәрәтәм!..

***

Без Камил белән «чәйханә»дә хәйран озак утырдык. Ул әнисенең кырыгын үткәрергә җыена. Әле һаман аны югалту кайгысыннан арына алмый интегә. Тора-тора да:

– Э-эх, үкенечкә калды. Соңгы минутларда әнием янында була алмадым, – дип, күкрәген төя.

Мин аны тынычландырырга тырышам. Ул инде байтак кына сыраның «башына җитте», һаман тынычлана алмый изалана.

– Э-эх, әнкәем, бәгърем! Ул, бәлки, бер йотым суга тилмереп яткандыр... Э-эх!..

Әнисен югалту кайгысына тора-бара сыра сөреме дә өстәлгәч, ул бөтенләй йомшарды. Кесәсеннән кулъяулык алып, күз яшьләрен сөртте.

– Э-эх, әнкәй! Әнкәй! Бәхиллеген дә ала алмадым. Ул, мөгаен, миңа рәнҗеп киткәндер. Абзыкаем, мине эт итеп сүк! Тукма! Бәлки, миңа җиңелрәк булыр...

Мин аны тагын тынычландырырга тырышам:

– Энем, син үзеңне алай артык битәрләмә инде. Син болай да әниеңне тәрбияләгәнсең. Кайбер сансызлар шикелле инвалидлар йортына да, акылга зәгыйфьләр йортына да тапшырмагансың. Ул сиңа рәнҗемәс.

Камил беразга тынычлангандай була.

– Абый, сез мине сыраханә корты – алкаш дип уйламагыз тагын. Мин монда шул янган йөрәгемнең ялкыны басылмасмы дип кенә кердем.

– Юк, энем, нишләп алай уйлыйм ди. Май чүлмәге тышыннан ук билгеле дигәндәй, синең тәртипле егет икәнлегең болай да күренеп тора, – дим, аннары сүзне икенчегә бормакчы булып өстим, – улыгыз белән очрашып торасызмы соң?

Мин уйлаганча түгел икән шул. Мин аның авырткан сөяленә басканмын икән. Камилнең кыяфәте тагын кырысланды.

– Лиана, мондагы фатирын сатып, Пермь якларына китте. – Ул йодрыгы белән җиңелчә генә өстәлгә сугып алды. – Ә мин улымны Пермьгә түгел, Каф тау артына алып китсәләр дә, барыбер эзләп табачакмын!

Без аның белән мәйханәдә күпме утырганбыздыр, хәтерләмим. Ахыр чиктә иске дуслар шикелле куллар биреп саубуллаштык. Ул үз юлына, мин үз юлыма китеп бардык.

***

Көннәр көзгә авышкач, без Камил белән тагын очраштык. Дөресрәге, ул үзе мине, башымны иеп, уйланып барган кешене, танып эндәште.

– Исәнмесез, абый! Әллә берәр кайгы килдеме, башыгызны иеп, уйланып барасыз?

Аның кәефе күтәренке, йөзе май кояшыдай балкый иде.

– Юк, килмәде. Кайгыны көтеп торган кеше юк әле монда. Килсә дә, качып калырга исәп. Болай гына уйланып бара идем. Гадәтем шулай. Җәмәгатем дә, башыңны күтәр, дип ачулана. Чир китә, гадәт кала, диләр бит. Ә мин һаман шул гадәтемнән арына алмыйм. Йә, энем, үзеңнең хәлләрең ничек соң?

– Әйбәт! Аллага шөкер, әйбәт. Әле шушы арада гына әнкәйне төшемдә күрдем бит, абый.

– Ничегрәк итеп күрдең соң әниеңне, энем?

– Нәрсәгәдер шатланган. Миңа ягымлы гына карап, нәрсәләрдер әйтте. Аркамнан сөйде. Уянгач, сүзләрен исемә төшерергә тырышып караган идем дә, булмады. Нәрсәгә юрарга микән?

– Яхшыга. Әйбәт төш күргәнсең бит, энем. Димәк, әниең сиңа рәнҗеми, бәхиллеген бирә. Авыр чакта аны каядыр илтеп ташламаган, тәрбияләгән улы булуына сөенә.

Камилнең май кояшыдай балкыган йөзе тагын да яктырды.

– Шулай дисең инде алайса, абый...

– Әйе, нәкъ шулай. Киләчәктә атнага бер тапкыр булса да догадан ташлама. Үзең укый белмәсәң, әниеңә атап, хәер бир.

– «Әлхәм» белән «колһуалла»ны гына беләм шул. Ә-ә, әнкәй өйрәткән «аятелкөрси»дә бар бит әле.

– Ихлас күңелдән укысаң, алары да әйбәт, энем, укы гына...

***

Күпмедер вакыттан соң без Камил белән янә бер тапкыр очраштык. Хәер, аны очрашу дип әйтеп тә булмый торгандыр. Ул сөйкемле генә бер хатын-кыз белән култыклашып бара. Егет шулкадәр сүзгә мавыккан иде, мине күрмәдеме, танымадымы – сәлам дә бирми үтеп китте. Мин аңа үпкәләмәдем, тамчы да рәнҗемәдем. Киресенчә, аларның пар аккошлардай атлауларына чиксез шат идем. Җырдагыча «җан яраткан, күңел тарткан» кешең белән генә шулай илегеп сөйләшеп була торгандыр. Камилгә сыена төшеп атлаучы ул ханым кем иде? Миләүшәме, башка берәүме?.. Анысы ул кадәр әһәмиятле дә түгелдер. Иң мөһиме: янәшәңдә сине ярты сүздән аңлый торган парың булу...

Аллаһы Тәгалә барча җан ияләрен дә парлы итеп яраткан. Шул исәптән Камилне дә...

Минем үз гомеремдә ялгыз канат кагып сәфәр чыккан торна да күргәнем юк. Аяз күктә алар һәрчак: «Тор-рыйк! Тор-рыйк! Бер-гә тор-рыйк!» – дип күмәкләшеп очалар. Оя корган, бала чыгарган җирләрен ташлап киткәнгәме, тавышлары гына бераз моңсу, ямансу...

**Редакциядән:**

*Бу айда каләмдәшебез үзенең юбилеен билгеләп үтә. Аңа исәнлек-саулык, иҗат уңышлары телибез.*



Мөхәммәт
Мирза

# САБЫРЛЫК СОРЫЙМ ЯЛВАРЫП...

***

*...12 октябрь төнендә*

**1**

Көн дә бер җөе сүтелә
Хыянәт төененең...
Ышанмастан ышанырсың
Кырын эше дүрт йөз елдан
Басып кергәч өеңне...

Биш гасыр битлек астында
Хыянәтченең бите...
Кушучлап җыйган карасын
Илем-ыруым өстенә
Бүген ул тагын сипте...

– Аһ, – дигәнче аяз күгем
Корымланып каралды...
Котылгысызлык хастасы
Кара елан угы булып
Бәгыремә кадалды...

**2**

Өметсезлек әрсезләнеп
Бәрә дә килә кереп...
Кулыңнан китә бар эшең...
Ул тора мыскыллап көлеп,
Син елыйсың үкереп.

Өметсезлек – ярты үлем,
Теләп-теләмәсәң дә
Күрә алмыйсың үзеңне,
Белә алмыйсың сәбәбен,
Көне-төне эзләсәң дә...

Мөхәммәт МИРЗА (1953) – *шагыйрь; «Киек каз юлында», «Тере су», «Адәм баласы», «Берүземә бер диңгез» һ.б. күпсанлы китаплар авторы. Татарстанның Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты. Казанда яши.*

Юлбасарлар, илбасарлар
Басып кергәч илемне,
Өйдә – илдәге уйнашка
Җанкаем яныпкөенде –
Иблис шашып сөенде...

**3**

Тарих – сәхнә, уен, имеш...
Чуалган мең мәртәбә...
Кемдер әйткән: «Сабыр итик,
Сабырсызлык – чыгынкы тай –
Сындырып тибә тәртәгә»...

Сабырлар итеп саргайдым,
Сарыдан якты кайгым...
Кемгә барып сарылсам да,
Юк бердәнбер юатучы –
Кемгә кирәк аһ-ваем...

Сабырлыкның чиксез чиге –
Шунда ди сары алтын?!
Алтын сарайлы чакларын,
Кодрәт-шөһрәтле чакларын
Саклый алмады халкым...

Сабырлык сорыйм ялварып,
Сәҗдәдә сорыйм оеп:
– Сынауларны бирдең мулдан,
Ярлыкагыл, – дип, – бер Ходам,
Барлык-берлегең тоеп...

* * *

*«Эфес каласы хәрабәләрендә»*

Меңьеллыклар аунап ята,
Тузанга батып...
Тарихы – төзәлмәс хата,
Узганга кайтып
Үкенүдән, үртәлүдән
Зыяны артык;
...Кан-яшькә коенган ташка
Җил елый ятып;
Ташларны өеп күтәргән
Субайлар ватык –
Хәрабәдәге хәлләргә
Битараф вакыт...

* * *

Килегез дә күрегез – торабыз ничек,
Яшәр өчен планнарны корабыз ничек...
Тапканыбыз тулаем «күченә» ничек –
Күрәләтә күргән күзне йомабыз ничек?

* * *

Язылганы – маңгаенда,
Укый белеп укысаң.
Дөньяны билəп алса да,
Илбасарга җир кысан...

Күклəрне билəп алса да,
Сулыш җитми – тарсына...
Дəгъва кыла комсыз кавем
Җир шарының барсына...

* * *

Сузылды яз,
Соңарды җəй...
Чигенмəде
Бер саплам да
Кыраулы көз –
Сызды йөзгə
Буразнасын;
Бəскə төрде
Төк-толымын;

Салмакланды
Адымнары –
Тəкъдиренə
Язган гомер
Фасылларын
кем дə булса
бер үзгəртə
аламы соң?

* * *

Сукмакны җəнлек тə сала,
Юлны – фəкать кеше.
Баланы җəнлек тə таба,
Шəхесне тик кеше...

Килəчəккə бар да бара,
Акыл тик кешедə...
Тик җəнлектəге самим хис
Ярлырак кешедə...

* * *

*Истанбул–Казан очкычы 1000 метр биектə...*

Синең дə бу мизгелдə
Түгелəме яшьлəрең?
Тоз йотып төшенерсең
Мəгънəсенə яшəүнең...
Белсəм дə Хак дөресен,
Фарыз бүген дəшмəвем...

Көтəсеңдер җавабым,
Өметең өзмисеңдер –
Зинһар, бимазаланма!
Иблиснең ялганыннан
Аклану эзлисеңдер –
Бу, ахыргы замана?!

Яшемə манып язам:
– Аһ, бу нинди бушану!..
– Амин! – дигəч, фəрештəң,
Иманыңа сыенып:
– Торып бас! – дип кушалу
Илһамланып һуш алу!..

## Адәм баласы

*Яңа бишьюллыклар*

* * *

Мәңгелек – чиксезлек,
Үлчәнми саннарда...
Адәм баласының
Санаулы сәгате
Чиксез гасырларда...

***

Яшәеш – вакытның
Мәгънәви асылы...
Адәм баласының
Туктаусыз яралып
Хак юлга басуы...

***

Залимлек – Иблиснең
Кодрәте – дәрманы...
Адәм баласының
Сакланганын саклар
Бер Хакның фәрманы...

***

Кышын яңгыр коя,
Әйтерсең, көз мәле...
Адәм баласының
Гел янәшәсендә
Гаҗәпләндергәне...

***

Зилзилә кубарды
Тау-тау дулкыннарны...
Адәм баласының,
Саламга тотынып,
Дога укынганы...

***

Чамасыннан узып,
Нәфесе азынган
Адәм баласының
Газаплар базыннан
Чыкмасы язылган.

***

Яратылышыннан
Ага да ага ул...
Адәм баласының
Язмышы ярына
Дулкынын кага ул...

***

Җиңгән гел җимереп,
Көчләгән, талаган...
Адәм баласының
Ганимәт малы да
Хәләлдән саналган...

***

Күл булганчы тамган,
Кыя-ташны ярган...
Адәм баласы үз
Тамчы хәлендә үк
Язмышына торган...

***

Очкыннан кабынып,
Бурасын ялмаган...
Адәм баласының
Йөз елдан янмаган
Курасы калмаган...

***

Арбасы җимерек,
Аты тугарылган...
Адәм баласының
Айныгач нияте –
Җәнҗал кубаруда...

***

Байның тук авызы
Ни әйтсә дә хаклы...
Адәм баласының
Ярлы ябагасы
Хуплауга яраклы...

***

Агымсу төбе – таш,
Күл төбе – ләм, үлән...
Адәм баласының
Төпсез күңле тоташ
Чиксез галәм белән...

***

Көндәшлек күршедән
Иртәрәк уята...
Адәм баласының
Калышмыйм дигәне
Кичтән үк соң ята...

***

Итагатьлелеге
Йөзенә язылган...
Адәм баласының
Бәйрәмдер һәр көне
Разыйга азыннан...

***

Җирлегә җир житми,
Маллының аз малы,
Адәм баласының
Матдәчелегендә
Нәфесе азганы...

***

Мәхкәмә ялчысы
Оран салды: «Басың!..
Адәм баласының
Тәкъдире камчысы
Яра сызды ярсып...

***

Ишек, тәрәзенә
Кадакланган такта...
Адәм баласының
Зимагурлыктасы
Кайгырмый бу хакта...

***

Бу дөнья бер бетә –
Кот чыгар кисәтү...
Адәм баласының
Башын комга тыгып
Качуда исәбе...

***

Җиһанда бер зат юк
Шикләнми тормаган:
Адәм баласының
Аңарга дигәнен
Көндәше урлаган...

***

Төптән күтәрелеп,
Биеккә үрелер...
Адәм баласының
Үргә менгәненә
Ерактан күренер.

***

Дәүләте, мөлкәте,
Йорты, биләмәсе...
Адәм баласының
Табып бәрәкәтен
Килә кинәнәсе...

***

Үзәгенә чапса,
Урталай ярыла.
Адәм баласының
Кулдаш балтасына
Көн дә эш табыла...

***

Еланнар туена
Юлыккан югалыр...
Адәм баласының
Җиде буынына
Риваяте калыр...

***

Хаклык – әйткәнендә,
Ваклык – кылганында.
Адәм баласының
Санлы саваплары
Ярлы калганында...

***

Комнан аркан ишеп,
Чүл корабын тарткан...
Адәм баласының
Табигать бер ишен
Хыялый яраткан...

***


Бай күзен май баскан...
Ярлы йөзе арык...
Адәм баласының
Шул хәлдәгеләре
Бер-берсеннән гарык...

***

Төшеменә күрә
Килешенер эше...
Адәм баласының
Эшсез вә төшемсез
Булыр гел бер ише...

***

Күкрәп килде дә
Бер таммыйча китте...
Адәм баласының
Гөлдәй иреннәре
Яргаланып кипте...



Альберт Хәсәнов

# ӨСТЕМДӘГЕ ЗАТЛЫ ҖИЛӘНЕМ...

ХИКӘЯ

Казаныбыздан көн кичке якка авышканрак мизгелдә чыгып киттем. Аттан төшсәм, арбага эләктем, дигәндәй, ашыгып, кабаланып, кичке бишләргә мин инде Саескан тавында идем. Бүген бит җомга көн, кичке якта кичүдә беркем булмас, дигән идем. Болытлар да куерып тора. Ашыкмаска, кабаланмаска соң, печән өсте җитте бит. Чалгы уйнатырга кул, уч төпләре кычыта торган чак. Ә Карабаш тугаенда мине әле чалгы белән бер тапкыр да кизәнмәгән ун гектар болын көтә. Кичүгә халык кара болыт булып җыйналган. Җитмәсә, Алексеевск ягына ташучы паромнарның да бүген берсе генә пыш-пыш килә. Гадәттә алар бишәү була торган иде. Халык та кичүдә болай җыйналмый иде. Елга порты ниндидер бәйрәм чараларымы, әллә өйрәнү-учениелармы үткәрә, диделәр. Пассажирларны тыз да быз ике якка ташып торучы паромнарның дүртесен шул чараларга алганнар икән. Анысы да аңлашыла.

Болытлар куерып торганда, көн кичке якка сәлам биргәндә, яр кырыена кара болыт булып җыйналган халыкның халәтен күз алдына китерү кемгә дә кыен түгел. Һәркемнең яңгырга кадәр, аяк асты коры чакта өенә кайтып керәсе килә. Халык гасабилана, бер дә юктан кабынып китәргә әзер. Әнә ике исерек бер-берсенең күлмәкләрен ертып якалашалар. Ә бу башта чегәннәр «спектакльләрен» әзерлиләр. Чегән диаспорасы әлеге «спектакльне», чыр-чу, шоу-бизнесны, бик оста корылган режиссура буенча башкарырга җыена бугай. Кайбер ачыгавызларның игътибарларын җәлеп итү максатында. Аларның бу трюклары миңа таныш. Бер тапкыр Казанда авыл хуҗалыгы алдынгыларының республика киңәшмәсендә булдык. Киңәшмәдән соң барыбызны да «Татар ашлары» ресторанына алып бардылар. Ресторанның икенче катында, дүрт-биш өстәлне берләштереп, чегәннәр төркеме туймы, мәҗлесме уздыра. Бер дә галәмәт чыр-чу, шау-шу. Хатын-кызлары, төрле яшьтәге бала-чагалары өстәлләр тирәли тыз да быз чабыша. Ресторанда алай кылану килешми дә. Әмма аларны кисәтүче кеше дә күренми. Чегәннәр исә ашап-эчеп, гитаралар чиртеп, җырлашып утырган җирдән кинәттән генә кызып, талашып киттеләр. Бу баштарак утырган кап-кара чәчле чегән егете, теге очта

---

Альберт ХӘСӘНОВ (1937) – *язучы, публицист; «Җәнбәт җәвере», «Бүре баласы Чатан», «Яратмый мөмкин түгел» һ.б. китаплар авторы. Рафаэль Төхвәтуллин, Саҗидә Сөләйманова исемендәге әдәби премияләр лауреаты. Әлмәт шәһәрендә яши.*

утырган егетнең йөзенә стакан белән чәй тондырды. Ачы гына сүгенеп куйды. Тегесе шунда ук өстәлгә менеп басты. Гармошка итеп бөкләгән йомшак хром итеге кунычыннан кояш нурларында ялт та йолт ялтырап торган зур гына пычагын тартып алды, йөзенә усал елмаю йөгертте. Пычагын учында шаярып-мазар гына ялт-йолт уйнатамы дип торсак, йөзен үзенә килешле куе кара сакал баскан чегән егетебез, пычагын бөтен залга ялтыратып, аңа чәйле стакан тондырган бәхетсез өстенә китте. Өстәлләр өстеннән. Ә залда утыручылар, сыннары катып, ни була соң инде бу, дип көткән арада, әлеге чегән, өстәлләр өстеннән лап-лоп атлап, стакан тондырган кардәше янына барып та җитте. Менә нинди тамаша. Килеп җитте дә үгез чалырлык пычагын теге бичараның корсагына тыгып та җибәрде. Каны тамып торган коралын, күлмәк итәгенә сөртеп, кире кунычына тыкты.

Зур киңәшмәдән соң гөр килеп гәпләшеп, ашап-эчеп, бал кабып, тәмләп чәй эчеп утырган зал бу тамашадан «аһ» итте. Күбесе йөрәген тотып, тизрәк нитроглицерин кабарга ашыктылар. Теге бичараның, пычак белән һөҗүмне алдан ук көткән төсле, күлмәк эченнән бөркелеп кан чыкты. Китте шау-шу, ах та вах, кычкырыш. Бар дөнья, җир йөзе үзенең бетмәс-төкәнмәс мәшәкатьләре, проблемалары белән чәнчелеп китсен шунда! Бар халыкның игътибары боларда, чегәннәрдә генә. Хәтта аскы каттан, раздевалкадан, ресторанга керүчеләрнең кием-салымнарын алып-биреп торучы пенсионер, һаман да акчага туймаган отставкадагы полковник-майор агайлар да бу тамашаны күрми калмаска, төркемнәре белән күтәрелгәннәр. Мондый тамаша, канкоеш, кул чабып сорасаң да дигәндәй, көн саен булып тормый.

– Милиция дәшәргә кирәк! «Ашыгыч ярдәм» машинасы! – дип кычкырдылар.

Чегән егетләре ул чакта бик талантлы режиссура сценариенә корылган «спектакльдә» уйнаганнар, халыкча әйтсәк, күз буганнар. Кул чабып, алкышлыйсы булган үзләрен. Пычак кадаганнан соң гөрләп кан акса да, чегәннәр милиция-мазар килгәнне, протоколлар төзегәнне көтмәделәр. «Канкоеш үзебезнең арада чыкты. Мы сами и разберёмся!» – дигән булып, бер-берсен ашыктырып, тиз генә чыгып сыздылар. Теге пычак кадалган егетнең дә күлмәк эчендә алдан ук канга охшаш сыеклык тутырган шешә булгандыр, мөгаен.

Чегәннәр куйган «спектакль»нең нәтиҗәсе шул: «Татар ашлары»на ашарга кергән ханымнарның бишәве шул мизгелдә кыйммәтле туннарыннан колак какканнар. Уникe ир – чәшке бүрекләреннән. Чөнки киемнәрне биреп-алып торучы агайлар да тамашачылар иде бит.

...Саескан тавы ярында халык бүген аеруча күп. Кичүдә дә чегән дуслар чираттагы тамашаларын куярга җыйналганнар иде төсле. Ныклап ызгышып китәргә өлгермәделәр. Югыйсә, халык ата – улны, ана кызны белми мәш килгән чак. Кичү сәхнәсе аларга бер дигән мәйдан иде. Тик ярга, пыш-пыш килеп, соңгы кораб-паром килде. Килде дә, киерелеп, бар көченә гудок бирде:

– Әйдәгез, хөрмәтлеләрем, барыгызны да палубага чакырам. Ашыга төшегез. Әле миннән төшкәч тә байтак кына кайтасыгыз бардыр. Көн кичкә авышып бара! – диюе булгандыр.

Чегәннәргә шул комачаулады, ахры. Халык, унтугызынчы гасырларда французларның Бастилия төрмәсен штурм белән алган кебек, баржага ыргылды.

Шунда, дебаркадерның бер ышыграк читендә, дөньяның асты-өскә килсә дә, исем китә бик, дип, бернигә катнашмый, шаккатмый, мин бу тормышта атаклы художник Крамскойның «Помпейның соңгы көне» картинасындагы хәлләрдән дә хәтәррәк хәлләрне күп күрдем, дигән кыяфәттә, шактый таушалган куе зәңгәр джинсасының ике тезе дә ертык, өстенә ковбойлар кия торган эре шакмаклы бумази күлмәк кигән, күп булса егерме-егерме бер яшьләр тирәсендәге бераз

сәер һәм серлерәк төсмерле бер егеткә игътибар иттем. Дөресрәге, күзем төште. Төшмәскә, әлеге егеттән бигрәк, аның янында, саф мәрмәрдән койган сын кебек, соры йонлы, гаҗәп сынлы овчарка утыра. Сын да сын, һәйкәл дә һәйкәл! Искиткеч күренеш. Мин үзем дә әүвәл-әүвәлтеннән, нәни бала чагымнан, эт-маэмай ыруы белән бер нәселдән. Аларның миндә Муйнак, Актүш, Акбай, Сарбай, Дүрткүз исемлеләре дә күп булды. Менә хәзер дә, аларны кайда күрсәм, очратсам да, нинди генә кызганыч шартларда булсалар да, сәлам бирәм, башларыннан сөеп узам, сыйпап, ипиле кулымны сузам.

Әлеге егетнең овчаркасы да прастуйлардан, урам маэмайларыннан гына түгел. Дворяннар кастасыннан булмагае! Беренче бәям – эт егете бик акыллылардан, интеллигент, эрудит затлардан булырга тиеш. Кеше телен, кирәкле командаларны аңлый, су кебек эчә булыр. Үзен-үзе тотышы да аристократларча. Кичүгә җыйналган халык арасында кайсылары аю кебек йонлач, бозау хәтле эре, ә гайреләренең тавык чукырлык та йоннары булмаган, уттай кызу җәй көне дә дер калтырап йөргән, өйдә асрашлы дворняшкалар да күренеп киткәли. Ә бу, мәрмәр сын, аларның ник берсенә борылып карасын. Аристократ!

Дебаркадерның такта идәнендә утыруын гына күр. Позасы – үз кадерен үзе бик белеп, горурланып утыручылардан. Безнең эрага чаклы 287-212 нче елларда яшәгән борынгы грекларның бөек галиме, катлаулы сызымнар өстендә озак баш ватканнан соң, ниһаять, өчпочмакның почмаклары квадратын исәпләп чыгаргач, «Эврика!» дип кычкырып җибәргән. Архимед агайныкы белән бер.

Хуҗа егет белән аның «мәрмәрдән койган сын»ы арасында сүзсез, кырыс әңгәмә бара. Анысын мин күреп сизәм. Алай да ни турында бәхәс тоталар икән алар?

Болар беркая да ашыкмыйлар, ахры. Халык, дебаркадер идәненә җәйгән чат шырпы калын такталарга абына-сөртенә, паромда үзләренә уңайлырак урын ала. Ә болар баскан урыннарында тора бирәләр. Кабалану исләрендә дә юк. Мондый чакта мин берәүгә дә сүз катмый узып китә алмыйм. Якынрак килдем, сүз катарга җыендым. Шунда егетнең артындагы стенада шактый эре хәрефләр белән язылган кәгазь кисәге күреп алдым. «Породистая овчарка Казбек. Три года. Срочно продаётся», – дип укыдым. Әһә-ә! Шуннан әлеге егеткә турыдан-туры сүз каттым. Колумб атлы булып чыкты ул егет. Геолог икән. Гади генә бер геологка мондый зур дәрәҗәле исем күбрәк түгелме, әй? Христофор Колумб – Америка материгын ачучы. Без аңа шуның белән бурычлы. Үзен кыю «диңгез бүресе» дип беләбез. Ярый, ярый, бу исемне син дә горурлык белән йөрт.

– Сколько же просишь, так сказать, за своего учёного пса, то-бишь волкодава? – дидем, тамагымны кырып.

– Вы правы, Казбек наш в самом деле с академическим образованием, очень умная служебная собака. Человеческую речь с полуслова понимает. Очень сложные команды легко выполняет. А на счёт цены... – Егет берара уйланып торды. – Тут ведь не рынок. Торговаться не будешь. Да и некогда, спешу я. Сколько дадите, как говорится, сколько не жаль. Казбек, мой пёс, очень добрый, рассудительный. Общение с ним – одна радость, одно удовольствие.

– Я вижу... – дидем мин.

Безнең үз өебездә дә тугры хезмәте өчен Чекист кушаматы алган Сарбай исемле дворняшкабыз бар. Бик яратабыз үзен. Өебезне дә бик тырышып саклый. Ишегалдыбызга күрше тавыкларын да кертми, аяк та бастырмый. Маэмай түгел, табыш! Әмма үземнең, һич югында, фасон өчен, дус-иш арасында бераз тәкәбберләнү өчен дигәндәй, Бөекбритания лордлары төсле, классик нәселле

күркәмрәк маэмай, җитәкләп түгел инде, ияртеп йөрисем килә. Для понта, для фарса, рус интеллигентлары әйтмешли. Ике тез башы ертык джинсалы егет Колумбның бу бурзае миңа бер күз ташлау белән ошады. Маэмай миңа да үз итеп, хәтта ышаныч белән карый төсле. Әллә шулай тоела гынамы?

– За сколько же рублей оцениваешь голубчика, спрашиваешь?

– Да здесь не базар. Дай сто-о... сто пятьдесят! И дело с концом, получай товар!

– Сто пятьдеся-ят! Я не ослышался? – Мине җиңелчә очкылык тотып алды. – Хәзер бит базарда каз канаты да биш йөз тәңкәләр. Чынлап, ялгыш ишетмәдемме? Чәнчә бармагымны тыгып, уң колак тишегемне кашып куйдым. Мондый затлы маэмайлар, мондый овчаркалар! Иң түбән бәядән исәп-хисап йөрткәндә дә, кыш кышлаган тана бәясе, кимендә дүрт-биш мең торалар. Артыграк булмаса әле.

– В чём дело? Бик арзан сорыйсың түгелме? – дидем. Хәтта сәеррәк, шөбһәгә тарта. «Акылыңдамы соң син?» – дип, чүт сорамадым. Килешмәс, дидем.

– Үзем дә бик беләм. Кичүгә инде өченче көн чыгам. Йөз илле сумга да алучы юк. Урыны ул түгелме? Ә мин иртәгә Ерак Себергә, экспедициягә очам. Геолог мин. Калдырыр кешем юк. «Мин сине бик яратудан гына суям бит, кәҗәкәем», була инде. – Егет йөзенә җиңелчә генә көлемсерәү йөгертте. – Ничего не поделаешь.

Ә Казбек арт аякларына утырган хәлдә миңа төбәлгән. Утырып торуы ук килешле. «Ал мине, агай, ал! Мин сиңа тугры хезмәт итәрмен.Үкенмәссең!» – дия төсле. Авыз тутырып әйткән дә булыр иде, теле юк бит бичараның. Мин дә үземне, мондый малны кулдан ычкындырырга ярамый, дип кисәтеп куйдым. Тәвәккәллә!

Кесәмнән мең тәңкәлек чыгардым.

– Йөз иллесе маэмаеңа үзең куйган бәя. Калганы сиңа премиальный булсын. Бигайбә!

Мондый чибәр эт егетеңне әтәч, песиләр бәясенә генә ала алмыйм. Минем аны муенчагыннан тотып йә янымда йөртеп, кеше, дус-иш арасында да күренәсем бар.

Казбекның күзләрендә: «Ай, маладис та, егет икәнсең, агаем!» – дигән шатлыклы очкыннар күрдем. «Кая, бер кочаклыйм әле үзеңне!» – дигән сыман, миңа тартылып куйды.

Ә хуҗа егетнең – Колумбның әллә ни исе китмәде. Мин биргән акчаны йәлт кенә йомарлап, шакмаклы ковбойкасының түш кесәсенә тыкты. Алай гына да түгел. Егет бераз сәеррәк, хәтта шиклерәк тә кыландымы? Кичү мәйданыннан тизрәк сызу, ычкыну ягын карады. Минем белән дә, аристократ Казбек белән дә кая ул җылы саубуллашу, җылы аерылышу? Китте дә югалды. «Бу агай уеннан кире кайтмасын, овчарканы миңа кире кайтармасын тагы», дип шикләндеме? Аптырагански.

Паромга төялгәч бушап калган Кичү мәйданында без Казбек белән икәү генә. Күзгә-күз карашып, тын гына торабыз. Ул арада баржабыз кузгалырга өченче гудогын бирде. Мин, Казбекны җитәкләп, шунда ашыктым.

Баржа палубасы пассажирлар белән инкубатордагы чебешләр кебек шыгрым тулы. Агымга каршы йөзеп, Чистай пристанена кичке сигезләрдә генә килеп җиттек. Бу вакытта безнең Чияле тауга машина, автобус-мазар туры килүе турында уйлыйсы да юк. Кунарга туры киләчәк. Йоклап чыгарга урын, кунакханә-мазар эзләп киттек. Казбек, акыллы баш, мине шунда ук үзенең хуҗасы итеп таныды. Туктап-туктап, аны башыннан сыйпап, сөеп алам. Мин – тормыш дигән иксез-чиксез диңгезнең кайчакны авызга алмаслык ачы катыкларын байтак авыз иткән,

татыган, ак сакаллы ук булмасам да, башыма ир-егет халкын бизәүче көмеш чал кергән чәчле агай. Педучилищедагы студентларга математика укытучы хатыным, берсе икенчесен куып үсеп килгән гүзәлләрнең гүзәле – өч кызымлы гаилә атасы!

Кама аша Саескан тавы кичүендә искиткеч оста режиссурага корылган «спектаклен» «Геолог» бик оста башкарды. Ул соңыннан дебаркадердан этешә-төртешә паром штурмлаган чегәннәр арасында күзгә чалынды. Чалынса да, Казбек аңа тартылмады. Ә минем – үз сөенечем. Мондый акыллы, күндәм маэмайның йөгәнен үз кулымда тотудан мин бик шат идем. Шушындый абруйлы, күрер күзгә дә сөйкемле овчарканы ияртеп, дус-ишләрем, күргән-белгәннәр арасында күренү минем күптәнге хыялым иде.

Чистай хәтле зур шәһәрдә анысы, кунар җир табарбыз да. Паспортсыз-нисез, бернинди документ-белешмәләрсез, бозау хәтле маэмай белән безне кунарга, йоклап чыгарга кертерләрме? Ул уй башыма хәзер генә килде. Урнаша алмасак, басуга чыгып, берәр печән кибәне төбендә кунарбыз. Көнаралаш явым-төшем булып торса да, җәй уртасы бит әле. Салкын булса, Казбекны кочаклап кунармын.

– Ризамы, дустым? – дим.

Сүземне аңлап, Казбек башын селки.

Ул арада Чистайның үзәк урамнарының берсендә маңгаена «Гостиница» дип язылган бер катлы төзек бина каршында туктадык. Эчкә уздык. Өстәл артында урта яшьләрдәге, ак чәчле, яшь чагындагы чибәрлеген җуймаган бер ханым утыра. Гозеремне белгәч:

– Что сез! Бездә ул якка бик строго! Сезне кертә, урнаштыра алмыйм, – диде. – Буш бүлмәләр дә юк.

Бездә, Рәсәйдә, элек тә булганнар, хәзер дә бар алар – адәм баласына кым-кырыс килгән чакларда, көтмәгәндә, миһербанлы кулларын суза торган тётя Нюралар, Нәсимә абыстайлар. Рәсәйне шулар аякта тота, шулар! Сау, исән-имин генә яшәсеннәр! Әлеге гостиницаның да түрендә, караңгырак почмагында, бер апай чиләк-швабралар белән дөбер-шатыр килә, җыештырып маташа иде, ахры. Администратор ханымның мине боруын ул да ишетеп торгандыр.

– Паром шулай соң килдемени? Бик соңга калгансыз бит, апайларым, – диде ул, бөтен интонациясе, безгә җылы мөгамәләдә дәшүе белән хәлебезне аңлавын күрсәтеп. – Сәгать тугызынчы. Җитмәсә сез икәү.

– Икәү шул, – дидем. – Юлдашымның документлары да юк. Алырга өлгермәдек.

– Хәзер кая барасыз инде? – Әлеге апай юеш чүпрәкләрен сыга төште. – Беркая да китмәгез. Минем тирәдәрәк булыгыз. Надежда Ивановна тугыз тулгач китә ул. Буш бүлмәләре дә бар. Райком секретарьләренә дигән бүлмәләре һәрчак буш. Үзем җыештырып торам бит. Шунда урнаштырырмын. Әнә, бурзаеңның да йокысы килә бугай, күзен ачып-йомып утыра. Рәхәтләнеп, байлар номерында кунарсыз.

Бу мәрхәмәтле ханымның исеме Сәрия апай икән. Рәхмәтләр яугыры үзенә. Аның әйткән сүзе дә аткан ук булып чыкты. Администратор ханым китү белән, ул безне, җилтерәтеп, райкомның беренче секретаре урнаша торган элитный номерга урнаштырды. Әй, киң күңелле дә икән бу Сәрия апа, җаныем!

– Юл йөргән кешеләрнең тамагы һәрчак бүре йотарлык ач була. Сез дә кыстатып торучылардан түгелдер. Номердагы «Мир» суыткычын да чистарта төшегез. Аны барыбер көнаралаш чистартып, яңа продухтылар белән тутырып торалар, – диде мәрхәмәтле апабыз.

Ачып карасак, анда ни генә юк: колбаса, тәмле балык уылдыклары, шоколад конфетлар. Мин дә, Казбек та туйганчы сыйландык. Шулай итеп, беренче секретарь бүлмәсендә Казан байларыча киерелеп йоклап чыктык. Мин – ике кешелек киң караватта, Казбек – йомшак диванда.

Иртән-иртүк өстемдәге юрганны Казбек килеп тартты. Вакытында аякта булып, үзебезнең Чияле тауга юл алдык. Мәшәкатьләрсез кайтып җиттек. Өйдәгеләрем юлдашымны килештереп кабул иттеләр. Нәселле берәр овчаркалы булырга теләгемне алар да белә, күптәннән хуплый иделәр. Капкадан керешкә:

«Кемне ияртеп кайттың? Кемгә хаҗәт бу килбәтсез нәрсә?» – дип, Чекист кына зур тавыш куптарганые да, «Тсс, Сарбай! Күпне күрмә!» – дип, бармак янагач, ул да тынды.

Ашагач-эчкәч, бөтен өй эчебез белән күлгә төшеп, коенып мендек. Монда да Казбек үзенең укымышлы, тәрбияле зат булуынраслады. Күлгә аягын да тыкмады. Ул һәркайсыбызның кием-салымнарын саклап утырды.

Коенып менгәч, былтыргы бик суык кыштан бераз чирләбрәк утырган әнис алмасы төбенә, бер төзек кенә оя урнаштырып, Казбекны чылбырга утырттым. Шунсыз ярамый. Күнегә торсын.

– Бездә шундый тәртип, – дидем. – Ишегалдын иңләп, эленке-салынкы, шалтай-балтай йөрү юк. Безнең хуҗалыкта үзеңне ничегрәк тоту тәртибен әнә Чекисттан сораштыр, өйрән. Ә хәзергә дворец-сараең шушы булыр!

Ә маэмаем йөзеннән, тәэсирле күзләреннән:

«Хуҗам! Мин барыннан да бик канәгать! Мине ияртеп кайтуыңа, җылы почмак бирүеңә дә бик шат, бик рәхмәтле!» – дигән сүзләрне укыдым.

Маэмайларның кайберләре кешеләрдән күп акыллы була. Сизгерлек дигән нәрсәне, зиһен, хәтерне, ис сизүне Тәңребез аларга кешеләргә караганда бермә-бер күбрәк биргән. Аларның сизгерлеге, хуҗаларына карата тугрылыгы искитмәле.

...Дөньяда бер ата көнче, тик үзен генә яратучы, беренче күрешкә күл балыгы кәрәкә төсле ваемсызрак, әмма бик тырыш Сарбаебыз янына кече кызыбыз Майшикәр:

– Әтием, һич көтмәгәндә генә нинди хәзинәгә юлыктым. Шулчаклы мәхәббәтле җан! – дип, өстенә карарга чиркангыч, шапшак, пычрак, чамадан, чиктәш тыш укмашкан, киезләнгән көрән йон баскан Кара Әхмәтне күтәреп кайтты. Моңа кадәр дә адашкан, ятим көчекләрне күп ташыды инде ул. Берләре ишегалдыбызда калдылар, икенчеләре, ашаткач, бераз хәл алгач, каядыр чыгып югалдылар.

Кызым Майшикәр кош-корт, өй тирәсе җанварларын бик ярата.

– Әтием, безгә туган як табигате бүләк иткән бу искиткеч затны – маэмай баласын җиде юл чатында ничек күрми узып китәсең? Чүт кенә машина астына кермәде. Алар тыз да быз узып кына торалар. Чүт таптап китмәделәр. Ишегалдыбыз киң, урын җитәрлек. Беразга яшәп торсын, – ди.

Аның һәрчак шулай инде. Кемне эләктерә, шуны күтәрә дә китерә.

Маэмай коточкыч ямьсез булса да, аңарда бераз гына юмор хисе дә бар төсле. Үзенең «Чаян» журналына язып чыгарлык килешсез кыяфәтенә – ноль внимания! Авызын чәп-чәп ачып япкалап, төчкергәләп, кашларын сикерткәләп, безне дә көлдермәк була.

Юантык тәпиләре генә түгел, хәтта корсак аслары да мулдан чат йон. Җирдән сөйрәлә. Урамдагы бар чүп-чарны, нефть-мазут, дегет тапларын җыештырып, сөртеп йөргәндер. Маэмай заты булып, кеше-карага, ят кешеләргә «Ау-ау!» – дип өрү юк та юк. Хәтта алардан ояламы, шүрли-куркамы? Болай үзе шушы кыяфәте белән дә килеп сыенырга, иркәләнергә дә каршы түгел.

Дүрт тәпиенең һәркайсы аю табаннары хәтле калын. Баскан җиренә, монда эзем калсын дип, бик ышанычлы баса. Эзләренең һәрберсе – Арча чабатасы эзләре хәтле. Әйе, бер дә тарсынып һәм тартынып басмый. Бу гадәтен каян алгандыр, кемнән йоктыргандыр – аралашкан, кулга алган чакта мут кына сул күзен кысып-кысып куя. Безгә шаркылдарга шул да җитә. Үзебез: «Бу мәхлук җанны, бер дә кирәге булмаса, Хак Тәгаләбез яратмаган, тудырмаган булыр иде», – дибез. Рас яраткан, җир йөзен бизәгән мәхлугыбыз Кара Әхмәт игътибарга һәм ихтирамга лаек җан дип, гаиләбез белән кабул иттек.

Менә шулар арасына, ата көнче, интриган Сарбай, май-мазутка баткан Кара Әхмәт янына, античный дөньяның күренекле фәлсәфәчесе Демокрит агай төсле, башы тирән уйларга бай төсмерле Казбекны алып кайттым.

Ишегалды егетләребез яңа кунакны дәррәү кул чабып каршы алмадылар, әлбәттә. Бигрәк тә ишегалдыбызда бар нәрсәгә күз-колак булып торган, үзен төп хуҗа итеп санаган Сарбай. Беренче көннәрне үк вак интригаларны оештырырга маташты. Аңа башында мыскал да үз уй-фикере булмаган Кара Әхмәт тә кушылды.

Казбек Сарбайдан дүрт-биш тапкырга гәүдәлерәк. Буй-сыны да килешлерәк. Кыяфәтне әйткән дә юк. Йөзе, күз карашлары, әйтәм бит, борынгы грек фәлсәфәчесе Демокритныкы. Сарбай алай да:

– Хуҗам, бу имгәкне ни дип кенә ияртеп кайттың инде? – дип, бөтен ишегалдына сукранып йөрде. Саф нәселле, тирән эрудицияле овчарка имгәк буласы, имеш. «Телеңне тый! Үзеңне бел. Атаң-анаң кемнәр икәнне белмисең. Шып бул!» – дип кисәттем мин Сарбай Чекистны.

Әллә этләр-маэмайларда, Сарбайда алдан күрү сәләте бармы? Сарбаебыз әллә ата көнчелеген тыя алмаган хисләрдән генә Казбекны күралмый ябырыламы?

– Тыныч булсана! – дим үземә. Кемнең хаклы булуын, кемнең ялгышуын алдагы тормыш үзе күрсәтер.

Ә Кара Әхмәтнең ишегалдына интеллигент овчаркалар гына түгел, арыслан, юлбарыс, хәтта жираф җитәкләп кайтсаң да исе китә бик. Ул үзенең ыстырам көлке кыяфәте белән дә җирдәге тере җаннарны исәпкә куя торган шүрлектә үзенә аерым урын биләве белән бик канәгать. Бу биеклек – аның өчен күк йөзендә җайга гына йөзгән иң биектәге болытларның табаннарын 8864 метрдан кытыклаучы, җир шарының иң биек ноктасы Эверест! Ул үз этикеты белән яши. Ашарга биргәндә дә, ачкүз булып ташланмый. Тәлинкәгә әдәп, итагать белән сузыла. Аягына ябышкан чүп-чарлардан уңайсызлана. Үзенең бар җитешмәгән якларына юмор белән, маэмайларча елмаеп карый.

Менә Казбек үзен ничегрәк тотар инде. Минем бу нәселле эт егете белән дусишләрем арасында, чыннан да, бераз гына мактанырга, хәтта тәкәбберләнергә дә исәбем бар. Халыкта «Тәкәбберлек – май басудан да харап!» – дисәләр дә. Кеше холык-фигылендә, бер тора торгач, андый яклар да калкып куя икән ул. Мин дә үземдә шундыйрак халәт сизә башладым. Хәтта масаю халәте. Мондый овчарка миндә генә бар, ә сездә юк, күрегез, көнләшегез, дигән.

Мине бит Карабаш болынында чалгы чыжлатмаган ун гектар печән көтә. Кояш та иртәдән кичкә кадәр елмайган җылы җәй булгач, яңгырлар да вакытында явып торгач, быел печән аеруча калын. Чабып, җыеп, кибәнгә куеп кына өлгер. Үткән атнада Казбекны да алып, күп сынауларга бирешмәгән «Жигули»ем белән, печәнгә төштек. Ун гектар мәйданны берүзең генә чабып чыгышлы түгел. Посёлокның үзеннән дүрт-биш егетне ялладым. Бер атна дигәндә болынның печәнен чабып, җилләтеп, кибәннәргә куеп чыктык. Көннәр булса, ишегалдына кайтарып аударасы гына калды.

Печәнгә Казбекны да алып бик дөрес эшләгәнмен. Печән өстендә бер-береңнең чапкан печәнен берәр йөк чәлдереп китү печәнчеләр арасында зур җинаятькә саналмый. Андый гына «шаярулар» еш булгалый. Печәнчеләр аны егетлеккә генә саныйлар. Ә үзең Карабаш болынына зурдан кубып печәнгә төшкәнсең икән, аны саклый да бел.

Карабаш егетләре кунарга өйләренә кайтып киткән кичләрне печәнне Казбек белән икәү сакладык. Печәнне чәлдерергә ник берәү килсен. Ә көндезләрен, тамак бик кипкән чакларны, Казбекны Чияле тауга салкын квас, әйрән алып килергә җибәрәм. Аркасына бәйләгән сумкасына литр ярымлы термос асып, чи йомыркалар, өчпочмаклар, кыстыбыйлар, башка ризыклар да төяп, сәгать ярымнарда әйләнеп килеп тә җитә өлгеребез. Чияле тау белән Карабаш арасы турыдан гына да унбиш чакрымнар. Аның тиз йөрүенә:

– Казбек дус, әллә инде син ракета тизлеге белән йөрисең? – дип гаҗәпләнәбез. Ә Казбек палатка алдына килеп сузылып ята да, акыллы кыяфәттә, безнең мактаганны тыңлый.

Печәннәрне уңышлы тәмамлап кайткан тын кичләрнең берсендә маэмаебыз нигәдер борчыла, муенына таккан чылбырны да килештерми, ыргыла башлады. Дулый, кабалана, чәбәләнә.

– Чү! Нишләвең бу, Казбек? – дип, бармак янадым. – Килешмәгәнне! Себерке сабы белән берне сыптырырга да күп алмам. Тынычланмасаң.

Чүт кенә тынып тора да тагын ыргыла башлый.

– Әллә берәр ярамаган әйбер каптыңмы? – дим.

Ә ул минем борчылып, аны сөеп, иркәләп сөйләвемне колагына да элми. Аптыраш. Үзен кая куярга белмәгәндәй, борчыла, бичара, бәйдән ычкынмак була. Болай булгач, мин аны чылбырына тагын да ныграк беркеттем. Ычкына калса, аның башында нинди уй-ният барын кем белә? Борчылыр-борчылыр да басылыр, тынычланыр, дип көттек. Ә таң алдыннан Казбегыбыз вак-вак итеп туктаусыз өрә, улап үкерә үк башлады. Бу ни хәл бу? Кисәтеп, бармак янавыма да игътибар итми. Бертуктаусыз ыргыла, чылбырын каермакчы, өзмәкче, ычкынмакчы була. Әллә, мин әйтәм, иректә йөрисе киләме? Күршебездә бала-чагасыз, хатыны белән икесе генә яшәүче прокурор Кашаповлар тора. Алар бик затлы, нәселле Принцесса исемле ана эт тоталар. Прокурорның хатыны Зөлхәбирә ханым ике сүзнең берсендә «Принцесса, Принцессам», дип кенә тора. Әллә, мин әйтәм, безнең Казбегыбызның күзе күршебез Принцессага төшкәнме? Алар арасында кайнар мәхәббәт туганмы? Әллә Казбек, тәэсирле җан, элекке хуҗасын – Колумб исемле егетне өзелеп сагынамы? Тукта, чү! Шунын янына качмакчы буламы?

Малкайны берничек тә тынычландырып булмады, ул шатырдатып чылбырын чәйни. Мин аны үгезләр бәйли торган бик таза чылбырга утырткан идем. Бөтен тешләрен сындырып бетерә бугай инде. Миңа да төпле генә карарга килергә кирәк. Аптырагач, тоттым да ычкындырдым моны бәеннән, чылбырдан.

– Бар, алайса, гүләй! Ычкындырам үзеңне, иректә ни эшләрсең икән? Берәрсен очраклы гына да өркетә күрмә. Соңыннан тавышы зур булачак, – дидем. Кая ул миңа җавап биреп торулар! Ычкындыруга, бәйдән котылуга, урам капкасын ачканны да көтеп тормады. Урам якка биек койма аша гына сикерде. Сикерде дә юк булды. Кичен дә кайтмады малым. Ике-өч көннән соң да күренмәде. Ишегалдындагы Сарбаебыз – Чекист кына ирония белән елмаеп йөри. Шундыйрак ул, төртке сүзлерәк. Ата көнче!

– Казбек белән бер дә галәмәт яратышасыз иде. Бар маэмай халкы

көнләшерлек мәхәббәтегез момент юкка чыкты. Казбекның духы да күренми, ау-ау, эһем-эһем.

Мин, чыннан да, «егетем» элекке хуҗасына качты, ахры, дип тора идем инде. Башкача кая булыр, кая йөри? Хәбәрне күрше малайлары Нурислам белән Володя китерделәр:

– Сезнең Казбегыгыз сыра чөмерергә ярата икән бит! Белми идегезмени? Ул шунда, «Голубой Дунай» сыраханәсендә. Сыра шупыра. Барып алыгыз. Үзебез тотып китермәкче идек тә, аягын да атламый, карыша, ачулы ырылдый гына.

Чыгып югалуына атна узды бит инде. Мин чыктым да Чияле тау шәһәрчегебезнең теге баштарак урнашкан «Голубой Дунай» сыраханәсенә йөгердем. Барып керсәмме, ни күрәм! Казбегым арт аякларына баскан. Өстен мәрмәр белән япкан, сыраханәләр өчен махсус чыгарылган, өч аяклы шактый биек өстәлләрнең берсенә алгы аякларын хуҗаларча куйган. Андагы разношёрстный контингент белән гамьсез сыра чөмереп тора. Оялмый, нахал. Тулы хокуклы үз кеше бу! Сыра чөмерүчеләр шунда сүз арасында Казбекка «Ят!», «Утыр!», «Шуыш!», «Бир бишне!» дигән төрле командалар бирәләр. Ә бу, бичара, аларны берсүзсез үтәп, башкарып тора. Тегеләре шуннан зур тәм табып, гөр килеп, кул чабып көлешәләр. «Ай, маладис!» – дип, Казбекның башыннан сыйпап алалар. Сыра кружкасына кушып, «Российская», «Крепкая»ны да тамызгалаганнар, ахры. Казбек мескенемнең ләх исерек хәлендә идәндә аунап яткан чакларын да күрүчеләр булган. Казбек менә хәзер дә, ни кушсалар, шуны үтәп тора. Чөнки үзен дә «сыйлыйлар» бит. Дөм-исерек хәлендә ул тагын да көлкелерәк буладыр. Мондагы халыкка нәкъ шул гына кирәк тә. Абау, җанашым, нәселле овчаркам Казбек чын алкоголик икән бит. Теге чакта Саескан тавы кичүендә кыршылган джинсалы, Колумб атлы «геолог» егет аны миңа тавык бәясе генә хакка бер дә юкка гына төртмәгән! Киткән чакта хәтта саубуллашмады да, тизрәк олагырга ашыкты. Казбекны кире кайтара күрмәсен дип шикләнгәндер.

Сыраханәгә килеп керү белән, мин:

– Казбек! Бу синме, балакаем? – дидем.

Маэмаем, ярымябык озын керфекләрен күтәреп:

– Э-э, хуҗам, синме? – дип җавап кайтарды, җиңелчә генә ырылдап куйды. – Менә шулай, хуҗам. Мин – беткән зат, законченный алкоголик. Син мине бусагаңнан да атлатмассың инде. Мин синең дәрәҗәңне төшерәм. Син бит кешеләр җәмгыятендә дәрәҗәле агай. Язучы! Безнең турыда, эт-хайваннар, кош-корт, өй-йорт маллары, кыргый җанварлар турында күп китаплар язгансың. Безне яратып һәм сөеп, укучыларыңны да яратырга, сөяргә өндәп. Тагын да язарсың әле.

Мин – конченый маэмай. Бала чагымда мин дә бик тере, туп кебек түгәрәк көчек идем. Колумблар гаиләсе мине питомниктан, көчекләр интернатыннан ике айлык чагымда сатып алганнарые. Мин яхшы, бай гаиләгә эләктем. Аңа сөенеп туя алмыйм. Өстенә ак җәймә җәйгән йомшак күн диванда гына йоклап үстем. Ашарга дигән ризыкларны фарфор тәлинкәләргә салып кына бирәләрие. Мине барысы да яраталар, кулга алып сөяләр, уйныйларые. Колумбның әтисе Христофор агай да бик яхшы кеше иде. Миңа, ашаганда, тәлинкәмә ике-өч тамчы гына «Русская водка» тамызалар. Мин шуннан әз генә исереп калгандай булам, барган җирдән авып-түнеп тә киткәлим. Аларга бу бик кызык, көлке тоела. Тора-бара мин бөтенләй күнегеп киттем. Хәтта сорап, булмаса табып та капкалый башладым. Колумбны да, Христофор агайларны да бик сагынам. Алар бер дигән кешеләрие.

Шушы хәленнән маэмай нык уңайсызлана, хурлана кебек. Колакларына хәтле кызара.

– Әйдә, Казбек дускай, өйгә кайтыйк! Өйгә кайтканның ояты юк, диләрме әле. Өйгә – безгә кайтыйк, калганын үзебездә сөйләшербез. Хуҗабикәң Сания апаң да, кызларым Гөлшат белән Гөлназ да сине бик юксыналар. Хәтта Сарбаебыз – Чекист та сине юксынып өрә. Сиңа карата көнчелек хисләре тотса да.

Егетләр әллә кайдан гына каеш муенчак табып китерделәр. Аны Казбек муенына кидердек. Ишегалдына без икәүләп – мин Казбекны җитәкләп кайтып кердек. Биләмче «егетемне» оясына ябып, бәйгә утырттым. Казбек, оясын тынчу санап, ишегалдына чыгып, чирәмгә сузыла: тынчудыр да, җәйнең кызу чагы. Акация шау чәчәктә. Шулай үлле-мәлледәй хәлдә оясы алдында сәгатьләр, көннәр буе ята. Күзләре дә йомык, махмыр кичерә. Берни капмый. Шул тирәдә чабышкан тавык чебешләре, иртәнге якта салкын чирәмгә басып тәпиләре өшегәнлектән җылынырга исәп тотып, җиргә сузылган Казбек сыртына тезелешеп кунаклыйлар. Аның сыртыннан рәхәтләнеп, ярыша-ярыша, борчамы-нидер чүплиләр. Чукыр-чукыр килешәләр. Бик канәгатьләр. Бу күренеш Казбекның үзенә ошыйдырмы-юкмы, ул тын алмый ята бирә. Әллә үле, әллә тере. Ашамый, алдына берөзлексез кызларым ташып торган салкын суны гына шупыра, балакай.

– Ят, ят! Шулай. Башыңа бераз акыл кермәсме, – дип узам яныннан.

Искиткеч акыллы, тик сөйләшә генә белми торган бер дигән нәселле-породалы овчарканың шушындый әрнүле хәлгә төшүен төптән танып, мин Казбекны бераз пешекләп алырга ниятлим. Бик кирәк чара. Ә хатыным Сания, кызларым Гөлшат белән Гөлназ Казбекка бармак янау түгел, сүз дә әйттермиләр. Овчарканы, алкашны Урал тавы булып яклыйлар. Алай гынамы? Комганда су җылытып, өстенә коялар, битләрен исле сабын белән юалар. Әниләре коймак-мазар пешерсә, беренче таба коймакны Казбекка чыгаралар. Кибеттән «Эскимо» алып чыгып, үзләре ашыйсы урында маэмайдан ялаттыралар.

Әмма шулай чыгып югалуларын маэмай һаман ташламады. Хроник алкоголик бит ул. Ә ул чир, зәхмәт үз эшен аккурат белә. Казбек та, ике айга бер булса да, башын җуеп, тәмам онытылып ала. Өебезгә килеп тә әйткәлиләр, барып, җитәкләп тә алып кайткалыйбыз. Биш яшьлек бала бит ул. Аны ни эшләтәсең инде? Медицина ярдәме белән дә дәвалап булмый икән.

Казбекны бик сөенеп, дәртләнеп алып кайтканыма ике еллап узды. Колумб дигән егетнең кулыннан сатып алганда, аңа өч яшьләр иде. Димәк, аңа хәзер биш яшь. Карамадым, асрамадым түгел. Миңа бу маэмайдан котылырга кирәк түгел микән, дигән уйлар да килгәли башыма. Яхшы, ямьсезләнмәгән чакта ук. Кешеләрдән уңайсыз. Урамга чыксаң да, китапханәгә, редакцияләргә, кибетләргә керсәң дә, гел аның турында гына сөйлиләр. Ничек түзәсез, диләр. Әйтерсең, күргән-белгәннәребезнең көндәлек тормышта бүтән сөенеч-кайгылары юк. Котылырга уйлап та, аны кая куясың? Гөнаһсыз бер җан иясе бит!

Беркөнне бездән ерак та булмаган «Водоканал» мастерскоена төштем. Бернинди максатсыз, усал ниятсез. Анда, шахмат клубына ничә ел бергә йөргән бер танышым, Ягъфәр эшли. Ул мине бер каравылчы агай белән таныштырды. Сүз иярә сүз чыгып, дигәндәй, хәлне, моң-зарларымны түкми-чәчми сөйләп бирдем. Андый мизгелләр барыбызда була, бик табигый халәт!

– Исең киткән икән иске чикмәнгә, – диде агай, борынныннан куе төтен җибәреп. Үзе болай аек. Исерек-мазар түгел. Амбар, склад, гараж, мастер

алачыгы тирәсендә андыйларны еш очратасың. – Ал да төш исерек алкашыңны. Әнә, уналты калибрлы пушкам баш өстемдә генә, ыргакта эленеп тора. Ярык түтәле булса да, ике гөрселдәтергә калдырмый. Курокны бер генә басам, җитмеш яшьлек аюыңны күз алдында мәтәлдерәм. Гөрес итеп ава. Алып төш маэмаеңны. Тиресе миңа булыр. Как раз кышка унтый тегәргә җыенып тора идем. Картаелды, аяклар сызлый башлады. Көтәм, сузма.

Аек булса да, бик тәвәккәл кеше күренсә дә, бу агай бераз гына күперенергә, хәтта шапырынырга да ярата икән. Миңа шулайрак тоелды. Ошамады ул агай миңа. Алай да килештек, Казбекны алып төшәргә булдым. «Бик яратканга гына чалам бит сине, кәҗәкәем!»

Берәр атнадан «Табигатьне яшелләндерү» конторыннан, өсте ябулы машина алдым. Анда да яхшы танышлар эшли. Маэмайны кузовка салып, «Водоканал» мастерскоена төшеп киттек. Төшсәңме! Агаем ләх исерек. Мастерской алачыгында, аягына баса алмый, идәндә ята. «Уналты калибрлы пушка»сы да элгән җирендә юк. Әллә урлап чыкканнар, әллә сатып эчкән. Мине, кузовта яткан Казбекны күреп, прәме учалана әле.

– Ах, миңа как раз кирәкле товар белән төшкәнсең. Бу «бүре»нең тиресеннән ике пар унтый чыга, ике пар! Кая? Пушкамны кая олактырдым икән соң? Чукынып киткере! Иртәгә төш. Әбәзәтельный. Мин хәстәрләнеп көтеп торырмын! Мин бит үтә тәвәккәл. Уналтынчы калибрдан шалт берне гөрселдәтәм. Бурзаең ничек тиресен тунаганны сизми дә калыр.

– Иртәгә дә, берсекөнгә дә аяк басасым юк. Мин бу «бүре» малаен аттырырга гомумән җыенмыйм, – дидем. Хәтта бераз кискенрәк тонда. Агай да аптырап тормады. Ләх исерек булса да:

– Менә кызык кеше икәнсең, чакырып төшердемме? Үзең төштең бит. Ә менә кузовтагы «бүре»ңнең тиресе ятларга эләгә калса, җә-ә-әл! Аннан ике пар бер дигән унтыйлар чыгар иде. Ике пар! Беләсеңме аларның ни бәя торганын? Белмисең шул.

Машинамның шофёры да бик уңай егет туры килде. «Әйдә, шофёр, тот рульне, юлларыңа бәхет яугыры!» – дип көйләп алдым да:

– Киттек Чирмешәнгә! – дидем. Андый чакта башка тәвәккәл фикере дә килеп тора бит аның!

– Чирмешәнгә үк? – дип сорады шофёр егетем Әсхәт. – Чирмешән бездән йөз егерме чакрымнарда.

– Беләм, – дидем. – Бензиныбыз җитмәсә, Шөгердә туктап, бакны мөлдерәмә тутырып, үзем салырмын.

Шофёр халкы белән эш йөртсәң, алар белән сүзне бензиннан башла. Замана тудырган корыч законнарның берсе. Мин дә шул юлны сайладым. Кузовтагы йөгебезне чүплеккә илтеп ташлап калдыра алмыйбыз бит. Ул тере җан гына түгел, бер дигән нәселле овчарка. «Салгаларга» яратса да, искитмәле акыллы җан. Үзем дә бик яратам. Ләкин бер начар шөгыле бар шул. Еш кына исергәли, шайтан!

– Абау! Сезнең авыздан бик кызык бер нәрсә ишетәм. Ул чир, алкоголизм дигән кабахәт нәрсә, хайваннар – дүрт аяклылар арасына да кереп киләмени? Вәт әкәмәт! Вәт зәхмәт?

– Килә шул. Анда, Чирмешәндә, яхшы белгән бер агаем бар, җитмәсә гармунчы. Тальянны бик шәп тарта.

Әсхәт, сүземне ярты юлда бүлдереп: «Әллә шул агайга этеңне гармун тыңларга алып барабызмы?» – дип сорады, бик җитди төстә.

– Без барасы, дөнья бәясе егет Мәүлетбай агай белән узган елны Казанда республиканың умартачылар киңәшмәсендә күрешкән идек. Бер кунакханәләрдә кунып, бергә ашап-эчеп йөрдек. Сөйләшергә, гәпләшергә бик уңай, укымышлы агай. Миңа бик ошаган иде. Тормышны сөйгән, бик уңган, тәвәккәл холыклы кеше. Мәүлетбай агай миңа: «Умарталыгым Чирмешәннән бик читтә, еракта, калын урман аланында. Умарталарымны басып, кәрәзле бал ашарга хулиганнар да кереп чыга. Сакларга бер адәм рәтлерәк бурзаймы, сизгер колаклы этме булдырасы иде. Туры килсә, акча түләп, сатып та алган булыр идем», – дигән иде.

– Шуңа барабызмыни? – диде Әсхәт тә. – Чирмешәнгә тек Чирмешәнгә.

– Барып карыйк, барып чыгармы сәфәребез, – дидем.

Йөз егерме чакрым хәзерге заман машиналарына арамыни ул! Чирмешәнгә төш алдыннан ук килеп җиттек. Мәүлетбай агай өендә юк. Үзе дә, тальяны да урманда – кортлары янында икән. Урман юлы баткаграк булса да, анда да тиз барып җиттек.

Мәүлетбай агай умарталыгында кортларны тузгытып, карап маташа. Кортларның шаулавыннан бөтен урман эче гөж килә. Агай, кортлар күч аералар, тубалга җыеп өлгерешле түгел, дип зарланды. Кая монда гармун тоту?!

Хуҗа безне якты йөз белән, зур кунакларына тиңләп каршы алды. Йөзе елмаюлы. Учакта тәмле бал белән хуш исле чәй өлгертте. Татлы-тәмле чәй эчеп утырабыз. Казбек та безнең янда. Килеп җитү белән, кузовтан сикереп төшеп, умарталыкны җентекләп, үз күзе белән карап чыкты. Маэмаебыз Мәүлетбай күңеленә беренче күрүдә үк хуш килде. Ул аны каклаган каз боты белән дә, кичә генә чалган тәкә ите белән дә сыйларга өлгерде. Шулай гәп корып утырганда, Мәүлетбай үзе:

– Габделхак, ахирием, маэмай үзеннән-үзе кулга ияләшеп тора. Бу малкаеңны миңа биреп калдыра алмассыңмы? Шушы кара урманда берүзем, бигрәк ялгыз бит мин. Өйдә балалар да җитәрлек. Хәзергеләр корттан талатырга, урманга да бик атлыгып тормыйлар. Ә балны яраталар гынамы! Ә маэмаең: «Мәүлетбай агай, кортларыңны үзем дә карашыйммы?» – дип, миңа сүз катып тора. Габделхак, ахирием, Казбек атлы маэмай егетең миңа бик ошады. Бәрабәренә ни сорасаң да, теләгән әйбереңне сора, жәл түгел. Умарталарымны сакларга миңа иптәшкә калдыра күр. Маэмайсыз яшәү уңайсыз булса, питомниктан үзеңә яңа эт малае – көчекме алырсың.

Миңа: «Кадерле Мәүлетбай агай, затлы этләр – овчаркалар токымыннан бу «егет»не махсус сиңа алып килдем. Игелеген күр! Озын гомерле булсын!» – дип әйтәсе генә калды.

Тәмләп, озаклап чәйләгәннән соң, без Казбек белән умарталыкның аргы читенәрәк барып бастык. Күк йөзеннән җай гына аккан ап-ак болытларга карап, гомерләрендә бер генә минут та лепердәми тора алмаган усак яфраклары шаулавын тыңлап, тын гына торабыз. Мин – Казбекка, ул миңа төбәлгән. Казбек дускаем, тормыш дигәнебез шулай көйләнгән. Французларча Селяви була. Ул аерылулардан, күрешүләрдән тора. Мин сине бик әйбәт җирдә калдырам. Монысын аеруча учти! Яңа хуҗаң Мәүлетбай агаңа тугры хезмәт ит. Сине монда калдырып китү миңа да шатлык түгел. Ә башка чарабыз да юк.

Җәй булса да, чүт кенә салкынчарак, җиләсрәк көн иде ул. Минем өстемдә, Германиянең иң атаклы тегү фабрикасы «Маде ин Германи»да махсус теккәндәй, миңа үтә килешеп, ятышып торган, күзне иркәләүче көрәнрәк төстәге бик затлы җилән. Күрсәң, үзең дә сизми сызгырып куярлык. Шулай

булырга тиеш тә. Мин бит язучы! Дуңгыз йә каз көтүчесе түгел. Кимсетеп әйтүемнән Алла сакласын, һәр эшнең үз үзенчәлеге... Металлурглар, корыч коючылар, әнә, киез кием, костюм-куртка кияләр.

Сөйләшергә инде бүтән сүз тапмый, Казбек – очлы колак белән кара-каршы торабыз. Икебездә дә гаҗәеп халәт. Исемең – Кавказ тауларының икенче иң биек ноктасы «Казбек!». Моның белән син дә үз бәяңне бел, диюем. Горур бул. Син, балакаем, берүк миңа үпкә тота күрмә. Минем гаиләмә сөенечшатлыкларны күп китердең. Кем белә, беравыктан, бәлки, тагын килеп чыгармын, күрешербез. Ә хәзергә сау бул... Дүрт аяклы тыйнак дустым.

Шулчак, һич көтмәгәндә, Казбек малай, минем бик затлы җиләнемнең нәкъ күкрәк өстенә уң як алгы тәпие белән шап иттереп китереп сукты. «Булмаса бир бишне!» – диюе булдымы? Аңламадым, нинди ым, нинди серле билге булды икән ул?

Казбекны Мәүлетбай агаем кулына тапшырганда: «Бу дустыбызның кача, чыгып юк була торган гадәте көчле. Сак бул!» – дигән идем.

Чуар йөрәк, тынгысыз җан Казбек Мәүлетбай умарталыгын да озак сакламаган. Качкан, шайтан. Бу хәбәргә хәтта сөендем дә...

– Миннән кача алма-ас! Мин аны мир үгезләрен арканлый торган, беләк юанлыгы чылбырга утыртам, – дигәние Мәүлетбай агай. Чуар йөрәк Казбек тәки качкан. Аны төрле авыллар тирәсендә аракы кибетләрендә күргәннәр. Эчкән хәлдә, кибет ишек төпләрендә аунап ятканын да. Мин, махсус машина яллап, бу авылларны йөреп, сораштырып чыктым. Күрүчеләр күп булган. Эзләдем, таба алмадым. Очрашканда, аны күрүчеләр, бераз елмаеп, чак кына уңайсызланып:

– Ул Алып гәүдәле маэмаегыз бераз җиббәреп алырга ярата иде бугай, – диләр. – Берәр кибет тирәсендәдер әле.

Шулай да нык үкенеч. Хәтта елыйсы килә. Аны беренче качуында ук тотып, алкоголизмнан дәвалаучы табибларга алып барырга булган. Юк, алып та барган идем бит. Алкоголикларны дәвалаучы, медицина фәннәре кандидаты башкорт егете Равил Шакирович Алибаев дустым катына. Якын фикердәшем булса да, ишектән үк шаркылдап көлеп:

– Тапкансың эш! Юк белән йөрисең! – дип каршылады. – Этләрне, мәчепесиләрне түгел, хайваннарның ике аяклыларын да дәвалап өлгерә алмыйбыз. Алар белән палаталарыбыз тулы.

Алкоголизм зәхмәте, җәмгыятебезгә бик кадерле бөек шәхесләрне генә түгел, аристократлар сыйныфыннан булган бер дигән овчарканы да харап итте, имансыз, дип килешергә генә кала. Кешеләр, бу зәхмәттән сак була күрегез, дип кисәтми, бу хикәямне тәмамлый алмыйм.

Казбекның, теге затлы, миңа искиткеч килешеп торган җиләнемнең түшенә шап иттереп суккан эзе һаман да бетмәде. Химчисткаларга биреп, чистартып карадык. Юк, бетмәде. Җиләнемне дә яратып киям, өстемнән төшермим. Ул эзне таныш-белешләрем, дусларым да беренче итеп күреп алалар. Затлы җиләндә нинди эз, нинди билге бу? Нигә аны юмыйсыз? Хәтта май-дегет тапларын да юк итә торган порошоклар кибет саен. Нигә шуларны кулланмыйсыз?.. Серне ачып, сөйләп биргән чакларым да күп.

Ә менә теге чакта Казбек түшемә нинди максат белән шапылдатты икән? Җиләнем түшендә дүрт бармак эзе бүген дә ярылып ята. «Хуҗам, бир бишне!» – диюе булды микән, әллә нык үпкәләпме? Ул серне мин бүгенге көнгә кадәр ачканым юк. Нык уйлансам да. Җиләнем үтә затлы булганы өчен генә түгел, ә

түш өлешендә ярылып яткан тамгасы, чабата хәтле эт-бурзай тамгасы булган өчен якын һәм кадерле.

**P.S.** Башка әйтер сүзем булмаганда, мин: «Аһ, Алла!» – дип куям. Бу мәгълүматларны «Ватаным Татарстан» газетасының 87 (27699) санында басылган битеннән алдым. Узган Бөек Ватан сугышында, махсус хәрби паёклар алып, алтмыш меңнән артык этләребез хезмәт иткән. Диверсантлар итеп хәзерләнгән дүрт аяклы балакайларыбыз дошманның дистәләрчә эшелоннарын күккә очыра. Танкларга һөҗүм максатында өйрәтелгән йонлач маэмайлар, дошманның өч йөз меңнән артык бронетехникасын юк итә. Беркут, Казбек, Каштанкаларның, аркаларына мина тагып, безнекеләр өстенә ажгырып килгән «Фердинанд», «Мёртвая голова» танкларына каршы үзләрен кызганмый шуышканнарын мин бик яхшы күз алдына китерәм. Сугыш операциясен бер танк хәл иткән чаклар да булгандыр. Дүрт аяклы геройлар дошманның 300 меңнән артык техникасын юкка чыгаралар.

Элемтәче маэмайлар ике йөз меңнән күбрәк донесениене иясенә китереп җиткерәләр. Ат урынына җигелгән дүрт аяклы санитарларыбыз каты яраланып кан эчендә яткан җиде йөз меңнән артык кызылармиячене һәм аларның командирларын сугыш кырыннан алып чыгалар. Аларны ничек сөймисең дә, кулыңа, кочагыңа алып, башларыннан сыйпамыйсың, юеш борыныннан әп итеп алмыйсың.

Сапёр этләр ярдәмендә 303 шәһәр һәм торак-яшәү җирләре, шул исәптән Ленинград, Киев, Харьков, Львов, Одесса мина-шартлаткычлардан чистартыла. Шул рәвешле, дүрт миллионнан артыграк дошман минасы һәм фугас бомбалары табылып зарарсызландырыла.

Урам чатларында, базар, вокзал ишек төпләрендә гамьсез дөнья көтеп йөргән маэмай егетләренә җылы сәлам биреп:

– Бөек Ватан сугышында дошманны тар-мар итеп, җиңеп чыгуыбызга сезнең өлкән нәселләрегез егетләре дә зур өлеш кертте. Хәтта үз гомерләрен биреп. Исемнәре дан-хөрмәткә күмелгән Ватан уллары Александр Матросов, Газинур Гафиятуллин һәм башкалар кебек, сезнең дә геройларыгыз бар! Гомер кешегә дә, кигәвен-үсемлекләргә дә кадерле. Үз гомерен биреп, фашистларның бер «Фердинанд»ын юк иткән маэмай да герой! Бу исемгә бәхәссез лаек.

«Эт – кешенең дусты», – дибез. Кеше дигәнең агач башыннан төшеп, атлап китү белән, беренче гамәле итеп этне ияләндергән. Чөнки аңа ышанычлы дус кирәк булган. Шул көннән бирле миллион еллар маэмай халкы белән дус яшибез. Мәңге шулай булсын. Мин хәзер дә Казбекны еш искә төшерәм. Башын котылгысыз алкоголизм сөреме баскан бәхетсез җан исән булса, мин аны үзебезгә алып кайтырга, дәвалап карарга да әзер. Инде дәү үсеп бетсәләр дә, кызларым да һаман Казбек турында сорашалар, ул менә-менә кайтып керер кебек...

**Редакциядән:**

*Каләмдәшебез бу айда үзенең юбилеен билгеләп үтә, аңа исәнлек-саулык, иҗат уңышлары телибез.*

# КЕМ УЛ ӘХМӘТ САТТАР?

Күпкырлы талант иясе, уникаль шәхес ул Әхмәт Саттар. Инде өлкән яшьтә булса да, Аллаһ биргән асыл сыйфатларын һаман чарлау-яңарту, «яхшы» булганны «бик яхшы» итәр өчен тырышып йөргән көне. Халыкта андыйлар турында, гадәттә, «тик торуны белмәс тынгысыз җан», диләр. Чыннан да, бер карыйсың, яшәгән Мәскәвендә күптөрле очрашу-кичәләргә чакырып алалар үзен; икенче күргәндә, киностудиядә төшерелүче ниндидер фильмда катнашырга чакырып телефоннан шалтыраталар; янә игътибар итсәң, якташларының мәнфәгатен кайгыртып, туган ягы Түбән Новгород якларына сәфәр чыкканын беләсең; боларга тагын аксакалның мәшәкать-борчуларга тулы җәмәгатьчелек эшчәнлеге, милләт гамен кайгыртуы өстәлә. Шигърият дөньясына чумып, кыен вә катлаулы жанр – энҗе-мәрҗәннәргә тиң робагыйлар язуы үзе ни тора! Менә карагыз әле:

*– Тугач та без – үлем токтыннары,*
*Суласак та ирек һавасын.*
*Кешелегең күпме данлы булса,*
*Мәңгелеккә шулай авасың!*

– дип яза ул үзенең дүртьюллыгында. Шәп бит, ә?! Яки «Яхшылыкка һәйкәл» шигырен алыйк:

*– Тулып ята сугыш һәйкәлләре*
*Мәйданнарда, музей түрендә...*
*Агач булсын, тимер, мәрмәр булсын –*
*Яхшылыкка һәйкәл салыр өчен*
*Соң түгелдер әле бүген дә!*

– диюе үзе бер ачыш. Нибары дүрт юлдан гыйбарәт шигырь эченә шулкадәр мәгънәне сыйдыр әле (повесть-романнарыңа торырлык), шагыйрьләрдән бик сирәгенең генә кулыннан киләдер мондый хикмәти могҗиза.

Фәлсәфи мәгънәгә ия робагыйлары янәшәсендә Кешелек дөньясын яшәтүче, аңа Җирдәге тормышны дәвам итәргә рух өстәүче, кешене шәхес иттерүче мәңгелек тема – мәхәббәт темасы да фикри тыгызлыгы җәһәтеннән бер ягы белән дә калышмый Әхмәт Саттарның «Ихлас» нәшриятында дөнья күргән «Робагыйлар» китабындагы дүртьюллыкларында.

Авторның чагыштырмача зур булмаган (нибары 160 бит) «Робагыйлар» китабы дүрт бүлектән тора. «Кечкенә булса да, төш кенә», дигәндәй, шулай булуга карамастан, ул шактый ук киң спектрны колачлаган. Әйтик, аның «Робагыйлар» дип исемләнгән 106 битле өлеше, робагыйлардан тыш, «Мәхәббәтнамә», «Әдәби портретлар», «Багышлаулар»га бүленгән. Алардан соң «Кечтеки мәсәлләр» дигән мәсәлләре, публицистика, рецензияләр урын алган. Китапның ахырына язучының кыскача иҗади биографиясе китерелгән. Хәер, боларны сөйләү – бер нәрсә, картинаны тулысынча күзаллау өчен, нәшрият басмасын кулыңа тотып уку лазем. Ә мин үзем өчен Көнчыгышның бөек робагыйчысы Гомәр Хәйямнәр традициясен тиешле югарылыкта дәвам итүчене ачтым, шигъриятькә гашыйк бик күпләр өчен дә бу шулайдыр дип уйлыйм.

**Фирдәвес ХУҖИН**



Әхмәт
Саттар

# ШИГЪРИЯТКӘ БИРДЕМ ГОМЕРЕМНЕ

РОБАГЫЙЛАР

## Уйла, каләм!

Сүз әйтердән алда уйла, каләм,
Юлчы юлны сайлаган сыман...
Маңгай бөкмик ялган күзгеләргә, –
Каләмчеләр исә – каһарман.

## Сөю җәмгыятен төзербез!

*«Җир – Мәхәббәт планетасы...»*
Антуан де Сент-Экзюпери

Мәхәббәттән кача алмабыздыр,
Матурлыкка һәрчак әзер без.
Планеталар бергә туганлашкач,
Сөю җәмгыятен төзербез!

## Минем корал

Минем шигырь – дүрт көпшәле мылтык.
Оста ата беләм – мәргән күк...
Көпшәләрдән ләкин ядрә түгел,
Сүз коела энҗе-мәрҗән күк!

## Су алмасаң – чишмә кибә...

Без бит гасыр тирәнлекләреннән
Күтәрелгән нәсел ләбаса!
Корып-кибеп юкка чыга чишмә,
Үз ишләрен әгәр тапмаса...

Әхмәт САТТАР (1937) – *шагыйрь; «Җырлар», «Робагыйлар» һәм рус телендә чыккан башка китаплар авторы. Мәскәүдә яши.*

## Кое кануны

Чүлдә – үлән, коеда су типте –
Гәрчә Кояш дөрләп янса да...
Китте халык, сулды-кипте кое,
Су калмады анда тамчы да!

## Шигырьләрем – кошларым

Дала сыман ачык шигырьләрем,
Белми дала аран-бикләрне.
Шигырьләрем – азат кошлар сыман, –
Канатлылар белми чикләрне.

## Кем кулында дөнья?

...Күпләр күтәрелгән таҗ-тәхеткә
Һәм уйлаган: зирәк – ул гына...
Лира һәрчак читтә... Тәхетләрне
Тапшырыйк без Шагыйрь кулына!

## Метаморфоза

Күпме контрастлык: роза гөлләр
Чәнечкедә, әнә, утырган…
Ишәк дигән олы-ы-ы башлы хайван
Башын «кибәк» белән тутырган.

## Яшәсен сәер кеше!

*«Шат күңелле кешеләр сәламәт булучан...»*
Амбруаз Паре, XVI гасыр табибы

«Юләр», диеп, әйдә, атасыннар –
Сәерлеккә кайчак ни җитә?!
Күңелсезләнмичә яшә, дустым,
Дөньялыкта шулай кич-иртә.

## Тынычлык турында

*«Сугыш – нәҗес нәрсә...»*
Франклин Рузвельт,
АКШ Президенты

Бомбалардан тетрәп тора дөнья,
Ярый әле Акыл тора сакта...
Әй син, Кеше, йөгәндә тот утны,
Күзалмасы кебек Җирне сакла!

## Фикер туганда

Фикер туа, яшен сыман яшьнәп,
Тик булмасын аның зәхмәте.

Хакыйкать һәм сүзләр туган икән,
Бу бит безгә – Ходай рәхмәте!

## Шагыйрь һәм җыр

Вакыт һәм Парнас алдында
Кирәксә, шагыйрь, тезлән...
Шигырь ул – үз балаң кебек:
Яхшырак булсын бездән!

## Югары тойгы

Киеренке хәлдә нервыларым,
Җир-ананы тоймый аякларым.
Мин ишетәм... йолдыз яуганны,
Тарих даласында булганны...

## Ни бирдең, эволюция?

Белсәң иде серен дөньялыкның,
Нигә елый кеше, ник сөя?
Сугышабыз, зыр-зыр әйләнәбез –
Шул булдымы эволюция?..

## Яхшылыкка һәйкәл

Тулып ята сугыш һәйкәлләре
Мәйданнарда, музей түрендә...
Агач булсын, тимер, мәрмәр булсын –
Яхшылыкка һәйкәл салыр өчен
Соң түгелдер әле бүген дә!

## Буразнада йолдыз


Һәркемнең бар күктә үз йолдызы,
Буразнасы – җирдән, түтәлдән.
Йолдыз үрләренә меңдең икән,
Буразналар, димәк, күтәргән!

## Йортыңа иминлек булсын

Әйтерсең лә без сугышны күмдек,
Әмма Ике Дөнья тартышта.
Солых телим чит ил чордашыма,
Тормышында якты балкышлар!

**Редакциядән:**

*Каләмдәшебез бу айда үзенең юбилеен билгеләп үтә, аңа исәнлек-саулык, иҗат уңышлары телибез.*



Рөстәм
Зарипов

# ӘНИЛӘР

БӘЯН

*Вакыт җиткәч кенә кадерләргә,*
*Кереп югалалар каберләргә....*
Мөдәмил Әхмәтов

Елның елында хәрби диңгез флоты көнен Мишә буендагы изгеләр чишмәсе челтерәп аккан тау итәгендә, учак ягып, казан асып уздырабыз. Мәҗлес кич башлана һәм таңгача дәвам итә. Флотта хезмәт иткән, текә вазифасы, административ маясы ышыгында хатыны исемендәге табышлы бизнесын армый-талмый алга кәшәләүче Әхмәт дустыбыз ел саен сарык чалдыру, җәтмә белән балык сөздерү, табын әзерләтү, аның тирәли келәмнәр җәйдерү, палаткалар кордыру, кулъюгычлар куйдыру, сөлгеләр элдерү, печәнен чаптырып, машиналар өчен мәйданчык әзерләү, килер юлларны тигезләү-төзекләндерү һәм барыбыз өчен дә җитешле санда тельняшкалар сатып алу хәстәрен күрә. Биредә Әхмәт яшелчә, җиләк-җимеш үстерү, атлар асрау һәм кымыз җитештерүне җайга салган. Җирләр анықы икәнен якын-тирә авыл халкы бик белеп тә бетерми бугай, чөнки дустыбыз, «нигә кош-кортларыгыз, мал-туарларыгыз минем биләмәләрне таптый», дип әлегә вакланмый. Озак еллар Иделдә ак пароход йөздергән Фәрит кордаш бәйрәмебезгә баштанаяк ак формадан килә, һәм аңа Адмирал әфәнде, дип кенә мөрәҗәгать итәбез. Күбебез флотта хезмәт итмәсә дә, тельняшкалар киеп, бераз кызып алгач, әкренләп диңгез бүреләренә охшый төшәбез. Безгә шулай тоела. Хәер, читтән күзәтүче ятлар ничек бәяли торгандыр, Аллаһ сакласын... Саф һавада табынга килгән һәр ризык, итле шулпа, шашлык, бәлеш, табада кыздырылган елга балыгы, көлгә күмеп пешерелгән бәрәңге – бар да әйбәт үтә. Халык мәкале хаклы: аш – ашка, урыны башка. Әлбәттә, мәҗлескә кереш сыйфатында иң алдан чыгарылган флотча макорон да тиз ялмана. Чәй, аннан катырагы өчен кружкалар, аш тәлинкәләре, кашыклар

Рөстәм ЗАРИПОВ (1952) *– язучы, публицист; «Тамчы гөл», «Чыңгызхан китергән бәйрәм», «Әфлисун җиле» исемле китаплар авторы. Саба районы Шәмәрдән бистәсендә яши.*

– бар да безнең чордагы хәрби хезмәттәгечә әлүминнән. Кымызны касәгә салып сыйланасы. Кайсыбызның нинди дәрәҗәгә ирешкәнен исә чирәмлектә тезелешкән машиналар «әйтә». Көяз иномаркалар рәтендә, ә алар арасында танк шаелары да юк түгел, тыйнаклык саклап, тегеләрнең укалары коелмасын тагы, диебрәкме, берара читкә тайпыла төшеп, боегыбрак торучы, үз илебездә чыккан транспорт чараларының «тезләре» сыгылганрак, һәм «борыннары» салынкырак. Хәлбуки, тора-бара күңелләр нечкәрә, кайсыбызның ничә яшьтә булуы, иҗтимагый баскычта ниткән кирттә канат җилпүе онытыла, һәм без бары тик дуслар, ахириләр генә булып калабыз. Әңгәмә җанлана, кыза, кайный, күбекләнә. Һәм куыклар да оча башламый микән? Элегрәк, яшьрәк чакта сүзебез күбрәк кызлар, мәхәббәт өлкәсендә яуланган үрләр хакында урала торган иде. Инде ул чорыбыз сагынып сөйләргә генә калып бара бугай. Дөрес, әле дә хатын-кыз темасы тәҗеллеген җуймады җуюын, тик бераз шиңә, куырыла төште, димме, мактанышуларыбыздагы шигъриятне елдан-ел тормыш прозасы кысрыклый. Кыскасы, без фәкыйрьләр өчен эштә килеп туган кыенлыкларны ерып чыгу, дәү түрәләр белән бәрелешләрдән кемнәрнең ниткән «каурыйлары» коелып исән калуы хакында кыйссалар елдан-ел кызыграк тоела бара...

Утыра торгач, һәр җәй көтеп алынган шушы очрашуыбызга турылап, Сәлимулла кордаш чыгарган җырга да чират җитә...

...Кызырата тавы, Мишә яры...
Тау өстендә тора бер болыт...
Күңелдәге хисләр, якты төсләр
карашлардан ташый, нур булып...
Үзебезнең җырны җырлыйк әле,
кубарылсын җанның юшкыны,
ялкынланып янсын безнең учак,
биекләргә менсен очкыны!
Кызырата тавы, Мишә яры, –
бәллүр чишмә чыга ургылып.
Сөйләшәсе сүзләр хәттин ашкан,
күңелләрдән ташый, моң булып.
Яшьлектәге дуслар җанга якын.
Яшьлектәге хисләр кадерле.
Яшьлектә җырланган җырлар гына
телә җанны, өзә бәгырьне...

Һәм тагын үзебезнең җырны җырлау мөһимлеге хакындагы кушымта арага керә. Тик аның соңгы юлы «йолдызларга ашсын очкыны», дип тәмамлана... Бу сүзләрне, теләк-тәкъдимнәребезне искә алып, Әмир яшьти корыштырган иде...

Җыр, әгәр дә аңа җан иңгән икән, күңелләрне уртак дулкынга турылый һәм андыйдан соң беркавым айный алмый, әсәрләнеп, сүзсез утырыла...

Адмирал әфәндене тау исеме сәерсендергән булып чыкты, һәм аның капылт кына:

– Ниткән Кысыр ата тавы ул? – дип, кызыксынулы соравы моңга бирешүчәнрәкләребезне, җырның тылсымлы тәэсиреннән «уятып», тып иттереп җиргә төшереп бастырды.

– Хозыр Ата дигән сүздән үзгәргән, – дип, ашыгып ачыклык кертте Әхмәт, гармунын читкә куеп.

– Что за мужик?

Терекөмештәй хәрәкәтчән һәм җитез Әхмәт, урыныннан торып, гасабиланып, баскан ноктасында бөтерелеп алды һәм, шагыйрь дустыбыз тарафына ишарәләп:

– Менә шушы кеше иң төгәлен әйтә инде аның, – дип котылды.

– Пәйгамбәр, – дип ачыклык кертте Әмир, тыныч кына. – Терек суы эчкәнгә, мәңге яши. Мөсафир, дәрвиш кыяфәтендә кешеләргә юлыга һәм, күңелләре сафракларга, «инде беттем», дип торган мәлләрендә игелек кыла, булыша, ярдәм итә.

– Димәк, ул бу тирәләрне ураштырган! – дип тел шартлата Адмирал.

– Бер сукмактан йөрибез, – дип ризалаша Әмир. – Әхмәтнең кабаттан мантып китүенә шул сәбәпче түгел микән әле?

Як-яктан:

– Ни булган иде Әхмәткә? Без берни белмибез! – дигән кызыксынулы сораулар, борчылулар яңгырый.

– Әй, – дип көрсенә Әхмәт, чыраен чытып һәм сул кулын кырыйга таба селтәп куя.

– Йә-йә, без дә белик, – дип гөрләшә башлый мәҗлестәшләр.

– Кем дә кем Әхмәт белән булган хәлне белергә тели, шул иптәшләрнең кул күтәрүен сорыйм. Каршылар? Тоткарланучылар? Бертавыштан! – дип сөрән сала Адмирал.

– Туктачы, Адмиралым, – дип, аның җиңеннән тарта Әмир. – Бәлки, кешенең ничек итеп күлмәген күтәртеп – эченә, чалбарын төшертеп, артына тибүләреннән алган тәэсирләре белән уртаклашасы килмидер? Кукраюлары бик күңелле, кәкрәйтүләре бик яман, дип җырлыйлар түгелме соң хәләл җефетеңнең туган якларында?

– Алай ук түгел бит инде, – дип, янә сикереп тора Әхмәт. Ул, гадәтенчә, урынында зыр итеп бөтерелеп ала да, тәвәккәлләп, үзенең сөйкемсез сөяккә әйләнүе тарихын бәян итәргә керешә... Сөйләгән саен, сүз агымы тизлеге арта тора һәм бермәл ул кызулый ук башлый:

– ...Чакыртып алды бу мине. Килеп кердем кабинетына. Келәмнәр калын анда, аяклар бата да, баш әйләнеп киткәндәй була, күз алдында әйберләр тотанагын җуеп йөзә башлый. Өстәлләр кара агачтан, ә шулар, мокытны кырык ел укыт, барыбер мокыт, дигәндәй, колхоз рәисе зәвыгынча, «Т» хәрефе ясап тезелгән. Бар бит әле Әмир ярата торган Гамил Афзал шигырендә, ничек әле, «татарга кол кереп утырган», дигән төше. «Колхоз» тагын да тирәнрәк кереп утырган безнең югары катламнарга...

– Иҗади катламнарда да хәл шул, – дип сүз кыстыра Әмир. – «Декамерон»ны да укымаган гыйбадлар язарга өйрәтә башлады бүген...

Адмирал аңа «тсс» дип, бүлдермәскә кисәтеп ым кага.

– Әмир хаклы, барыбыз да колхоз кадрлары, – дип дәвам итә Әхмәт. – Хуҗа түрдә, ә як-яклап, «тән»гә якынаю җае тапкан «алтылы чыбыклар» күзләрен тасрайтып утыра. Мине күрүгә, агаебыз корт чаккандай чәчрәп урыныннан купты. Бер кулын кесәсенә тыккан да, әйтерсең, анда бильярд шары бар, шуны, әле уңга, әле сулга әйләндерепме-әйләндерә. Дулкынланган чакта моның бугаз төере бүртеп, күлмәк якасына сыймый башлый икән, һәм ул юк

муенын, ата каз сыман әледән-әле алга суза... Аны, ишеткәнсездер, бәлки, үзенең иң якыннары урыныннан очыртырга маташты. Беренче булышчысы, уң кулы дисәң дә ярый, миңа телефоннан шалтыратып, фәлән көнгә табын әзерләргә боерган иде. Өстән кушкач, йөгерә-чаба үтәми булмый. «Сезгә каршы этлек план корачакларын мин каян белим, үзегезнең төчкергәнегезгә дә, башкасына да ярхәмикалла дип торучылар иде ләса ул мәҗлестә», дип карыйм, ишетүче юк. Яраннарының әле берсе, әле икенчесе, эшемдәге юк җитешсезлекне бар итеп, турыны да кыекка чыгарып, минем бакчага таш томыра. Минем дә ачу купты. Сорау бирүчене шыр тилегә чыгара торган җаваплар телгә килеп кенә тора. Күрәм, гаепләүләренең нигезсезлеген чәлпәрәмә китерүче дәлилләрем агайның ачуын кабарта гына бара. Башта бурлаттай кызарды моның чырае, аннары агара төште һәм тора-бара яшелләнә үк башлады. Тәрәзәдән шундагы Татарстан байрагына төшеп уйнаган яктылык кайтарылып, шулай төрләндердеме, шайтан белсен... «Беләм мин синең эшләгәнеңне, ишәк тә эшли!» – дип үкерде бу бер мәлне. Һәм шул мизгелдә аның текмә-тек маймылга охшаганлыгын аңыштым. Аермачык күрәм, агайның умыртка сөяге җилкәсенә җитәрәк, сорау билгесенә охшап, капылт дуга булып бөгелгән. Кәкре куллары озын, ә киң борын тишекләреннән мүк сыман йонургый. Калын кашлары гүяки тулаем йөнтәс танавын кырып хасил ителгән... Маңгае тар, булса булыр нибары ике бармак иңе, алгы яктан пеләшләнүе генә аны ерактан киң күрсәтеп күзне саташтыра икән. Абайлап алам, моның тирәсендәгеләр дә килеш-килбәтләре, үз-үзләрен тотышлары белән һәм фикер сөрешләрендәге кәкрәю-тураюлары аша да шул җан иясенә иш. Миннән ни көткәннәрен төшенеп, гаҗиз хәлдә кабул итү бүлмәсенә атылып чыгам һәм, иреннәре җете кызылга буялган, нечкә билле, мул арт санлы ниндидер мартышка киңәшенә буйсынып, үз теләгем белән эштән китү хакында, әйткәннәрен сүзгә-сүз тезеп, гариза сырлыйм.

– Ашыкмадың микән? – дип мөгрәп куя Адмирал.

– Ә нишләргә боерасыз? Кая барма, хуҗаның йөгерек күзле шимпанзе, горилла, орангутанг, лемур табигатьле туган-тумачасы, әшнәләре... Ә мин шулардан кимме? Ай үттеме-юкмы, тырыша-тырмаша торгач, күңелемә хуш шул даирә станына кабаттан әйләнеп кайта алдым, һәм, кем әйтмешли, янә пальмадан пальмага сикереп, кокос чикләвеге чирттереп яткан көн...

– Ничек алай ансат кына?

– Ансат түгел, парин. Батып барганда, бер хәтәр текә танышым йонлач кулын сузды. Инде, кирәге бүтән чыкмастыр, дип уйлап, элек кылган игелекләрен оныта, аннан читләшә дә башлаган идем. Яхшылык хәтердә озак сакланмый, яманлык кына мәңге истән чыкмый бит ул. Берәр нәрсә сорасаң, колагы кызара башлый аның, шул сыйфатын өнәми идем. Һәм, маңканы агызып, кабат шул кешегә барып аудым... Ул, билгеле, башта әйтәселәрен тезде... Аннары, урыс әйтмешли, мине «отмазал»...

– Димәк, бар да тәртиптә?

– Ут йотуларымны әни авыр кичергән. Бар да урынына утырды, дип җиңел сулыш алган көннәрнең берендә якты дөньядан китеп барды...

...Олыгая төшкән саен, сабыйлыгыңа якынаясың, кемгәдер нарасый чактагыча елышасы килү тойгысы арта бара... Зур гына берләшмәдә техник күзәтчелек мәшгулиятендәге Госман дустыбыз кыйссасы да ахыр чиктә шул фикерне өлешчә булса да куәтләүгә кайтып калды... Аның Казаннан электр

поездында мәҗлесебезгә кайтышлый юлыккан маҗарасы шактый гыйбрәтле булып чыкты... Госманның тавышы җанга ятыш, салмак, һәрвакыттагыча, ул сүз тәмен һәм үз кадерен белеп, сеңдереп, шома сөйли. Усал телләр Госман әфәнденең, һәр чыгышын көзгегә карап ятлый, дип гайбәтен сата. Шулмы гаеп? Үрнәк аласы урында, урынсыз ыржаю. Мөкәммәл җөмлә төзи белүчеләр ник кимегән, корыштырганнарында мәгънә коргаксыган, радиолардан берсеннән-берсе ямьсез тавышлы алып баручыларның төчеләнеп һәм ахахайлап тозсызланулары, ясалма көлүләре, ялган шатланулары, риядан борчылулары тәмам азу ярган, ә алар белән әңгәмәгә дәшелгән мөһим вазифа ияләренең бер-берсенә бәйләнешле рәттән өч җөмлә төзеп әйтә алуы могҗиза буларак кабул ителә башлаган, ихласлык компрыкка тибәрелгән бер заманда, җырлап торган эзлекле сөйләмгә юлыгу, кем әйтмешли, тәнгә сихәт, җанга рәхәт ул...

«...Димәк, сезнең белән күрешү ниятеннән юлга җыендым, – дип башлады Госман әкәбез. – Гаражымдагы өч машинаның берсен хатын иярләп, таң тишегеннән кияүләргә чыгып тайган, олы кыз шалтыраткан, имеш, икенчесен малай алып сызган, өченчесе кыз карамагында, анысы кая олаккандыр, шайтан белсен, һәм мин, «самый кирәк чагында, атаң өйдә булмады», дип, баласына зарланган хатын сыман, берүзем «атсыз» торып калганмын. Нишлисең, автобуска утырдым да дырык-дырык вокзалга юл тоттым. Вокзал, пардан зәңгәр бушлат кигән каравылчылар белән тутырык икән хәзер. Беренче катта да эленке-салынкы кайнашалар, икенчесендә дә шулар эштеренә. Казна киеме кигән әлеге ваемсыз чырайлы затлар миңа шик белдереп, сөзеп-сөзеп карап узалар. Чак кына арурак дигәннәре металл сизүче махсус капкадан капшап-тикшереп эчкә уздырды. Билет алыйм дисәм, касса тәрәзәләренә «тәнәфес» дип язып куйганнар. Автобустан төшкәндә, кыек басып, аякны авырттырган идем, биредә икенче катка көйләнгән эскалатор ватылган булып чыкты, ничек кирәк алай баскычтан тәпи-тәпи югары күтәрелдем. Киттем, күрсәткеч буенча бәдрәфханә юллап. Анысының ишегендә «ремонт» дигән язу эленеп, иң якын хаҗәтханәнең кызыл бинада булуы хәбәр ителә. Юл тотам кызыл бинага. Кызылында каравылчылар тагын да ишле булып чыкты. Центнер, центнер ярымлы, хөрәсәнлекләре һәм хәрәкәтләрендә шәйләнгән, күз карашларыннан сирпелгән мондый нөсхәләрне кайлардан табып бетергәннәрдер... Ничек кирәк алай тикшерүләрен узып, патша җәяү бара торган җирне эзләп тапсам, ишек катындагы будка тәрәзәсеннән йокыданмы, башкасыннанмы шешенгән йөзле хатынның кабартма авызы, иренеп кенә, «егерме сум», дип мыгырдана... Билет булса, бушлай кереп булуын әйтеп тормый җиңгәгез. Ә миндәйләргә билет юклык касса өчен тәнәфес оештырып хәл ителгән. Кем белә, бәлкем, бәдрәф бер көтү каравылчылар штатын финанслау чыганагы булып калгандыр?.. Кесәмнән меңлекне алып хатынга сузам. Теге баш чайкый, вагым юк, ди... Будка бәләкәй, хатын зур, ул аны гүяки киеп куйган... Тутагыз шуннан көч-хәл сыдырылып шуып чыга да, мине озаклап тентеп-тикшереп керткән ишек катына барып, бушлатлылардан меңлегемне ваклатып килә...

Вокзал идәнен юып тазартучы агрегат биредә үзйөрешле түгел, ә этеп азапланулы икән һәм аны, адым саен кабелен сүтеп һәм җыеп, билгеле бер аралыкта урнаштырылган розеткаларга тоташтырып эшләтәсе... Яхшы, хуш, миңа дигән электричка китәргә егерме минут кала, аның кайдалыгын

игълан иттеләр. Турникет аша абына-сөртенә чыгып, башта мәтәлә-казала бишенче катка йөгереп менеп, әйтелгән юлга барасы, аннары шул югарыгы каттан перронгача йөгереп төшәсе. Анда лифт бар барын, әмма эшлиме ул, юкмы, эләгеп буламы, аңышып торырга вакыт тар. Төшкәндә ишекләре ачык иде дә, ярты юлда эләгеп калу ихтималыннан шөлләп, ул уңайлыктан файдаланырга базмадым. Егерме минут үтте дигәндә, бер вагонга кереп, ишек катындагы рәтне калдырып, икенчесенә барып җирләшүем булды, кузгалып та киттек. Электр поезды бер алып биреп китсә, хутлы элдерә икән... Тимер тәгәрмәчләр «кайтасың», «кайтасың», дип җанны алгысыта. Кайтабыз. Вагонда халык әллә ни ишле түгел, алай да әңгәмәләр кушылышыннан туган гөж, тәгәрмәчләр тыкылдавы кысасында йокыны китереп тирбәтә, мәмрәтә. Изрәп йокыга китәргә, вакыт-вакыт әле ачылып, әле ябылып торучы шудырма ишек чыгарган дыкылдау һәм тамбурдан кергән тәмәке сасысы комачаулый. Анысына да күнегер идең, әледән-әле билет тикшерүчеләр өере бимазалый. Инде алары да тынычланып, каядыр сеңгәч, бераз черем итеп алырга була, дигәндә генә, салонда янә ниндидер ыгы-зыгы купты. Соңгы рәттә урнашкан әзмәвер гәүдәле сәрхуш ир-ат йодрыкларына ирек биргән, янәшәсенә туры килгән күршесе, гөжләп кан саркыган авыз-борынын учы белән каплый төшеп, ишеккә ташланды. Сугыш чукмары исә аны куалап вакланмады, бу матавыктан котылырга омтылып урыныннан купкан икенче күршесенең дә ипи шүрлегенә менеп төште. Бәладән башаяк, дип, таярга маташкан күршесе кискән агачтай аугач, бичараның касыгына ботинкасы белән каерылып тибәргә дә онытмады. Теге мескен, ничек кирәк алай, дүртаякланып, шудырма ишек ачылган шәпкә тамбурга атылып чыгарлык дәрман таба алды тагын... Юка гәүдәле, кара яулык япкан әбекәй, каударланып, «улым», «улыкаем», дия-дия, чыгырыннан чыгучыны тынычландырырга азаплана, әмма күкрәге җиңү дәрте белән тулышып алгысыган ир-ат өчен аның чапалануы, бәйләнчек черки безелдәве сыман гына тоелгандыр... Бермәл, гүяки кисәк яңгыраган уртак әмергә буйсынган сыман, арткы рәттәге пассажирлар дәррәү урыннарыннан купты. Әһә, минәйтәм, хулиганны, уртага алып, «эре иләктән иләмәкче» болар. Тик ялгышканмын, гомуми кузгалыш тәртип урнаштыру ниятеннән түгел, ә һәркем үзе хакында борчылып, бәладән ераккарак качу, күченү хәстәрен күрә булып чыкты. Мин әллә нәрсәсенә ирендем, гомуми талпынышка иярмәдем, «тамыр җибәргән» урынымны ташлыйсым килмәде. Алай да ыгы-зыгы купкан почмакка күз ташламый да булмый. Карашларыбыз очрашты, һәм чамаладым: йодрыкларына ирек бирүченең минем белән дә аңлашырга исәбе юк түгел... Менә ул, урыныннан торып, каршыма күчеп утырды. Майлы тонык карашы белән сөзеп баштанаяк күздән кичерә абзагызны. Әшәке итеп елмая. Уң кулыма күн перчаткамны кияргә өлгерәм. Йодрыклар җыйнак минем, селтәнергә туры килгән мәлләрдә, бармаклар таралып очмавын кайгыртмый булмый. Менә каршымдагы әзмәвер урыныннан куба. Мин дә җәлт кенә, тегене тәрәзә янында калдырып, аралыкка чыгып басам. Һәм без, ике утыргыч арасында йөзгә-йөз, Тукай язганча, «күзгә күзне нык терәп» тын торабыз. Беләм, моның ишеләрдә эт холкы, карашыңда әз генә курку сизелсә дә, бугазыңа ыргылачак. «Төкерәм мин сиңа» дигән мыскыллы елмаю да әзмәвернең сабырын төкәндерә күрәсең, саллы йодрыгының күз төбемә турылануын

абайлыйм. Тидерә алса, башны өзүе бик мөмкин, шайтан алгыры... Минем бәхеткә, әлеге әфәнде ярыйсы гына салган, авырлык үзәген саклау турында кайгыртмый. Башны кырыйга алып калырга өлгерәм, алай да татуировкалы йодрыгы колакны яндырып ышкылып үтә... Инде сугуы бушлыкка тару аркасында алга сөрлеккән эре гәүдә мәтәлсен өчен, юлыннан читкә тайпыла төшеп, аяк чалып, җилкәсеннән алга йолкытырга, аңа юнәлеш бирергә генә кала. Һәм, ишелеп барган мәлендә нечкә җиренә типми дә булмый, югыйсә, кем әйтмешли, салондагы халык дөрес аңламаска мөмкин... Таудай гәүдәле сәрхуш йөзтүбән барып төшкәч, тын алганын көтеп тормый, башына аяк белән басып, «кузгалсаң, күзеңне тибеп очырам», дип кисәтәм. Мондый чакта әмернең кыска – миендә сыңар сыры барларга да барып җитешле булуы хәерле. Вагонда шәхси хакимиятен шактый уңышлы урнаштыра башлаган кемсә, инде бите белән пычрак идәнне «үптерүгә» карышмый. Ул арада арык гәүдәле кара яулыклы кечтеки әбекәй кырыма килеп, «улым, зинһар, үтерә күрмә», дип, бии-бии ялварырга керешә. Мин аяк астымда ятучыга:

– Әниең сүзен тыңла моннан ары, – дим дә гәүдәсе аша, артына басып, башмак эзе калдырып атлап чыгам һәм кабат урыныма барып утырам.

Әби, каударланып, тәүфыйксыз малаена торырга булыша, кадерлесен, куркыныч урыннан тизрәк, «әйдә, әйдә», дип читкә өстери, һәм алар ничек кирәк – алай кабат үз урыннарына барып урнашалар. Вагонда тынлык хөкем сөрә, гөжләү туктаган, тәгәрмәчләр генә тыкылдый. Тегесе дә, монысы да кызыксынып мине күзәтә. Берсе, теләктәшлек белдереп, баш бармагын күрсәтеп, ахмакларча елмая да...

Хәлбуки, ун-унбиш минут үттеме-юкмы, теге бәндә кабат урыныннан куба. Торып баскач һәм як-ягына каранып алгач, тәвәккәлләп алга, халык ишле тарафка, салон түренә төбәп кузгала. Кырымнан узышлый, болганчык карашын минем тарафка ташлап ала, үз итеп күз кысуыма тешләрен шыгырдата һәм ары китә. Ул да булмый, ирле-хатынлы рәткә туктап, берара чама тартып карап торгач, саллы йодрыкларыннан икесенә дә өлеш чыгара. Миңа исә алга таба вакыйгалар үрелеше ничек дәвам итәчәген кызыксынып күзәтергә генә кала. Мәгълүм ки, кешеләр иҗтимагый корылыштан арына алмый. Рәсмие колачламаган мәлләрдә «үзешчән» әйдаманнар «йөк»не үз җилкәләренә алырга гына тора. Балалар бакчасыннан, мәктәпләрдән керешеп, армия һәм төрмәләрдә дә хадимнәр юк чакта, «патшалы» уены уйнала. Хәтта вагонда вакытлыча гына булса да баш буласы килү ихтыяҗы бар булып чыкты. Беләм, идәндә күрәләтә аунатылу белән, бу дәгъвачының инде укасы коелды. Шул хәлдән соң вагон дәрәҗәсендәге хакимияткә ирешергә маташырга инде соң, аның аңа дәхеле төкәнде, һәм мондый, урынсыз талпынышны гафу итмәячәк затлар табылырга тиеш... Чебиләр арасында да, берсенең артын икенчесе чукып канатса, кан күргән кошлар яралаучыны, чиратлап чукып, үтерми туктамый. Хәтерлисезме, Гүзәл Яхина дигән язучының урыс телендәге китабы Мәскәүләрдә бик югары бәяләнгәч, башта берәү чукырга азапланды, аның башлангычына икенчесе иярде, өченчесе чәчрәп чыкты... Безнең Әмир, инстинктка буйсынып, шул каләмдәшләренә кушылмаса гына ярар иде, дип кан калтырап тордым. Кетәклекне – ватан, киртәне тәхет санаучылар, үзләренең кытаклауларын җыр дип инанулары сәбәпле, әнә шулай ду кубып алдылар... Иманым

камил, биредә дә «кызыл чеби»ләргә хас шаукым чагылыш табачак! Хактан да, иң соңгы рәттә утырган ике егет бер-берсенә карашып алдылар да, урыннарыннан торып, кулларына ирек бирүчегә таба юнәлделәр. Сүз озайтып тормастан, берсе, сугыш чукмарының артына төшеп, ике кулын култык астыннан уздырды һәм муенын йозаклады, ә икенчесе, кай җире кычыта, һәйбәтләп керендерергә кереште. Бичара әби дә шул тирәдә әбәләнде, тик аның инәлүенә боларның исләре китми булып чыкты... Ахыр чиктә шактый кызганыч хәлгә төшкән бәндәне, ора-тибә, үз урынына озатып куйдылар... Вагонда ниндидер шыксыз тынлык урнашты. Тәгәрмәчләр шыкылдавы яңакка, касыкка бәргән сыман итә башлады. Ләкин, тора-бара тагын бар да янә үз эзенә төште, билет тикшерүчеләр керде, аларның үзләрен тәфтишләүчеләр пәйда булды, әңгәмәләр яңарып, салонда гөж яңарды, һәм янә изрәтә башлады. Йокыга китеп кенә барганда, кемдер җиңемнән тартып уятты. Күзләрне уып, яхшылабрак карасам, милиция хезмәткәре. Мин аны, кондуктор, дип буталып, кесәмнән алып билет сузам.

– Исәнмесез. Сезгә әнә теге хулиган бәйләнгән, диделәр? – ди погонлы, мине очлы карашы белән бораулап.

Вагон патшасы булу хыялы чәлпәрәмә утырган тарафына карыйм. Битенә идән пычрагы йоккан, йодрыклар төшүеннән шешенеп киткән чырайлы танышым катында янә бер милиционер кунаклаган булып чыкты...

– Бер дә таныган кешем түгел.

– Вагонда ут өереп сугышканны күрмәдегезме? – ди милиционер, иренен бүлтәйтеп.

– Ә үзегез кайда идегез соң, ут өереп сугышканда?

– Сорауларны биредә мин бирәм. Ул Сезгә бәйләнгән. Менә бу иптәш шулай дип раслый.

Як-якка каранам, һәм миңа баш бармак күрсәтүченең катымда елмаеп торуын абайлыйм.

– Сез, мине бу исерекне кыйнады, дип күрсәтмә бирдегезме? – дип сорыйм аңардан.

– Юк, юк. Сез нәрсә, – дип өтәләнә баш бармак күрсәтүче. – Сез идәндә аунатмасагыз, аның арт сабагын укыткан ике егет тә хулиганга сүз катарга базмый иде, дидем генә мин.

– Ә кайда соң ул батыр юлдашларыгыз?

– Төшеп калдылар.

Милиция хезмәткәренә яртылаш борылып:

– Мин бирегә күрше вагоннан күчеп утырдым, – дип белдерәм. – Монда бер мужик утыра иде. Иптәш мине шуның белән бутый бугай?

Милиционер сораулы карашын баш бармак күрсәтүчегә юнәлтә. Теге «әллә тагын» дигән мәгънәдә җилкәләрен сикертә...

– Кайда соң ул мужик?

– Ә мин белергә тиешме?

– Бик кыю сөйләшәсең син, абзый кеше, кем дип белик үзеңне? Документың бармы?

– Гражданин.

– Нәрсә?

– Конституциянең икенче маддәсе нигезендә, дәүләт өчен иң югары кыйммәткә ия зат. Аттестация узсагыз, сез моны белергә тиеш идегез...

Паспортны күрсәтәсеме? Таныклыкнымы? Бәлки, әүвәл үзегез белән таныштырырсыз, лейтенант әфәнде?

Әңгәмәдәшем, минем кесәдән ала башлаган ике башлы сәмругкош сурәтле таныклыгымның читен күрүгә, капылт тынычланып:

– Ярый, ярый. Хәерле юл сезгә. Борчыган булсам, гафу итегез, служба шундый. Лейтенант Ибраев булам, – дип, честь биреп, елмая-елмая, чигенә-чигенә, коллегасы катына ашыга.

Тәртип саклаучылар авыз-борыны җимерек, тәмам юашланып калган юлдашыбызны, урыныннан кузгатып, этә-төртә алга юнәлтәләр. Теге өч-дүрт адым киткәч абынып, идәнгә утыра. Кара яулыклы юка гәүдәле әби дә күләгә сыман шул тирәдә кайнаша. Чүгә-чүгә нидер сөйли, ялвара. Егетләр әзмәверне өстерәп карыйлар, әмма нәтиҗә «ай киттек, ел киттек, энә буе җир үттек» шае. Әңгәмәдәш погонлы егет аптыраган кыяфәттә миңа мөлдерәп карый. Мин, дустанә елмаеп, күз кысам һәм җиңелчә генә кул селтим. Һәм форма кигән егетләр, «табышларын» калдырып, вагоннан чыгып китәләр. Аларны аңлап була билгеле, үзе тәпиләмәгәндә, мондый центнер ярымлы бәндәне күтәреп йөртү ни пычагыма?! Бик күп булса, нибары унбиш тәүлеклек «таяк» эшләнә, ә хулиганлык маддәсе «тегәргә» шаһитлар юк. Күренеп тора, тәҗрибәләре дә сай. Безнең участковый андый әзмәверләрнең артына төшеп, бер кулы белән җилкәсеннән, ә икенче кулын ботлары арасына тыгып, нечкә җиреннән умырып тота да этеп алып китә, теге мескенгә аяк очларына басып, вак адымнар белән йөгерә башлаудан гайре әмәл дә калмый...

Әби, кәкрәя-бөкрәя, улына янә торырга ярдәм итә, аннары аны иң якын утыргычка таба этеп утырта... Башындагы яулыгын салып, башта тирләгән үз битләрен, аннары сөекле улының пычранган чыраен ышкып тазарта башлый...»

Госман сөйләүдән туктый. Без аның кыйссасы дәрьясында йомычка булып агабызмы, йөзәбезме, һушка килә алмый торабыз. Тынлыкны бу юлы да һәрвакыт аек акыллы Адмирал бүлә:

– Шуннан ни?

– Һаман да шул чеби теориясе, Адмирал әфәнде.

– Нәкъ Әхмәт очрагындагыча.

– Ниткән чеби теориясе тагын?

– Милиционерлар да бит чукылганны чукырга килеп җитеште... Һәм минем кыйссада да бердәнбер чын кеше – әби. Әни кеше...

Тамак чылатып, бераз капкалап алгач, иң текә иномарка иясе Әгъләметдин сүз алды...

...«Мин карьера ясарга бәләкәйдән керештем, – дип башлады ул үзенең хикәясен. – Элек авылда мал-туар ишле, сарыгын, сыерын, танасын аерым-аерым чиратка салмый чыгарсаң, урамга сыймаслык була торган иде. Әти юк, әни берүзе тормыш арбасын өстерәп чиләнә, мин исә – борын асты кипмәгән олы малай. Алай да елдан-ел дәрәҗәм күтәрелә бара. Башта ат көтүе көттем. Аннары авылдашлар, сарык көтүе көтәргә лаек, дип таптылар. Өченче елны – таналар, ә аннан соң савым сыерларын ышанып тапшырдылар. Өч кеше алындык анысына: мин, бер аягы гарип Әшрәфҗан абый һәм шуның Равил атлы энесе. Көтүлек җире әкәмәт шәп безнең, көн уртасында малларны чишмәле урман аланына кертәбез. Бүтән урында маллар төш тирәсендә

ике сәгать ятып ял итсә, биредә дүрт сәгатьсез кузгаласылары килми. Ә сәгатьне аяк табаны белән күләгә үлчәп чамалыйбыз. Вакыт иркен, хет йоклап ял ит, хет берәр эш тап. Әмма Равил тынгысызлый, әйдә, көрәшәбез, дип тинтерәтә. Син миннән зур бит, дип карыйм үзенә. Муен тамырына кундыра, артка тибә, төрлечә каһәрли. Күнми кая барасың. Көрәшәбез. Өч яшькә аерма бала чакта нык сиздерә, моның борыны астына инде мыек типкән. Алай да бирешәсем килми, этләшәм, бөтереләм, күкрәге астына керәм, читкә йолкынам – ектырмыйм тегеңә. Гарьлегеннән бу мине муеннан кысып аска бөгә дә йодрыгы белән башны төя башлый. Әшрәфҗан абый ыржаеп көлеп тик карап тора. «Көч кенә керсен, исеңә төшерәм әле мин боларны!» – дип карыйм. Юк, әшәкелеген арттыра гына, мәлгунь. Беләә, эти юк, абыйлар юк. Узынуы – яклаучым булмаганга. Берсендә каты ук эләктерде, күзгә чыккан яшьләрне җиң очы белән ышкый-ышкый, «бүтән болай яшәп булмый», дип, эш ташлап өйгә кайтып киттем. Әни фермага ат җигеп йөри иде минем, бидоннар белән сөт ташый, күтәрә шуларны, төшерә, эре сөякле иде мәрхүмәкәй. Әбәдкә кайтып керде бу. Син нишләп囗 эштә түгел, дип тәфтишли. Башта ык-мык килдем. Кыйналу хакында сөйләргә тел бармый, горурлык мишәйт итә. Җилтерәтә башлагач, күңел чайпалып китеп, буа ерылды, дөресен сөйләп аттым. «Әйдәле! Утыр арбага!» – диде әни. Киттек кузгалып. Әни, ике кулы белән дилбегәгә тотынып, аякларын аерып кабык арбага баскан, күк биянең сыртын дилбегә очы белән каезлапмы-каезлый. Аланга чаптырып барып кердек. Тегеләр абыйлы-энеле ипи белән күкәй ашап, шешәдән сөт чөмереп утыралар. Әни, ыжгырып килә-килешкә Әшрәфҗан абыйны гарип аягыннан эләктереп җиргә сөйрәп төшерде дә: «Син нигә фәләненә җон чыккан энеңне тыймыйсың, аксак тәре?!» – дип, зур кытыршы учлары белән моны шапы-шопы яңакларга да кереште. Әни булгач, миңа да йөрәк керде, батыраеп Равилнең бугазына барып ябыштым. Чыбыркысы янында аркылы ята иде, шуны эләктереп алып, шомарып сөякләнгән сабы белән шалт башына! Җирләр акыра малаең. Бермәл ычкынып китеп, торып ук йөгерде.

...Еллар үтте. Армиядән кайткан елны авыл Сабан туенда батыр калдым. Элек кичке уеннар бик күңелле иде: гармунда сыздыру, җырлап бию, наза уйнау дисеңме. Буа янында уза иде ул безнең. Шуны урталай бүлеп ай юлы сызылган. Әлеге «дус» – Равил очрап тора. «Яшьти, тимә, гаеп миндә булган», – дип, күзгә мөлдерәп карый. Бераз салган. Өр-яңа кәчтүмнән. «Нинди яшьти булыйм ди мин сиңа? – дим. – Сикер суга! Йөз, колач салып!» Китте бу кереп. Бермәл аркам белән тоям, кемдер миңа төбәп карап тора. Киртә белән тондырмагайлары тагы, дип борылсам – әни. Шелтәләп, баш чайкый...»

– Булмаса булган икән, кая, мин дә сөйлим, алай булгач, дип, утырган җиреннән калкынып куйды авылда калып, тәрәзә-ишек, башка шундый эшләнмәләр ясап көн күрүче алтын куллы дустыбыз Хөснулла. – Эчеп җибәр салганын, сорама каян алганын, дип җырлыйлармы әле, берәрне төчкертик тә аннары мин сөйләгәнне тыныч кына йотып утырасы була. Тоттыгызмы? Тотсагыз, башлыйм.

– Ашыктырма, Хөсни. Үзең дә капкала. Күрәм, чабышка җыенган ат сыман ярсыгансың.

– Яшь фил кебек дулкынлана, – дип өсти Әмир.

– Әйдәгез, тоткарламыйк, югыйсә ялындыра башламагае. Сүз сиңа, Хөсни, чурт с ни...

– Рәхмәт, Адмирал әфәнде. Димәк, менә болай. Минем ике апам тугач, сугыш башлана. Әти сугыштан исән кайта һәм янә ике кыздан соң, көтеп алган малай, мин дөньяга аваз салам. Әти яуда чакта ике бала белән торып калган әни тормышның ачысын-төчесен җитәрлек татый. Элек авылда эш кенә түгел, әле чират буенча дежур, ягъни кизү тору тәртибе дә булган. Кышкы бер көндә моңа әнә шул кизү чираты тәртибендә район үзәгенә пакет илтергә куша авыл советы рәисәсе. Иптәшкә ундүрт яшьлек бер кызны ияртәләр. Буран чыгып тора, дигәнгә дә йомшамый рәисә хатын, ашыгыч илтергә кирәк, төрмәгә китәсең киләме әллә, дип җикеренә. Әнкәй белән үсмер кыз җиде чакрым ераклыкта урнашкан район үзәгенә җәяүләп чыгып китәләр. Өстә юка телогрейка, башта җеп шәл, аякта иске чабата, юлга чыкканда ашаган ризыклары – алабута күмәче...

Районга җитеп, башкарма комитетны табып, кирәкле кешене көтеп алып, шул пакетны тапшырып кайтырга чыкканда, җәяүле буран көчәя төшә. Күпмедер вакыттан соң ул котыра ук башлап, бермәл басуда күк белән җир тоташа, бернәрсә күренмәслек була һәм болар адашалар. Адашып караганнар белә, әллә кайлардан әйләнеп йөрелә... Шактый чакрымнар узгач, үсмер кыз бала йончып, тәмам хәлдән тая. Әни аны арка кочтырып юлын дәвам итә. Бара торгач, безнең Ямбулаттан алты-җиде чакрым читтә урнашкан күрше авылга бөтенләй икенче яклап килеп чыгалар. Хәер, алай әйтү дөрес үк булмый, чөнки аркадагы юлдаш сулыш алудан туктаган икән. Әни аны бер агач төбенә сөяп калдыра да, зират почмагы абайланган авылга үрмәләп диярлек барып җитеп, иң кырый йортның ишеген кага. Анда үзе сыман ике балалы хатын яши икән. Өендә бер кыерчык икмәге юк, миче суык. Карап торган кәҗәсе бар, һәм шул хатын абзарга кәҗәсен саварга чыгып китә. Җеп өзәрлек хәле калмаган әнигә хәзинәсендә барын, ягъни яңа савылган шул ярты кружка сөтне эчерә. Бу юмартлыкны бәһаләп бетерерлек түгел – күрше авыл хатыны асылда бер белмәгән кешенең өзелә язган гомерен үзе һәм ике баласы гомереннән өлеш кисеп ялгый...

Әни, әнә шул ярты кружка сөттән алган егәр белән, кар ерып, авылыбызга кайтып җитә, туры авыл советына барып, хәлне аңлата. Авыл советы рәисәсе аңа «кеше үтерүче» дип ташлана, өтермәдә черетәм, дип яный... Кызның әнисе Хәмдениса апа шунда була, яман хәбәрне ишеткәч, сыгылыплар төшә... Ат җигеп, кемнәрдер әни әйткән агач төбен эзләп китәләр һәм өч сәгать йөреп, тапмый кайталар. Янә әнине утыртып алып китә болар. Аның да өйдә ике баласы бар югыйсә, ачмы алар, тукмы – монысын тикшергән кеше юк... Агач төбендә калган кыз бала табыла... Бәхеткә, эт-кош тимәгән. Районнан милиция һәм табиб килеп җитеп, мәетне тикшереп, әнине гаепсезгә чыгаралар...

Менә сугыштан мәрхүмә кызның әтисе Габделхәй абый кайтып төшә. Ә әни аның күзенә күренергә яхшысынмый, очраганда, барган җиреннән борылып, гел читкә тайпылу ягын карый. Ә беркөнне Габделхәй абый өебезгә үзе килә. Керергә рөхсәт сорый, исәнләшә. Аннары болай ди:

– Мин сугышта йөз меңнәрнең кырылуын күреп кайттым, сеңлем. Газиз кызымның үлеме – шул фаҗиганең бер йомычкасы... Сиңа үпкә сакламыйм,

синең бер гаебең дә юк, берүк миннән дә, Хәмдия апаңнан да читләшмә, кыенсынма...

Бу хәлләрдән соң күп еллар узгач булды монысы, салкын кара көзнең җилле бер көне иде, без өч малай – авыл советы сәркатибенең улы Наил, мин, Габделхәй абыйның төпчеге Рәшит – бәрәңгесе алынган бакчабыз читендә учак ягып, бәрәңге пешерергә ниятләдек. Учагыбыз дөрли башлап, рәхәтләнеп җылынырга өлгермәдек, бакча башыбызда күзләре тонган һәм акайган өч-дүрт ир-ат пәйда булды һәм болар безгә таба атыла-бәрелә йөгерә башладылар. Качарга омтылдык, өлгермәдек, сүгенә-сүгенә эләктереп алдылар да, җилтерәтеп, каккалап-типкәләп, колхоз идарәсе һәм авыл советы урнашкан кәнсәләрнең әле миче дә чыгарылмаган, эшләнеп бетмәгән яңа ягына кертеп, өстән бикләп алдылар. Бүлмә суык һәм караңгы иде, берзаман тамак та ача башлады. Яшьтиләр безгә ашарга ипи белән алма алып килделәр. Тәрәзә борысы өстендә калдырылган арадан, кулга шырпы кертә-кертә, күчтәнәчләрне кабул итеп алдык. Вакыт-вакыт ишекне ачып, безне барлыйлар һәм яныйлар: имеш, район үзәгеннән милициягә, аннары өтермәнгә озатачаклар. Урнашкан бүлмәбезнең бер дивары артында бухгалтер белән читават шалт та шолт чут төймәсе тарта. Тәрәзәгә килгән дуслар әйтүенә караганда, минем әни безне яклап нидер әйтергә тырышып караган икән дә, «этлекнең башы – синең малайда», дип, аны тиз туктатканнар. Наилнең әтисе, гомумән, каты кыланды, үз улы дип тормастан, әле кертеп япканчы ук, аңа биргәләп алырга өлгерде... Ихтимал, сугыш инвалиды агай, янгын чыгара язуда гаепләнүче без фәкыйрьләргә карата нәфрәтле һәм каныбызга сусап ярсыган төркемне суыта төшү өчен, юри кырыс кылангандыр...

– Әни белми минем монда икәнне, әни белсә, ничек тә коткарыр иде, – дип, авыр сулый Рәшит дустыбыз.

Рәхмәт төшкере, Рәшитнең әнисе Хәмдениса апага кемнәрдер безнең хәлне ирештергән булып чыкты. Иелебрәк, ыңгырашыбрак атлый торган иде ул, авыр хезмәт елларыннан «сәлам» булып тәне, буыннары сызлагандыр, күрәсең. Әле әнисе урамда чакта ук, кәнсәгә кереп җитмәгән килеш үк, сыкрап сулыш алуыннан таныган Рәшит, күзләрен очкынландырып елмаеп:

– Әни!.. – дип шатланып кычкырып җибәрде.

Өчебез дә шәмәрешеп, колакларны ишеккә терәп, тын калдык. Ул арада Хәмдениса апаның ишекне шыгырдатып ачып, тупсадан кергәне, янә ыңгырашып куйганы ишетелде.

– Нәрсә, – диде ул әкрен, йомшак тавышы белән, әмма һәркемгә дә ишетелерлек итеп, – бер кызымны үтергән идегез, инде улыма керештегезме?!

Үле тынлык урнашты. Ул да булмый, ишек шартлап ачылды һәм без шунда ук азат ителдек. Бүтән ут белән уйнамаска сүз дә бирдерделәр шикелле. Рәшит сүз биреп мәшәкатьләнмәде, чөнки улын җитәкләгән, ялкын бөркегән күзләрен яшь каплаган ананы тоткарларга берәү дә йөрәксенмәде...

Кымыз кыздыра ахры, дусларыбыз укучы малайлар сыман, кулларын күтәрә төшеп селки-селки, «мин сөйлим» дә «мин сөйлим», дип, Адмиралны бимазалыйлар. Җитди көндәшлек шартларында сүз дилбегәсе күрше авыл егете, һөнәри шагыйрь буларак танылып килүче Әмиргә күчте...

– «Кеше барыбер кошлар нәселеннән», дип язган иде бер затлы шагыйрәбез,

– дип кереште сүздән чәчәк ясый белүче уйчан дустыбыз. – Адмирал безне диңгез бүреләренә охшатып тост әйтте. Ә чынлыкта көтүдәге сарыкларга охшыйбыз түгелме? Менә бит әкәмәт, берәү керешкән тема башкаларны да үз кәлиясенә сөйрәп төшерә... Әниләр турында сөйләшәбез... Миңа ошый. Мин каршы түгел...

– Ике ноктаны туры сызык тоташтыра, – дип куйды Адмирал. – Әйдә конкретрак.

Әмир, аны ишетмәде дә бугай, тыныч кына башлаганын дәвам итте:

– Сабый чакта кызлар, малайлар бергә, дөнья бетереп урамда уйнаганда, маңгайга-маңгай чәкешеп аласың һәм берәрсе авызын җәеп, «әнигә әйтәм мин сине», дип, сузып елап җибәрә. Чынлыкта, әнисенә кайтып әләкләүчеләр арабызда бик булмады да шикелле, ә ул сүз тезмәсе авырлык килү белән ихтыярсыз, үзлегеннән ычкына.

– Ә кем бәхәсләшә?

– Әниләр турында гыйбрәтле хәдисләр бар, байтак җырлар, әдәби әсәрләр иҗат ителгән, ә тирән мәгънәле әйтемнәрнең исәбе-хисабы юк. Безнең авылда «Ана – казна» дигәне әйләнештә йөри. Ягъни, һәркемгә чикләнүләрсез ярдәм сорап мөрәҗәгать итү мөмкинлеге тупланган чыганак, – ул сиңа тормыш бүләк иткән әниең. Аның сиңа булган мәхәббәте – бетмәс-төкәнмәс һәм иксез-чиксез. Ул – һәрвакыт, син хаксыз булганда да, бөтен дөньяга каршы барып булса да, яклаучың һәм аңлаучың.

– Килешәм, дәлше.

– Башлангыч мәктәптә укыганда, сыйныфташым Сәлмән белән авыл клубында кичен, качып кереп, «Кодин» дигән фильм карадык. Ул да, мин дә, ни гомерләр үтеп, шуны оныта алмыйбыз. Хәтердә уелып калган эчтәлек болай: төрмәдә утырып кайткан башкисәр егет карт, саран әнисе белән тыныша алмый. Аны үзе өйдә чакта гел урамдагы эскәмиягә чыгарып утырта. Шул егет бер заман мәхәббәтен очрата. Нәтиҗәдә, әнисенә карата мөгамәләсе уңай якка үзгәрә. Ә бер кичне, ниһаять, өйдә яшәү хокукына ирешкән әни кеше кухняда чүлмәктә май кыздыра һәм сөйгән ярын уйлап, бәхетле елмаеп йокыга талган улының ачык авызына китереп шуны сала... «Бу – ялган, мондый әни булмый, ул бер җен карчыгы гына», – дип чатакама килде Сәлмән яшьти. Ихтимал, ул шулай булгандыр да, чөнки фильмдагы вакыйгалар граф Дракула ватаны Румыниядә бара.

Бала чакта малай кеше сугышмый, тукмалмый гына үсми. Икенче класста парта өчен тарткалашканда, әлеге дә баягы шул дусның кулына карага манып яза торган ручка белән кадаганмын. Туган көнемдә котлау сүзе әйткәндә искә төшерде, рәхмәт яугыры.

Батыр ярасыз йөрмәс, дигән юатулы мәкальне малайларга еш ишетергә туры килә. Кайбер чәүчәләк ата-ана, балалар арасына кереп, улының йә кызының дәрәҗәсен төшереп бетерә. Бу җәһәттән мине уңайсыз хәлдә калдырулар булмады. Хәер, бер тапкыр булды бугай, әгәр шулай дип әйтергә яраса. Унынчы сыйныфта район үзәгендә укыган чак, дүшәмбе көнне беренче дәрескә соңга калуны, шимбә көнне соңгы ике дәресне калдырып качуны җайга салдым. Әле кайсы атнаны чәршәмбе көнне дә соңгы дәресне «тозлаштырам». Хикмәте шул: интернатта яшәү туйдырды, күңел авылга, әни пешергән ризыкка тарта. Дәрес калдыруның янә бер сәбәбе – элегрәк безнең авылда «сөрән сугу» дигән гадәт бар иде.

Киләчәктә армиягә алынуын күздә тотып, ир баласы булган һәр йортта мәҗлес уздырыла. «Алмагачы» көенә гармун тартып, җырлар җырлап, җиденче класстан башлап кәеф-сафа корып йөрибез, әй. Һичкем, болай ярамый, дип тыймый.

Калдырган дәресләр шактыйга җыелган һәм кышкы каникул чорында педсовет җыеп, безнең ишеләрне акылга утыртырга ниятләгәннәр. Чакыртуга буйсынып, авылдан район үзәгенә килеп, туганнарда тукталдым. Педсовет кичке дүрттәме, алтыдамы башланды. Дәрестән качучы башка сыйныфташлар миннән акыллырак булып чыкты, берсе дә килмәгән. Көн тәртибе буенча алдан ниндидер ике мәсьәлә талкынгач, «десерт»ка мине уртага чыгарып бастырдылар. Мөнбәрдән минем гаепне класс җитәкчесе бәян итте. Каладан кайткан бер кыз белән кичен кинода очрашырга сүз куешкан идек, авылга кайтып җитеп булмаска охшап тора. Мәҗлестә һәркемгә тост әйттергәннәре сыман, биредәге «тамада»ның да исәбе – берәүне дә өлешсез калдырмау. Ә, бәлки, тәртип шулай куелган булгандыр, шайтан белсен. Мин инде, үз предметларын әйбәт белгән өчен, кайбер укытучыларым яклар, һич югы рәхимлерәк кыланыр дип өметләнгән идем дә, сыйныфташ кызлар әйтмешли, «чош сиңа». Бары тик трактордан укыткан Исрафил абый белән физкультура укытучысы Ильяс абый гына гомуми юнәлештән тайпылырга җөрьәт иттеләр. Байтак укучыларга исәп тотып туплаган «запаслар» бер ялгызыңа тотылгач, авырга туры килә икән. Түзәм, күз яше күрсәтергә исәп юк, алай да ике биткә «ут капты». Кайберләре сорау да бирә, әмма ык-мык җавапларымны ошатмыйлар. Өер белән дөмбәсләгәндә, дөмбәсләнүченең фикере, хаклымы-түгелме, өч тиен дә тормый, әлбәттә. Ышанмасагыз, Әхмәттән сорагыз. «Гаиләсендә дөрес тәрбия алмаган», – дип, «фаш» итүче табылды, ниһаять. Һәм шул мәлдә бүлмә ишеге шартлап ачылды да, анда әни күренде. Ул, беркемнән рөхсәт-фәлән сорап һәм исәнләшеп тормый түргә узды. Мамык шәле артка шуышкан, туны җилбәгәй ачык, күкрәгендә орден-медальләр планкасы, мәгариф отличнигы билгесе шәйләнә. Әнине биредә таныйлар, исемен әйтеп пышылдашулары колакка керде. Залда уңайсыз тынлык урнашты. Әни «хөкемдарларым»ны һәм «хөкем» процессы шаһитларын берәм-берәм күздән кичерде. Аннары әкрен генә сүзгә кереште: «Тавышыгыз урамда, педагог иптәшләр. Коридорда, ишегегез төбендә кәмит тыңларга техничкаларыгыз җыелган. Нәрсә бар анда дигән соравыма берсе, «өерләре белән бер малайның әнәсен өшкерәләр», диде. Мине өшкерәсез булып чыга инде, ягъни мәсәлән. Нормаль коллективта мәнсезлекне авызлыкларлык хет бер абруйлы шәхес табыла. Кызганыч, сезнең арада андый шәхес юк. Баланың көндәлегендә билгеләре әйбәт, класс җитәкчесенең аны-моны язганы юк, миңа мөрәҗәгать итүчегез кая? Кем хокук бирде сезгә укучы балага Линч суды оештырырга? Бу ниткән педагогик алым?»

Әни җиңемнән эләктерде һәм, катгый итеп: «Киттек, улым. Монда бер акыллы кеше дә юк», – дип белдерде. Мин, «нишлим икән инде», дип, трактор буенча укытучы Исрафил абыйга борылдым. Ул күз кысып, елмая төшеп, баш селкеп, «китә аласың» дигән ишарә ясады. Әле генә умарта күчедәй гөж килеп торган бүлмә инде тып-тын. Әни мине җилтерәтеп диярлек алып чыгып китте. Ә тышта бурап-бурап кар ява. Әни авылның шәп атын җиктереп килгән. Ат тотучыбыз – шундый эшләргә җәлеп ителүче колхозчы Миңнулла абый иде

бугай. Ат гайрәтле, төренергә дип чанага салынган толыплар зур үлчәмле һәм калын, якалары биек, җиде чакрым араны, кар бураннары туздырып, бик тиз кайтып җиттек.

Сабыр холыклы әнинең шул чакта ни өчен күкерттәй дөртләп кабынуын үзем әти булгач аңладым. Берәрсе белән мәңге дошманлашасың килсә, баласы турында кыек сүз әйтү дә җитә икән.

...Әнием колхоз парторгы, бер үк вакытта мәктәп мөдире һәм укытучы булып эшләве, кайчак райком әгъзасы булып та сайлануы аркасында вакыты һәрчак тар булуы сәбәпле, сүзнең кыскасын сайлап, үтемлесен табып сөйләшә иде, мәрхүмә. Бермәлне, студент чагым, китәр вакыт җиткәч тә, әллә нәрсәсенә җыенып җитә алмыйм, ә аның мине озаткач, үз планнары булган, кырыс кына: «Кайткач кайтырга кирәк, киткәч китәргә кирәк ул», – дип ычкындырды. Үзе исә бик тиз китте. Бер көн дә урын өстендә аунап ятмады...

Әмир хикәясе дә Адмиралны әллә ни кузгата, дулкынландыра алмады. Ул, бушап калган чәркә-касәләрне тулыландырып чыккач, шагыйребезгә борылып:

– Безнең коллективны сарык көтүенә охшатуың ошамады, – дип куйды. Һәм: – Әйдә менә шушыны тотып куй да, сарык түгеллегеңне раслап, экспромт шигырь яз, алай бик акыллы булгач, – дип өстәде.

Әмир, касәдәге кымызны бушатып, мыекларын сыпырыштыра-сыпырыштыра, янган учакка беркавым карап уйланып торды. Аннары акрын гына:

– Акыннар гына «барган шәпкә» иҗат итә. Татарда андый практика юк бугай, – дип, икеләнүен белдерде.

– Булдыра алмыйсың икән, халтурщик, дип мөһер сугабыз. Башкалар язганны алдыңа салып, шуны төрләндереп, балалатып, сагыш, ялгыш, язмыш, җан атам, яратам сүзләрен туглаучылар сыңары булып чыгасың.

– Аһ, алаймы?!

– Түгел икән, күрсәт талантыңны. Кем әйтмешли, чыгарып сал.

– Әйе, әйе. Салып сөйләш!

– Башта сал, аннары чыгар...

Әмир янә уйга талды. Аннары теш арасыннан сыгып:

– Алайса, менә монысын йотып торыгыз, – дип пышылдады:

> ... Кайчак хөкем итә якын дуслар,
> сөйгән ярлар, җиде ятлар да...
> Япа-ялгыз газиз әниең килә,
> сине араларга, якларга...

– Караңгыда өченче сортка бата бу, давай, дәвам ит, – дип гөрләде Адмирал.

> ...Уңны-сулны тоймый чапты гомер.
> Юлга алсу гөлләр сипкәннәр.
> Җиңел икән яшәү дөньяларда,
> син дип шундый йөрәк типкәндә...

– Ниндидер уртак калып сизелә-сизелүен. Бусы да түзәрлек, дип торыйк. Дәлше!

...Башны аска иеп торам әле...
Сары яфрак күмә каберен.
Яфрак өзелгәндә искәрәбез,
газиз әнкәйләрнең кадерен....

– Тәк , шигырь шәп. Шуның өчен менә сиңа «Тукай» премиясе! – дип, Әхмәт әңгәмәгә кушылды. – Моны машинаңа тиз илтеп кил, – дип, «Токай» дигән язулы шешә сузды.

– Әх, Сәлимулла юк. Шушы шигырьгә ятышлы көйне ничек тә укмаштырыр иде, мәрхүм, – дип уфтанып куйды Госман...

– Егетләр. Әйдә, иртәгә Сәлимуллаларга сугылабыз. Аның бит абыйсы да бар иде... Әнисе үлгәндер инде...

– Әйткән сүз – аткан ук!

– Күчтәнәчкә башланмаган бер ящик виноград калды, – диде Әхмәт, шунда ук изге ниятнең матди ягын кайгыртып. – Зәет, мә, шуны багажнигыңа илтеп куй, ату онытыла...

Акыллы әйтте, тиле йөгерде, дигәндәй, кушканны үтәми булмый. Әхмәт, дус кына түгел, турыдан-туры түрә дә булгач, уңны-сулны истә тотмый булмый.. Әйләнеп килеп табынга чүгәләгәндә, ул янә мине искәрде һәм:

– Егетләр, әйдә, Зәетне дә сайратыйк. Әз сүзле кеше күңелендәниләр бар икән, чыгарып селкесен! – дип тәкъдим кертте.

– Селкесен, селкесен, – дип шаулашты дусларым.

– Минем белән андый сөйләрлек хәлләр булмады, – минәйтәм. – Эшлим, хатын бар, балаларның үз тормышы, оныклар үсә. Әни исән, намазын укыштыра, – дип җавап күндердем, ык-мык килеп.

– Йә, йә, ялындырма. Һәркемнең күңел сандыгында сөйләрдәй нәрсәсе була.

– Элегрәк инде булды бу хәл, Әхмәт безгә килгәч, әнинең, «и йөргән булган идегез кабарынып, икегез тиң кемнәргә килеп каптыгыз», дигәне булды, – дип ычкындырдым.

– Әйе, әйе, истә ул минем, – дип көлеп җибәрде Әхмәт. – Бибикамал апа – турыдан яра торган кеше.

– Өченче балабыз тугач, «балага батырды» дип мыгырданганы истә калган әнинең. Күрәсең, ике бала бар чакта әле ул мине хатыннан йолуга өметләнгән... Бетте. Минем шул гына.

– Бик әз булды бу, кече телгә дә йокмады.

– Кымыз кызулыгы җитмәсә, менә монда француз коньягы да бар. Мә әле. Бәлки, шуннан соң телең ачылыр?

Мин боларның басымына түзә алмадым, әлбәттә, француз сыеннан авыз иткәндә, Әхмәт чәнечкегә кадап сузган лимон кыерчыгын да чәйнәдем. Аннары, ипләп кенә,

– Бәлки, сезгә Сәлимулла кыйссасы ярап торыр? – дип куйдым.

– Бигрәкләр шәп булыр.

– Әйдә, кереш инде, алайса таң ата башлады.

– Ошатмасагыз, ярты юлда бүлдерерсез.

– Килештек.

Һәм мин Сәлимулла кордаштан ишеткәнемне такылдарга керештем...

«...Сәлимулланың әтисе Кәлимулла абый сугыштан бер аягын калдырып кайта. Акылга зәгыйфь апасы сугышка кадәр туган. Аннары Галимулла,

Галимулладан соң Сәлимулла дөньяга килә. Әтиләре, өй салырга хыялланып, аксап-туксап урман кискәндә, агачка басылып үлә. Болар бик авыр тормышта үсте. Ашарга, ягарга утыны кирәк, колхозда коры таякка эшлисе... Бар юанычлары – Кәлимулла агайдан калган гармун. Гаиләдәге өч бала да, хәтта юләр апалары да шуны шәп кенә шыңгырдаталар. Өй иске, тәбәнәк, анда өстәл, бер сәке, бер-ике утыргыч, аннары савыт-саба шкафы һәм вәссәлам.

...Ул чорда күп кенә авылларда Сабан туе уздыру турында авыз ачулар юк, тын да чыкмый, чөнки һәркайда юклык, ачлык, ялангачлык, ятимлек, бүтән төрле сугыш яралары, җитмәсә хакимият кырыслыгы эт булып талый. «Дәрт иткән – җиңгәсен үпкән», дигәндәй, безнең авыллар Сабан туе уздырырга карар кыла. Ир-егетләр, ат җигеп, колга тотып, тальян гармун тартып, җилкәләрдән кочаклашып, «Алмагачлары»н җырлап, бирнә җыярга чыгып китәләр. Хәл кадәренчә кайсы баш яулыгы, кем кулъяулык, кем күлмәклек тукыма кисемтәсе, тастымал, сөлге чыгара, иң ару дигән бүләкләр колгага бәйләнә, тыйнаграклары кабык арбага теземләп салына. Ул чак урамнарда яшел чирәм. Ялан тәпиле, такыр башлы ике малай, аның берсе Сәлимулла, чиләк тотып йомырка җыеп йөри. Менә төркем авылны бүлгән Каравыл елгасы уйсулыгына җитә. Чиратта – ике тәрәзәле, әлеге коры елгага авам-авам дип алга сөрлеккән салам түбәле өй. Череп каралган капка-койма дигәннәре ярымҗимерек хәлдә. Сәлимуллалар өе. Сугыш вакытында Мәмдуха апа иләс-миләс кызы белән хәер сорашып тамак туйдырган. Ә хәзер, Кәлимулла агайсыз да калгач, ничек туеналардыр, бер Аллаһы Тәгалә генә белә. Бирнә җыючылар боларның өе яныннан туктарга яхшысынмыйча шыпырт кына узып китәләр. Бер өйгә тукталалар, икенчесенә. Һәм шулвакыт «аһ» итәләр: такта кебек юка, чандыр гәүдәле Мәмдуха апа ямау өстенә ямау салынган, кайчандыр манылган, инде үз төсен оныткан бердәнбер күлмәге итәгенә урала-урала, ниләрдер кычкыра-кычкыра, боларга таба җан-фәрман йөгерә. «Нишләп безгә туктамадыгыз?! Нишләп безне мыскыл итәсез сез?!» – ди икән ул, өзгәләнеп. Үкереп елый-елый, такмаклый-такмаклый, килен булып төшкән чагында ук алып килгән кызыл башлы Казан сөлгесен колгачыга китереп тоттыра. Сөлгене бирнә колгасының иң очына бәйлиләр, чөнки арада иң затлы бүләк – шул сөлге. Бирнәчеләр чираттагы йортка барышлый әледән-әле Мәмдуха апа ягына әйләнеп карыйлар. Сәлимулланың әнисе, бар да әйбәт, минем өчен борчылмагыз, дип әйтергә теләп булса кирәк, уңайсызланып кына кул изи...»

Икенче көнне, табигать кочагында төн уздырган дуслар, куе чәйләр эчеп хәл-тын алгач, машиналарына утырып һәркайсы үз юлы белән китәргә ашыкты. Сәлимуллаларга сугылуны барыбыз да онытканбыз булып чыкты. Уртак ниятебез икенче көн кояш баеганда гына исемә төште. Мин яшәгән район үзәгеннән туган авылга ара әллә ни ерак түгел, әманәтне иясенә тапшыру өчен шунда укталдым.

Соңгы елларда безнең авыл котайды, матур кирпечтән өелгән зур һәм биек, төсле калай түбәле йортлар байтак калыкты. Күпләрнең капка-коймасы да сырлы-сырлы төсле калайдан хәзер. Шәп йортлар янәшәсендә Сәлимулла салган яңа өй инде бәләкәй генә булып калган. Дөрес, ул такта белән төрелеп, кайчандыр буялган булган. Тора-тора буяу уңган, урыны-урыны белән касмакланган. Келәгә басып, җилкапка аша ишегалдына үтүгә, өйалды

баскычында утыручы карчык, Сәлимулланың әнисе Мәмдуха апаны күреп алдым. Болай да ябык әбекәй тузганак сыман гына булып калган, катырак җил иссә, очып китәргә дә мөмкин.

– Исәнмесез, Мәмдухәттәй. Менә бу Сезгә Әхмәттән күчтәнәч иде, – дип, сусыл йөзем тәлгәшле әрҗәне алдына китереп куйдым. Аның җыерчыклы, чак кына калтыравыклы эре тамырлы кулларын учыма алгач, ишегалдында ямь-яшел чирәмлектә оя-оя яран гөлләре шау чәчәктә утыруына игътибар иттем.

– Кем соң син, улым? Кем малае? Бер дә таный алмый торам.

– Сәлимулла белән дуслар идек. Мирзанур малае. Сезгә кереп чәй эчкәләгән дә булды минем. Галимулла абый ни хәлләрдә?

– И, балакаем. Ир-ат кыска гомерле бит ул, – дип җавап күндерде Мәмдухәттәй, тирән көрсенеп. – Әүвәл картым вафат булган иде, аның артыннан кызым, аннары, ару гына яши башлагач, бер-бер артлы улларым-багалмаларым бакыйлыкка күчте... Япа-ялгызым торып калдым менә. Күчтәнәчләр күтәреп зурлап хәлемне белүең өчен Аллаһтан мең рәхмәт яусын. Артык күп түгелме соң бу? Кая куеп бетерермен?

– Артса, күршеләрегезгә күчтәнәчкә өләшерсең.

– Әйдә, өйгә үт, улым, чәй куям, юлдан килеп арыгансыңдыр?!

– Юк, юк. Машинага биш минутлык юл, өстәл артыннан кубып кына кузгалган идем.

– Күчтәнәч китергән кешене болай гына җибәрү ярамый бит инде. Китми тор, улым. Мин, хәзер.

Мәмдуха апа өенә кереп китте, мин өйалды баскычына утырып калдым. Яран гөлләрне аралап искән җилдән тәмле хуш ис борынга бәрелә.

Менә ишек ачылып, Мәмдуха апа да күренде. Кулында ап-ак оекбашлар.


– Берсен Галимуллама, икенчесен Сәлимуллама, дип бәйләгән идем. Кими калдылар, менәтерәк. Әрәм булып күп яттылар, җитәр. Берсен Әхмәткә илт, икенчесен үзең рәхәтләнеп ки. Җылы тәннәрегездә тузсын.

– Кирәк түгел иде инде.

– Ал, ал, улым. Рәнҗетмә берүк.

– Ишегалдың матур, Мәмдуха апа. Яран гөлләрең төрледән-төрле.

– Яздан чыгарып утыртам мин аларны. Кич саен шуларга карап юанам аннары...



Рәмис
Аймәт

# КЫЯЛАРСЫЗ КАЛГАН ДӨНЬЯЛАР

## Тормыш поезды

Тормыш – поезд. Ыргыла ул
Билгесез, ят елларга.
Өметсезлек, бушлык көле
Ятып кала шпалларга.

Чылбырланган вагоннарда
Зынҗырланган җаннар бара.
Ыргый поезд, язмышларның
Кыргый җилен ера-ера.

Кемдер күптән бу сәфәрдә,
Кем утырды яңа гына...
Кизәнсәң дә, сугалмыйсың
Син дөньяның яңагына.

Дөнья үзе кыйный сине,
Уңлы-суллы, уңлы-суллы.
Безгә дигән өлешме бу,
Яшәү дигән җәза шулмы?!

Ыргый поезд... «Яшәргә!» дип,
Кайный җанда укталышлар.
Кайда «Бәхет», «Шатлык» дигән
Без төшәсе тукталышлар?

Юк, туктамый, җилдерә ул,
Хәтсез хәтерләрне иңләп.
Юл буенда безгә дигән
Тукталышлар кала иңрәп.

Рәмис АЙМӘТ (1968) – *шагыйрь; «Шомырт салкыннары», «Айның аръягында», «Бозлы җилкәннәр» һ.б. татар, рус, төрек телләрендә дөнья күргән китаплар авторы. М.Җәлил һәм Һ.Такташ исемендәге әдәби премияләр лауреаты. Казанда яши.*

Көтә безне соң тукталыш...
Соңгы... «Сагыш» атындагы. –
Рельсларның кочаклашып
Тәүбә кылган чатындагы...

## Хөрмәтле Лена Шагыйрьҗан ядкаре

Гөлтләде дә... сүнде соңгы шәме...
Ятим калды өе шагыйрәнең.
Сыкрап куйды микән шигырьләре,
Өзелгәндә кылы бәгыренең?!

Аһылдады микән гарешкәйләр,
Ашкан чакта күккә шагыйрь җаны?
Аңа дөнья – үзе шигырь иде,
Дөнья үзе шагыйрь итте аны.

Корып куеп тәрәз пәрдәләрен,
Бизде кайчак, бизде дөньясыннан.
Байкот итеп ул сикерде кайчак
Язмышларның текә кыясыннан.

Ул сикерде... Мәрхәмәтле Хода
Чөйде аны, чөйде гел биеккә.
Биеклектә бөеклекләр яулау
Китерделәр аны соңгы чиккә:
«Яшисем дә килми хәтта, энем!»
Аһ, әйттертте дөнья, әйттертте.
Әйтерсең лә тәкъдир, качып кына,
Өметкәйләренә ут төртте.

...Китте шагыйрь, салават күперенә дә
Керми калган серле бер төш булып.
Гомере дә тоелгандыр аңа
Сабыйлыкта күргән бер төш булып.

Ул киткәндә, матәм көен көйләп,
Акты сагыш, акты болыт-болыт.
Ул үзе дә инде күк катына
Чигелгәндер, моңлы шигырь булып...

***

Дию абындымы?
Таулар убылдымы?
Буталдымы иман-кыйблалар?
Корып мәкер-хәйлә,
Калмадымы әллә
Бөркетләргә кунар кыялар?

Әллә бөркетләр дә
Вак җан-бөртекләргә
Әйләндеме таусыз, кыясыз?

Тәхет-кыяларсыз,
Өмет-ояларсыз
Тагын күпме җаннар кыясы?!

Таулар – Күк терәве.
Күкләр иңрәве
Ишетеләме? Безне кем аңлар?
Нинди юллар ярыр?
Белмим, кая барыр
Кыяларсыз калган дөньялар?!

## Ялгыз скрипкачы

Урам чаты.
Кич.
Ялгыз скрипкачы.
И елата ятим скрипкасын.
Җан асрарга бераз «таммасмы» дип,
Җиргә салган иске кепкасын.

Скрипканың да, көйсез дөнья кебек,
Көйсезләнеп беткән кыллары.
Үзенең дә җан кыллары өзек,
Хәрәкәтләнә тик куллары.

Ул Җан, бәлки, күптән өмет өзеп,
Ташлангандыр текә кыядан.
Юк, еламый кыллар, алар бары
Шыңшый-шыңшый көлә дөньядан.

...Карашлары югалалар китеп,
Әллә кая – төпсез упкынга.
Кемне – упкын йота, ә кемнәрдер
Эләгәләр тозак-капкынга.

Упкыннарга китеп убылмады,
Онытылмады инде кем генә!
Күпме аһәңсазлар, каләмдарлар
Төшмәделәр тормыш төбенә!..

Кепкасына сыңар тиен «тамса»,
Гамьсез уйларын ул тугарып,
Моңын җуйган дөнья төпкеленнән
Карашларын ала кубарып.

Көе белән нәүмиз күңелләрдә
Уята «Татарстан таңнары»н,
«Казан кичләре»н ул шыңшыта да
«Катюша»га күчә аннары.

Катюшалар...
        Утлы яңгырларын
Койган чакта дошман өстенә,
Хәерчелек таңы атар, диеп,
Уйламаганнардыр һич кенә.

Ялган хисләр, ялган төсләр – бар да –
Үткәннәрдән «якты» истәлек.
Яңа байлар үрчи барган саен,
Яңа хәерчеләр тора өстәлеп.

Көзге җилләр генә түгел, хәзер
Язгысы да аның, һай, ачы.
Тынны буа тынчу, үле һава.
Урам чаты.
Кич.
Ялгыз скрипкачы...

## Үткән көннәр

*Әй, кая ул көн ки бездә –*
*Шәп торулар бар иде...*
Дәрдемәнд

Кайда калды, әй ул үткән көннәр?
Яшьлекнеңме аргы ярында?
Әй ул көннәр, һаман атлар кебек,
Утлап йөри хәтер кырымда.

Һәрбер чаттан бага, әй ул көннәр –
Телгәләнә күңел, ярсына. –
Көтмәгәндә, таныш сукбай эттәй
Килеп чыга минем каршыма.
Көтмәгәндә... тәүге сөю сыман
Төшләремә килеп керә лә...
Хәтеремдә, гүя тәмам арган,
Соңгы әйләнешен көтеп алган
Казан трамваедай сөйрәлә.

...Уч төбендә кебек иде Казан,
Һәрнәрсә дә таныш, үз иде.
Сөембикә манарасы да бит
Кыз чагыдай гүя төз иде.

Чынга ашмас бәллүр хыялларны
Йолдызлардан йөрдекме эзләп?..
Безнең шашып, ихлас көлүләрдән
Күк гөмбәзе торды күк зеңләп.

Кабан күле генә түгел, монда
Һәрбер чатның сере бар иде.
Күпме генә иңләп-буйласак та,
Казан урамнары тар иде.

Тар иде шул безгә бар нәрсә дә,
Тарлык-татарлыктан качарга
Җитмәде көч, барыбер, теләгәнчә
Күк гөмбәзен киереп ачарга.

Дошманнарның эргәсенә кайчак
Күмгән чаклар булды «мина» да.
Урамнарда таңнар аттырсак та,
Куркытмады безне ул чак хәтта
Вәхши Казан феномены да.

Һай, гомерләр....
          Үтте китте бар да...
Маңгайларга салып үз эзен.
Яшьлек эзем калган урамнарны
Иңләп йөрим хәзер берүзем.

Әй, кайда сез, кайда, дус-ишләрем?
Гыйсъян Рөстәм, трибун Леналар?[1]
Диварларга эленеп калды бары
Сез уйнаган мандолиналар.

Ияләнә бара бугай күңел
«Әлвидагъ»лар, «Сау бул!», «Хуш!»ларга.
Якыная бара... хатирәләр,
Ерагая... якын дуслар да...

[1] Шагыйрьләр Рөстәм Сүлти һәм Лена Шагыйрьҗан күздә тотыла.



Айгөл
Хөснуллина

# ЯЗМЫШ КАЙТАВАЗЫ

БӘЯН

**1**

Кышкы юлдан машина белән җилдерүләр рәхәт тә соң! Бульдозерлар, яңа яуган кар өемнәрен як-якка эттереп, олы юлны бик яхшылап ачканнар. Машина алга җилдерә, ике яклап ак бөркәнчек япкан агачлар, авыр башларын бер якка салып, арттан иярергә тырышкандай итеп озатып калалар. Кар өстендә бер-берсен куышып кояш нурлары шаяра. Күңелдә нигәдер рәхәт тантана. Радиодан салмак кына көй яңгырый. Юл иркен, машиналар да әллә ни күп түгел.

Әмма бу шатлык озакка бармады.

Авыл каршына килеп җитү белән, Сания «шып» итеп тукталды, машинасыннан төште. Әнә, ул барып керәсе авыл аяк астында җәйрәп ята. Йорт түбәләре һәм морҗалар ак бүрек кигән. Якындагы зират рәшәткәләре өстенә дә толып якасыдай булып калын кар яткан. Болары – сагындырган матур күренешләр. Тик менә авыл урамына машина белән ничекләр итеп керәсе икән? Үтеп-сүтеп йөрүчеләр эзеннән ясалган «кәҗә сукмагы» гына чекерәеп күзгә бәрелеп тора.

Саниянең бу авылга йомышы бар. Кире борылып китү турында уйлыйсы да юк. Шуңа күрә ул үзенең машинасын юл читенә куеп калдырды да «кәҗә сукмагы»ннан атлап китте.

Кайда икән соң бу авыл советы дигәннәре? Элек мәдәният йортында иде ул. Инде югары очтагы мәдәният йортыннан хәрабәләр генә утырып калган. Анда авыл советы да, почта да, колхоз идарәсе дә, хәтта саклык кассасы да – бөтенесе бергә тупланган иде бит. Бу җирләрдән ниндидер дәһшәтле сугыш узып киткән диярсең, бар да җиргә иңгән. Кайчандыр гөрләп торган авыл үзе дә ничектер тынып, моңсуланып калган. Ап-ак кар юрганы астына чумып, әйтерсең, ул татлы йокыда.

Авыл гына түгел, монда яшәүчеләр дә йоклый бугай, урамда хәтта адашып йөргән этләр дә күренми. Сания чарасызлыктан як-ягына борылып карады,

---

Айгөл ХӨСНУЛЛИНА – *вакытлы матбугатта басылган күпсанлы хикәяләр авторы. Казанда яши.*

олы юлдан шулкадәр изаланып килеп тә авыл советын таба алмый китсенмени инде?!

Шулчакны ул авылның икенче очында кар көртен көчкә ерып килүче олы яшьтәге бер апаны күрде. Аның килеп җитүен көтеп торса, шактый озак вакыт узасын уйлап, аңа таба атлады.

– Исәнмесез, авыл советының кайдалыгын әйтә алмассызмы икән?

Хатын, чит кешене танырга тырышып, сагышлы караш белән аңа төбәлде һәм: «Кем буласың, сеңлем, нигә кирәк ул сиңа?» – дигән урынсызрак соравын әйтеп ташлады. Ә аннары үз соравыннан үзе үк уңайсызланып: «Мәктәптә утыра алар хәзер, әнә тегендә...» – дип, аскы урам ягына төртеп күрсәтте. Сания рәхмәт әйтергә дип авызын ачарга да өлгермәде, күптән берәр кеше белән сөйләшергә сусаган бу апа үзенекен тезеп тә китте:

– И-ии... кызым, ничекләр итеп кердең соң син безнең авылга, җәяү кердеңме? Быел персидәтел бигрәкләр азды, клуб буеннан олы юлга кадәр генә ачтырта да, вәссәлам, урамнарны эттертми. Үз машинасы «виздихут» булгач, безнең кебекләргә әйләнеп тә карамый. Балалар да шуңа юньләп кайта алмый, кайткан саен интегәләр... Алар кайттымы, тәмам хафага төшәм, ничек кайтып керерләр, аннары ничек чыгып китәрләр дип йокысыз калам. Җаен дә шул хәл инде, балакаем, яңгыр яуса – батып яталар. Бетте авыл. Яшьләр юк, безнең ишеләр дә елдан-ел сирәгәя. Нинди бай колхоз иде бит заманында, барын да талап, юкка чыгарып бетерделәр, имансызлар. Без эшләгәндә, сыер фермасы дүртәү, сарыкныкы икәү иде. Атларны әйткән дә юк. Ничәмә машина, күпме трактор тезелеп торды. Кайда алар хәзер? Үзләре череп баеп беттеләр әнә, – дия-дия, урам башындагы ике катлы хансарайга ишарәләде... – Уллары да, кызлары да кыйбатлы машиналарда йөри, фермадагы соңгы таналарны быел көзен төяп алып чыгып киткәч, колхоз бетте. Бар эшкә яраклысы әнә шул алпавытка ялланып эшли. Кеше байлыгын күпсенә дип уйлый күрмә, кызым, авылны бетерүләренә генә эчем поша минем, – дип, күз яшьләрен җиңе белән сөртеп куйды.

– Алай ук булмас әле, Алла теләсә, – дип, Сания аны юатырга теләсә дә, гомер юлында күпне күреп, шактый вакыйгаларның шаһиты булган бу апа һаман үзенекен сукалады:

– Булмаган кая, ул бит үз хезмәте белән мал табып җәфаланмый, авылның бар булганын сатып рәхәт күрә. Амбарга кадәр сүтеп озатты. Монда яшәүчеләргә рәхәт дисеңме? Үзенә каршы чыккан һәркемне сугып ега, авылдан куа. Үзсүзлеләр читкә эшкә йөри, ә юашлар, барыр җире булмаганнар – моның колы. Җир кишәрлекләре бүлеп биргән булдылар. Элек ичмаса печәнен, икмәген, балын бирәләр иде. Хәзер алырсың шайтаннан иман! Авылны шушының кебек адәмнәр кулына тапшырып, хөкүмәт ни уйлыйдыр, белмим... Басуларда алабута белән шайтан таягы үсә. Ферма, амбарларны утынга сүтеп ташып бетерделәр. Җәен авылда казлар коенырга буа буучы да юк бит хәзер. Күперләр череп беткән. Зиратка ел саен су керә. Авыл советы да берни эшләми. Менә шундый хәлләр, кызым. Мин газеталар алдырам, телевизор карыйм. Кечкенә генә авылларга тау ярып, асфальт җәйгәнен күрсәтеләр әнә, безгә ике чакрым да кертә алмыйлар. Ходай гына сакласын инде, каты авырып китсәң, ашыгыч ярдәм дә керә алмый безгә. Авылда табиб та юк, кибет тә ябылырга тора... Менә кибеткә барышым иде әле, хәзер халык шунда гына очрашып бер-берсенең хәлләрен белешә. Күршегә күрше керү дә бетте. Бушка ярты кашык тоз да бирмиләр, олыларга

ярдәм итү дигән нәрсә бөтенләй юк инде ул. Безнең балалар үскәндә, атна саен олыларга «тимурчылык»ка йөриләр иде ичмасам, су алып кайтырга, утын ватарга ярап куялар иде. Хәзерге балалар менә шушы тар сукмакта каршы очрасалар, сине шунда көрткә төртеп калдыра бит...

Сания әлеге апаның озын-озаклап зарлануларын, туйганчы эчен бушатуын көтеп тора алмавын аңлап, як-ягына каранды да, рәхмәт әйтеп, тын гына аңардан аерылып китәргә ниятләде. Апа кеше шуны сизеп бугай:

– Ии-и, кызым, кичер инде башыңны юк-бар белән чуалтканга, әнә теге сукмактан аска таба төш, яме, – дип ишарәләде. Сания уңайсызланып булса да мәктәп юлына борылды, кичкә кадәр шәһәргә кайтып җитәсе дә бар бит әле аның.

Әйе, бу авылны танырлык түгел, шушы урамнардан гөрләп мәктәпкә ашыккан сабыйлар, ашыга-кабалана эшкә барган халык кая китеп югалган? Балачакта Саниялләр үз авылларыннан тракторның зур бер чанасына төялеп мәктәпкә киләләр иде. Алардан гына күпме бала, шуның өстенә тагын күрше авыллардан килеп укучылар бар. Бер сыйныфта егерме-утыз бала иде. Ничә тапкыр шушы тыкрыктан чана белән ауган очраклары да булды аларның. Шул хәлләр исенә төшеп, Сания үзалдына елмаеп куйды.

Бервакыт шулай тракторчы Самат абыйлары борылыштан кискен борылды һәм чанадагылар юл буендагы кар өстенә борчактай сибелде. Чана кырыенаябышып, хезмәт укытучысы Илдус абый гына калган иде. Ничек шундый да зур корсаклы абый тотынып калырга өлгергәндер, Ходай белсен. Җепшек карга битләре белән килеп төшкән балалар һәм укытучылар чыр-чу килә. Кемдер берәүнең башына баскан, кемдер олы гәүдәле Фәрдәния астында калган, ә инде каладан практика үтәргә кайткан укытучы Рузалия апаның куян бүреге кар астында ук күмелеп калган. Шулай аунап-әүмәкләшеп алганнан соң, яңадан чанага төялделәр. Юлның-юл буе гел шул хакта сөйләшеп кайтты алар ул көнне. Их, балачак хатирәләре, бигрәкләр дә татлы шул алар! Күңелнең иң нечкә кыллары тибрәнеп куя. Хәзерге балаларның искә алып сөйләрлек мизгелләре бар микән? Аларның вакыты күбрәк телевизор, компьютер каршында үтә, рәхәтләнеп урамнарда, болыннарда чабып уйнаганнары да юк. Дуслаша да белмиләр. Киеменә, әти-әнисенең кем булуына карап кына аралашалар. Элек бар да тигез, балалар инкубатор чебиләре сыман бер «кием»нән иде. Хәтта хәллерәкләр дә балаларын аздырмады. Авылда берәрсенә матур кием алсалар, икенчесе дә шәһәрдән шундыйны алып кайттыра. Ул заманнарда баштарак әйбере, ахырдан акчасы булмады. Үсмер чагында әнисе ваучерга сатып алган бер яшел кофтасын бик яратып киюен әле дә яхшы хәтерли Сания. Башкаларда юк иде ул, шуңа да кадерләп, саклап киде. Менә шул кофта уен вакытында кадакка эләгеп ертылган иде. Сания аны кайткач тексә дә, ул беренче матурлыгын югалтты. Әнисе, кызының борчылуын сизеп, Казанга баргач, яңасын алып кайтачагына өметләндергән иде. Тик ни генә алып кайтсалар да, анысы кебек килешеп торганы очрамады бугай.

Мәктәп елларының татлы хатирәләренә бирелеп, авыл советына – элеккеге мәктәп бинасына килеп җиткәнен дә сизми калды Сания. Шул ук яшел ишек, шул ук сары идән такталары... тик коридорны тутырып шау-гөр килеп торган бала-чагалар гына юк, нindидер шомлы тынлык.

Шулчак Саниягә кемдер исеме белән эндәшкән кебек булды, ул ирексездән коридорның аргы башына борылып карады. Чү, ни бу? Күзенә күренә бугай – сыйныфташы Камил басып тора түгелме соң анда? Әйе, элеккечә йомшак тавышы белән ул эндәшә икән:

– Нишләп йөрисең, Сания? Кайчан кайттың? Сине күрмәгәнгә...

– Әйе шул, күпме гомер үткән, – диде Сания үзен нәрсәгәдер гаепле сизеп.

Шушы киеренкелекне өзү өчендер, күрәсең, Камил үзенә генә хас елмаю белән:

– Күпме сулар аккан, сабакташ... – диде дә җиңелчә генә Саниянең иңбашына кагылып алды. Инде кырык яшенә якынлашкан Саниянең бөтен тәне нииндидер рәхәтлек тоеп чемердәп китте. Күптән бу ләззәтле дулкынны тоймаган икән ич Сания. Классташы Камил аны әнә шул дулкыннарда тирбәтә түгелме? Кайчандыр үсмер чакта кичергән татлы сөю хисе әле дә исән микәнни? Хатынның йөрәге ничектер ярсып җилкенеп куйды. Камил әллә ни үзгәрмәгән үзе, шул ук уйнап торган зәңгәр күз, кайчандыр аны яшертен генә үпкән тулы-назлы иреннәр, иркәләп кочкан киң җилкәләр. Бары Сания тузгытып шаяртырга яраткан чәчләрен генә чал ала башлаган, алар тәрәзәдән төшкән кояш яктысында көмештәй ялтырап тора...

– Сулар аккан шул... – диде Сания, дулкынлануын сиздермәскә тырышып. – Син үзең монда нишләп йөрисең, Камил?

– Әнинең вафатыннан соң йортны һаман да үз исемемә күчерә алганым юк, менә шул мәшәкать белән йөрим әле. Ә сине монда нинди җилләр ташлады?

– Минем дә синең кебек кәгазь эше белән йөрүем. Хәзер кайда соң син, Камил? Авылдан китәргә мәҗбүр иткәннәр, дип ишеткәнем бар иде барын, бу дөресме?

Бу сорауны ишеткәч, Камилнең нишләптер төсе үзгәреп китте, йөзенә ниндидер кызыллык иңде. Сания үзенең кирәкмәгәнне ычкындырганын аңлап, сүзне икенчегә борырга тырышты:

– Балаларың да зурдыр инде, мәктәптәме һаман? – дип сораган булды.

Камил турында барын да белеп гомер итә иде югыйсә. Хатынының кем булуын да, ничә баласы барлыгын да, ничә яшьләрдә икәнен дә яхшы белә. Күптәнге танышы Зәйнәп барын да аңа сөйләп тора, шул авылныкы булганлыктан, бөтен мәгълүматны кайткан саен Камилнең җиңгәсеннән белешеп килә дә бәйнә-бәйнә Саниягә чәй янында тезеп сала.

– Балалар үсә, без дә олыгаябыз инде, Сания. Малай унбердә укый, кызыбыз алтынчыда, – дип җаваплады Камил.

Шулчакны, алар тавышын ишетептер, мөгаен, элеккеге география кабинетының ишеге ачылып китте һәм аннан яшь кенә бер кыз килеп чыкты:

– Исәнмесез, сез минем янгамы?

– Авыл советы секретаре сез булсагыз, сезнең янгадыр, – диде Сания, аның каршысынарак атлап.

– Узыгыз, кереп утыра торыгыз. Мин хәзер киләм, – дип, кыз коридорның икенче башына таба китте. Сания белән Камил бер-берсенә карашып алдылар да, бүлмә эченә узып, өстәл янындагы урындыкларга кереп утырдылар. Стенада шул ук карталар, хәтта шкаф башында да алар укыган вакытлардан калган глобус басып тора. Камил, глобуска күз ташлап:

– Сания, хәтерлисеңме? – дип, серле ым белән, шкаф башына ишарәләде.

Хәтерләми ни: Сания белән Камил аны ялгыш икесе төшереп ватканнар иде бит. Бервакыт класс бүлмәсен җыештырырга калгач (ул чакта аларның очрашып йөрүен беркем дә белми иде әле), Сания шкаф башындагы әнә шул глобусны сөртергә дип менеп китте. Шаян табигатьле Камил, форсаттан файдаланып, дус кызының урындыгын селкеткән булып кыланды. Менә шулчак глобус кыз кулыннан ычкынып китте дә идәнгә төшеп ярылды! Куркып калудан бер-

беренә караштылар, аннары тиз генә чүмәшеп, икегә аерылып киткән глобусны күтәреп алдылар. Сания тәмам елар дәрәҗәгә җиткән иде. «Борчылма, Сания, хәзер ябыштырабыз аны», – диде Камил, кызны тынычландырып. Егет җитез адымнар белән укытучы өстәле тартмасыннан келәй табып килде һәм алар икәүләп ябыштыру эшенә керештеләр. Кыз егетнең назлы карашын тоеп кыенсынды, шуңа да күзләрен күтәреп карарга да кыймады. Камил глобус турында уйлап та бирми иде шикелле, аңа сөйгәненең җылы сулышын тою, аның озын керфекләренең тибрәнүен карап тору рәхәтлек бирә иде. Менә ул түзмәде, Сания сизмәгәндә генә кызның иреннәренә үрелде... Бу – аларның беренче үбешүләре иде.

...Әлеге хатирәләр исенә төшеп, Сания Камилгә карап янәдән елмаеп куйды. Шулчак бүлмәгә теге чандыр гәүдәле кыз да килеп керде:

– Тыңлыйм сезне... күрше авылдан Бибинур апа кызы бит әле сез? – диде ул, Саниягә күз ташлап.

– Әйе, сезгә шалтыраткан идем, кәгазьләр әзер, дигән идегез...

Кыз өстәлдәге кәгазьләр арасында актарынды да Саниягә, ике урынга кул куярга кушып, белешмә кәгазен кулына тоттырды. Сания, рәхмәт әйтеп, ишектән чыгу юлына кузгалган гына иде, шулчак Камил, ашыгып кына:

– Сания, мине көт әле, яме, – диде.

Озак тормады ул, алар бергәләшеп урамга чыктылар. Әкрен генә буран чыгарга азаплана иде. Камил Саниянең машинасы авыл башында калуын белгәч, үзенеке белән озатып куярга булды. Сания ризалашты, сыйныфташыннан тиз генә аерыласы килми иде аның. Көч-хәл белән авыл башына чыгып җиткәнче бер авыз сүз сөйләшмәсәләр дә, аерылышыр чак җиткәч, бер-берсен уздыра-уздыра сөйләп киттеләр.

– Сания, нигә соң син теге вакытта классташлар очрашуына килмәдең? Аннары бөтенләй әллә кая күченеп киттең дә югалдың, ни телефоның, ни адресың юк... Әлегә кадәр шуны һич аңлый алмыйм... гафу ит, мин сине үпкәләттемме әллә? – дип тезеп салды Камил бер сулышта.

– Камил, син үзең мине гафу ит... Кеше сүзе белән юләрлек эшләдем ул чакта. Башка берәүне сөя, әйтергә генә кыймый, диде бит дустың Алмаз.

– Ә син шуңа ышандыңмы? Ул бит үзе сине сөя иде, менә нәрсә!..

– Соңрак аңладым шул, ул вакытта сиңа үч итеп башкага кияүгә чыгарга ризалык биргән идем. Горурлыгым бәхетемә аяк чалды... Камил, беләсеңме, син әле дә минем йөрәгемнең иң түрендә... Сине уйламаган бер генә көнем дә булмады. Тик байтак гомерләр үткән, икебезнең дә үз тормышы, үз гаиләсе, безнең элеккеге эзләребез инде җир өстеннән югалган, язмышка буйсынмый ни эшли алабыз соң, – дип, Сания читкә, тәрәзәгә таба борылды. Күзләренә тыгылган энҗе яшь бөртекләрен күрсәтәсе килми иде аның.

Камил бу халәтне тоеп, аңа комачауламаска теләп, икенче як тәрәзәгә борылып тын гына утыра бирде. Аның да тамагына төер тыгылган иде. Шул рәвешле тын гына берникадәр вакыт утырдылар. Икесе дә үзенең тирән уйларына бирелгән иде. Ниһаять, тынлыкны Камил бозды:

– Сания, мин сине, ай-хай, озак көттем, Түбән Камага күченеп китте, дигәч, анда барып чыгарга уйлаган идем, военкоматтан повестка килеп төште. Ә хәрби хезмәттән кайткач, синең кияүгә чыгуыңны әйттеләр. Институтка укырга кергәч, мин дә Миләүшә дигән кыз белән таныштым. Яратуым көчле булмаса да өйләндем, әниемә авылда ярдәмче кирәк иде бит.

– Камил, нигә авылга кайткач, кабаттан шәһәргә киттең соң? Авылыбызны

алдынгылар рәтенә кертеп, телевизорлардан күрсәтә башлаганнар иде бит. Ә син бер мәлне барын да ташлап китеп бардың... – дип, сүзне икенчегә ялгарга омтылды Сания.

– Ул чагында якыннарымның гомере авыл язмышыннан өстенрәк булды шул...

– Әйе, ул чакта авылда булган хәлләр әле дә башка сыймый, ничә кешенең гомере өзелде. Нигә диген әле? Кемнеңдер баш бирәсе килмәве аркасында бит, – дип, Сания бозлана башлаган тәрәзәгә төбәлеп авыр уйларга чумды.

Камилнең дә хәтерендә ул елларда булган сәер вакыйгалар тезмәсе яңарды...

**2**

...Камил, авыл хуҗалыгы институтын тәмамлагач, яшь хатыны Миләүшәне ияртеп туган нигезенә кайтып төште. Аны агроном итеп билгеләделәр, хатыны күрше авыл мәктәбендә балалар укыта башлады. Кайткан шәпкә әнисенең тузып барган йортын рәткә китерделәр, каралты-куралар яңартылды. Уллары туды. Тормыш үз көенә ару гына бара иде. Ә ике елдан район башлыгы Хәмзә Закиров Камилне колхоз председателе кәнәфиенә тәкъдим итте. Янәсе, элеккегесе – Алмаз Рәшитович бернигә яраксыз, үзен генә кайгырта. Хөкүмәт биргән кайбер акчаларның да кая киткәнлегенең очына чыга алмыйлар икән. Камил башта, дусты Алмазга каршы бармыйм дип, карышып торса да, соңрак бу хәлләрнең чынлыгына төшенгәч, ризалашты. Әнә шул чагында ачылды да инде Алмазның чын йөзе. Яңа хәбәрне ишеткәч, ул идарә бүлмәсендәгеләрнең барысының да башларына тиздән зур бәлаләр ябырылачак дип куркытты. Ул гына да түгел, Камилгә бармагы белән төртеп турыдан-туры: «Ә син, егет, әйдә, эшләп күрсәт, сиңа тагын... боламык бит син... Карарбыз, ничек тырышырсың икән, ә мин игътибар белән читтән күзәтеп торырмын», – диде. Ә аннары ишекне бүлмә ишелерлек итеп бәреп чыгып та китте. Барысының да күңелен авыр тойгылар биләп алса да, сөйләшүне дәвам иттеләр. Бу сөйләшү ярты төнгә кадәр барды, алга таба авылның киләчәге тамырдан үзгәрергә тиеш, дип таралыштылар.

Җыелыштан чыкканда, Камилнең башы тубал кебек иде – әйтерсең, ниндидер чүп-чар тутырып тыгызлап куйганнар. Бу олы вазифаны башкарып чыга алырмы соң ул, кыенлыкларга каршы торырлык көчләрне каян табар? Шундый авыр уйлар белән атлап бара торгач, капка төпләренә кайтып җитүен сизми дә калды. Хатыны әле ятмаган, кече якта нидер эшләгән булып йөри, ирен күргәч, ул, елмаеп:

– Йә, ничек үтте җыелыш? – дип, аның каршына килде... – Бик арыгансың бугай, әйдә, өстеңне сал да бераз капкалап ал. Урын җәелгән, ятарсың, – диде. Кара-каршы утырып чәй эчкән арада Камил хатынына өстән-өстән генә җыелыштагы хәлләрне сөйләп бирде. Кайберәүләрнең зәһәрләнеп янап чыгып китүе турында ләм-мим, берни әйтмәде, билгеле.

Шулай итеп, Камил җиң сызганып туган авылын тергезү эшенә кереште. Бу җәй урталары иде. Кырларда алтын башаклы бодай, арышлар талгын гына җилдә тирбәлә. Фермадагы терлек-туар, эсседән әлсерәп, болын-тугайларда утлап йөри. Алар өчен кышка яшел азык әзерләү эше дә гөрләп бара. Камил өеннән иртәнге дүртләрдә чыгып китеп, төнге уникеләрдә генә кайтып керә башлады. Яшь хатыны аны бөтенләй күрми дә диярлек. Баштарак Миләүшә, аның эше шундый дип, үзен юатты. Ә беркөнне сөт тапшыра торган җирдә авыл гайбәтчеләренең: «Камил әле дә Санияне ярата икән, шуңа хатынын

күрәсе килмичә, кырдан кайтып керми», – дигәнен ишеткәч, гарьләнеп өенә кайтты. Каенанасы Мәйсәрә апа белән уртага салып сөйләшкәч кенә, азрак тынычланды ул. Ана кеше явызларның кеше арасын шулай бозарга теләвен, авылда алардан көнләшүчеләр күплеген килененә бәйнә-бәйнә иләп кенә аңлатты. Миләүшә басылды. Өйдә булган бу сөйләшү каенана белән килен арасында сер булып калды шикелле.

Авылдашларының күбесе Камилне агроном булып йөргән чагыннан ук үз итеп өлгергәннәр иде инде. Авыл картлары да килеп киңәшләрен биреп китә. Олысын да, кечесен дә эшләтә белде Камил, ниндидер сөйкемле сөяге бар иде аның. Сыер савучы апалар да аның лагерьга килүен зарыгып көтәләр иде. Инде аларның пычрак ерып йөргән, акчага тилмереп утырган чаклары артта калды, сөт тә торбалар аша гына йөгерә, он, печәнне дә сыерлар алдына техника китереп сала, ташып йөрисе юк, уч тутырып хезмәт хакы да алалар. Трактор йөртүче исерек Гайфулла белән курка-курка эшкә барулар да бетте, инде аларны машина илтеп куя, алып кайта. Хәтта Гайфулланы да айнытты Камил, бу хәлнең сәбәбен авылдашлары да аңышмый калды. Еллар буе салып йөргән кеше табибларга алып бармыйча да айнысын әле! Тора-бара ул кулдан машина сатып алды, күрше авыл кызы белән никахлашып та куйды. Баштарак бар да әнә шулай җиңеллек белән бирелде Камилгә. Кирегә сукалап йөрүчеләр дә булды билгеле, шул ук Алмаз ындыр табагыннан ике капчык бодай урлаганда тотылды. Кырдан кайтып килгәндә, Камил үзе тотты аны, бодайны кире кертеп бушатырга кушкач, карышты, гадәтенчә янады. Ахырда Камил: «Әйдә, эшне беренче юлга зурга җибәрмик», – дигәч, ризалашкан булып баш какты. Бу хәлнең ахыры болай гына бетмәячәген уйлап та карамаган иде ул чагында Камил. Аның дәвамы кара кайтаваз булып бер айдан соң яңгырады.

***

Ул төнне Камил саташып чыкты, төшендә кара этләр белән сугышты. Уратып алган әлеге этләр аның бөтен тәнен канатып бетерделәр, ул алар белән сугышып арыды, талчыкты, җиргә егылды. Инде бер эт авызын зур итеп ачып кабып йотарга торганда гына, ул куркудан уянып китте. Таң атып килә иде. Шулчак урам як тәрәзәсе каршында кемнеңдер: «Камил абый, Камил абый!» – дип кычкырганы ишетелде. Йорт хуҗасы тиз генә урындык башындагы чалбарын эләктерде дә тәрәзә каршына атылды, анда ике атна элек кенә үзендә машина йөртүче булып эшли башлаган Әнәс басып тора иде. Тәрәзә ачылу белән, егет гаугаланып сөйләп китте: «Камил абый, анда... урта басуда иген яна!»

Камилнең башына тукмак белән суккандай булды, бар өмете шул басуда иде бит аның, шундый да тулы башаклар... бар да солдатлар кебек бер рәткә тезелгән иде. Ирнең башы әйләнеп киткәндәй булды, шулай да үзен кулга алып, ни булганын белү өчен торып килгән Миләүшәдән өстенә кияргә бирәр нәрсә сорап алырлык көч тапты. Хатын, каударланып, урындык башына кичтән үтүкләп элгән зәңгәр күлмәкне алып бирде. «Мин киттем, Миләүшә, урта басу яна, диләр», – дип кенә әйтте дә бәрелә-сугыла ишектән чыгып та китте Камил.

Авылның аргы башына таба кара төтен җәелеп, һавага көйгән башак исе таралган иде инде. Камил җил-җил атлап клуб янына килеп җиткән арада, аны Әнәс машинасы да куып җитте. Ишек ябылуны да көтеп тормастан кузгалып киткән машина иген басуына таба ыргылды! Алар барып җиткәндә, басуның шактый өлеше янып беткән иде, Камил белән Әнәс ут өстенә көрәкләп җир ата

башладылар. Ирләр шабыр тиргә батты, битләре ялкын кызуыннан алсуланды, кызышты. Ә янгын бирешергә теләми иде, бар дөньяны йотарга торган зәһәр аждаһа сыман, ул көчәя генә барды. Сап-сары башаклар күз ачып йомганчы кара күмергә әйләнде. Шул арада районнан ике янгын сүндерү машинасы килеп җитте, авыл халкы да бер-бер артлы басуга ашыкты. Күмәк көч белән шактый вакыттан соң гына янгынны сүндерүгә ирештеләр.

Инде барысын да бер генә сорау борчый иде. Шушы гөнаһлы эшкә кемнең кулы барды икән? Бу хәлләрдән соң кешеләр күзенә ничек күренер икән ул? Аллаһы Тәгалә бар бит. Хәер, күпләр күңелләре белән моның кем эше булуын сиземлиләр дә иде инде.

Камил, тәмам корымга батып, өенә төштән соң гына кайтып керде. Миләүшә шуны алдан ук чамалап, мунча тергезеп җибәргән иде, ир тиз генә өстенә бер чиләк су койды да, берни дәшми-нитми генә бер чынаяк чәй эчеп, тагын өйдән чыгып китте. Иренең мондый борчулы чагында берни сорашмавың хәерлерәк икәнен белгән хатын аны капка баганасына сөялеп сабыр гына озатып калды. Машина, тузан туздырып, районга таба чапты.

– Ничек сез күрә торып бодай басуының янып бетүенә юл куйдыгыз? Күз карасыдай уңышны саклап, басуда кунарга тиеш сез хәзер, – дип кычкырып каршы алды Камилне район җитәкчесе урынбасары Самат Хәбирович. Узган кич шактый гына «төшереп» алган булса кирәк, шешенке күзләре, кызыл йөзе Камилдә чиркану хисе уятты. Ни дигән була бит, үзе кайчан кырга чыгып быелгы уңыш белән кызыксынды икән соң әле? Хәер, көн дә табигать кочагында кызлар белән кәеф-сафа корырга ярата, дигән гайбәте таралырга өлгергән инде аның, шунда яшел үлән исе иснәп кергәлидер, мөгаен. Камил, шул уйларына бирелеп, бер ноктага текәлеп тора бирде. Шулчак ишектән Хәмзә абыйсы – район җитәкчесе үзе килеп керде.

– Нигә тавышланасыз, тагын ни булды? – дип, җил-җил атлап, түр башына барып утырды. Урынбасар койрыгына баскан мәче сыман читкәрәк сикерде. Ул үзен «хуҗа» итеп тоя гына башлаган иде ләбаса, ризасызлыгы йөзенә чыкты. Ә аннары:

– Ярар, Хәмзә Харисович, мин китим әле, ашыгыч эшем бар иде, – дия-дия, чыгып китү ягын карады. Камил бүгенге иртәдә булган хәлләрне Хәмзә абыйсына бәйнә-бәйнә сөйләп бирде. Район башлыгы: «Да-а... кемдер сине өнәмидер, күрәсең...» – дип, тир бәреп чыккан маңгаен сөрткәләде. «Ярый, хәзер уфтанып утырудан файда юк, калганын исән-имин җыеп алырга кирәк. Иртәгәдән аргы басуга комбайннарыңны чыгар», – диде дә өстәл өстендәге кәгазьләрне актара башлады. Алар хәйран озак сөйләштеләр, колхоз эшләрен дә, гаилә хәлләрен дә. Ахырда район җитәкчесе: «Борчылма, бар кайт, эшеңне эшлә, җинаятьчене табарбыз, вакытның кадерен белик, бар да җайланыр», – дип, аның иңбашына кулын салып озатып калды.

Хәмзә абыйсы тынычландырырга тырышса да, күңелендәге авыр тойгылардан арына алмады Камил. Машинага утыргач та, күп нәрсәләр хакында уйланып барды. Бу борчулар юкка түгел иде шул, чынлап та, кемдер аңа аяк чала, авылына, авылдашларына зыян сала... Кайда ялгышты соң рәис, кемне рәнҗетте? Аның эшләгән эшләре белән кемдер канәгать түгел, димәк. Алмаз этлек эшләмиме икән? Булмас-булмас, үзе хуҗа булган кеше, үзе чәчтергән игеннәргә ут төртәме соң?

Әлеге уйларыннан Әнәснең:

– Камил абый, кайтып җиттек, – дигән тавышы айнытып җибәрде Камилне.

Председатель, машина ишеген ачып, җиргә төште. Идарә каршында беркем юк, элек карт-корылар булса да җыелышып хәл-әхвәлләрен сөйләшеп утырырлар иде, бүген исә, артык эссе булганлыктанмы, алар да күренми. Камил бүлмәсенә ашыкты, эшлисе эшләр шактый иде әле. Ферманы, ындыр табагын яңарту өчен бүрәнәләр, такталар кайтартасы, мәдәният сарае, мәктәп өчен калай ташытасы, Малмыждан сыек май ясау өчен махсус җиһаз алдырасы һ.б. мәшәкатьләр бар иде. Иртәгәдән басуда икмәк тә суктыра башларлар.

Җанын-тәнен биреп, яратып эшләде Камил – туган авылы яңа йортлар белән бизәлә, яшьләр авылда калырга теләк белдерә башлады. Моны күрү яшь җитәкчегә этәргеч кенә биреп торды. Аның планнары зурдан иде: тора-бара тегү цехы ачу, яңа нәселле атлар, сыерлар алу, теплицалар булдыру. «Эшлим дигән кешегә субсидияләр бирелә, төрлечә ярдәм күрсәтелә», – диде бит Хәмзә абыйсы.

Тырышты Камил, дүрт ел эчендә авылын тәки алдынгылар рәтенә чыгарды, сөт саву буенча да, эре терлек үрчетү буенча да беренчеләрдән булдылар, авыл җитештергән сыек майлар Казан кибетләренә озатылды.

Күңелсезлекләрнең башы Хәмзә Харисовичның фаҗигале төстә юл һәлакәтендә үлүе белән башланып китте. Камил бу олы хәсрәтне бик авыр кичерде, әлеге кеше әтисе кебек якын иде аңа, бөтен эшенә ярдәмче, киңәшче булды. Инде менә иң зур терәге юк. Остазын соңгы юлга озатканда, Камил хисләрен тыя алмый азапланды. Ир-атка сер бирүләр ярамый, билгеле, тик атылып чыгарга торган күз яшьләрен тыяр хәл юк иде, бәгыре таш булып катты, сулышы кысылды. Кеше-мазар күргәнче дип, ул ирексездән башын түбән иде. Зират эчендәге каеннар җилдә сагышлы тирбәлә, яфраклары әкрен генә шыбырдаша, алар, гүя, мәрхүмгә җир куенында тыныч йокы телиләр иде. Күмү эшләре тәгәлләнгәч, бар да тавыш-тынсыз гына зиратның көмеш айлы яшел капкасы ягына таба юнәлде. Камил зират читендә зар елаган хатын-кызлар арасыннан остазының тормыш юлдашы – Гөлнур апаны аралап алды да, аның иңнәренә сак кына кагылып: «Апа, кичер инде, ашыгыч китәсем бар, кич шалтыратырмын», – дигән сүзләрне әйтеп өлгерде. Гөлнур апасы әллә аңлап, әллә шулай тиешлеген чамалагандай итеп баш какты.

Камил, машинасын кабызды да авылга таба юл алды. Бүген Әнәс аның белән бармаган иде, рәхәтләнеп үз иркеңә уйларыңа бирелеп кайтырга була. Әнәс яхшы егет үзе, тик кайчагында күп сөйли, тәмам ардыра. Бәлки, ул шулай Камилне бераз борчуларыннан арындырмак буладыр, әллә ниткән мәзәкләр, кызык хәлләр сөйләп тәмам башны катыра. Бүген исә Камилгә үз уйлары белән калырга бирәү дә комачауламый. Башында йөз төрле уй. Әй, кыен да соң бүген... Рәхәтләнеп сөйләшер, күңел бушатыр кешесе дә юк бит аның. Дус булып йөргәннәре дә ялагайлану өчен генә. Миләүшәсе дә ачылып китә торганнардан түгел, Сания белән сөйләшеп утыргандагы кебек күзгә-күз карашып рәхәтләнеп серләшә алмый ул. Сания үзе белән бөтен дөнья ямен алып китте, диярсең. Кайчагында Камилне шундый төшенкелек биләп ала ки, аның әллә кайларга китеп югаласы килә. Саниясе белән китеп югалыр иде дә бит, ул кияүдә, баласы бар. Радиодан да, йөрәкне өздереп:

> Яшьлектә сөйгән яр,
> Сагындым килеп ал...

– дип җыр сузалар җитмәсә. Сания белән китеп барыр иде микән Камил?

Хәзер, нәкъ менә шушы минутта каршына зәңгәр күлмәген киеп килеп чыкса, һичшиксез, ияреп китәчәк. Тик бу – бары хыял һәм аны чынга ашырырга ярамый. Әйе, әйе, ярамый! Инде Камилнең улы бар, Миләүшәгә биргән вәгъдәләрен дә ничек таптап үтмәк кирәк, аларны бәхетсез итеп, үзең турында гына уйлау зур гөнаһ булыр.

Менә таныш борылыш, тиздән аларның авылы. Тау итәгенә һәм елга ярына елышып утырган авылы бигрәк матур инде! Тирә-яктагы урманнар, гаскәри кебек тезелеп, әйтерсең, авылның тынычлыгы сагында тора. Тау итәгенә җәелгән чәчкәле чуар келәм исә ниндидер сихри көч белән үзенә тартып тора. Их, шул келәм өстеннән, яланаяк килеш иртәнге чык тамчыларына баса-баса, бер урап кайтасы иде. Ә аннары, шул хәтфә келәм өстенә ятып, зәңгәр күктәге ак болыт көймәләренә утырып туйганчы йөзсәң икән! Кояш нурларында иркәләнеп алу өчен елга өстендә сикерешеп уйнаган балыклар белән колач җәеп бер коенсаң да була. Бу рәхәтлекләр өчен Камил җанын бирергә әзер. Шушы матурлыкны, хозурлыкны ничек ташлап китмәк кирәк. Юк, китмәячәк ул моннан, китмәячәк! Саниясе чакырса да – китмәс!

Әнә шундый уйлар дулкынында тирбәлеп кайтты Камил.

Авылга килеп кергәндә, машинасы белән тузан туздырып, аның янәшәсеннән Алмаз узып китте – акны-караны күрми, башы-күзе акайган. Камилгә сәлам бирү кая ул, борылып та карамады. Ул узып киткәч тә, Камил берничә тапкыр көзгесенә карап алды, арттагы машина бөтенләй күренми, тузан өере генә өстерәлеп бара сыман. «Да-а, малай, каядыр ашыга», – дип куйды үз-үзенә Камил.

Алмазның болай ашкынуы юкка булмаган, моның сәбәбе ике көннән соң мәгълүм булды. Ул, дуамалланып, Самат Хәбирович янына җилдергән икән, бу хакта Камилгә Хәмзә абыйның элекке сәркатибе Халисә шалтыратып әйтте. «Алар озак сөйләшеп утырдылар, Алмазны элеваторга эшкә билгеләделәр. Кемнедер, мин сезне дип аңладым инде, тиздән юлдан алып атабыз, дип лаф ордылар, Камил абый, саграк булыгыз», – диде. Димәк, Алмаз үзенә яклаучы тапкан, ә Саматы күптән үзен район җитәкчесе итеп күрә иде бит инде, ниһаять, хыялы чынга ашкан, күрәсең.

Камилгә район җитәкчесенең кем булуы мөһим түгел иде, фәкать аның хуҗалык эшенә генә аяк чалмасыннар. «Нидән курыксаң, шул килә дә чыга», дип тикмәгә генә әйтмәгәннәр шул – Камилгә аяк чалып кына калмадылар, сугып җиргә дә аудардылар. Иң элек, Хәмзә абыйсының кырыгы үткәннән соң, яңа җитәкче Камилне үзенә чакырып, нәселле сыерларның унбиш башын күрше авылга илтергә боерды, янәсе: «Син генә сөткә туенып яшәмә әле, аларга да булышырга кирәк». Икмәк саткан акчага хөкүмәт биргән субсидияләрне дә кушып алган, күз карасыдай саклап торган малкайларын председательнең бер дә бирәсе килми иде, ул теше-тырнагы белән карышты. «Нигә алар әзергә-бәзер яшәргә тиеш әле, тир түгеп табылганы гына кадерле була аның», – дип тарткалашты.

Самат Хәбирович үз сүзен бирмәде. Озак та үтмәстән, сыерларны алып китү өчен килеп тә җиттеләр, вәләкин савымчы апайлар «бирмибез» дип күкрәк-сәнәк тотып каршы чыкты. Вакытында Камил килеп җитмәсә, ниләр белән беткән булыр иде бу вакыйга. Председательләрен хөрмәт иткән апайлар, аның ни әйтәсен ишетергә теләп, бар да аңа төбәлде. Камил сабыр гына: «Борчылмагыз шулкадәр, без аларны җибәрергә тиеш, шулай хәл ителгән, сез карышып кына берни үзгәрми, зурга китсә, үзегезне җыеп милициягә ябып

куярлар, мин сезгә бераздан яңаларын кайтартырмын, Алла теләсә... әлегә әнә күрше авылдан алып килгәннәрен савып торырсыз», – диде. Савымчы Зөлфия бик карышасы килеп авызын ачкан иде, янында басып торган Сабира апа аның җиңеннән тартып куйды. Шул рәвешле, йөзләрендәге ризасызлыкны югалтмыйча гына, сыерларны машиналарга төяргә керештеләр. Күрше авылдан килгән сыерлар исә ике айдан соң бишкә генә калды, кайсы билгесез чирдән үлеп китте, кайсының күзе сукырайды, кайсының җилене корыды.

Күңелсезлекләр әле моның белән генә бетмәгән икән, кышын кырык баш үгез бозау егылып үлде. Иң элек ферма мөдире бер көн алдан биш бозау үлүен хәбәр итте. Ветеринар Илгиз аларның кинәт кенә үлүенә: «Кичә генә рәхәтләнеп ашап, мөгрәп торалар иде бит, бер төн эчендә ни булган аларга?» – дип гаҗәпләнде. Икенче көнне иртән калган утызы да егылып үлгәч, Илгизне йөрәк өянәге белән район хастаханәсенә алып киттеләр. Районнан тикшерүчеләр килеп төште, үгезләрне агулаулары ачыкланды. Иң элек бишесен, икенче көнгә калганнарын харап иткәннәр. Каравылчы Наилне күпме генә сорау алып интектерсәләр дә: «Беркемне күрмәдем, берни ишетмәдем», – дип, ул үз сүзендә тора бирде. Ә ике көннән соң Наилне ферма эчендә асылынган килеш табып алдылар. Мордар киткән Наилнең әнисе: «Ул төнне аны алып чыгып киттеләр, ул үзе эшләмәде бу эшне, мин әйткәннәрне беркемгә әйтмә, зинһар, үзең генә белеп тор, кызларыма зыян салырлар», – дип үтенеп елады. Камил, кемнең кулы уйнаганын сизенсә дә, берни эшли алмады. Өстәвенә, тикшерүчеләр дә «бернинди дәлилләр юк» дип районга кайтып киттеләр. Булса да, Самат Хәбирович күз йомарга әмер биргәндер, күрәсең: «Зурга җибәрмик, бу хакта өстәгеләрнең белми калуы хәерле», – дип, Камилне дә кисәтеп куюы бер дә юкка булмагандыр.

Шушы хәлләрдән соң Камилнең кулыннан эш төште, авылның якты киләчәген күләгә каплады. Бу вакыйгаларга ахыргы нокта Миләүшә тарыган хәлдән соң куелды.

Көннәрдән бер көнне Камилнең хатыны районга баргач, Әнәс аны, башка эше килеп чыгу сәбәпле: «Кайтканда килеп алырмын», – дип, хастаханә янында калдырып китте. Миләүшәнең эше бетсә дә, Әнәс күзгә күренмәде, ахырда хатын, кайта торырын уйлап, олы юлга чыкты. Ярты юлны ул узгынчы җиңел машина белән кайтты, икенче өлешен шактый гына җәяү тәпиләргә туры килде. Көзге җил тәмам үзәгенә үтте, битләрен, кулларын чеметте. «Кайда йөри инде бу Әнәс?» – дип, артына борыла-борыла кайта бирде Миләүшә. Менә шулчак аны бер «УАЗ»ик куып җитте, хатынның кул күтәргәнен дә көтмәстән, туктап та калды. Миләүшә, ниһаять, тәненә җылы иңәр дигән шатлыгыннан, берни абайламыйча, ачылып киткән ишектән машина эченә чумды. Руль артында таныш йөзле сыманрак кеше утыра иде. Хатын кайсы авылга кайтасын әйткәч тә, ул сүз дәшмичә, башын гына какты. Арткы утыргычта тагын ике ир-ат бар иде, Миләүшә аларны күз кырые белән генә шәйләде, никтер йөзләре кара сыман иде, борылып карарга кыймады, тын гына тәрәзәгә карап бара бирде. Авылларына бер-ике чакрым кала машина юл читендә туктап калды, Миләүшә ни булганын да аңышырга өлгермәде, йөртүче ишекне ачып төшеп тә китте. Машинасы ватылган, ахры, дип уйлап куйды хатын. Шулчак аның муенына нindидер очлы, салкын тимер кисәге терәп куйдылар, авызын, борынын капларга тырыштылар. Миләүшә чәбәләнергә омтылды, әмма аның кулларын кысып тотып, урындык артына таба каердылар. Машина эчендә:

– Тик кенә утыр, безне тыңла... бүген исән каласың килсә... – дигән тупас сүзләр яңгырады.

Арттагылар исә бу сүзләрдән шаркылдашып көлештеләр.

– Иреңә әйт, бер атна эчендә эшләрен тапшырып авылдан китмәсә, баласына, анасына, барыгызга да көн бетәчәк. Милициягә барып изаланмасын, безнең барысы да схвачено, ишеттеңме? – дип, арттагы ир-ат Миләүшәнең бугазына баса төште.

Хатын, аңлавын белдереп, баш чайкады. Инде нишләтерләр, көчләрләрме (карынында бит бала, ул бу хакта бүген генә белде), кыйнап кына калдырырлармы?.. Исән калса, улын алып иртәгә үк әнисе янына шәһәргә китеп барыр иде дә бит... Инде менә аның язмышы шушы хәшәрәтләр кулында. «Аллаһым, үзең ташлама мине», – дип ялварды Миләүшә, күзен чытырдатып йомып. Шулчак шофёр егет икенче яктан килеп Миләүшә ягындагы ишекне үрелеп ачты һәм хатынны машинадан тартып та төшерде. Хатын юл читендәге ташларга бәрелгән тезләренең, кулларының әрнүенә түзә алмыйча чыраен сытты. Ул аягына басканчы ук, «УАЗ»ик җилдереп китеп тә барды, номерын күрә алмады, пычрак белән сыланган иде.

Миләүшә, кыр буйлап авылга кистереп кенә чыгарга уйлап, юлдан түбән төште. Үзе гарьләнеп елады, үзе йөгерде, үзе Камилне сүкте. Әнәскә дә эләкте, егылып бетте, тезләрен янәдән канатты. Баш очында ямьсез тавышлар белән кычкырып йөргән козгыннар күңеленә шом салды. Чәчен-башын туздырып, тәмам пычракка буялып кайтып кергәндә, авылда караңгы төшкән, багана башларында ут яна иде. Миләүшә, ишектән керү белән, аптырап карап торган каенанасына бер сүз дә аңлатып бирә алмыйча, идәнгә шуып төште дә илереп елап җибәрде. Мәйсәрә апа киленен култыклап түргә таба алып китте. Ниндидер күңелсез хәл булуын сиземләсә дә, ана кеше әлегә берни сораштыруны кирәк тапмады.

– Сабыр бул, сабыр, әнә, сабыеңны куркытасың... Хәзер Камил кайтып җитәр... хәзер... хәзер кайнар чәй ясап бирәм, менә монда башың куеп тор, балакаем, – дип, ул Миләүшәне урынга яткырды да икенче якка чыгып, киптереп куйган мәтрүшкәләрен эзли башлады. Бераздан өйгә хуш исле үләнле, җиләкле чәй исе таралды. Мәйсәрә апа килененә яңа киемнәрен алып килеп бирде, табак белән җылы су алып килеп, аяк-кулларын юдыртты, чәй эчерде. Аннары калын юрганга төреп яткырды да тышка чыгып китте. Миләүшә идәндә гамьсез уйнап йөргән баласына карап хәрәкәтсез ята бирде.

Камиле эштән кайткач, булган хәлләрне елый-елый сөйләде Миләүшә, китәбез дип ялварды, ире риза булмый икән, үзенең иртәгә үк Казанга күчеп китәсен әйтте. Ир тыныч кына тыңлап торырга тырышты, хатыны кичергән хәлләрдән соң карышырга хакы юк икәнлеген аңлады. Шулай итеп, Миләүшә улын алып, Казанга күченеп китте, хат аша гына Камилгә икенче нарасыйның туасын хәбәр итте. Ир дә, әнисенең шактый үгетләүләреннән соң, балаларын ятим итмим дип, шәһәргә күчәргә мәҗбүр булды. Анда бераз аякка баскач, әнисен дә үз янына алып килде.

Авылның киләчәге хакында озак уйланды Камил, тик монда калып кына ул берни үзгәртә алмаячагын ачык аңлады, аңа нишләсә дә аяк чалачаклар иде. Шуның өстенә, тирә-яктагы авылларны инвесторлар яулый башлады, иртәме-соңмы алар монда да килеп тамыр җәячәк иде. Шулай итеп, Камилгә туган авылын, туган нигезен, күңеленә якын булган авылдашларын, киң басу-

кырларын, көр терлекләрен, балыклы елга-күлләрне, баһадир тауларны, кереп адашырлык урманнарны ташлап китәргә туры килде. Бу чын ир-ат өчен хас булмаган адым булмаса да, Камил язмышына буйсынды.

**3**

...Сания юл читенә күз салды. Тышта җәяүле буран, ул кар бөртекләрен өереп ала да юл кырыена китереп сылый. Бу «вальс»ны карап тору рәхәт тә, шомлы да кебек. Күңелгә ирексездән:

Әйләнә кар, әйләнә ак дөнья...

– дигән җыр юллары килә. Әйе, дөньясы да, ташкын хисләрдән башкайлары да әйләнә Саниянең. Ниндидер саташу бу, әлеге юләр хисләрне ничек тә йөгәнләргә кирәк ләбаса. Бу язмыш кайтавазы хәерлегәме? Үткәннәргә кайтып, йөрәк яраларына учлап-учлап тоз салу нигә? Язмышыңа буйсынып яшәү хәерле. Шәһәрдә аны ире, ике кызы, үзенең яраткан эше, хезмәткәрләре көтә. Ул бит бу ирешкән уңышларына шулкадәр авырлыклар аша килде. Аларны ничек бер мәлдә сызып атып булсын! Әле бит Казанга кайтып җитәсе дә бар, аның «тимер аты» инде күптән юл буенда зарыгып көтә. Машина өстен кар каплап та өлгергән, ян-якларына көрт баганаларын өйгән. Бу кар көртеннән чыгып, хисләрен йөгәнләп китә алырмы бүген Сания? Камилдән бер дә аерылып китәсе килми шул аның...

– Камил, нигә дәшмисең? Үзең турында сөйлә инде, хәзер кем булып эшлисең, кайда яшисең? – дип, тынлыкны бозды Сания.

– Мин җирдән, авыл хуҗалыгыннан ерак китә алмадым инде, Сания. Башта Казанга күченгән идек тә, соңыннан районга кире әйләнеп кайттык. Шәһәрнең һавасы тынны кыса, ул таш диварлар җилкәмә басып торадыр сыман. Күнекмәдем, яши алмадым шәһәрдә. Хәзер үземнең «Гаилә фермам» бар. Шулай дип аталган дәүләт программасы турында ишеттем дә җиң сызганып эшкә керештем. Башта бозаулар сатып алдым, инде алар сөт бирә торган сыер булды. Шул программа нигезендә ике савым аппараты бүләк иттеләр, үзем дә берничәне сатып алдым. Ялланып эшләүчеләрем дә канәгать, үземә дә җитә, Аллага шөкер. Кибетләргә сөт, эремчек тапшырабыз, тора-бара сыр цехы ачарга исәп. Ничек икәнен чит илгә барып белешеп, карап кайттым инде. Эштән курыкмаган кешегә авылда яшәргә була. Үземнең җиремдә югары сортлы бодай, борчак үстерәм, егерме баш умартам бар... җәйгә бал ашарга кил, Сания. Минем турыда сораштырасың да сораштырасың, үзең турында берни сөйләмисең, Сания?!

– Буйга җиткән ике кызым бар. Ирем – университетта профессор. Ә үзем – эшмәкәр. Башта, укып бетергәч, банкта эшләп алдым. Аннары, хезмәттәшләрем киңәше белән кредит алып, үз эшемне ачып җибәрдем. Тәмле-тәмле пироглар, өчпочмаклар пешереп сатабыз, – дип көлемсерәп куйды хатын.

– Да, тәмле ризыкларның рецептын Бибинур апа өйрәткән булгандыр инде, – дип елмайды ир. Бер мәлгә аларның карашлары очрашып алды. Камилнең һәр сүзен, һәр җөмләсен отып калырга, күңеленә сеңдерергә тырышты Сания. Тик менә саубуллашыр минутлар гына якынайганнан-якыная бара иде.

– Ярар, Камил, миңа кузгалырга вакыт, буран да көчәя, – диде, ниһаять, Сания һәм ирнең күзләренә тутырып карады. Камил дә зәңгәрсу күзләре белән аңа текәлгән, әйтерсең, ул аның бүгенге сурәтен шул рәвешле исендә

калдырырга тели иде. Көйдереп ала торган бу карашка, кайнар сулышка ничекләр бирешмәскә, ничекләр генә сер бирмәскә? Сания башындагы шәлен рәтләгән булды, тузгыган чәчләрен яшерде, бияләйләрен киеп, машинадан төшәргә теләгәндәй итте. Камил аны, җибәрмәскә теләп, кулларыннан тотты:

– Сания, тагын аерылабызмыни инде, син янәдән качасың, – дип пышылдады. Камил элеккегечә чибәр, мөлаем йөзле, яшьлектәге сөйгән ярының иреннәреннән үбеп алмас өчен хисләрен көчкә тыеп, йөгәнләп тора иде. Юк, ярамый, үпкәләр, рәнҗер, бозык адәмгә санап, алдагы очрашулардан баш тартыр. Бу ялгыш адымны ясап, киләчәктә Саниясен күрү бәхетеннән бөтенләй коры калуы да бар...

– Миңа китәргә вакыт, Камил... Инде яшьлек эзләребез суынган, үткәнгә юллар юк, язмышыбызга буйсындык инде без. Син – минем өчен иң кадерле кеше, тик хәзер үзебез өчен генә яши алмыйбыз, кичер, Камил... – диде Сания, яшьләре атылып чыгарга торган күзләрен яшерергә теләп. Аннан машина ишеген ачты да җиргә сикерде. Камил дә аны озатырга дип урыныннан калыкты.

– Сания, син дөрес әйтәсең инде... дусларча аралашып яшик, телефон номерыңны калдыр, менә минеке, – дип, Камил визиткасын сузды. «Шәхси эшмәкәр, фермер Камил Сәләхов» диелгән кәгазь кисәге иде ул. Хатын да үз чиратында кесәсеннән визиткасын табып бирде. Аннары машинасы ишегендәге карны бияләе белән сыпырып эчкә узды. Салкын, шундый шыксыз иде монда. Камилнең машинасындагы җылылык, аның татлы сулышы, үзенә генә хас хуш исе кышкы буранның теге ягында бүленеп калган иде. Йомшак буран эченнән Камилнең:

– Мин сине сагынырмын, Сания! – дигән сүзләре генә ишетелеп калды.

Әле җылынырга да өлгермәгән машина теләмичә генә алга ыргылды, тәрәзәгә кар бөртекләре сыланды, пыяла чистарткыч аларны бер яктан икенче якка куып йөртте. Саниянең бит алмаларыннан кайнар яшь тәгәрәде. Шулчак кесә телефоны шалтырады, анда, таныш түгел номер кабынган иде.

– Алло, кем әле бу?

– Сания! Мин бу, Камил... исән-сау кайтып җит, уйламыйча әйтелгән сүзләрем өчен гафу ит, зинһар, шалтырат яме, югалма...

Телефон өзелде. Күпмедер вакыттан соң буран туктады, кояш үзенең нурларын яңа кар өсләренә сипте. Машина тәрәзәсен сарган кар бозлы тамчылар булып аска тәгәри башлады. Саниянең исә үз уйлары карлы дулкындай агылды... Чын хисләр бернигә дә, хәтта язмышка да буйсынмый, күрәсең, әнә бит алар икесенең дә күңелендә яңадан кайнар чишмә сыман тибеп чыкты. Ә чишмәләр – елгага, елгалар – диңгезгә, ә диңгезләр әллә кайларга – океаннарга кадәр барып җитә лә ул.



Луиза
Янсуар

# ТУЗГАНАК ТАҖЛАРЫН КӨРИБЕЗ

## О-ныт-мас-ка!

**1**

Алар өчен телең дә юк синең,
Илең дә юк...
Сүндер төшләреңне!
Яшьлек хыялыдай
Беркатлырак
Булганга, ул бик тиз өшәндеме –
Безнең ирек?
Очсызгарак төшеп
Югалттымы үз кадерен, затын?
Алар өчен
Без олтырак кына,
Дәверләрдә солтан булган халкым.

**2**

Кемнең тәхетенә әверелер
Яңа җан йөгерткән кирмәннәрем?
Әйтерсең, мин, кендек каным тамып,
Дөньясына хәтта килмәгәнмен...
Бик борынгы кояш асларында
Күпне күргән
Һәм бик күпне белгән. –
Мин, әйтерсең, бетмәгәнмен янып,
Әйтерсең, баш калкытмаган көлдән.
Оныт, диләр,
Кайсы кышлауда син
Чыккан идең соңгы кабат кышлап.
Тик онытма:
Кемгә тез чүктең

---

*Луиза ЯНСУАР – шагыйрә; «Мин күкләргә кайтам», «Болан кызы», «Без җан өргән учак» исемле китаплар авторы. Россия-Италиянең Халыкара «Белла» һәм Республиканың М.Җәлил, язучыларның С.Сөләйманова исемендәге әдәби премияләр лауреаты. Казанда яши.*

Һәм
Ант китердең,
Кемнән алдың бөят.

Әйтерсең, без булмаган да җирдә.
Әйтерсең, без – тамактагы сөяк.

**3**

Яшем белән юып
Үбәм синең
Ташларыңны –
Хәрабәгә калган.
Дөньялыкның
Кай читенә барма,
Сөйләшәләр
Минем телдә һаман.

Кайсы гына
Туфрак
Сугарылсын,
Кубарылсын –
Минем тарих калка:
Тәңкәләре, әнә,
Сөңгеләре,
Каберлекләр
Еламсырап ята.

Әнә, бик борынгы
Тынлыгыннан
Күләгәләр
Күтәрелә иңрәп:
Мин – аларны,
Алар мине таный,
Һәрберсенә
Кушуч
Дога кирәк.

Сөт тәмен дә,
Сөю тәмен дә мин
Үз илемдә
Үз телемдә
Белдем.
Оныт, диләр,
Тик йөземә бәрә
Бик борынгы,
Ирек сөйгән
Җилем.

**4**

Оныт, диләр,
Кайсы җәйләүдә син
Чыккан идең соңгы кабат җәйләп.
Ул җәйләүдә атлар үрсәләнә,
Күз алартып, авызлыгын чәйнәп.

Кендек каным тамган тамырларны
Кубарам да,
Бер йодрыкка
Төйнәп,
Карап торам:
Ватанымны
Минем
Йота бара
Дәвасы юк
Үләт –
Б и т а р а ф л ы к
Ул очсызга төшә
Кемнәргәдер.
Ә кемгә –
Бик кыйммәт.

***

Сөйләшәсем килә, дисең,
килә сөйләшәсем.
Белмим, ләкин сиңа хәзер
ничек эндәшәсен.
Тынлык аша, колак ярып,
ишетелә тының.
Сүзләр күп ул,
сөйлим кайсын –
ялганынмы? Чынын?
Сиңа кайсы кулай, белмим,
һәм кайсысы тансык?
Гавамың бит
сүздән тора:
и сөйлиләр, ярсып,
кайчан кемне сөйгәннәрен,
сөймәүләрен кемне, –
агып керә бүлмәләргә
серме? Дөнья кере?
Безнең, дисең, сөйләшер сүз
бер дә калмаганмы?
Миндә сүзләр күп,
юк никтер –
сиңа яраганы.

## Югыйсә

Иделне кубарып җил исә...
кайдандыр –
Тынлыкның түреннән.
Тавышын ишетеп уяндым.
Качырды йокымны
бүген дә.
Уяндым,
шул тавыш эчендә
ишетеп тыенкы көлүен
кыңгырау чәчәкнең.
Көтүгә
әйдәкләп
Актырнак өрүен.
Төшләрдән төшләргә күчкәләп,
бер кайта,
бер килә йөрибез.
Ил дә шул
югыйсә.
Дәвер дә.
Тузганак таҗларын көрибез.
Ә аннан –
шашынган карларны...
Үзгәреш көтәбез –
кемнәндер!
Офыкта бер күкрәү
уяна…
Ул, бәлки,
соңарган сөрәндер?!
Төмәнче
гаскәрен барлыйдыр:
кем үле бу илдә?
Кем тере?
Иделне кубарып җил исә...
Җил түгел.
Халкымның хәтере.

***

Каракучкыл җилгә чыгып бастым.
Язмышымның шундый чаты бу:
Йә шул җилнең кочагында янып,
Йә, коргаксып, җиргә ятып үл.

Каракучкыл җилгә чыгып бастым,
Карашында күреп үземне.
Һәм карчыга күзле бер угланны,
Җирдә әйтелмәгән сүземне.

Каракучкыл җилгә чыгып бастым,
Әверелеп җаны корычка,
Атлагандай учагына Жанна –
Короленә тугры, кылычка.

Каракучкыл җилгә чыгып бастым.
Йөгәннәрен кулдан чөйде дә,
Ул күтәреп алып кайтты мине
Давыллардан корган өенә.

Һәм аңладым:
Мин дә – шул ук давыл.
Кубарылып, кайнап, сүнәбез...
Елмая ул:
– Очрашмаган булсак,
Белмәс идек хәтта – кемнәр без.

Каракучкыл җилгә кереп качтым.

## Кичке пастораль

Урамнарга кич кергәндә,
җил төргәндә – сине, мине, –
баш очында йолдызлана,
коңгызлана Аның иле...

Дөнья җиргә яңа туган,
күзен ачкан сабый ише.
Кайсыбызның өнедер бу,
кайсыбызның, белмим, төше.

Белмим.
Көләм!
Кыңгыраулар
көлә ерак басуларда.
– Алар, – дисең, – шундый наян
һәм нәзберек – ачулана –

Ялгыш кына орынсаң да...
кыңгыраулар –
күгең төсе.

Тып-тын гына эри бу кич,
биләвенә төреп
безне.

Кичләр хәзер сиңа охшаш –
үзе сабый,
бакый үзе,
дөнья җиргә яңа туган:
тибрәп тора
ап-ак бүзе.

Урамнарга кич кергәндә...
– Томан, – дисең, –
көзге... томан...
Мин кыңгырау
сабагында –
өзелми –
чак
эленеп
торам.

## ТУГАН ТЕЛЕМ

Горурланам мин үземнең
Татар булуым белән.
Ата-анам беренчелдер,
Аннан соң Ватан – беләм.

Туган телем – Анам теле,
Кимсетмәсеннәр ятлар.
Яшәтергә иде аны,
Күз карасыдай саклап.


План кормасын бәгъзеләр,
Бары бертеллелек, дип.
Аллаһ кавемнәрне бердәй
Яралткан, якын күреп.

Теленә кара язмышны
Кем генә теләр икән?!
Аңа ясин укысалар,
Иртәгә мин дә үләм.

Хәер, үлмим. Көтмәсеннәр.
Телем өчен көрәшәм.
Миллионлаган кардәшләрем,
Сезне дә шуңа дәшәм.

Ерак тарихтан билгеле
Татар теленең көче.
Төркиләрнең кабатланмас
Бизәге ул, бер төсе.

**Фирдәвес ХУҖИН**



Нурания
Төхбәтуллина

# СӨЙЛИ, ҖЫРЛЫЙ, САГЫНА ТОРГАН МАТЕРИЯ

ХИКӘЯ

Вакыт-вакыт көчәеп каршы искән ачы җил йөзләрне кисә, сулышны томалый, аяктан ега. Гәүдәне турайтыр хәл юк, үзеңнән-үзең бөкрәясең, котырынган җилдән җиргә капланып котыласы килә. Тик... капланып кара – әнә ике яктан һау-һаулаган бозау кадәр этләре белән конвоирлар төркемне алга куалый.

Ниһаять, җил чак кына басылгандай булды. Аякларын сөйрәрлек тә хәле калмаган хатын, җәзаланып барган җиреннән беренче тапкыр башын күтәреп, тирә-ягына күз салды. Ярабби! Иксез-чиксез киңлектә шәрә табигать. Күзне иркәләрлек бер генә яфрак та юк. Ни куак, ни алама гына булса да бер агач кисәге күренми, үләнгә охшаган фәкыйрь үсемлекләр җиргә шулкадәр дә сырышкан, аларны хәтта нинди көчле җил дә кузгата, тибрәтә алмый. Бары тик каядыр бик еракта, тау тезмәләренең кар каплаган түбәләре ялтырап тора. Тирә-яктагы үле бушлыктан җан өшеп китә, күңелне аңлатып бирә алмаслык төшенкелек били, сагыш баса.

Хатын бу җирләр турында кайчандыр укыганнарын исенә төшерде. Ураган көченә җитә торган аяусыз җилләрне Баренц диңгезе белән Карское диңгезе арасындагы климат үзенчәлеге һәм температура аермасы тудыра. Бу – җелеккә төшәрдәй зәмһәрир суыклар, мәңгелек бозлар, өермәләр хөкем сөргән тәмуг. Монда табигать иҗат та итми, җимерми дә (вафат булсаң, гәүдәң дә черемәячәк). Бу – үлем иле. Үлем иленә рәхим итегез!..

Газаплы уйларыннан котылырга теләп булса кирәк, хатын үткәннәрен уйлый башлады. Ә үткәннәре әнә генә, кул сузымында гына, гүя күз алдында гына...

Хакимият башында торган «Прагматиклар» фиркасе бу юлы да сайлауларда җиңеп чыкты. Хәер, прагматикларның җиңәсе праймериз вакытында ук күренде инде. «Капитал», «Оптиматы» (борынгы Римда аристократлар партиясе), «Salus populi suprema lex» (җәмгыять өчен файда – иң югары канун) кебек вак-төяк фиркаләр 10% та тавыш җыя алмады.

---

Нурания ТӨХБӘТУЛЛИНА – *вакытлы матбугатта дөнья күргән күпсанлы хикәяләр, «Мутантлар» дип аталган китап авторы. Әгерҗе районы Кадыбаш авылында яши.*

Элеонора, шәһәр судьясы, шушы фирка әгъзасы. Әгъзасы дип кенә әйтү аз, фирканең җәмгыятьтә югары катлам тәшкил иткән элитасына керә иде ул. Менә хәзер аның сайлаудагы җиңүне билгеләп үткән мәҗлестән кайтып барышы. Үзйөрешле аквамобильнең чак кына тирбәлгән йомшак кәнәфиенә ярым ятып, күзләрен йомган хәлдә, хатын бераз черем итеп алды. Ардырган иде, чөнки шәһәрнең иң бай ресторанында уздырылган бу мәҗлескә кичен эштән соң җыелдылар. Хәер, залның күркәм бизәлеше, өстәлләрнең затлы эчемлек, ризыклардан сыгылып торуы, дәртле музыка, тантанага җыелучыларның шатлыклы йөзләре – барысы да эйфория атмосферасы тудырганга, Элеонора да күмәк бәйрәмгә кушылып киткәндәй булды. Кайтырга чыккач кына, ару-талу үзен сиздерде. Юлы ерак әле. Алар – хәрби инженер булып хезмәт итүче ире Ян һәм Эльвина исемле кызы – шәһәр читендә менә дигән комфортлы йортта яшиләр. Гомеренең шушы дәрәҗәле, өстәвенә күпләр хыяллана да алмаган байлыкта, муллыкта үтә торган чорына җиңелдән килмәде ул.

Аны тудырып-үстергән гаилә уртача тормышлы иде. Элеонораның әтисе – заводта инженер, әнисе табибә булып эшләде. Бервакыт аларда ниндидер юбилей булып, бәйрәмгә әтисенең хезмәттәше белән хатынын да чакырганнар. Шул ханым, нишләптер, биш яшьлек Элеонорага игътибар итеп, аны шаяртып, сөйләштереп торган. Кызчыкның җитдилеге, аның үткен җаваплары кунакны гаҗәпләндереп, ул баланы элиталы мәктәпкә илтеп карарга киңәш иткән. Шулай итеп, әңгәмәләр, тестлар узып, Элеонора гадәти булмаган мәктәптә укый башлады. Анда балаларны, сыйныф саен тестлар уздыра-уздыра, ел саен аерым-аерым төркемнәргә тупладылар. Шулай итеп, кыл иләктән или торгач, кызны уку-укыту программасы яшерен булган ябык мәктәпкә кабул иттеләр. Монда аларны яңа җәмгыять төзү буенча белгечләр итеп әзерлиләр булып чыкты. Аналитик фикерләү сәләтенә ия Элеонорага югары математика, информатика кебек төгәл фәннәр җиңел бирелсә дә, әдәбият, тарих, хокук белеме кебек гуманитар циклга керә торганнарын үзләштерү проблема тудырды. Юк, ул аларны белми түгел, белә, ләкин аларда китерелгән фактларны, вакыйгаларны программа таләп иткәнчә шәрехли алмый, чөнки программадагы рухи, дөресрәге бөтенләй дә рухи булмаган юнәлешләрне, кыз бик озак кабул итә алмый йөрде. Ә сәбәбе – гаиләдә алган әхлакый тәрбия белән мондагысының капма-каршы диярлек булуында иде. Менә, мәсәлән, өйдә аны дөреслек, хакыйкать иң югары рухи кыйммәт дип өйрәттеләр. Әтисе:

– Аристотель дә: «Платон миңа дус, ләкин хакыйкать кыйммәтрәк», дигән бит, – дияргә яратса, әбисе исә: «Туры сүзем таш ярыр», – дип куя иде. Өстәвенә әбисе – намазлы-ниязлы кеше. Биш вакыт намаз аның яшәү рәвеше кебек, уразаны да һич калдырмый. Элеонорага да кечкенә чагында догалар өйрәтте ул, тик үсә-үсә кызның кызыксыну юнәлешләре башка якка – дөнья гыйлемнәре үзләштерүгә, спортка, яшьтәшләре белән аралашуга китте. Әйе, ни әйтсәң дә, «Үә мәл-хәйәәтү-ддүнйәә иллә мәтәәгүл-гүруур» (дөнья – ул сезнең кулыгызда бер алдавыч уенчыктыр).

«Дога – гыйбадәтнең җелеге, намазга басарга да вакыт», – дип тәкрарлаган әбисенең сүзен игътибарга аласы итмәде кыз. Әбисе үгетләп тә, ачуланып та карады, тик оныгы намазга басарга ашыкмады, аны ничектер икенче пландагы әһәмиятсезрәк нәрсә дип шәрехләде. Ах! Ничек ялгышкан ул! Ничек әбисенең «Фәз күруунии әзкүркүм!» (әй, бәндәләрем, искә алыгыз Мине сөенечле вакытыгызда, искә алырмын сезне авыр вакытыгызда) дигән кисәтүе хакында фикерләп карамаган.

Бу үкенү соңрак киләчәк, ә хәзергә ул дәрәҗәле мәктәптә белем ала. Тик монда бөтенләй башка төрле ориентирлар.

Дәреслек болай аңлата: «Борынгы ыруглык чорында кешеләр тупас көчкә генә буйсынган. Тора-бара, җәмгыять тормышы үзгәрешләргә дучар була башлагач, башлыклар, гади халык төркемен буйсындырып тоту өчен, тупас көчне канунлаштырган. Шулай булгач, канун ул – шул ук көч инде, бары тик цивилизация битлегенә генә төренгән. Димәк, кем көчле – дөреслек шуныкы. Ә кем көчле? Кемдә алтын – шул көчле».

Яңа җәмгыятьнең пароле – ул көч һәм икейөзлелек икән. Ә инде сәясәт дигәннәре әхлак белән бөтенләй дә килешми, чөнки алдашу, хыянәт, мәкер, кирәкле һәрнәрсәне сатып алу ише түбәнлекләр уңышлы сәясәтнең шартлары булганлыктан, сәясәт-пычрак нәрсә дигән әйтем киң таралган.

– Ничә гасырлар буе яңгыраган «Liberte, egalite, fraternite» (ирек, тигезлек, туганлык) дигән шигарьләр гомумән дә халык массаларының аңын томалау өчен генә кулланыла, – ди дә укытучы, бармакларын җәеп, кулын алга суза. – Күрегез, бармаклар тигезме? Тигез була да алмый. Кешеләр дә шулай. Акыл, сәләт, физик көч төрле кешедә төрлечә. Табигатькә каршы барып кына аларны тигезләргә була. Менә ничек: – укытучы кулын йодрыклый, – менә хәзер алар тигез. Ирек дигәне исә, гомумән, абстракция гына. Ирек ул бөтенләй башка нәрсә. Хәзер аңлатам.

Аннан укытучы сорау куя:

– Әйтегез әле, нәрсә ул акча?

Төрле яктан төрле җаваплар килә.

– Юк, берегезнең дә җавабы дөрес түгел. Акча – ул ирек. Димәк, ирек – ул акча; алтынлы, ягъни акчалы кеше чын мәгънәсендә irекле кеше. Ә инде туганлык дигән нәрсәгә килсәк, тамырлары тарих төпкеленнән килгән халык аны үзенең бик тә мәгънәле бер гыйбарәсендә уналтынчы гасырдан башлап болай аңлаткан: брат братның көтү көткәненә рад. Борынгы рим шагыйре Плавт бу турыда кискенрәк тә итеп әйткән: «Homo homini lupus est» (Кеше кешегә бүре). Төшендегезме инде?

Мәктәптә иң игътибар ителгән нәрсә – ул пропаганда фәне. Һәм аны үзләштерүгә карата катгый таләпләр куела иде. Халык аңы белән ничек идарә итүгә аеруча басым ясала... Бу манипуляция, нигездә, массакүләм матбугат чаралары (укытучы аларны җәмгыятьнең нервлары дип атады) ярдәмендә башкарыла икән. Элеонора хәтерли әле, беренче дәрестә үк укытучы бу чараларның яңа җәмгыять төзүдәге ролен ассызыклап, Йосеф Геббельс сүзләрен китергән иде: «Бирегез миңа массакүләм информация чараларын һәм мин теләсә кайсы халыктан дуңгыз көтүе ясармын». Шулай ук «Информация кем кулында булса, шул – дөньяга хуҗа» дигән афоризмны да бик еш тәкрарлап тордылар. Ә инде киләчәк җәмгыятьнең Конституциясенә килгәндә, анда халык өчен дип язылган хокукларның күпчелеге фактта фиктив, ягъни чынбарлыкта куллану өчен яраксыз булачак. Массаларны сәясәттән, тормыштагы проблемалардан читләштерү максатында исә Римның «Panem et circenses» («Икмәк һәм тамаша») дигәнен үрнәк итеп алып, халыкка вакыт-вакыт төрле тамашалар, бигрәк тә спорт ярышлары оештырылып торачак икән.

Менә шундый төшенчәләрне үзләштереп укыды кыз. Монда аларны кырыс реалистлар итеп, хәтта ки хиссез-моңсыз роботлар кебек итеп әзерләделәр... Сагыну-сагышлар, үкенү, хакыйкатькә омтылу, ярату-сөю,

кызгану, ярдәм итәргә теләү кебек кешегә хас эмоцияләрдән алар азат булырга тиеш иде.

Укуының соңгы елында Элеонора яшьләрнең «Реалистлар» төркеменә керде, чөнки моннан «Прагматиклар» фиркасенә туп-туры юл. Тик максатына бик озак ирешә алмый йөрде кыз. Чөнки... чөнки ул ирекле, ягъни акчалы түгел иде. Гаиләсендәге бер вакыйга гына аңа хыялына ирешергә мөмкинлек бирде.

Әбисе еш кына үзенең әбисен әхлак эталоны буларак искә ала иде. Ерак әбиләре балалар сәнгать мәктәбендә директор булып эшләгән. Татарларга хас сыйфат: эш аты булган, вазифасына зур җаваплылык белән караган. Үзенә зур таләпләр куйгангамы, кул астындагылардан да эшләрен тиешенчә башкаруларын таләп иткән. Эш таләп иткән – бары тик шул гына, ләкин, гомумән алганда, аларга карата йомшак мөгамәләдә булган. Әлеге демократия, либераллык аңа кыйммәткә төшкән: әбисенең таләпләрен өнәмәгән ике хезмәткәр, коллективны аңа каршы котыртып, ул шундый, ул мондый, дип, төрле ялалар ягып, бу эзәрлекләүгә ата-аналарны да тартып, әбисен директорлыктан алдыртуга ирешкәннәр.

Элеонора бу турыда кечкенәдән ишетеп үскәнгә, чыгарылыш сыйныфына җитәрәк, әлеге ерак тарихны үзенчә анализлап карады һәм, алган белемнәренә таянып, шундый нәтиҗәгә килде. Әле бит урыс патшасы Пётр I үз заманында болай дигән: «Кешеләрдә дөреслек бик аз, ә мәкер күп». Бәс, шулай икән, ягъни яхшы күңелле кешеләргә караганда начарлары күбрәк икән, алар белән идарә итү дә авторитар, алай гына да түгел, куркыту белән булырга тиеш. Кул астында эшләүчеләр салып куйган киемеңнән дә курыксыннар! Ерак әбисе, идарә итүдә демократик мөнәсәбәтләр урнаштырырга тырышып, бик нык хаталанган. Әйе, Элеонора өчен бу зур сабак. Әнә укытучылары да тукып тора: «XIX гасыр галиме Маркс «Бытие определяет сознание» дип искәртүгә карамастан, гасырлар узып, бөтен дөньясы үзгәреп бетсә дә, көнкүрештә әллә нинди техник җиһазлар кулланыла башласа да, том-том китаплар, картиналар язылса да, гаҗәеп музыкаль әсәрләр тудырылса да, интернет әллә нинди яңалыклар, искитмәле хәлләр турында шауласа да, кеше дигәнең үзгәрешсез кала, ул консерватив: һаман шулай эгоист, көнчел, мин-минлекле, явыз; аның яшәү прицибы – үземнеке үзәктә, кешенеке кештәктә. Менә шундый җан ияләре белән җитәкчелек итү өчен, кырыс реалистлар кирәк шул. Ә ерак әбисе, күрәсең, романтик булган, шуңа да картиналар язгандыр инде ул. Аның ике картинасы пейзаж булса, өченчесендә – «Әнием мирасы» дип аталганында – чигүле намазлык, яшел дисбе һәм Коръән китабы сурәтләнгән иде.

Ерак әбисеннән калган ике картинаны аукционга куеп саттылар. «Әнием мирасы» дип аталганын, ерак әбиебезнең ядкаре дип, үзләрендә калдырдылар. Картиналарны сатудан кергән акча гаиләнең матди хәлен көткәннән дә югарыга күтәрде, бу инде Элеонораның юлында яшел ут кабынуга тиң иде. Ул алтын яшьләр арасында бөтерелә башлады. Озак та үтми аны «Прагматиклар» фиркасенә дә кабул иттеләр. Сәясәттән аермалы буларак, суд өлкәсендә хакыйкать хөкемлек итә дип (гаиләдә салынган оеткы тәэсир итми калмагандыр шул), Элеонора тикшерүче булып эшли башлаган иде. Фиркагә керүгә, аны өлкән тикшерүче итеп куйдылар. Ә инде күп тә үтми, кызның һәр эшкә җаваплы карап, тырышып эшләвен, проблемаларны аек акыл белән хәл итүен, мәсьәләгә һәрвакыт практик якын килүен исәпкә алып булса кирәк, судья итеп билгеләделәр.

Ябык мәктәптә аларны, судьяда хөкем ителүчегә карата бернинди кызгану хисе булмаска тиеш, дип өйрәттеләр. Җинаять кылган икән, җәзасын алсын. Җинаятьчегә карата симпатия туу – бөтенләй дә мөмкин булмаган хәл: юкка гынамыни үлчәү тоткан хөкем алласы Фемида барлык дәреслекләрдә дә күзләре бәйләнгән килеш сурәтләнә. Җәза карары фактлар нигезендә канунның хәрефенә кадәр туры китереп чыгарылырга тиеш. Гадел хөкемнең тагын бер шарты – ул инде һаман шул Пётр I әйтеп калдырган кагыйдә: «Надлежит законы и уставы писать явно, чтобы не перетолковывать». Судьяның, киләчәктә төзәлергә мөмкинлек бирергә кирәк дип, җинаятьчене акларга яки җәза чарасын киметергә хакы юк – ул тәрбияче түгел; кылынган җинаять өчен башкаларга да сабак булырлык җәза бирергә тиеш. Карар чыгару процессына бернәрсә дә тәэсир итә алмый, бигрәк тә акча төртүришвәт турында сүз дә булу мөмкин түгел. Судьяларның эш хакы шактый югары булып, взятка алучыны үлем җәзасы көткәнлектән, бу турыда хәтта уйларга да ярамый. Өстәвенә судьяның ялгыш карар чыгарырга һич кенә дә хакы юк. Әгәр дә судья, ялгыша калып, идарәче даирәләр бу турыда белеп алса, судья үзе җәзага тартылачак, хәтта аны үлем җәзасына хөкем итәргә мөмкиннәр. Бу хәл бигрәк тә сәяси җинаятьләргә карата чыгарылган хөкем карарларына кагыла, чөнки яңа җәмгыять кануннары буенча иң зур җинаятьче дип хөкүмәткә, идарәче фиркагә каршы чыккан кеше санала. Шулай итеп, Элеонора нык үзләштергән белеме нигезендә, кырыс, хәтта ки аяусыз судья иде. Бернинди эмоциональ халәт: елмаю-көлүләр яки күз яшьләре, хәйлә, адвокатларның ялкынлы нотыклары Элеонораны теге яки бу якка авыштыра алмый. Ул таш кыя кебек үз урынында нык утыра, катгый принципларыннан чигенергә аны бернәрсә дә мәҗбүр итә алмый.

Шул рәвешле, еллар йөгерә торды. Элеонора да, Ире дә тырышып хезмәт иттеләр, кызлары Эльвина рәсем ясауга сәләтле булып, сәнгать мәктәбендә укый иде. Эльвинага ундүрт яшь тулачак Яңа елны алар, гадәттәгечә, Мальдив утрауларында – океан ярь буенда ук урнашкан виллаларында каршыладылар. Яңа елның беренче көнендә Ире Ян белән Элеонора – Мале шәһәренең икенче читендә яшәүче дусларына, Эльвина исә, мольбертын күтәреп, океан ярына эскизлар ясарга дип төшеп китте. Ә ике сәгатьтән цунами яр буендагы барлык йортларны, шул исәптән Элеонораларның виллаларын да диңгезгә юып төшергән иде.

Өсләренә ишелеп төшкән бу кара кайгы Элеонораларны сытты, изде. Хатынның аңы томалангандай булды. Ул эшен ташлады. Өй эчендә кара күләгә кебек анда-монда сугылып, миңгерәйтелгән кешедәй йөрде. Ничек инде аның бердәнбер газизе – кызы юк?! Ничек алай булырга мөмкин?! Әнә бит өй эчендә һәммә нәрсә аның элек тә булганын, хәзер дә барлыгын сөйләп тора. Элеонора, саташкандай, баласының киемнәрен, сумкаларын капшый, аннан аларны күкрәгенә кысып, кайнар күз яшьләренә манчый. Йөрәге сыкрап, бик озак итеп зал түренә эленгән натюрмортка – газизенең иҗатына карап тора. Анда сурәтләнгән күктәтиләр, ромашкалар, үлән сабакларын сыйпый. Бу авыр, иге-чиге күренмәгән саташулы төштән һич кенә дә айнып чара юк. Ире Янның да чигә чәчләре агарып чыкты, ул ничектер бөкрәебрәк калды, һич тә элеккеге – җеп белән тарттыргандай төз гәүдәле хәрби димәссең. Ян казинога йөрүен дә, гольф уйнавын да ташлады. Берәр шөгыль булсын дипме, эшеннән кайткач, интернет архивларда казынып, борынгы бабаларын, нәсел җебен эзли башлады. Элеонора да, чарасызлыктан, гөлләр,

чәчәкләр үстерергә тотынды. Тик инде ул бер генә чәчәкне дә өзә алмый: чәчәк өзәргә үрелсә, гомере киселгән кызы искә төшеп тетрәнеп китә, кулы һавада асылынып кала. Әниләренә барганда да, ул элеккечә чәчәк бәйләме түгел, хәсрәттән тагын да картаеп киткән кадерлеләренә чүлмәге белән гөл алып бара торган булды.

Хәсрәт диңгезендә бата-калка яшәгән көннәрнең берендә Ян, ничектер дулкынланыбрак, хатынына эндәште:

– Җаным, карасана, минем чыгышым татарлардан – польша татарларыннан икән бит! (Ян милләте белән поляк иде.) Өстәвенә нинди нәселдән диген әле – шагыйрь Адам Мицкевич нәселеннән!

Тик бу хәбәр Элеонораны бик гаҗәпләндермәде.

– Исең киткән, – диде ул. – Франция императоры Наполеон Бонапарт әле үз заманында ук, копните любого русского и найдёте татарина, дигән бит. Җир йөзендә тамырларында татар каны акмаган милләт сирәктер ул.

– Өстәвенә, – дип дәвам итте Ян, – минем нәселемдәгеләр, телләрен югалтсалар да, диннәрен саклаганнар – алар һаман ислам динендә икән бит.

Шунда кинәт Элеонора әбисенең: «Балам, Аллаһы Тәгаләнең барлыгына, берлегенә инанып, иманлы булып, ислам диненең бавына ныгытып тотын, шуның буенча бар, ул, адашып, ялгыш юлга кереп китүдән саклар, авыр чакларда таяныч, терәк булыр», – дигәнен исенә төшерде. Әйе, әбисе хаклы булган! Ник кенә сөенечле чакларында ук әбисе өйрәткәнчә дин юлына басмагандыр! Кем уйлаган соң ул шундый кара хәсрәт күрер дип. Гомер юлың шатлыкка күмелеп, гөрләп барганда да, Аллаһы Тәгаләне һич кенә дә истән чыгармаска кирәклеген кем белгән. Менә бит, үзең төшенмәсәң,тормышның ачы, аяусыз сабагы акыл бирә икән.

Өч ел үтеп китте. Элеонора һәр кичне, күтәргесез авыр кайгы иңнәрен баскан килеш, йокларга ята, иртән күзен ачуга, үзе белән гүргә керәчәк шул кайгысы көтеп тора, ул көне буена да хатынны тынгылыкта калдырмый. Ходайның язганы шулдыр дип, кызы рухына догалар укып, хәсрәтле ана намазга басты, кара кайгысын эченә йотып, дөньяга да чыга башлады, бераздан эшенә кайтты. Тик йөрәк ярасын каплаган юка гына элпә астында һич җуелмас канлы яра саркый иде. Шушы яра Элеонораның дөньяга карашын, уй-фикерләрен бик нык үзгәртте. Ул инде элеккечә кырыс хөкемдар түгел, ә һәрбер җан иясен кызгана торган нечкә күңелле, миһербанлы анага әйләнде. Аның кебек үк фаҗигале язмышка дучар булган аналар аңа хәзер туганнары кебек якын тоелды.

Әнисе белән бергәләп әбисеннән калган видеоархивны карап утырганда, ул бер шигырьгә тап булды. Авторы Хәсән Туфан диелгән. Инглизчә укып, аралашып үскән Элеонора рус, татар телләрен ипи-тозлык кына белсә дә, шигырь аны тәэсирләндерде.

Юл читенә басып, уйга талып,
Карап тора гүзәл миләүшә.
Кайларгадыр барган юлчы аңа
Йомшак кына итеп эндәшә:

– Тартынма син, сеңлем, ятсынма син,
Сөйләшик бер утырып янәшә.
Ятлар түгел, сиңа минем аша
Бертуганың – матдә эндәшә.

Ничә миллион гасыр үтте инде
Безнең шушы җиргә килгәнгә...
Син бер гөлгә инде әверелгәнсең,
Ә мин менә – кеше дигәнгә.

Мин – бу кырлар, сулар, җилләрдәге
Атомнарның иске туганы:
Материя мин, җаным,
Аның бары
Сөйли, җырлый, сагына торганы.

Әйе, чынлап та, кеше – материянең «Сөйли, җырлый сагына торганы». Сагына шул, бик сагына газизен Элеонора. Сагынуларына юк чара. Шуңадырмы, күңеле бик нечкәрде, йомшарды аның. Хәер, кешенең тәне бит каты таштан, салкын тимердән яратылмаган, туфрактан ул, йомшак туфрактан яратылган (шуңа да кире туфракка кайта). Каты булу кешенең табигатенә үк туры килми, чөнки аның Раббыбыз тарафыннан бүләк ителгән рухы шушы суык, мәрхәмәтсез дөньяга җан җылысын өрү, миһербанлылык күрсәтү, яшәешебезгә, үзара мөгамәләбезгә, тирә-як мохитебезгә яхшылык, күркәмлек бирү миссиясе белән җир йөзенә килгән бит.

Мондый кичерешләр белән хөкемдарлык һич яраша алмый иде. Элеонора эшен ташларга булды. Тик, күрәчәгенәдер, китеп өлгерә алмады – аңа сәяси җинаятьчеләр эшен карап, хөкем чыгарырга туры килде. Җинаятьчеләр дип, болар студентлар, әле балалыкларыннан да чыгып бетмәгән яшьләр иде. Алар «Азатлык!», «Табигый байлыкларны – илнең һәрбер гражданына!», «Прагматикларны хакимияттән куарга!» кебек шигарьләр күтәреп, университет мәйданына чыкканнар. Аларга башка яшьләр дә ияргән. Тикшерү материаллары буенча, оештыручылары бер кыз булып чыкты. Судта да барлык гаепләнүчеләр төп фигурант итеп аны атадылар. Шунда, суд барышында, Элеонора бу очракта бер дә кирәкмәгән шигъри юлларны исенә төшерде. Кечкенә чагында әбисе җитәкчелегендә татарның даһи шагыйре Габдулла Тукайның «Таз» дигән бу шигырен күрше балалары белән инсценировка итеп куйганнары бар иде: «Башчыбыз таз, бер заман без уйнадык...»

Әйе, уйнаганнар. Тик ахырын уйламаганнар. Тукай шигырендәгечә, балалар гына шул. Барысы да башларын игән, гаепләрен таныйлар, димәк. Чү, берсе башын горур тотып басып тора. Аның чыраенда үкенүнең әсәре дә юк сыман. Бу – теге оештыручы кыз. Элеонора, аны яхшырак күрергә теләп, күзлеген киде һәм кинәт утырган урыныннан авып китә язды: нәкъ үз кызы Эльвинаныкы кебек куе зәңгәр күзләрнең акыллы карашы аңа төбәлгән иде. Өстәвенә кызның йөзе дә таныш кебек тоелды. Таныш шул, әйе, таныш... Бу бит... бу бит кайчандыр, күптән инде, аның Эльвинасы белән бергә балалар бакчасына йөргән кыз. Дөрес, хәзер ул үскән, үзгәргән дә кебек, тик йөзеннән элеккеге сабыйлыгы чыгып бетмәгән. Аның Эльвинасына да хәзер шулай егерме яшь булыр иде...

Бу яшьләр инде университеттан куылганнар, димәк, җәзаларын алганнар. Юридик күзлектән караганда, «Non bis in idem» (бер җинаять өчен ике жәза каралмаган). Ләкин болар гади генә түгел, сәяси җинаятьчеләр иде шул. Ә андыйларга җәзаның катысы каралган, бигрәк тә оештыручыга – теге горур кызга, димәк. Боларны – төрмә, ә оештыручыны арктик киңлекләрдә яки сусыз чүлләрдә гомерлек сөрген көтә. Озак баш ватты Элеонора. Теге кызны

сөргенгә җибәрү үз кызын җәзага тарту белән бер иде аңа. Ниһаять, ни булса, шул булыр дип, төркемдәгеләрнең барын да зур штрафка тарту белән чикләнде – ун ел буе хезмәт хакларының дүрттән берен «Прагматиклар» фиркасенең исәп-хисабына күчереп барырга тиеш иде болар.

Сәяси җинаятьчеләрне канун нигезендә хөкем итмәгәне өчен җәза озак көттермәде – Элеонораны егерме биш елга сөргенгә озаттылар. Егерме кешелек мәхбүсләр төркемен тимер рәшәткәле ябык фургонда башта Архангельскига алып килделәр. Анда аларны, карантин дип, салкын, дымлы камераларда айга якын тоттылар. Аннан өсләренә барысына бер үлчәмдәге өс киеме – тупас, калын материалдан сырып тегелгән, матрос бушлатын хәтерләткән килешсез куртка, сырган чалбар, аякларына калын табанлы унты сыман итек өләштеләр. Шушы котсыз киемнәрне киеп алгач, барысы бертөсле соры массага әйләнгәндәй булды, аларны тик җиңнәренә, арка-күкрәкләренә сугылган саннары буенча гына аерырга мөмкин иде. Ил-көненнән аерылырга мәҗбүр ителгән бу бәхетсезләрне очкыч белән Баренец һәм Карск диңгезе арасындагы Яңа Җир архипелагының Көньяк утравына озаттылар. Димәк, Элеонораның калган гомере боз диңгезендә – мәңгелек төн иле булган караңгы, коточкыч салкын урында үтәчәк икән. Хәер, калган гомере озын түгел инде – булса, алты-җиде ай булыр. Аның укыганы бар: мондагы уран шахталарында эшләүче тоткыннар шуннан да озакка тарта алмый, диләр.

Иллюминатордан очкыч астындагы болытларга карап барган Элеонораның башына: «Их, очкыч берәр кыягамы бәрелеп, мәтәлеп төшсә, нинди яхшы буласы, минут эчедә бөтен әрнү-сыкрауларга нокта куелыр иде», – дигән көфер уй килеп китте. Ул юлдашларына күз салды. Аларның да йөзләрен өметсезлек пәрдәсе сарган иде. Шулай да бераздан тоткын хатын, аңына килгәндәй булып, үз-үзен шелтәләп алды: шайтан гына өметсез ул. Дөрес, алда үзен кара язмыш көткәнен, бәлкем, инде гомеренең дә санаулы гына калган айлары, атналары, хәтта көннәре булырга мөмкин икәнен ул чамалый, тик нишләптер күңел төбендә өмет чаткысы пыскып ала иде. Караңгы, авыр уйлардан хатынның башы авырта башлады. Шунда әнисенең (ул да, Элеонора кебек үк, оныгының һәлакәтеннән соң ныклап торып дин юлына баскан иде): «Мөэмин кеше Коръән аятьләреннән шифа табар» дигәне исенә төшеп, үзе генә ишетерлек итеп иреннәрен кыймылдатып, «Аятелкөрси»не укый башлады.

Очкыч Амдерма-е дигән хәрби аэродромга төшеп утырды. Җиргә аяк басуга, мәхбүсләр чайкалып китеп егыла яздылар – шулкадәр дә көчле җил иде. Көч-хәл белән, каршы искән җилдә иелә-бөгелә атлаган тоткыннарны сакчылар еракта каралып күренгән бинага таба куалады. Бераздан җил басылгандай булды, вак кына яңгыр пыскаклый башлады. Коеп яумаса да, барып җиткәнче, өс-башны чылатты. Өстәвенә көне дә салкынча, җылылык биш-алты градустан артмыйдыр, ә бит әле көз түгел, җәй – июль уртасы.

Соры төстәге, тәрәзәсез таш бинаның шыксыз озын, ялангач коридорында тоткыннарны сафка тезеп, номерлап санагач, конвой башлыгы Элеонораны үз янына чакырды.

– Сезгә бер ай госпитальдә эшләргә, – диде ул, фәрман биргән кырыс тавыш белән.

Менә, гомере бер айга озыная булып чыкты...

Коридорның таш идәнендә төн үткәргәннән соң, бәхетсез мәхбүсләрне, амфибиягә төяп, архипелагның Төньяк утравына озаттылар, ә Элеонораны Белушья Губа дигән посёлокка алып киттеләр.

Монда аны конвоир тиешле, документлар нигезендә, госпитальнең баш табибына тапшырды. Илле-алтмышлар тирәсендәге (нишләп ирекле баштан Алла каргаган җирдә эшли икән бу олы яшьтәге кеше, дигән уй узды хатын күңеленнән) табиб Элеонораның әле гүзәллеген җуймаган йөзенә бер генә күз ташлады да:

– Сез шәфкать туташы булып эшли алырсызмы? – диде. Гомере кыл-җеп өстендә торган хатын юк дип әйтә аламы соң?! Ябык мәктәптә аларны беренче ярдәм күрсәтергә, укол ясарга өйрәттеләр. Әнисенең табибә булуы да аны бу өлкәдә күпмедер дәрәҗәдә хәбәрдар итә, ә латин телен ул су урынына эчә иде.

Йөз илле авыруга исәпләнгән бу хәрби госпитальдә шәфкать туташлары болай да җитешми икән, өстәвенә икесе декрет ялына киткән. Элеонораны монда җыештыручы итеп теркәделәр, чөнки сәяси тоткыннарга табиб яки шәфкать туташы булып эшләү тыелган. Табигый сәләте, тырышлыгы, медицина өлкәсендә булган кадәр белеме аркасында ул эшенә бик тиз төшенде. Ике атна да үтмәде, аңа инде операция барышында шәфкать туташы булып эшләргә туры килде. Тик... менә инде ай үтеп бара. Тиздән, бик тиздән аңа да нурланыштан газап чигеп үләчәк мәхбүсләр сафын тулыландырырга туры киләчәк.

Кызының һәлакәтеннән соң аның яшисе килмәгән чаклары күп булды. Менә хәзер, үлем күзенә карап торганда, яшисе килү теләге көчле. Нишләпләр шулай икән? Нинди гаҗәп нәрсә син, тормыш! Яшәпләр туеп булмый. Әйе, Аллаһның кешегә иң зур бүләге – ул яшәү, гомер. Кем белә, бәлкем, язмыш аңа тагын бер тапкыр мәрхәмәтле булыр: уран шахталарына җибәрмичә, бакыр базларына, марганец, кара кургаш, цинк шахталарына яки Карск диңгезе шельфындагы нефть промыселларына гына озатыр.

Чынлап та, язмыш аңа тагын елмайды. Кемнәрдәндер үтенеп, ялынып, әгәр ул дигәнчә булмаса, контрактны өзеп кайтып китәчәген ультиматум итеп куеп, баш табиб аны бер елга калдыруга ирешкән булып чыкты. Бу турыда хезмәттәшләреннән ишеткәч, Элеонора аларның әлеге вакыйгага карата фикерләрен дә белде. «Нинди кайтып китсен, ятим калган дүрт оныгын аякка бастыру өчен, акча эшләргә килгән бит, китәме соң», – диештеләр.

Менә, ул-бу булмаса, гомере тагын бер елга озайды. Эшлә дә эшлә. Хәер, эштән кала аның башка нәрсәсе бар соң?.. Ул госпиталь бинасында караватбелән өстәл генә сыярлык чолан сыман караңгырак бүлмәдә яши. Китап укырга, язарга ярамый, интернет турында, билгеле инде, хыялланырга гына кала. Туклануы – тоткыннар паёгы, аш пешерүчеләр авырулардан артып калган ризыкны сирәк кенә булса да бирештерәләр. Элеонорага персонал белән дә, авырулар белән дә, эшкә кагылышлы темалардан кала, аралашу тыелган. Авыруларның күбесе хәрбиләр булганлыктан, аңа ир-атлардан сүз кушучылар күп, ләкин хатын ләм-мим дәшми иде. Аңа госпиталь территориясеннән чыгып йөрү дә тыела. Чыгып та кая барасың? Диңгездәге моржлар, тюленьнәр, диңгез казларын карыйм дип, яр буена ак аюлар янына төшсәң генә инде. Ак аюлар үзләре дә кайвакыт посёлок урамнарына килеп чыгып, монда яшәүче хәрбиләрне, төзүчеләрне куркуга салган очраклар бар икән. Элеонора тәрәзәгә карады. Салкын, фәкыйрь табигать күренеше бәгырьләрне кискән сагышны тирәнәйтә генә иде. Аяк астын мүк, лишайниклар каплаган, анда-санда күренгән кәкре-бөкре кәрлә каеннар, җиргә ята төшеп үрмәләп үскән таллар, кыска гына үлән сабаклары бер дә тынып тормый торган ачы, кискен җилдә менә-менә үләм-бетәм дигәндәй сыгылалар, ярдәм өмет итеп, җиргә сырышалар. Кыш турында инде әйтеп

тә торасы юк. Мондагы күпсанлы күлләрне, елгаларны төбенә кадәр катыра торган, җелегеңә үтәрдәй кырык-илле градуслы салкыннар, өстәвенә ураган җилләре, ноябрь уртасыннан гыйнвар ахырына кадәр җитмеш көнгә сузылган караңгы төн. Җәйләрендә – мәңгелек туң, территориянең шактый өлешен каплаган калын боз катламы, фәкыйрь флора. Шушыларның барысы өстенә монда үткән гасырларда үткәрелгән атом-төш сынауларының кара шәүләсе төшкән кебек. Әллә инде Карск диңгезе төбенә күпләп күмелгән радиоактив калдыклар шундый шом таратып тора, белмәссең.

Тик шушы шартларда да кешеләр эшлиләр, яшиләр. Каз Җире дигән ярымутрауда, Белушья Губа бухтасының яр буена урнашкан бу посёлокта, өч меңләп кеше яши. Монда хәрби полигон булганлыктан, халыкның күпчелеге ир-атлар – төзүчеләр, хәрбиләр. Посёлок яхшы үсеш алган инфраструктурага ия, бухтада диңгез порты төзелгән, гомумән, монда – боз илендә дә тормыш кайный. Әйе, биредә дә яшиләр, эшлиләр, тик алар бит иректә, ә Элеонораның һәр адымы диярлек сак астында, ул, монда яшәүчеләрдән аермалы буларак, күп нәрсәдән мәхрүм. Ах! Әгәр дә ул иректә булса... Ә болай... Ул – кол, ул үз-үзенә хуҗа түгел. Хатын белә: ул инде беркайчан да иректә булачак түгел, беркайчан да якыннарын күрә алмаячак, гомере шушында киселәчәк. Алда гел караңгылык, яктылык күренми. Әле дә ярый, монда эләккәнче, ислам диненең бер баганасы булган намазга өйрәнеп калган. Әбисе әйткәнчә, авыр вакытларда тотынырдай, таянырдай бердәнбер мөмкинлек ул. Намаз аның юанычына, яшәү белән бәйләүчесенә, тәмуг газапларында җан асраган мәхбүскә рухи көч бирүче саекмас чыганакка әйләнде. «Әлләзии халәкаль-мәүтә үәл-хәйәәтә лийәблүүәкүм әййүкүм әхсәнүгәмәләә үә һүүәл-гәзизүм-гафур» (мин сезне үлем белән яшәү арасында кылган гамәлләрегез аша сынау өчен генә җибәрдем), – ди Аллаһы Тәгалә. Әйе, Элеонора да шушы сынау дөньясына килгән икән инде, сынауны лаеклы рәвештә, сабырлык белән үтү лазем, намаз аша Аллаһка үзенең барлыгын, Аллаһ Раббысын гел истә тотуын хәбәр итү дә кирәктер. Һәм мәхбүс шулай эшләде дә.

Ел да үтте. Элеонора, алдагы язмышы турында уйларга да куркып, эшләде дә эшләде. Ике елдан аның коткаручы фәрештәсе булган баш табиб та континентка кайтып китте. Яклаучысыз калган хатынның күңеленә боз салкыны йөгерде: нишләтерләр аны, исләренә төшеп, шахтага озатырлармы? Ләкин ел арты ел узды, аны килеп алып китүче күренмәде, Элеонора дамоклов кылычы астында эшләвен дәвам итте.

Менә инде шушы боз диңгезендә Элеонора тугызынчы җәен каршылады. Аңа кырык сигез яшь тулды. Нишләп адәм дигәнең шушы авыр шартларда да тормышка ябышып ята икән? Кызы-газизе күптән теге дөньяда. Ире, бәлкем, исәндер. Әти-әнисе исән микән соң? Алар картлар иде бит инде. Элеонорага бу газап утравында ни калган? Әллә теге чакта юлдаш мәхбүсләреннән аерылып калып, ялгыш эшләдеме? Гәүдәсе күптән инде крематорийда яндырылып, җаны кош булып очкан булыр иде бит. Шулай уйлана торган булды үлмәс борын боз тәмугына эләккән ана. Тик дөнья куласа: бер әйләнә, бер баса дип юкка гына әйтмәгәннәр икән.

Июль азагында Элеонораны башка мәхбүсләр белән, очкычларга төяп, һаман шул Амдерма-е аэропортыннан Воркутага алып киттеләр. Монда аларның кулларына документ һәм беркадәр акча күчерелгән банк картасы биреп (калганын компенсация рәвешендә өйләрегезгә кайткач алырсыз,

диделәр) тараттылар. Илдә зур сәяси үзгәрешләр булып, хакимият алышынган, «Прагматиклар» фиркасе куып таратылган икән.

Элеонора өйләренә икенче көн кичкә авышканда гына кайтып җитте, чөнки аларның шәһәренә вакуум поезд (капсулалар эчендәге пассажирларны труба буенча бер сәгатьтә мең чакрымга илтеп куя торган) ике көнгә бер генә йөри икән. Кодны җыеп, зур тимер капканы ачты. Баскычтан күтәрелеп, өй ишеге янына килде. Һаман шул өч төймә урынында тора. Элеонора үзенең төймәсенә бармагын тидерүгә, ишек акрын гына бер якка шуышты. Хатын эчкә атлады. Тып-тын иде, ире дә, хезмәтчеләр дә күренмәде. Ул, юл киемнәрен дә салмыйча, залга узды. Зал нәкъ ул киткәндәгечә, бары тик түр диварга кызының-бәгырь кисәгенең зурайтылган фотосурәте эленгән. Яшь тулы күзләре белән ана баласына текәлде, калтыранган куллары белән рәсемне сыйпады, аннан карашын кызының «Кыр чәчәкләре» дигән натюрмортына күчерде – ул иске урынында эленеп тора иде.

Кинәт сабый елавы ишетелде. Хатын, бу ни бу, дип уйларга да өлгермәде, залның йокы бүлмәләре ягындагы ишеге ачылып китеп, кулына бала күтәргән яшь кенә хатын-кыз килеп чыкты. Ул да, Элеонора да, соң дәрәҗәдә гаҗәпләнеп, бер тын бер-беренә карап тордылар. Элеонора, аңына килгәндәй булып: «Сез кем?» – дип сорады. «Ә сез?» – диде теге хатын, сорауга сорау белән җаваплап, һәм шунда ук, нәрсәдәндер курыккандай, тиз-тиз: «Сез Элеонорамы?!» – дип өстәде. Яшь хатынның тавышы да, йөзе дә таныш кебек тоелды. Соң бу... соң бу... аларда бакчачы булып эшләгән кешеләрнең кызы бит. Ә бала? Элеонора сабыйга күз төшерде: ике яшьләр чамасындагы малай коеп куйган бәләкәй Ян иде.

Элеонора, дәшми-тынмый, стенадан кызының натюрмортын алды да саубуллашмый-нитми борылып чыгып китте.

Инде кызларын исән килеш күрүдән өметләрен өзгән ата-анасы, Элеонораны күргәч, бәхет-шатлыкларыннан күз яшьләренә күмелде. Ярабби, Аллаһы Тәгалә карт белән карчыкның кызларына исәнлек сорап, намаздан соң ялварып укыган догаларын, риясыздан биргән хәер-сәдакаларын, тоткан уразаларын игътибарга алып булса кирәк, аның гомерен саклаган. Ат йөрер дага белән, адәм йөрер дога белән дип әйтүләре хактыр.

Гаҗәп, монда да зал идәненә җәелгән калын келәмдә өч яшьләр чамасындагы кызчык уйнап утыра иде. Сабый башта Элеонорага ятсыныбрак карап торды да аннан, йөгереп килеп, аның итәгенә ябышты: «Әни, әнием, сагындым! Нигә озак кайтмый тордың?» – дип елап иркәләнә башлады. Гаҗиз калган хатын, баланы күтәреп алып, күкрәгенә кысты. Кызчык Элеонораның әнисенең сеңлесенең оныгы икән; өч ай элек әти-әнисе, әбисе авиакатастрофада һәлак булганнар.

Элеонораның хәлләреннән бераз хәбәрдар булганнан соң, әти-әнисе, кыенсынып кына, Ян турында сүз башладылар. Ябыгып, ярты гәүдәсе генә калган саргайган йөзле кызын йөрәге белән җәлли-җәлли, үзләрен дә гаепле санап, әнисе сыкрый-сыкрый сөйләде дә сөйләде. Хатыны өчен Янны да буш калдырмаганнар: фиркадән чыгарып, отставкага җибәргәннәр. Элеонораны бик сагынган, юксынган ул. Тик инде аның мәңге кайтмаячагын уйлап, биш елдан соң өйләнергә булган – нишләрсең, ир кешегә ялгыз яшәве читен.

– Кирәкми, – диде Элеонора, әнисен бүлдереп, – Ян да, сез дә гаепле түгел. Язмышымдыр. Ходай Тәгалә бәхетен дә, бәхетсезлеген дә үзе ала, үзе бирә. Менә бит, гомерем бетмәгәч, тәмугтан да исән чыктым, бәхетемә

тагын бер кыз да бирде, әйеме, бәбекәем, – дип, хатын баланы кочып сөйде, тегесе көмеш кыңгыраучыклар чыңлаган яңгыравыклы тавыш белән көлеп җибәрде.

Икенче көнне Ян үзе дә килде. Ярабби, элеккеге ир солтаны урынына Элеонора каршында газаплы тормыштан тәмам бетәшкән карт басып тора иде. Кая киткән аның киң җилкәләре, шәмдәй төз буе? Тирән буразналар каплаган сөйкемле чыраена аптырау галәмәте чыккан Ян да хатынының йөзендә элеккеге – бер кашык су белән йотардай – Элеонораны күрергә теләп булса кирәк, гаҗәпләнебрәк текәлеп карап тора иде. Икесенең дә күзләрендә яшь күренде, алар балаларча, үксеп дигәндәй, елап җибәрделәр. Иргә дә, хатынга да авыр, бик авыр иде.

Елап туйгач, Ян Элеонорага зур гына шкатулка сузды. Хатын аны таныды: монда ул бәхетле чакларында алтын балдакларын, куш беләзекләрен, зөбәрҗәт, рубин кашлы йөзекләрен, энҗе муенсаларын, бриллиант кашлы алкаларын саклый иде. Элеонора сак кына шкатулканы ачты. Зәркән әйберләре элеккечә шунда ята.


– Йорт-җирне бүлешүгә килгәндә... – дип, авызын ачкан Янны хатын бүлдерде:

– Кирәкми, миңа хәзер шушысы да җитә, – дип, шкатулкага ымлады.

– Рәхмәт, – дип кенә әйтә алды Ян, нишләптер каушап.

Элеонора яңа тормышына кыеннан ияләште. Аңа һаман, комендатурага барып, билгеләнеп кайтасы, ярым ач килеш авырулар белән процедуралар үткәрәсе, дәшми-тынмый, чукрак кешедәй йөриседер кебек тоела, өстәвенә, менә-менә, һау-һаулап этләр ияртеп, конвоирлар килеп чыгар төсле. Ул йоклый алмый, элеккеге борчу-хәсрәтләре аңа һич кенә дә тынгылык бирми. Дөрес, коръән, намаз уку аңа бераз җан тынычлыгы бирә бирүен, тик элеккеге мәхбүс барыбер тулысынча нормаль халәтенә кайта алмый интекте. Бу хәлендә хатын эшкә дә урнаша алмый иде. Аптыраганнан, Элеонора кичерешләрен телефонына төшерә башлады. Яза торгач, бер ел дигәндә тулы бер роман килеп чыкты. «Ураганнар илендә» дип атады аны элеккеге тоткын. Романны укучылар шактый күп булып чыкты, җәмәгатьчелектә аның белән кызыксыну киң таралыш алды. Ә өч елдан роман буенча «Боз тәмугында» дигән зур популярлык алган фильм эшләнде. Фильмның презентациясе, зурдан кубып, тантаналы шартларда үткәрелде. Анда хатыны белән Ян да чакырылган иде. Элеонораның тулыланып, түгәрәкләнеп киткән нурлы йөзенә, шатлыктан балкып торган күзләренә сокланып карап торган Ян да ничектер үзен бәхетле сизде; ул чын күңелдән Элеонораны зур уңышы белән котлады...

Тормыш үз асылына кайтып дәвам итте.



*Сәгыйть Әхмәтҗанов – 1960 елны Баулы районы Татар Кандызы авылында туа. Казан дәүләт мәдәният институтын тәмамлый. Бүгенге көндә Баулы шәһәрендә яши.*

Сәгыйть
Әхмәтҗанов

# УЛ ХАКЫЙКАТЬНЕ БЕЛГӘН...

## Давыл

Ни булган соң бу дөньяга?
Җәй гел кояштан иде.
Дошманга да җавабыбыз
Таш түгел, аштан иде.

Ераклардан куе болыт
Каралып монда ага.
Тагын көрәш башланамы –
Безнең капканы кага.

Ялтырый, ялт-йолт киләдер
Офыкта күк йөзләре.
Һәр болыт бер аждаһадыр,
Канлы чокыр – күзләре.

Түбәләрне куптарырмы?
Диварлар чыдар микән?
Диварларны терәшергә
Күршеләр чыгар микән?
Чыкмый да чыдар микән?

Кояш кайда? Колмы әллә?
Безнеме әллә яратмый?
Якты нуры белән ярып,
Ник давылны таратмый?

Таң алдыннан йокы тәмле,
Бәла-каза көтмиләр.
Илне каплап давыл килә,
Чаң кагам – ишетмиләр.

И торыгыз, туганнарым,
Беләкләрдән бәйләник.
Гарасат җиңә алмаслык
Таш диварга әйләник!

Безнең күкрәккә бәрелеп,
Башын ярсын ташка ул,
Кояшны да кол итәргә
Уйламасын башка ул!

## Шагыйрь абыем Рәшит Әхмәтҗанга

*Талларга качты сандугач,*
*Мин аны эзлиммени?*
*Сандугач керде күңелгә –*
*Җырламый түзиммени?!*
Рәшит Әхмәтҗан

Сандугач иде күңелеңдә,
Ялыккандыр шул җаның:
«Аръягында сайрыйм әле
Бу битараф дөньяның», –
Дигәнсеңдер, аңлыйм сине,
Арыткандыр дөньяны,
Көйгә салып булмасмы, дип,
Меңгә бүлү бер җанны.

Сандугач иде күңелеңдә,
Сайра да сайра гына...
Күбрәк кырылдымы җаның
Шигърият кайрагына –
Нечкәрде, өзелде кинәт,
Көйләрең тынды, дисәм:
«Шагыйрьләр үлә димени?!
Шагыйрьләр мәңге исән!» –
Дип, җиһаннан кычкырасың,
Шул бәгырьләрне кисә!

И абый, аңлыйм, һәр шагыйрь
Ул хакыйкатьне белгән…
Шагыйрь абыем үлмәс тә,
Рәшит абыем үлгән!

Сандугач идең күңлемдә!
Сайрар да сайрар идең…
«Каләмем сынды, энекәш,
Соңгысы иде», – дидең.

***

Йоклар әле бу ил чак кына,
Таң да ата монда сак кына,
Тауларын да сарган ак томан,
Йокы белән төргән шәл сыман.
Бөккәлидер кундәм талларын
Давыл түгел, зәгыйфь җилләр дә.
Хисләр каткан монда таш булып
Егәр сүнгән тимер билләрдә.
Акча төсләренә манчылган
Тамырлардан бәргән кан монда.
Базарлардан алган бәяле
«Саттым-алдым» һәрбер җан монда.

***

Син эзләгән ак идеал мин түгел ул.
Мин гөнаһлар белән бергә үрелеп үсәм.
Син эзләгән тапсыз Кояш мин түгел ул.
Менә – Җирем! Шуннан атлыйм.

Барысын да шуннан таптым.
Үз күңелем:
Үзем таплыйм,
Үзем пакьлыйм!
Ялгышларым барлап, Җирдән атлыйм.
Тик
Син зләгән – мин түгел ул.

## Мал

Без өйләнгәч, төн кыскарды, диләр...
Безнең заман, чынлап, әллә ни!
Җырлап яшәр өчен килгән идек,
Мал дәрьясы йотты җәлләми.
Мал дәрьясы чоңгыллары тирән,
Бер бөтереп алса – җибәрми.
Гүргә хәтле шулай безнең йөрәк:
«Мал! Мал!» – диеп һаман тибәрме?
Андый йөрәк... элек иде сирәк.
Тибүеннән типмәү хәерлерәк!

## Мизгелләр


Шатлыкның да, газапның да һәр мизгеле,
Кан сарса да, җан алса да, барыбер изге.
Бер бәхеткә, бер хәсрәткә ташласа да,
Синең гомер түгелмени шул бер мизгел?!
Әче, димә, төче, димә, туктаталсаң,
Тотып кара мизгелләрне кочагыңда.
Син аларның гүзәллеген, бик әзлеген
Аңлый алырсың бары тик шул чагында.

***

Агым суның яры була, таралыплар
Сахраларга сибелепләр кипмәс өчен.
Ирекнең дә яры була, чиге була,
Ил ирләре башын салып бетмәс өчен.
Күккә якыннарның бер сүзе дә
Сәбәп кайчак күкләр күкрәвенә.
Илләр күкрәгенә ук яуганда,
Калкан була ирләр күкрәге лә!

***


Күңелем ап-ак кәгазь иде,
Әллә кайдан юшкын җыйдым.
Җыюлары минут булса,
Юуларын еллар юдым.
Юдым, ләкин пакь кәгазьдән
Нидер җуйдым... нидер җуйдым.



*Бу фоторәсемнең төшерелүенә нәкъ 70 ел. Совет чорында төрле милләт язучылары Мәскәүдә М.Горький исемендәге Әдәбият институтының икееллык югары әдәби курсларында профессиональ белемнәрен арттыралар иде. Шул курсларда укучылардан бер төркем. Сулдан уңга: Камчы Җунусов (Кыргызстан), Павлюс Ширвис (Литва), Семён Данилов (Якутия), Зәки Нури (Татарстан). Мәскәү. 1957 ел.*



*Күренекле балалар шагыйре Хәкимҗан Халиков (1933-2002).*



*Замандаш шагыйрьләр, фронтовиклар, фикердәшләр. Сибгат Хәким (сулда) һәм Михаил Львов (Габитов Рәфкат Дәүләтша улы). М.Львов атаклы рус шагыйре булып саналды. Үз вакытында байтак татар шагыйрьләренең (С.Рәмиев, М.Җәлил, Ш.Маннур, Ә.Давыдов һ.б.) шигырьләрен рус теленә тәрҗемә итте. Үткән гасырның 70нче еллары.*



*Шагыйрә Сәҗидә Сөләйманова Казан университетының Актлар залында чыгыш ясый. Президиумда татар халкының күренекле шәхесләрен күреп була. 1965 ел.*



*«Казан утлары» журналының 80 еллык юбилее уңаеннан үткәрелгән әдәби-музыкаль кичәдән күренеш. Камал театрының күренекле артистлары Рамил Вәҗиев (сулдан уңга), Ринат Таҗетдинов, Венера Шакирова, Фәнис Җиһанша, Әзһәр Шакиров. 2002 ел.*

*Сәхифәне* **Равил ФӘЙЗУЛЛИН** *әзерләде.*

# БЕР ГАСЫР МИЛЛӘТ САГЫНДА



*Бер гасыр дәвамында мәркәзебез халкына белем һәм тәрбия биргән мәгариф учагы – Габдулла Тукай исемендәге 1 нче татар гимназиясе бу көннәрдә үзенең юбилеен билгеләп үтә. Аңа, аз да түгел, күп тә түгел, нәкъ 100 ел. Шул уңайдан гимназия директоры* ***Гөлфия Гаяз кызы ШӘМСИЕВА*** *белән әңгәмә кордык.*

***– Гөлфия ханым, элек-электән Яңа татар бистәсендә яшәүче халык аң-белемле, тәрбияле булган. Бүген сезнең гимназия моңа нинди өлеш кертә? Әлеге бистә һәм бер гасырлык мәгариф учагының тарихына тукталыйк әле...***

– Гимназиябезнең ачылуы XIX гасыр башына туры килә. Тарихи документлардан күренгәнчә, 1816 елда Яңа бистәдә классик язучы һәм иҗтимагый фикер иясе Фатих Әмирханның әтисе Зариф хәзрәт тырышлыгы белән һәм аның җитәкчелегендә «Әмирхания» мәдрәсәсе ачыла. Гимназиядән ерак булмаган бер йортта Фатих Әмирхан яшәп иҗат итә, һәм аның янына фикердәше, чордашы, дусты Габдулла Тукай да килә торган була. XX гасырда да төрле хәлиткеч вакыйгаларны үз башыннан кичергән әлеге уку йорты – гимназия үз эшчәнлеген хәзер дә заман сулышын тоеп, ягъни XXI гасырда да югары дәрәҗәдә дәвам итә.

1 нче татар гимназиясе, гасырлар алышынуга карамыйча, милләтебез тарихында җуелмас эз калдырган шәхесләрнең исемнәре белән бик тыгыз бәйләнгән. Иң башта бөек Тукаебыз исеме белән бәйле – ул Яңа бистә һөнәрчеләре Мөхәммәтвәли белән Газизә гаиләсендә тәрбияләнә, 1907 елда Казанга яңадан кайткач та биредә еш була. Анда аның дуслары Хөсәен Ямашев, Мәхмүт Дулат-Али, Фатих Әмирханнар яши. Яңа бистәдә «Әмирхания» мәдрәсәсендә Гаяз Исхакый белем ала һәм, анда яшәгәндә, үзенең «Тәгаллемдә сәгадәт», «Кәләпүшче кыз», «Өч хатын белән тормыш», «Бай углы» исемле танылган әсәрләрен яза.

Социалистик революциядән соң, 1917 елда, Яңа бистәнең Эш урамындагы 43 нче йортта урнашкан мәдрәсә беренче совет мәктәбе итеп үзгәртелә. Шулай итеп, татар бистәсендә түләүсез татар мәктәбе ачыла. Башта мәктәптә 50 укучыга 2 укытучы белем бирә. Укытучыларның берсе – күренекле татар журналисты һәм язучысы Вафа Бәхтияров. Ул «Әл-ислах» газетасында Ф.Әмирхан һәм Г.Тукай белән бергә эшли.

Аннан мәктәпне Кызыл Татарстан урамындагы 16 нчы йортка күчерәләр. Шулай итеп, «бердәм хезмәт мәктәбе» ачыла.

1918 елда мәктәп ике бинага: Кызыл Татарстан урамындагы 16 нчы йортта һәм Хөсәен Ямашев урамындагы 72 нче йортта урнаша. 72 нче ике катлы йортта 1937 елга кадәр эшли. Мәктәпнең мөдире Мәхмүд Галиев була. 1921 елда мәктәп беренче укучыларын чыгара. 1921-1922 уку елында мәктәптә укытуның икенче баскычы башлана. 13 нче номерлы беренче баскыч мәктәп белән 14 нче номерлы икенче баскыч мәктәп бергә кушыла да беренче һәм икенче баскычлы 13, 14 нче номерлы җидееллык мәктәпкә әйләнә. Мәктәпнең директоры булып Мәрдәнов Һади Әхмәт улы эшли.

1924 елда мәктәпкә татар халкының бөек мәгърифәтчесе Каюм Насыйри исеме бирелә. Каюм Насыйри Яңа бистә балаларына рус теле өйрәтә. Әдип, һәр укучы татар теле белән беррәттән рус телен дә яхшы үзләштерергә тиеш, дип саный.

1928-1929 уку елы башында бу мәктәптән «Октябрьнең 10 еллыгы» исемендәге

җидееллык мәктәп аерылып чыга. Ул яңа салынган бинага (хәзерге 13 нче номерлы мәктәп) урнаша. Төп өлеше К.Насыйри исемендәге 14 нче номерлы җидееллык мәктәп булып кала. 1937 елда мәктәпне элеккеге унберенче мәчет бинасына күчерәләр. 1953 елда исә әлеге мәгариф учагы урта мәктәпкә әйләнә.

1960 елда инде мәктәп хәзерге дүрт катлы бинага күчә һәм «35 нче номерлы урта мәктәп» дип атала башлый.

1961 елда мәктәп кайбер предметларны инглиз телендә укыта торган урта гомуми белем бирүче мәктәпкә әйләнә. Мәктәптә икенче класстан башлап, инглиз телен өйрәнәләр. Уку рус, татар, инглиз телләрендә алып барыла. Шушы ук елда мәктәпнең СССР Педагогия фәннәре академиясе милли мәктәпләр институтының Татарстан филиалы терәк мәктәбе итеп расланысы очраклы түгел.

Ниһаять, 1990 елда татар һәм рус телләрен укытуда яңа технологияләр куллануда бөтен республикага дан казанган 35 нче мәктәп базасында Татарстанда беренче булып гимназия ачыла. 1 нче номерлы татар гимназиясе Казанда татар мәгарифен үстерүдә беренче карлыгач була.

Безнең беренче укытучылар авыр көрәш елларында имтихан узалар, мәктәпнең хәзерге бай традицияләренә нигез салалар. Үзләренең бөтен гомерләрен бистә халкына аң-белем бирүгә багышлаган В.Бәхтияров, Г.Хөсәенов, Һ.Мәрдәнов, М.Галиев, Татарстанның атказанган укытучылары Г.Якупов, Б.Аитова, Х.Шамкин исемнәрен халык онытмый.

Укучыларыбыз да әлеге исемнәр белән яхшы таныш. Гимназиядә 50 ел дәвамында эшләп килгән туган якны өйрәнү музее бу юнәлештә алыштыргысыз вазифа башкара. Ул Татарстан Дәүләт музееның филиалы булып тора. Аны оештыруны башлап йөрүче, 40 ел буе алыштыргысыз җитәкчесе – Гөлчирә Хафиз кызы Шәмсетдинова. Музеебыз мәктәпнең тәрбия процессында мөһим роль уйный. 1 сентябрьдә 1 нче сыйныфларда тәүге дәресне музейдан башлау – матур традицияләребезнең берсе. Әнә шулай бала күңелендә туган җиргә, үз милләтеңә мәхәббәт тәрбияләнә.

Музей татар халкы тарихын өйрәнүдә дә мөһим роль уйный. Эзләнү эше барышында, тарих өчен кирәкле мәгълүматлар табыла. Идел ярында мамонт сөякләре табу, борынгы кешенең мамонт сөягенә ясаган рәсеме хәтта «Татарстан тарихы» дәреслегенә кергән. Генерал Я.Чанышев, Ленинның шәхси шофёры М.Бурнашев белән очрашулар турындагы мәгълүматлар музей мирасханәсе хәзинәләрен тәшкил итә.

Күрәбез: республикабыз, башкалабыз тарихында тирән эз калдырган бик күп вакыйгалар һәм шәхесләр бер үк вакытта әлеге гимназия тарихын да формалаштыра. Шуңамы, әллә урнашкан урынына бәйле башка берәр сихри-даһи көчме, бу белем бирү йорты әлеге милли-мәдәни юнәлешкә йөз тоткан эшчәнлеген бүген дә уңышлы алып бара!

Хәзерге вакытта Казанның Габдулла Тукай исемендәге 1 нче татар гимназиясен республикабызда һәм аннан читтә дә әйдәп баручы яңа төр белем бирү оешмаларының берсе дип беләләр.

***– Бер гасыр дәвамында белем һәм тәрбия биргән мәгариф үзәгендә кемнәр генә белем алмагандыр... Гимназияне тәмамлаган кайсы күренекле шәхесләр сезнең мактанычыгыз булып тора?***

– Бер гасыр эчендә мәктәпне тәмамлаучылар арасында бик күп танылган шәхесләр бар. Алар – мәктәпнең горурлыгы гына түгел, ә республикабызда билгеле затлар.

Гомәр Гыйматдинов – Бөек Ватан сугышы герое – Мәскәүдән Берлинга чаклы сугышчан юл үткән. Аның легендар сугыш юлы турында «Возрождённая легенда» исемле документаль фильм да төшерелгән. Сөембикә Баязитова – медицина хезмәте старшинасы. Бөек Ватан сугышы елларында Франция халкының героинясына әйләнгән, Кызыл байрак ордены белән бүләкләнгән. Курку белмәс татар кызы дошман пулемёты астыннан 45 сугышчыны кораллары белән бергә сугыш кырыннан алып чыккан. Озак еллар Мәскәүдәге Патрис Лумумба исемендәге Халыклар дуслыгы университетының профессоры булган Габделхак Галиуллин, Ленин ордены кавалеры, татар халык ашларын өйрәнеп, даими рәвештә аларны пропагандалаучыларның

берсе Юныс Әхмәтҗанов, Татарстанның атказанган артисты Гөлсем Сөләйманова, РСФСРның атказанган укытучысы, татар халкы тарихын өйрәнүгә зур өлеш керткән бөек педагог Гөлчирә Шәмсетдинова, РСФСРның атказанган рус теле һәм әдәбияты укытучысы Миннехан Әхмәтҗанов, Татарстанның атказанган укытучысы, республика күләмендә татар телендә физика укытуны әйдәп барган Наил Гыймадиев, Татарстанның атказанган укытучысы Роза Сыромолотова, Татарстанның атказанган укытучысы Диләрә Сибгатуллина, ТАССРның мәгариф отличнигы, Республиканың атказанган укытучысы Ләлә Галиева, рус теле һәм әдәбияты укытучысы, ярты гасыр гомерен мәктәп белән бәйләгән педагогларның берсе Джема Камалова, шушы мәктәптә укып, соңыннан утыз елдан артык гимназиядә математика укыткан Әлфия Исхакова, Россиянең атказанган укытучысы Равил Усманов һәм тагын бик күпләр – безнең мәктәпнең элеккеге укучылары.

Бөек композиторыбыз, XX гасырның танылган музыканты Салих Сәйдәшев исеме дә мәктәп тарихы белән бәйле. Ул 35 нче мәктәптә кызлар хорын җитәкләгән. Мәктәп укучылары белән Зәңгәр күлгә экскурсия вакытында танылган «Зәңгәр күл» җырын иҗат иткән.

1 нче гимназия – традицияләргә бик бай белем учагы, чөнки монда мәктәпнең рухын, җанын белгән һәм шуны дәвам итә торган, үзләре биредә белем алган элеккеге укучылар эшли. Мин үзем дә биредә укыдым.

Татар мәктәбе – милләт сакчысы ул. 90 нчы елларда татар гимназияләре гөрләп ачылганда, зыялыларыбыз, үзләренең балаларын татар гимназияләренә урнаштырып, ана телендә белем-тәрбия бирү хокукын алды. 1 нче гимназиядә татарның күренекле вәкилләренең балалары укыды һәм укый.

***– Һәр җәмгыятькә сәләтле кешеләр кирәк. Сезнең гимназиядә сәләтле балаларны иҗатка тарту, фән белән кызыксындыру юнәлешендә нинди эшләр алып барыла?***

– Г.Тукай исемендәге 1 нче татар гимназиясе белем һәм тәрбия бирүне заман ихтыяҗларын аңлап оештыра. Заман уку-укыту эшчәнлегенең барлык тармакларына яңалыклар кертә. Мәгариф өлкәсендәге җитди үзгәрешләр фәннәрне тирәнтен өйрәнү һәм балаларның табигый сәләтен үстерүгә юл ачты. Хәзерге чорда дөньякүләм мәсьәләләр хакында фикер йөртерлек шәхес тәрбияләү аеруча әһәмиятле.

Сәләтле яшьләр – җәмгыятьнең төп байлыгы. Һәр бала үзенчә сәләтле. Без, баланың сәләтен вакытында күреп, аны үстерү өчен уңайлы шартлар тудырсак кына, көтелгән уңышларга ирешә алабыз. Сәләт бары тик дөрес оештырылган эшчәнлектә генә үсә. Сәләтле балалар белән эшләү – безнең гимназия эшчәнлегенең иң мөһим юнәлешләренең берсе. Һәр баланың үзенчәлеген һәрвакыт игътибар үзәгендә тотабыз һәм аларның бу сыйфатларын тагын да үстерергә тырышабыз. Сәләтле балалар белән эшләүнең төп максаты – һәр укучының сәләтен, иҗади башлангычын үстерү. Мондый укучылар белән эшләгәндә, эзләнү, яңа мөмкинлекләрне файдалану мөһим.

Сәләтле укучылар белән эшләү уку елының беренче атнасыннан башлана: укытучылар, сыйныф җитәкчеләре сәләтле балалар базасын төзи. Гимназиябез мөгаллимнәре шуны яхшы аңлый: сәләтле булу нәселдәнлеккә генә бәйле түгел, монда бала яшәгән мохитнең кыйммәтләр системасы да зур әһәмияткә ия; билгеле бер шартлар булдырганда, укучыларның күбесендә теге яки бу сәләтне үстерергә мөмкин. Сәләтле балалар базасын түбәндәге юнәлешләр буенча төзибез: интеллектуаль (олимпиадалар, фәнни-гамәли конференцияләрдә катнашучылар), рәсем сәнгате, әдәби иҗат (шигырь, хикәя иҗат итүчеләр, нәфис сүз бәйгесендә катнашучылар), музыка коралларында уйнаучылар, җырчылар, биючеләр, кул эшләре белән шөгыльләнүчеләр, спорт ярышларында катнашучылар. Гимназиядә эшли торган түгәрәкләр дә укучыларны һәрьяктан үстерүгә хезмәт итә.

Гимназия – гуманитар белем бирә торган уку йорты. Җәмгыятебездә нинди генә авыр шартлар булмасын, без ана телебезне, әдәбиятыбызны, тарихыбызны тирәнтен өйрәнү бурычын беренчел куярга тиеш. Шуны истә тотып, бездә «Каурый каләм», «Яшь хәбәрчеләр» түгәрәкләре эшли. Укучыларыбызның иҗат җимешләре 2003

елдан «Гимназия хәбәрләре» газетасында басыла. Гимназиянең ай саен чыга торган «Гимназия хәбәрләре» газетасы – 2007 елдан виртуаль газета. Аны чыгаруда һәр укучы, һәр сыйныф җитәкчесе катнаша, һәр рубрикасына укучыларның, түгәрәк җитәкчеләренең йөрәк җылысы салынган. Беренче иҗат җимешләрен «Гимназия хәбәрләре» газетасында бастырып каләм чарлаган укучыларыбыз район, шәһәр, республика күләмендә үткәрелгән иҗат бәйгеләрендә зур җиңүләр яулыйлар. Каләм тибрәткән укучыларыбыз «Шигъри сүз» район бәйгесенең, «Илебездә, телебездә, күңелләрдә Тукай мәңгелек» шәһәр бәйгесенең «Яшь шагыйрь» номинацияләрендә күп еллар дәвамында беренче, икенче урыннарга лаек булдылар. Бөтенроссия «Илһам» яшь иҗатчылар бәйгесе үткәрелә башлаганнан соң, укучыларыбыз гимназия данын ел саен еракларга таратты.

Укучыларны театр сәнгате ярдәмендә тәрбияләүгә гимназия мөгаллимнәре һәрвакыт зур игътибар бирде. Гимназиядә уку дәверендә үзен яшь артист итеп тоймаган бер укучы да калмый, дисәк, хата булмас. Театр артистлары белән очрашулар, сыйныф җитәкчеләренең иҗади эшчәнлеге эзсез югалмады, укучылар театр сәнгатен яратып кына калмадылар, аның серләренә дә төшенделәр: район, шәһәр бәйгеләрендә уңышларга ирешеп, Туфан Миңнуллин исемендәге фәнни-гамәли республика конференциясендә 2013 елда – II урынга, 2014 елда – Гран-прига, 2015 елда I урынга лаек булдылар.

Фәнни-гамәли конференцияләргә әзерләнү һәм анда катнашу белем алуда зур әһәмияткә ия. Гимназия укучылары төрле дәрәҗәдәге фәнни-гамәли конференцияләрдә даими катнашты һәм алдынгы урыннар яулады. Фәнни хезмәт язып чыгу өчен, шактый күп вакыт сарыф итәргә, эзләнергә, баланы да тикшеренү эшенә өйрәтергә кирәк. Язачак тема буенча материал туплау, аны өйрәнү, әдәбият исемлеген барлау эшен укытучы башта үзе өйрәнә, аннан соң гына балага тәкъдим итә. Гыйльми эшләр башкару укучыларның танып белү активлыгын камилләштерергә һәм үстерергә, фәнни-популяр һәм башка төр өстәмә әдәбият белән җентекләп эшли белергә өйрәтә. Бәйге-ярышларда катнашу тырышлык, максатка омтылучанлык, мөстәкыйль фикер йөртә белү кебек мөһим шәхси сыйфатлар тәрбияләргә дә булыша. Максатчан хезмәтнең нәтиҗәләре дә куанычлы. Укучыларның Бөтенроссия Н.И.Лобачевский исемендәге фәнни конференциясе, Каюм Насыйри исемендәге төбәкара фәнни-гыйльми укулар, Туфан Миңнуллин исемендәге фәнни-гамәли республика конференциясе, «Ломоносов укулары», «Фән көннәре», «Фән дөньясы», «Фәнгә адым» кебек шәһәр фәнни-гамәли конференцияләрендә укучылар һәр уку елында уңышка ирешә.

Һәр баланың үсеше өчен бертигез шартлар тудыру, аларның сәламәтлеген ныгыту һәм укучыларны гүзәллекне тоярга өйрәтү максатыннан, гимназиябездә физик тәрбия сәгатьләренең бер сәгате соңгы елларда хореография дәресенә бирелде. Гимназиядә белем алучы 600гә якын баланың һәрберсе бию дигән олы сәнгатьнең тәмен татыды. Уку елы дәвамында үткәрелә торган чараларның барысында да яңадан-яңа биюләр күреп, укытучы һәм укучыларыбыз иҗатына сокланабыз.

Гимназия укучыларын еллар аша да үзенә тартып тора. Монда укыганнар үзләренең балаларын, һичшиксез, үз мәктәбенә алып килә, шуңа күрә укучылар династиясе – бу мәктәп традициясе. Мәктәп, гаилә традицияләрен саклап, тулы бер милләтне яшәтә. Татар мәктәбе ул – милләтне саклап, киләчәккә илтүдә алыштыргысыз мөһим этап. Гимназия озак еллар «Татар гаилә фонды» белән хезмәттәшлек итә. Алар белән очрашулар, гаилә бәйрәмнәре, уртак чаралар – барысы да татар балаларын милли традицияләрдә тәрбияләү өчен алып барыла.


Заман һәрвакыт үзгәрештә. Безгә шуны истә тотарга кирәк: укучыларыбызга сәләт, омтылышларын заман таләпләренә җавап бирерлек итеп белем бирсәк кенә, алар мөстәкыйль яши, тормышта яңа үрләр яулый ала.

***– Тулы җавапларыгыз өчен зур рәхмәт!***

*Әңгәмәдәш* – **Рамил ХАННАНОВ.**

# БҮГЕНГЕДӘН – ТАРИХКА ТАБА

## МӨСӘГЫЙТ ХӘБИБУЛЛИНГА 90 ЯШЬ



Халкыбыз нинди генә катлаулы, вакыт-вакыт фаҗигале чорлар кичерсә дә, шул чорларны образлы сурәтләп баручы каләм осталарына кытлык кичермәде. Моннан ярты гасыр элек, ягъни алтмышынчы еллар ахырында, татар прозасында тагын бер яңа исем барлыкка килә – Мөсәгыйт Хәбибуллин. Ул инде бу вакытта дүрт дистәне тутырган була. Кемдер әйтер, кеше иҗат каләмен кулына мөмкин кадәр иртәрәк алса, нәтиҗәлерәк була. Без дә моның белән килешәбез. Әмма һәр кешенең үзенә генә хас яшәү, көн итү мохите, язмышы була. Сүз дә юк, бу чолганыш гаилә хәлләре, андагы рухи халәт белән генә билгеләнми, ул бик күпкә киңрәк даирәләр һәм хәл-әхвәлләр белән дә шартлана.

1927 елда туганнар өчен бу бигрәк тә шулай. Бу елгылар, дөресен әйткәндә, ике ут арасында калдылар дияргә мөмкин. 1941 елдагы сугыш башланганда, аларга ундүртенче яшь була. Безнең Мөсәгыйтнең дә, Оренбург өлкәсенә кергән Габдрахман авылында башлангыч мәктәпне тәмамлаганнан соң, күрше Татарстанның Баулы районындагы Шалты мәктәбенең җиденче сыйныфына күчкән чагы. Мәктәптә укуга караганда, аларга инде күбрәк басу эшләренә йөрергә туры килә. Карт-корылар белән бергә, фронт өчен дия-дия, ни генә эшләмиләр, көнне төнгә ялгап урып-җыю йөген дә җигелеп тарталар. Тора-бара аның кебек яшүсмерләргә дә чират җитә. Унсигез яшьләре тулуга, аларны да хәрби хезмәткә ала башлыйлар. 1944 елда Мөсәгыйтләргә дә нәүбәт килә. 1927 елның беренче яртысында туганнар солдат каешын буалар. 25 декабрьдә генә туган Мөсәгыйткә хәрби комиссариатта комиссия үткәч әйтәләр: сиңа чират 1945 елга чыккач та җитәргә мөмкин. Сугыш, инде фашистларның үз җирендә барса да, яңадан-яңа көчләрне суырып кына тора иде.

Берничә көн үтүгә, аны авыл советына чакырталар.

– Сине Магнитогорскига һөнәр мәктәбенә җибәрәбез. Анда эшкә өйрәнеп, заводта эшләрсең, корал җитештерерсең. Фронт сиңа шул булыр. Дошманны анда синнән башка да җиңәрләр!

Күңеле белән сугышка барырга әзер булса да, сатулашып тора торган чак түгел. Тиз генә әзерләп, өйдәгеләр аны күрше өлкәгә озаттылар. Уку курсларын үтеп, металл кою заводында эшли башлады. Эшли-эшли өйрәнерсең, диделәр. Ул биредә шунысына игътибар итте: туган җирләрдән шактый ерак булса да, эшчеләр арасында татарлар да күп иде. Ник дигәндә, егерменче-утызынчы елларда социалистик төзелешләргә хисапсыз эшче көчләр кирәк булгач, аларның әтиләрен, абыйларын Уралга көчләп китергәннәр яки, юк кына гаепләрен табып, озын мөддәтләргә хөкем иткәннәр, биредә эшләргә мәҗбүриләгәннәр. Хәзер аларның байтагы үлеп беткән, болары – шуларның икенче буыны. Менә шуңа күрә үзе кебек слесарь, токарьларның күпчелеге безнең милләт кешеләре. Дөрес, аларның байтагы өлкәнәеп килә. Ара-тирә яшьрәкләр дә бар. Аларның кулы эшкә шулкадәр килешле ята, теге яки бу детальне ясаганда, күпвакыт

сызымга бер күз төшерүләре дә җитә, кулларына циркуль тотып үлчәп торуның хаҗәте дә юк. Шуңа күрә аларны сугышка да җибәрмәгәннәр, монда кирәгрәк дип исәпләгәннәр. Алар Мөсәгыйткә дә гел киңәшләрен биреп тора, эшләп күрсәтә, карап торып эшләтә. Менә шундый кайгыртучан җылы мөнәсәбәт яшүсмергә күңел рәхәте бирә, таяныч була. Цех начальнигы, аның ярдәмчеләренең бәйләнеп торуларына да бик исе китми. Үзе дә шушы бер-ике ел барышында, өлкән һөнәрдәшләре дәрәҗәсенә үк җитә алмаса да, эшендә шактый камиллеккә ирешә. Аңа хәтта, эшеннән аерылмыйча гына, металл эше буенча техникумда уку мөмкинлеген дә тудыралар. Өч ел уку дәверендә ул инде бу өлкәдә нәзари яктан остазларыннан күпкә алгарак китә, аның өчен заводта хезмәт баскычларыннан күтәрелү мөмкинлекләре дә ачыла.

Ләкин яшьтән үк авыл киңлекләрендә, яшеллек мохитендә саф һава сулап, җан рәхәте бирә торган суларында коенып үскән егетнең күңелендә сагыш-әрнү, туган ягына омтылу хисләре отыры арта гына тора. Көннәрдән бер көнне гаиләгә бәйле җитди сәбәпләр бу мәсьәләне катгый итеп кую мөмкинлеген бирә, ниһаять, аны җибәрергә булалар. Октябрск каласында нефть чыгару оешмасында мастер булып эшләп алганнан соң, ул егерме алты яшендә туган авылына кайтып урнаша. Җанга якын җирләрдә дүрт-биш ел инженер-механик булып хезмәт итеп, үзенең бу җәһәттән дә кирәкле кеше икәнлеген раслый. Шуңа тагын Баулыда сигез ел автомеханиклык хезмәтен башкарганлыгын да өстәсәк, урау юллар буйлап йөреп, кулына эш һәм иҗат коралы итеп каләмне алганчы, утыз өч яшькә җиткәнен дә сизми кала.

Ул үзенең хезмәттәшләреннән китап укырга яратуы белән аерылып тора. Аның китап җыю гадәтенә сәерсенеп караучылар да була. Әмма үзара аралашкан иптәшләре, теләсә нинди тормышчан мәсьәләләр турында сүз барганда, аның төпле итеп, әйтергә теләгән фикерләрен алар күз алдына да китермәгән мисаллар белән дәлилләвенә күптән инде игътибар итә киләләр. Матбугатта сирәк булса да хикәяләре басыла башлагач, Мөсәгыйткә «язучы» дигән кушамат тагучылар да алар була. Ул моңа шатлана гына һәм уйлап куя: их, чыннан да, язучы булсаң иде ул! Ә ничек язучы булырга? Һәм карарга килә – көчне район матбугатында сынап карарга кирәк. Болай да җирле газеталарда төрле хәбәрләр белән катнашкан егетнең ниятенә каршы килмиләр. Баулыдагы «Байрак», Азнакайдагы «Маяк» газеталарында җиде ел журналист булып эшләү аның каләм көченә зур сынау була. 1971 елда, ягъни кырык дүрт яшендә, университетның татар бүлеген читтән торып тәмамлавы каләм тибрәтү эшчәнлеген яшәү мәгънәсе итеп сайлаганлыгына дәлил булып тора. Аның иҗатка килүе әнә шундый урау юллар аша була.

Тормышның үзендәге кебек үк, М.Хәбибуллин әдәби иҗатта да чынбарлыкның бер өлкәсеннән икенчесенә күчә торды, төрле тәҗрибәләр ясады. Аның хикәяләрдән торган беренче китабының «Җиде юл чатында» дип аталуы да очраклы булмагандыр. 1951 елда яшьләр җыентыгында басылган беренче хикәясеннән башланган бу иҗат төрле мәүзугларга сукмак салып карады.

Без, каләм тибрәтүчеләргә, бигрәк тә чәчмә әсәрләргә өстенлек бирүчеләргә, талант бөреләре янына тормыш тәҗрибәсе, әйләнә-тирәне төрле яклап танып-белүгә ихтыяҗ да кирәк, дибез икән, бу М.Хәбибуллин мисалында да раслана. Аны 1971 елда Язучылар берлегенә алырга тәкъдим иткән өлкән әдибебез А.Расих та нәкъ шулай яза: «Дөньяны күп күргән, тормышны якын белә торган, хезмәтнең шофёрдан башлап инженерга кадәр булган барлык баскычларын үткән кеше», – ди *(Казан утлары. – 1971 – №2. – Б.184)*.

Аның тормыш юлында тагын бер сәхифә бар. Авылда, иген кырлары кочагында үскән малай сугыштан соңгы елларда нефтьчеләр арасында да кайнап ала. Шул арада ул кара алтын чыгаручыларның икенче даирә кешеләре генә түгел, бәлки бөтенләй башка гамь белән яшәүчеләр икәнен дә аңлап ала. Ник дигәндә, иген үстерүче өчен җир яшәү чыганагы булса, җирнең маен суыручыларга, аның өстенә караганда, асты кадерлерәк икән. Бу, авыл кешесе үлчәме белән бәяләгәндә, гайре табигый хәл. Шул турыдагы борчуларын ничә еллар күңелендә йөрткәннән соң, дүрт дистә чиген узгач, әлеге хакта «Икмәк кадере» дигән әсәрен язуы шуның нәтиҗәсе.

...Район башлыгы кабинетына шушы төбәкнең җитәкчеләре җыела. Бер күмәк хуҗалык җитәкчесе биштәреннән түрәнең өстәленә кабарып пешкән икмәк чыгарып куя һәм шундагыларга әйтә:

– Кем таптый ала шушы икмәкне? Кем?!

Барысы да аптырап кала. Бу бит әле сугыштан соңгы гына еллар. Биредә утыручылар бер туйганчы ипи ашау хыял гына булган ул елларны яхшы хәтерли. Шуңа күрә, нәрсә сөйли бу, тик торганда икмәкне кем таптый алсын? – дип, гаҗәпләнеп карап торалар. Болай эшләү өчен, шыр юләр булырга кирәк.

Шулай да бүлмәдәгеләрнең берсе әлеге икмәкнең районнагы иң абруйлы өстәл өстенә куелуының сәбәбен чамалый. Бу бәндә – шушы төбәктә нефть эзләүчеләр эшчәнлегенә җитәкчелек итүче Ходайбирдин. Ул әлеге икмәкнең хуҗасы Кадыйровның нәфрәте үзенә төбәлгәнлеген аңламаслык ахмак түгел. Чөнки соңгы көннәрдә генә аның кешеләре, авария ясап, шушы хуҗалыкның уңдырышлы җирен пычратып, эштән чыгарганнар иде. Күңелле эш түгел, анысы. Әмма ул үзенә аклану да таба. Без бит ул бозылган җир өчен аларга акча түлибез. Әлеге кишәрлекләрдән җыеласы икмәк бәясе, нефтьнеке белән чагыштырганда, күпкә кимрәк. Шуңа күрә нигә ул кадәр борчылырга? Без бит нефтьне алтынга сатабыз!

Ике җитәкченең бер үк нәрсәгә төрле караштa торуларын күреп утырган район башлыгы аларның кайсысы хаклы булуын аңларга тели. Кемгә өстенлек бирергә? Әлеге сорауга катгый җавапны ул нефтьчеләр чиновнигының менә бу сүзләре яңгыраганнан соң таба:

– Иптәш Кадыйров, ипиегезне алып китегез, монда ач кешеләр юк!

Чыннан да, бу очракта нәрсә кадерлерәк: икмәкме, әллә нефтьме? Ләкин җавап бер: алтынны (сарымы ул, карамы) ашап булмый. Яшәү чыганагы – икмәк! Май сеңгән җирләр тагын ничә еллар буе икмәк үстерергә яраксыз булачак әле.

И.Гази кебек бездәге нефтьчеләр турында беренче романны иҗат иткән олы әдип тә әсәр коллизиясенең тормышчан каршылыкларга нигезләнүенә игътибар итә. «Повестьны зур канәгатьләнү белән укып чыктым. Язучы өчен тормыш тәҗрибәсе бик зур сыйфат», – ди ул *(Казан утлары. – 1977. – №12. – Б.151)*.

Әлеге әсәр укучыны барыннан да элек күтәрелгән темасының безнең җөмһүрият өчен аерым бер әһәмияткә ия булуы белән уйланырга мәҗбүр итсә, шуннан соң язылган «Унсигезенче яз» повесте сәнгатьчә эшләнеше буенча алга китешне күрсәтә иде. Монысы – язучы өчен иң мөһиме. Чыннан да, унсигез яшәр Әнрүсә белән булган вакыйгалар укучыны чын-чыннан дулкынландыра. Заманында, зур сәнгатьтә урын алу максаты белән, баласын ташлап башкалага киткән Мөнирә әллә ни уңышка ирешә алмаган. Аның каравы, ул үзе дөньяга китергән баласына «апа» гына булып калган. Кыз исә, балигъ булгач, Мәскәүдә узачак җыр ярышына барырга сайланып алынган. Ихтимал, аңа бу юнәлештә бәхетле юл ачылыр дигән өмет туа. Авторның уңышы – Әнрүсәнең күңел тирбәлешләрен шактый тоемлы итеп бирә алуында. Шулай да әле М.Хәбибуллинга шул чор тәнкыйтендә каләмен тагын да камилләштерергә кирәклеге турында киңәшләр дә ишетергә туры килә. Н.Гамбәр, мәсәлән, хис-кичерешләрне вакыйга-картиналар аша сурәтләү урынына вакыт-вакыт аларны сөйләп чыгу белән узып китмәскә кирәклеген искәрткән иде *(Гамбәр Н. Бәхеткә юл – гел алда // Казан утлары. – 1977. – №12. – Б.150)*. Шулай да авторның үзенә килгән күпсанлы хатлар, очрашуларда әйтелгән фикерләр әсәрнең бигрәк тә яшьләр тарафыннан бик җылы кабул ителүен күрсәтә иде.

Хәзерге чорда төрле чыгышларда, матбугат битләрендә әдәби әсәрнең тәрбияви әһәмиятен бәяләп бетермәү яки аны бөтенләй инкарь итүләр дә сирәк күренеш түгел. Сорау туа: алай булгач, ни өчен иҗат итәбез? Танып-белү яки тәрбия җәһәтеннән әйтәсе сүзең үзең өчен дә ачык булмаганда, тулыканлы әдәби тукыма барлыкка килергә мөмкинме? Әдәби әсәр, ахыр чиктә, бары тик әхлакый, тәрбияви генә була ала. Шушы таләпкә җавап бирмәгәндә, аның кеше күңеле өчен кыйммәте калмый. Уңай образлар аны кабул итүче өчен үрнәк булып хезмәт итсә, кешене тискәре образлар да тәрбияли – андый булмаска дигән сабак бирә. Мөсәгыйт абый моны яхшы аңлап эш итә. Геройларын ботаксыз-чатаксыз идеал итеп кенә күрсәтми, аларны, үз җайларына куеп, барлыкка килгән мохит шартларында иркле яшәтә. Аның китапларын яратып, укучылар аларның нәкъ менә шул хасиятләрен хуплыйлар да. «Хәтер ярлары», «Сулар үргә акса да...» кебек әсәрләрендәге сәнгатьчә камиллеккә ирешүдәге кайбер

җитешсезлекләрне күрсәтсә дә, Р.Мостафин «бу хәл аларның популярлыгында чагылмый», – диюе белән әдипкә хас иҗат алымнарын хуплавын күрсәткән иде *(Социалистик Татарстан. – 1984. – 16 март)*.

Шулай да иҗатының беренче чорында М.Хәбибуллин ил күләмендә «Чоңгыллар» романы белән танылды диярге кирәк. Анда авторның әсәр тудыруда кулланыла торган мөмкинлекләренең күбесе урын алган. Шул елларда роман Мәскәү нәшриятларында гына да өч тапкыр басылып чыкты, Россия Язучылар союзы премиясенә лаек булуы да аның югары бәяләнүе турында сөйли. Дөрес, бүгенге көн өчен анда күтәрелгән мәсьәләләрнең мөһимлеге кимегән дә булуы мөмкин. Әмма гомум кабул ителгән кешелек кыйммәтләренең иң асылларыннан берсе булган мәрхәмәтлелек дигән нигез төшенчә бервакытта да кыйммәтен җуймый. Байлыкка омтылу әнә шул кешелелеклелек дигән төшенчәнең затлы өлешләрен тәшкил итүче шәфкатьлелек, игелеклелек кебек сыйфатларны басып китмәскә тиеш. Романнан килеп чыга торган шушы төп фикер бүген аеруча мөһим.

Повесть-романнары белән бер үк вакытта М.Хәбибуллин иҗатының беренче чорында (ягъни тарихи темалар белән мавыгып киткәнче) хикәя жанрын да үги итмәде. Ул аларда да тормыш күренешләрен сурәтләүдә шул елларда мәҗбүри булган идеология таләпләреннән читтәрәк калырга омтылды. Кешеләр арасындагы күптөрле мөнәсәбәтләр арасыннан яшәешебезнең әхлакый катламнарына мөрәҗәгать итү, күңелдәге тирән кичерешләрнең көчен ачарга омтылу аның өчен төп юл булып әверелде. Шул нисбәттән, «Яңа өй» хикәясе аеруча гыйбрәтле. Ярулла дигән егет, үз ихтыяры белән сылу хатынын калдырып, кайчандыр шахтага эшкә китә. Шунда бәхетсезлеккә юлыгып, бер кулын, бер аягын өздерә. Еллар үткәч, гарип хәлендә Хәнифәсе янына кайтып егыла. Әмма чибәр хатынга менә дигән, сәламәтлеге ташып торган ир табылган. Гаилә бик матур итеп яшәп ята. Укучыны гаҗәпләндергәне шул: аз гына горурлыгы булган ир үзе аерган хатыны янына кайтып кермәскә тиеш иде. Нихәл итәсең, шулай да бу тормышта булмастай хәл түгел. Билгеле инде, ул бирелдә артык кеше. Язучы Яруллны, шул рәвешле, гаять кыен әхлакый шартларга куя. Аның әлеге гаиләдә үзен төксе итеп каршылауларына тап булырга бөтен нигезе бар. Халык сүзе белән әйткәндә, ул – бирелдә киселгән икмәк. Гаҗәпкә каршы, Хәнифәнең хәзерге ире Нурислам аңа ачык йөз күрсәтә, «баҗай» дия-дия, мунчада да юындырып чыгара. Кем белә, гарип ир аларның үзенә карата мөнәсәбәтләрендә чит итүләрен сизсә, түзәр дә иде әле. Әмма мондый шәфкатьлелек, кайгыртучан карашны тою аңа психологик яктан көчлерәк тәэсир итә. Ул үзен болар каршында хәтта көнчелек хисләре тудырырга да лаек булмаган бер мәхлук итеп тоя һәм тормышын һәлак итү адымына бара. Аның яшәештәге соңгы адымы алдыннан булган әчке кичерешләрен бирү тирәнлеге хикәянең сәнгатьчә эшләнешендәге иң уңышлы як дип саналырга тиештер.

«Өченче вагон» хикәясеннән дә нинди дә булса иҗтимагый яңгырашлы әйберләр көтү урынсыз. Егерме яшьләрдәге Алсуның чын сәнгать күренешен зәвыксызлыктан, ихлас сөюне ясалмалылыктан аера алуына килү эволюциясен бирү хикәядә төп бурыч итеп алынган һәм оста рәвештә тормышка ашырылган.

Әдәби мәйданда М.Хәбибуллинның хикәя жанрындагы елдан-ел ныклы урын ала баручы уңышлары турында тагын да бәян итәргә мөмкин булыр иде. «Таң чишмәсе», «Әбиләр чуагы» кебек әсәрләре дә аның бу өлкәдәге казанышлары буларак санала ала. Шулай да бу очракта аның «Таңана» исемле хикәясе аерым бер игътибар итүне сорый. Ул язучы иҗатындагы кискен бер борылышның өметле хәбәрчесе буларак та кызыклы.

Эш шунда: язучының тормыш юлында аның ике ел Таҗикстандагы бер мәктәптә тарих укытучысы булып эшләү сәхифәсе бар. Шул елларда ул уйлый башлый: менә без дәрес саен рус дәүләте тарихын, аның патшаларының гамәлләрен өйрәнәбез. Ә менә шушы таулы җөмһүриятнең, ягъни Таҗикстан дигән илнең дә бай үткәне булган бит. Ул мәктәптә өйрәнелергә тиеш түгелмени? Татар тарихы белән дә шул ук хәл. Мөгаллим Мөсәгыйт Мөдәррис улы шушы уйларын очраклы рәвештә әлеге мәктәпкә килеп чыккан зур галим, тарихчы, этнограф һәм географ Лев Гумилёв белән уртаклаша. Тәнендә күпмедер дәрәҗәдә татар нәселе каны да булган Лев Николаевич аңа әйтә:

– Татар тарихы – олы, катлаулы һәм дөнья үсешенә зур өлеш керткән халык тарихы.

Сез аны өйрәнегез, белегез, яңа буыннар хәтеренә салыгыз. Дөрес, сезгә үткәннәрегезне хакыйкый бәян итү җиңел булмас. Моны мин үз мисалымда яхшы беләм. Мин гомер буе татарларны яклап яшәдем.

Менә бу сүзләр яше кырыктан ашкан Мөсәгыйткә нык тәэсир итә. Олуг галим безгә – татарның тормыш тоткасына әверелгән буыны ир-егетләренә – әнә нинди акыл бирә. Моңа битараф булырга мөмкинме? Бу эшкә керешү өчен, миңа Казанда булу кирәк, – ди үз-үзенә булачак язучы. – Бары тик Казанда! Кайтам, җиң сызганып шушы эшкә керешәм.

Һәм 1971 елда ул даими яшәү өчен Казанга килә. Биредә дә теләсә кайда түгел, эшкә нәкъ менә язучылар даирәсендә урнашуга ирешә. Аңа оештыру эшләре буенча сәркатиплек вазифасын тапшыралар. Ул шушы гаять мәшәкатьле йөкне унсигез ел тарта. Шул ук еллар аның каләм тибрәтүенең дә иң үрчемле вакыты. Ләкин, шулай да, омтылыш зур булса да, тикшеренү, иҗат эшләрендә үзеңнән дә алгарак чыгып чабып булмый. Әдәби чолганышта баш-күз алырга, бүгенге яшәешне, тормышны эстетик үзләштерүдә дә тәҗрибә тупларга, шул ук вакытта тарихи чыганакларны өйрәнү эшенә дә чумарга кирәк. Чөнки Гумилёв әйткәннәр колакта һаман яңгырап тора. Ленинградка барып, Лев Николаевич белән тагын очрашып кайта. Аңардан үткәннәрне барлау һәм күзаллау буенча киңәшләр ала. Ул күрсәткән юнәлешләрнең мөһимлеген тагын да ачыграк күз алдына китерә башлый. Тора-бара Мөсәгыйт ага шуны төшенә: тарихны фән итеп өйрәнүдә фактларны, түкми-чәчмичә, булганынча барлау, алар хакында аерым күренешләрдән гомумиләштерүләргә килү кирәк булса, язучы өчен шулар өстенә образлы фикерләү дә таләп ителә. Теге яки бу концепцияне нигезләү өчен фактлар җитенкерәмәгән вакытта, язучы, әлбәттә, мөмкинлек биргән дәрәҗәдә әсәр тукымасына хыялларын да кертеп җибәрергә мөмкин. «Ләкин моны, – ди үзе дә тарихи әсәрләр язган рус әдибе А.Н.Толстой, – шулай итеп эшләргә кирәк, бу (ягъни уйлап чыгарылган) чынбарлыкта булмаган булса да, булырга мөмкин итеп бирелсен».

Беренче тәҗрибә буларак, М.Хәбибуллин әлеге юнәлештә, инде әйтелгәнчә, «Таңана» хикәясен язды. Борынгы чорларның зур хакимнәре арасындагы хәлләрне сурәтләү ул инде бер кызның ике егетнең кайсысына өстенлек бирүе турындагы күңел кичерешләре генә түгел, монда бик киң фикерләү, русча әйткәндә, масштаблылык белән эш итү сорала. Шул ук вакытта тарихи күзаллау, тел-өслүб җәһәтеннән дә шул ерак дәверләр үзенчәлекләрен нечкәләп белү мөһим. М.Хәбибуллин бу таләпләрне яхшы тоеп эш итәргә тырыша. Нәтиҗәдә, әлеге хикәядә явызлыкның киләчәктән мәхрүм икәнлеге шактый тәэсирле раслана. Үзен кешеләрдән өстен исәпләп, Аллаһы белән тиңләшергә омтылган идарәче табигать тарафыннан ук юкка чыгарыла. Безнең эрага кадәр 530 еллар элек фарсылар белән сөннәр арасындагы әлеге сугыш вакыйгаларын үз вакытында Геродот дигән билгеле тарихчы язып калдырган булган. М.Хәбибуллин, бөтендөнья тарихындагы бу һәм башка чыганакларга таянып, шул ерак дәверләрдәге хәлләрне бүгенге укучы күз алдында җанландыра.

М.Хәбибуллинның «Кубрат хан» романын яза башлавы да нәкъ шул сиксәненче еллар башына туры килә. Бу инде Геродот язуда беркетеп калдырган чорлардан мең елга соңрак булган вакыйгаларны чагылдыру иде. Тарихтан хәбәрдар кешеләргә болгар тарихындагы иң күренекле шәхесләрнең берсе Кубрат хан икәнлеге яхшы мәгълүм. Шулай да әлегә кадәр бу зур идарәче кайчандыр булган, яшәгән бер абстракт кеше буларак кына шәйләнә иде. Мөсәгыйт абый аны холкы-фигыле, йөреше-торышы, кылган эшләре белән үзенә хас сыйфатларга ия зат итеп тасвирлады, ягъни ул инде күз алдында җанлы фигура булып гәүдәләнде. Шуның белән язучы иҗатта яңа мөмкинлекләрен ачты. Сүз дә юк, чыганаклар сәнгатьчә образлар тудырырга ярдәм итәрдәй мәгълүматларга ярлы. Аның каравы, төрки халыклар, Дунай буйларындагы болгарлар, хәзәрләргә кагылышлыларында бу бөек элгәребезнең кылган гамәлләре,дәүләтнең иминлегенә куркыныч янаучы чолганышта аның тарафыннан ясалган хәлиткеч адымнар хакында теркәлеп калган сәхифәләр аз түгел. Бу очракта Кубрат образын шул кылганнарына бәрабәр итеп бирү бурычы тора иде. Бусы инде, тарихчылардан бигрәк, иҗади рәссам эше. М.Хәбибуллин нәкъ шулай эшләде дә.

Тарих сукмакларына бер кереп киткәч, инде әдип шул юнәлештә байтак башка

табышларга да юлыкты. «Илчегә үлем юк», «Шайтан каласы», «Сөембикә ханбикә һәм Иван Грозный», «Хан оныгы Хансөяр», «Аллаһы бүләге», «Батый хан һәм Ләйлә», «Айбиби», «Атилла» кебек романнарының исемнәрен әйтеп чыгу да бу иҗатчыга карата хөрмәт һәм соклану хисләре уята. Халкыбыз тарихындагы ерак дәверләрдәге вакыйгалар, фаҗигаләр, шул чорларның тарихи шәхесләре кичергән гаҗәеп катлаулы хәлләр, аның каләме белән калын-калын китапларда тупланып, рухи хәзинәләребез булып әверелде.

Тора-бара әдип үзе дә уйлары-кичерешләре, мавыгулары белән тарихыбызны гәүдәләндерүче булып тоела башлады. Язучылар берлеге рәисе булып эшләгән елларымда ул ара-тирә йомышы төшеп кергәләп тора иде. Хәл-әхвәл сорашкач, ниндидер бер бәйләнешен табып, үткәннәр турында мавыгып сөйләшергә керешеп китә дә ни өчен килгәнен дә оныта. Белеп торам, чыгып киткәч, яңадан борылып керәчәк һәм гозерен әйтәчәк. Шулай була да.

Бер елны без өчәү – шагыйрь Харрас Әюп, Мөсәгыйт абый һәм мин Истанбулга төрки халыклар язучылары форумына бардык. Билгеле булганча, бу шәһәр заманында Византиянең башкаласы булган. Шул дәверләрдән сакланган диварларны, башка төрле корылмаларны Мөсәгыйт абый куллары белән сыйпап-сыйпап уза иде. Әйтерсең лә, ул аларда үткәннәрдән сакланган вакытлар тирбәлешләрен тоеп, аларны күңеленә җыеп йөри. Шәһәр буйлап сәяхәт итә торгач, без тирә-ягында күренекле шәхесләрнең һәйкәлләре тезелеп торган бер бакчага килеп чыктык. Берәм-берәм карап барганда, уртак каһарманыбыз Атилла сыны гәүдәләндерелгәненә тап булдык. Мөсәгыйт абый аның белән аеруча кызыксынды. Берничә тапкыр тирәли әйләнеп чыкты. Мин әйтеп куйдым:

– Күрәм, сез, Мөсәгыйт абый, Атилла бабабыз янында юкка гына бөтерелмисез. Мөгаен, нәкъ менә хәзер – шушы урында аның турында язу нияте барлыкка килде. Йөзегездән үк күреп торам.

– Син дөрес әйтәсең, Атилланы чынбарлыгы белән халкыбызга танытмый торып, төркиләрнең тарихын тулы итеп күз алдына китерәбез, дип әйтү мөмкин түгел.

Шушы сәфәрдән кайткач, Мөсәгыйт абыебыз Атилла белән «авырды». Казандагы китапханәләрдә-архивларда утырды, Ленинградта, Киевтә булды, яңадан махсус рәвештә барып Истанбулдагы чыганакларны өйрәнде. Аннан соң өендә, үзен дөнья мәшәкатьләреннән аерып, язу өстәле янына утырды (дөресендә «басты» дияргә кирәк, ник дигәндә, ул язу машинкасын буена таманлап эшләнгән биек аяклы өстәлчеккә куя, шунда аягүрә торып яза). Берәр елдан култык астына калып папка кыстырып килеп керде.


– Булды бит, менә! «Атилла»ны синең алдыңа китереп салам.

Роман беренче меңьеллык урталарында яшәүче халыклар язмышына кискен үзгәрешләргә китергән вакыйгаларны иңләве белән дә зур яңалык иде. Укучылар аны шулай бәяләделәр дә.

Әлбәттә, олы әдип һәм аның зур иҗаты турында бер мәкаләдә барысын да әйтеп бетерү мөмкин түгел. Шунысы ачык: Мөсәгыйт Хәбибуллин дигән олпат язучыбыз үзенең 90 яшен менә шундый киң колачлы иҗат нәтиҗәләре белән каршылый. Аның әсәрләре халкыбызның дөньяга, үткәннәребезгә дөрес карашын булдыруда, ахыр чиктә, милли аңын үстерүдә бик әһәмиятле бурыч үтәде. Узган гасырның соңгы чирегендә боларга ихтыяҗ аеруча зур иде. М.Хәбибуллин каләме нәкъ кирәк вакытта, андый әсәрләргә сорау арткан елларда хәрәкәткә килде. Аның егетлеге көтелгән сүзне кирәк вакытта әйтә алуында күренде. Без аңа алга таба аеруча саулык-сәламәтлек, тыныч картлык телик. Мөсәгыйт абый Хәбибуллинның туксан яшен тыныч күңел белән каршыларга тулы нигезе бар.

**Фоат ГАЛИМУЛЛИН**

# ҺӘРКЕМ ЯШЬЛЕГЕН ЭЗЛИ



Була шундый әсәрләр – исеме телдән төшми, кайтып-кайтып укыйсың, сокланасың да хәтта. Язучысын сагынабызмы, геройларының язмышы синекенә охшаганмы, әллә кабатланмас югалтулары хәтеребезне яңартамы?!. Җирсүнең аңлатып булмый торган өянәге бу.

Әхсән Баяновның (алга таба – Әхсән Баян) «Яшьлегемне эзлим» повестен эзлим. Шөкер, редакциябездә 95 ел буе чыккан журналларның бөтен нөсхәләре дә саклана, кирәксә, һәр санның электрон версиясе дә бар.

Һәркем үзенең яшьлеген эзли.

*Алыгыз. Еллар, биргән акылыгызны,*
*Кайтарыгыз*
*Яшьлегемне кире!*

Повесть әнә шулай, авторның үз шигъри юллары белән башланып китә, ул «Казан утлары»ның 1967 елгы (нәкъ 50 ел элек) өч санында басылып чыга. Бу вакытта инде авторга кырык яшь тулып килә. Кырык яшь – кеше гомеренең югалтуларны барлый торган фасылы. Һәм инде дистәләрчә шигырь китабы чыгарып өлгергән Әхсән Баянның монументаль прозага керү урталыгы.

Урам исемнәре, тарихи кыйммәтләр, эстетик зәвыклар яңарган, «җылылык еллары» бу. Партиячыл әдәбияттан ялыккан укучы инде яңа идеаллар эзли.

Гариф Гобәйнең биш тапкыр кабатлап басылган «Маякчы кызы», Фатих Хөснинең «Йөзек кашы», Миргазиян Юнысның «Безнең өй өянке астында иде», Аяз Гыйләҗевнең «Җомга көн кич белән», «Өтәч менгән читәнгә» повестьлары әдәби мохиткә яңа сулыш алып керде.

Әхсән Баяновның «Яшьлегемне эзлим» повестен унҗиде яшемдә үк укыган идем инде, кабат укып утырам.

*«Сезнең чит кеше өенә үзе юкта кергәнегез бармы? Бик сәер һәм катлаулы хис били анда күңелне. Кеше дөньясына керүең аермачык сизелеп тора. Бөтенесе дә монда синең иркеңдә, сиңа кеше үз өен, юк, өен генә түгел, үз тормышын, үз күңелен ышанып калдырган...»*

Үзе өйдә юк чакта, кырык яшьлек Әхсәннең «өенә керәм», геройларын бәхетле-бәхетсез иткән гашыйклар дөньясын үзем аша үткәрәм, бүгенге күзлектән карап нәтиҗә ясыйм. Мин бу повестьның автобиографик булуын телим...

Әхсән Баян Язучылар оешмасына килгән саен бәйрәмчә киенгән була иде: пөхтә, җыйнак, зәвыклы. Аның нәсел-шәҗәрәсе борынгы татар морзаларына барып тоташканны яхшы беләбез. Сынаулы караш, төзек чырай. Талир тәңкәләргә сугарлык илаһи силуэт... Өстендә көрән төстәге вельвет костюм-чалбар, курткасы да көрән төстә – түше ялтыравык, ә җиңнәре кайры күннән иде. Аягында замш туфли – анысы да көрән. Чәченә чал йога башлаган ирләргә көрән төснең килешкәнен мин Әхсән абыйны күргәч кенә аңладым. Аңа гел абыем дип эндәшәсе килә... Әнис (повестьның төп герое) Консерваториягә керү турында хыяллана, тик музыкаль белеме җитми, иллә дә шәп баянчы, клубта кызлар тынгы бирми торган сөйкемле сөяк... Әхсән дә – Югары Яркәйдә, Мәдәният йортының сәнгать җитәкчесе, фамилиясенә күрә оста баянчы,

ягымлы тембрлы тавышлы. Әниснең мәхәббәт маҗаралары язучы биографиясенә теркәлгән географик мохиттә бара... Язучы белән персонаж туып-үскән уртак манзара: мәңге яшь һәм һаман Яңа Агыйдел; Илеш урманы, Югары Яркәй урамнары; биек таулы Исмаел ярлары; Базы болыны, Түбән Черек күл былбыллары, Әнис белән Фәһимә кочаклашып йөргән мул табигать кочагы. Сөйгән ярларны бер-берсеннән аерган Уфа – Казан сәяхәте...

Язучы, үзенең Әнисенә бәхетле минутларны бүләк итәр өчен, каләменнән килгән бөтен көчен куллана: печән болынын яшенле яңгырдан юдыра; әрәмәлекнең бөтен сайрар кошын шул тирәгә җыя; хуш исле исерткеч җиләкләрдән иләсләнгән Фәһимә кибән эчендәге куышка үз иреге белән килеп керә... Әлбәттә, язучы ошбу «зөфаф кичен»дәге тәүге хисләр давылын укучының гайрәтен чигерерлек итеп төчеләнеп, тәфсилләп сурәтләми. Ул әле, шушы төннән башлап, ким дигәндә, өч кеше өчен ачы язмыш яралганын да искәртми. Язучы үзенең уяулыгын югалта... Тукта, бу бит печән өсте, авылның чалгы-сәнәк тотардай яше-карты, егет-кызлары барысы да болында. Кунып эшләр өчен, кибән эченә куыш ясардай чыбыкларны да әрәмәлектән кумәкләп кистеләр, шау-гөр килеп ташыдылар... Димәк, никахсыз Әнис белән Фәһимәнең ни кылганы бөтен авылның күз алдында... Печәннән соң урак өсте дә бәйрәмчә уза... Ә көз җиткәч, егет Свердловскига китеп бара. Консерваториягә керә алмаса да, кыз янына әйләнеп кайтмый. Ул хәтта сөйгәне белән кайчан да булса күрешәсенә дә ышанмый. Аның каравы, яңа мәхәббәт маҗаралары башлана: Әнис, язучының туган төбәгеннән бик ерак китмичә генә, Лена исемле тагын бер кыз белән дуслаша (ул якта яшәүче татарлар арасында Лена, Рита, Борис – киң таралган исем), һәм аларның мөнәсәбәте тирәнәйгән саен, Фәһимә ерагая, хәтта кибән куышына кергән черкиләрне сагынырлык, ахыр чиктә «яшьлекне эзләү» газабына китерә.

Фәһимәне күрмәгән арада Лена белән мавыгуны Әнис үзенең йомшак күңелле булуыннан күрә.

*Ни хикмәттер, кеше еласа, кызганудан минем йөрәк сызлый, һәм, кем генә булмасын, мин аны юата башлыйм, сүзен тыңларга, теләген үтәргә тырышам. Үземә кыенлык китерә торган эш булса да, аныңча эшлим, ди Әнис.*

*Һәм йомшаклыкның нәтиҗәсе дә шунда ук.*

*– Кил әле, утыр әле, – диде Лена, ышыграк җиргә, куак артына җиткәч... Бүген мин синең ихтыярда. Аңлыйсыңмы син?!*

Әлбәттә, кызның бу сүзләре күз яшьләре белән әйтелә.

Көтмәгәндә генә Әнис үзендә каты бәгырьлелек, «батырлык» тәрбияләмәк була. Ул Лена алдында тере куянны «теш белән суя», канатлары да чыкмаган кошларны оясыннан алып һавага ыргыта, мескенкәйләр, лыпылдап җиргә килеп төшә. Ләкин төп героебыз Әниснең бу «батырлыгы» аны тискәре образ буларак кына үстерә. Бактың исә, каты бәгырьлелек һәм батырлык бер-берсенә капма-каршы төшенчә икән. Фәһимә Әниснең хыянәтен гафу итми һәм үзенә-үзе кул сала...

Алга таба егеткә Валя кызыга... Пешеп килгән җиләктәй Хәтирә очрый.

Ә илдә сугыш бара. Фронтка китәргә яше җитмәгән Әниснең кыланышлары тылда калган ир-атларның яшәү рәвешенә әверелгәндәй тоела. Халык ач-ялангач, өшегән бәрәңге – иң тансык ризык, җан өшердәй салкын өйләр, шыксыз клубларда күңел ачулар, кырдан икмәк урлаулар, бүреләр улавыннан соң авыл читендә баян авазы, сугыш чыгарган көйләр, аерылышу җырлары...

Повестьта Бөек Җиңү көне калку сурәтләнми. Җәмгыять өчен шушындый олуг бәйрәм ике-өч абзац белән генә әйтеп үтелә (!) Әхсән дә, Әнис тә сугыш чоры яшьләре ләбаса!

Минемчә, романлык материалны повесть күләменә калдырып, автор нык ашыккан, ул әсәрнең укучы кулына тизрәк барып җитүен теләгән. Урыны-урыны белән тоташтан күпнокталарга мөрәҗәгать итә. Һәм укучы күпнокталар, бер сүзле җөмләләрне, туры сөйләмнәр арасындагы бушлыкны үз тәҗрибәсе, үз бәясе белән тулыландырып укырга тиеш була.

*Атлыйбыз,*

*Декорация бер үк: кояш, зәңгәр күк, җир өсте.*

*– Акыллым минем...*
*...Еллар аша карыйм.*
*Иртә...*
*– Син анда нишләрсең минсез?*
*– Белмим.*
*Көн уртасы...*
*Алар бер үк урында унар тапкыр булганнардыр инде.*
*– Ташлап китмә мине.*
*Кич. Утлар кабынган инде...*

Әхсән Баян йогынтысында, кайбер яшь прозаиклар шигырь белән проза симбиозына охшаган әлеге алымны кулланып та карадылар, ни хикмәттер, ул стильгә үк әверелә алмады.

Зурдан кубып иҗат итәргә җыенган кеше ашыгып яши, күңелендәген тизрәк әйтеп өлгерергә тели. Повестьның, автордан кала, башка мөхәррирләр укымыйча гына басылып чыгуы нык сизелә:

*«Элек ире белән торган квартираларында, ике бүлмәле әйбәт квартирада, хәзер башка семья яши, ди. Нindidер закон нигезендә ул шушы квартирасын кайтарырга хокуклы... булдыра алгач карасын инде үзе дидем. Без аның белән кайчан да булса әнә шул квартирада торырга тиеш икән, өчәүләп була инде...»*[1] – дигән җөмләләр еш очрый. Һәм аларны каләм тотып укыйсы килә.

Язманың ахырына җитәрәк булса да, кереш сүз өстим әле, «Яшьлегемне эзлим»нең язылу чоры 1964-1966 дип куелган. Нәкъ менә шушы елларда, төгәлрәк итеп әйткәндә – 1965 тә, «Совет әдәбияты» журналы «Казан» утлары» дигән яңа исем белән чыга башлый. Һәм исеме үзгәргән арада, журналда бер-бер артлы дүрт-баш мөхәррир алышына. Алар арасында Әхсән Баянов та бар. Җаваплы мөхәррир булып Рафаэль Мостафин сайлангач, Ә.Баян җаваплы секретарь вазифасында кала, ләкин бу урында да озак эшләми (1977-1981 елларда ул әле кабат килә, бу юлысы инде баш мөхәррир урынбасары булып). Урынның тотрыксызлыгы ашыгып язарга мәҗбүр иткәндер, бәлки... дигән фикер туа...

Язучылыкны төп һөнәре итеп сайлаган Әхсән Баян гомеренең илле елын иҗатка багышлый: «Ут һәм су», «Таш китап» романнарын, дистәдән артык повесть һәм күп кенә драмалар язып өлгерә. Ә Татарстанның Халык шагыйре буларак аның поэтик иҗатына күзәтү ясауны, аңлашылса кирәк, мин бүген максат итеп куймадым... Чөнки сүз башы бит... «Яшьлегемне эзлим» повесте турында... Инде финалына килеп җиттек бугай:

*Миндә Бетховен үлде...*
*Үземнән башка беркемне дә гаепли алмыйм.*
*Агыйдел рапсодиясе.*
*Беркем, беркайчан ишетмәячәк аны.*

Хыялый һөнәрләренә ирешә алмаган Әнис туган авылына кайтып егыла. Көч җыя да яңадан юлга чыга, бу юлысы инде пароходта: Агыйдел – Чулман – Идел аша Казанга килешедер...

Бәхетлеләргә дә, бәхетсезләргә дә иҗади мәйдан киң бит ул – Казанда!


Әйткәнемчә, бу повестьны мин, беренче тапкыр, унҗиде яшемдә үк укыган идем. Гамәл дәфтәрем чиста иде әле ул чакта. Ләкин мин үзем дә Әнис нең язмышын кабатладым... Әдәби әсәрнең кыйммәте нәрсәдә соң?! Гыйбрәтме ул, кисәтүме, әллә үрнәкме? Бәхетсезлек үрнәк була аламы? Әдәби геройлар сурәтләнгән эстетик дөньяга карап – әнә бит, алар да минемчә яши, дип акланырга бер сәбәп кенәме?..

Бу сорауларга мин илле елдан соң да җавап таба алмадым.

**Камил КӘРИМОВ**

[1] Өземтә элек басылган вариантта бирелә.

# ӘНВӘР ӘЗИ



Әнвәр абый белән ныклап танышуым 1990 елның ахырында булды. «Салават күпере» журналы редакциясенә ул алты яшьлек кызы Айгөлнең төсле карандашлар белән ясаган рәсемен алып килгән иде. Киләчәктә җырчы булып танылу алачак кызының «Вафа хәзрәт мәчете» дигән рәсеменә Әнвәр абый белән икәү бик сокланып, гаҗәпләнеп карап торган идек. Айгөлнең ул рәсеме 1991 елда «Салават күпере»нең гыйнвар санында басылды.

Хәсән Туфан, Газиз Кашапов, Рәис Беляев кебек күренекле шәхесләре белән данлыклы Аксубай тумасы Әнвәр әзи белән, бигүк еш булмаса да, вафатына тиклем шактый аралашып, ут-күршеләр булып яшәдек.

Әнвәр әзи берсендә, минем өйгә шылтыратып, яңа чыккан китабын типографиядән алып кайтуда булышуымны үтенде. Татар һәм рус телендә меңәр данәдә басылган «Әхмәд ибне Фадланның 921-922 елларда Болгар дәүләтенә килгәндә язган сәяхәтнамәсе» дигән саллы һәм затлы басма иде ул. Шуны алып кайтышкан көнне, ягъни 2013 елның 11 мартында: *«Хөрмәтле Ләбиб белән Фиданиягә олы ихтирам һәм изге теләкләр белән Әнвәр Хәйридән бер истәлек»*, – дип язып, Әнвәр абый бер китабын мин бахырыгызга бүләк тә иткән иде.

Опера-балет яисә Камал театрларында булган төрле кичәләрдән, концерт-тамашалардан, гәпләшә-гәпләшә, Әнвәр әзи белән бергә кайткан чаклар һаман да истә. «Сәләт» лагеренда балаларга ачык һавада бергәләп дәрес биргәнебез әле дә күз алдымда тора. Вафатына бер көн кала да «Сәләт»нең Биләрдә узган форумында катнашкан булган икән ул...

И язмыш, диген...

Аның балачагы күп яшьтәшләренекеннән әллә ни аерылмый да кебек. Бөек Ватан сугышыннан соңгы бик авыр, михнәтле елларда, төгәлрәк итеп әйтсәк, 1947 елның 2 декабрендә мең гасырлык Шәрбән авылында гап-гади колхозчы Нәҗибулла абзыйның ишле гаиләсендә сигезенче бала булып дөньяга килә ул.

Ачлы-туклы яшәсәләр дә, гаиләдә һәрчак күңел күтәренкелеге хөкем сөргән. Китаплар бихисап булган: гарәп хәрефләре дә, латин һәм рус хәрефләре дә, кулдан язылганнары да, басмалары да... Менә шул китапларны аларга кичләрен әбиләре дә, әниләре дә, этиләре дә чиратлашып укыган. Изге Коръәннән сүрәләр, догалар өйрәткәннәр, төрле гыйбрәтле хәлләр, вакыйгалар сөйләп, балаларга ничек итеп тәртипле, әхлаклы, иманлы, намуслы-вөҗданлы, гадел, тырыш, эшчән, ярдәмчел булып яшәргә кирәклеген төшендергәннәр.

Әти-әниләре бик кунакчыл кешеләр булганлыктан, Әнвәрләргә тирә-күрше апалар, әбиләр еш кына кич утырырга кергән. Алар сугышта һәлак булган яисә хәбәрсез югалган газиз ирләрен, улларын сагынып, кайгырышып, бергәләп елашып утырганнар. Шул ук вакытта кемдер ямау ямаган, кемдер оекбаш, бияләй бәйләгән, кемдер исә юкәдән чабата үргән. Шул арада берәве үзенең осталыгын күрсәтеп ала – мөнәҗәтен, бәетен әйтә, икенчесе халык җырларын җырлый, өченчесе экияттер-мәзәктер сөйли. Вакыты булып, өйдә туры килгән чагында, өй хуҗасы Нәҗибулла абзый да моңлы һәм матур тавышы белән борынгы татар халык җырларын сузып җибәрә торган булган.

Әлеге кич утырулар бүрәнә ярыгына кыстырып куелган чыра уты яктысы астында барган. Рафик абыйсы белән Әнвәрнең көндәлек эшләре, әлбәттә, бер кочак утынны чыра итеп нечкә телемнәргә телеп, шуларны мич башында киптерү һәм, кич утырганда янып барган чыраның күмерле башын сулы савытка коеп төшереп, чираттагы яңа чыраны бүрәнә ярыгына кыстырып куюдан гыйбарәт була...

Менә шуларны күреп, тыңлап үскән Әнвәр 1954-1962 елларда Шәрбән сигезьеллык мәктәбендә белем ала. Бишенче сыйныфка җиткәндә, авыл һәм мәктәп китапханәләрендәге барча китапны укып бетерә. Дүрт ел рәттән җәйге каникуллар вакытында ат көтүе көтә. Бер ел (1962 елның көзеннән 1963 елның көзенә кадәр) Аксубай урман хуҗалыгында өлкәннәр белән иңгә-иң торып урман кисә. 1963-1966 елларда исә туган авылында – «Большевик» күмәк хуҗалыгында тракторчы һәм комбайнчы ярдәмчесе булып эшли. Шул ук елларда ул күрше Октябрь (хәзерге Нурлат) районының Колбай Мораса (мәшһүребез Г.Кариевның туган авылы) мәктәбендә укый. Әнвәр әзиебез әйтүенчә, «әдәбиятка һәм тарихка мәхәббәте шушы мәктәптә укыганда уяна».

1966 елда, китап белән шыплап тулган зур фанер чемоданын һәм урын-җир кирәк-ярагы белән дыңгычлап тутырылган арыш капчыгын «өстерәп», Казан дәүләт университетына укырга керергә дип килгән егет, авылдан вакытында паспорт ала алмавы сәбәпле этисе Нәҗибулла абый аны бер сарык бәрабәренә көчкә юнәтә, көтмәгәндә-уйламаганда, Казан театр училищесында белем ала башлый.

И аның ул чактагы күргәннәре!.. Кем әйтмешли, бер китап язарлык.

Лаеш шулпасын, юк, үзе әйтүенчә, ябалак шулпасын күп эчәргә туры килә шәкерткә. Әмма бала вакыттан михнәткә, нужага, авыр эшкә пешеп үскән тырыш, эшчән, үзсүзле-үҗәт һәм сабыр-түзем авыл егетенә шәһәрнең әлеге кырыс сынаулары романтика гына булып тоела.

Имтиханнар биреп йөргәндә үк, Әнвәрнең кунар урыны булмый. Училищега якын гына булган Щапов бакчасы йортсыз-җирсез авыл егетен үзенә сыендыра. Әүвәл, коры һәм җылы вакытта, караңгы төшкәч, ул куаклар астына гәзитләр җәеп йоклый. Яңгырлар ешайгач, биек агач башына үрмәләп менеп, ботакка атланып, агач кәүсәсен кочаклап йокларга өйрәнә. Суыклар башлангач, Әнвәр шул тирәдәге зур өйләрнең подъездларына, подвалларына, чормаларына кереп төн уздыра. Мәрхәмәтсез кешеләр аны, әлеге җылы урыннардан да мәхрүм итеп, урамга куып чыгара. Ничарадан – бичара егет, чиратлаштырып, әле елга портында, әле тимер юл вокзалында яисә автовокзалда кунып йөрергә мәҗбүр була. Ләкин анда да аны җылы кочак белән көтеп торучы булмый...

Атнасына ике тапкыр гына ашарга гадәтләнгән Әнвәр беркөнне төнлә бер эскәмиядә йоклап китә. Өстән туктаусыз карлы яңгыр ява. Шуны сизмичә изрәп йоклап яткан Әнвәр кинәт гөрселдәп юеш җиргә килеп төшә. Күзен ачкач, ул үзен өч исерек егет уратып алганын күрә. Берсенең кулында пычак сыман нәрсә шәйләнә. Шактый вакыт әүмәкләшә торгач, Әнвәрнең йөрәге турысыннан өстәрәк өлеше авыртып куя. Явызлар тырнагыннан көчкә ычкынып, бар көченә йөгереп китә ул. Бераз баргач, бөтен тәне буйлап кан акканын сизеп, кулын куеп караса, шактый зур җәрәхәт күреп ала. Егетнең бәхетенә, пычак эчкә үтмичә, шактый тирән булып буйга кергән була. «Үзең тәртипсезләнеп, сугышып йөргәнсең», дип, укуыннан куып чыгаруларыннан куркып, җәрәхәте турында бергә укыган якын иптәшенә дә белгертми. Ярасын, тоз сөртеп, ике атна эчендә төзәткән Әнвәр аның ничек әрнүен һәм авыртуга ничек түзүен үзе генә белә...

Әмма, шундый авырлыкларга карамастан, әти-әнисен тынычландырып, «минем өчен борчылмагыз, барысы да яхшы», дип, авылга хат арты хат яудыра Әнвәр...

Башка бер кунар урыны да калмагач, үҗәт егет Казанның Яңа Татар бистәсе зиратына – Тукайлар, Әмирханнар, Мәрҗаниләр... «янына» юл тота. Шул чакта күргән-кичкәннәрен исенә төшереп, Әнвәр әзи болай дип сөйләгән иде: *«Чардуганнар эчендәге куе ябалдашлы агачларга аркамны терәп, кабер ташларына утырып төн чыгам. Туңудан, зиратны яңгыратып ютәллим, үзем бертуктаусыз селкенәм. Торып, бер урында сикергәләп алам да янә ташка утырам. Кайвакыт озаграк утырсам,*

*чалбарым һәм костюм чабуым бозланып ташка ябышып каткан була иде. Иртә белән, кеше-кара күргәләгәнче, зираттан чыгып китәм. Өч тиен дә акчам булмаганлыктан, ун тукталыш арасын йөгереп үтеп, тәмам җылынып, тирләп-пешеп, дәрескә барып керәм. Шулай өч ай Казанның михнәт-газап казанында кайнагач кына, кечкенә бер фатирга урнашу насыйп булды...»*

...Фатирга урнашкач, аның тормышында яңа этап башлана: һәр атна саен, ял көннәрендә, өч кеше берләшеп, вагоннардан алтмышар тонна (һәр тонна өчен Әнвәргә бер сум акча түлиләр) күмер яисә цемент бушата ул, кичләрен исә театрларыбызда куелган спектакльләрдә «халык массасы» булып катнаша. Ул вакытта театр училищесында татар теле һәм әдәбиятын Вахит ага Хаков Казан дәүләт университетыннан килеп укытып йөри. Мөгаллим-остаз, дәресен тәмамлаган саен: «Энем, башың эшли, син фән кешесе булырга тиеш, әйдә, университетка укырга күч!» – дип әйтә торгач, Әнвәр, документларын алып, әлеге уку йортына китә һәм, имтиханнарын уңышлы тапшырып, тарих-филология факультетына укырга керә. Аны 1973 елда тәмамлаган егет чын-чынлап фән дөньясына чума.

Хезмәт юлын 1969 елда Казан шәһәрендәге 80 нче мәктәптә гарәп теле укытучысы ул анда 1974 елның маена кадәр эшли һәм Татарстан дәүләт музеенда борынгы кулъязмалар буенча фәнни хезмәткәр булып башлаган Әнвәрнең шул ук ел ахырында матбугатта тәүге язмасы дөнья күрә.

Төрки телдә (гарәп, фарсы, төрек һ.б.) теләсә кайсы гасырда язылган һәм басылган китапларны укый белүче һәм тәрҗемә итүче яшь белгечнең исеме фән даирәсендә бик тиз таралып өлгерә...


Озын сүзнең кыскасы, фәнни иҗат эшчәнлегенә кадәр төрле кыенлыклар күргән, аннан соң да тормышның төрле сынауларын кичкән, төрле елларда, әйтик, 1991-1995 елларда – «Мирас» журналы редакциясендә, 1996 елдан башлап Татарстан Милли китапханәсендә эшләгән, бер үк вакытта Казанның дистәгә якын югары уку йортында гарәп һәм иске татар теле, татар рухи мәдәнияте, ислам дине, халык педагогикасы һәм медицинасы тарихын укыткан Әнвәр Нәҗибулла улы Хәйруллинның олуг галим, текстолог, исламият белгече һәм тәрҗемәче булып танылуында, әлбәттә, аның түбәндәге саллы хезмәтләренең өлеше бинаһая зур: болар – Шиһабетдин Мәрҗанинең «Мөстәфадел-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар»ы (1989), Ризаэддин Фәхреддиннең «Болгар вә Казан төрекләре» (1993), шул ук мәшһүрләребезнең хәзерге телгә күчерелгән башка әсәрләреннән «Ислам дине нинди дин?», «Дини вә иҗтимагый мәсьәләләр», «Нәсыйхәт-1», «Нәсыйхәт-2», «Нәсыйхәт-3», «Тәрбияле бала», «Әһле гыяль», «Шәкертлек әдәпләре», «Укыту кагыйдәләре», «Тәрбияле ана», «Тәрбияле хатын», «Гаилә» һәм шулай ук Г.Курсави, К.Насыйри, М.Бигиев, З.Камали, Г.Ибраһимов, М.Йортыши, Г.Сөләйман, Г.Акыш кебек фикер ияләренең аерым әсәрләре, авторның үз хезмәтләре – «Шәһри Бану – Шәрбән кыйссасы» (1996), «Ислам дине бәйрәмнәре» (1996), «Ризаэддин Фәхреддин әсәрләрендә тәрбия-әхлак мәсьәләләре» (2004), «Әхмәд ибне Фадланның 921-922 елларда Болгар дәүләтенә килгәндә язган сәяхәтнамәсе» (татар һәм рус телләрендә, 2013).

Татарстанның һәм Россиянең атказанган мәдәният хезмәткәре (1991, 2008), Татарстанның атказанган фән эшлеклесе (1999), К.Насыйри, Ж.Вәлиди һәм Р.Фәхреддин исемендәге премияләр лауреаты (2004, 2008, 2011), 2005 елдан Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы (тәкъдимнамә бирүчеләр – М.Госманов, Р.Вәлиев, Ф.Баттал). Әнвәр Нәҗибулла улы Хәйри 2014 елның 20 июлендә кинәт вафат булды.

Үз гомерендә 800гә якын мәкалә язган, туксанга якын китап бастырып чыгарган могтәбәр шәхесебезнең тормышы вә фәнни иҗаты кичекмәстән тирәнтен өйрәнелер һәм аның турында да җитди хезмәтләр язылыр әле дигән изге өметтә калам.

**Ләбиб ЛЕРОН**

# КАЛӘМ БЕРГӘЛЕКТӘ КӨЧЛЕ




Инде беркем инкарь итмәс, безнең бүгенге күпкырлы иҗтимагый тормышны социаль институтлардан башка күзаллап булмый. Алар ил-көн яшәешен тиешле рәвештә җайга салуда, кешеләр эшчәнлеген көйләүдә бәһаләп бетергесез әһәмияткә ия. Мәгыйшәт кылу тәртибен ныгыткан мондый ысуллар үрнәге алга китешнең нәтиҗәлелек дәрәҗәсен дә ачык күрсәтә. Социаль институтлар исә байтак максатларны колачлый: икътисади, сәяси, мәдәни, тәрбияви... Зур сынаулар кичкән Язучылар оешмасы да, һичшиксез, шул төрдәге мәгълүм төзелмәләрнең берсенә керә.

Чыннан да, әле 1934 елда СССР Язучылар союзы төзелгәндә үк, аңа идеологик вазифа йөкләнәчәге шактый алдан сиздереп куела. ВКП(б) Үзәк Комитетының махсус карары чыгу (1932 ел, 23 апрель) бу мәсьәләнең игътибар үзәгендә торганлыгын раслый. Каләм әһелләре бергәлеген җәмгыятьнең социаль җигемендә күрү табигый дә, чөнки әдәбият дәүләт кайгыртуындагы әхлакый тәрбия эшеннән читләшә алмый. Сәнгать әдәп җирлеген ашлый, күңел галәменә сафлык өрә. Монысы бәхәссез. Совет чорында язучыларның «кеше рухы инженерлары» дип аталуы, аларга карата үзгәрәк мөгамәлә күрсәтү тикмәгә генә түгел. Гыйбрәтле тәҗрибә киңәш биргәнчә, кемнәргәдер йогынты ясаучыга үзегез йогынты ясагыз. Мондый әмәл электән килә. Әлбәттә, хакимият әдипләрдән халык мәнфәгатьләренә туры килмәгән максатларда файдаланырга да, еш кына аларны җитәкчелекнең күндәм хезмәтчесенә әверелдерергә дә тырышкан. Төрлечә эзәрлекләүләр дә хәтер елъязмасында саклана. Боларына әле киңрәк тукталырбыз. Һичнәрсәгә карамастан, кешелекнең намусы саналган чын язучылар үзләренең төп юнәлешеннән барыбер тайпылмады.

Җәмгыять тормышының мөһим атрибутын горуранә гәүдәләндергән Язучылар оешмасы да үз тарихының теләсә кайда чәчелеп яткан мәгълүматын барларга тиештер. Ул моңа бик лаек. Милләт гаме белән янучы әдипләрне берләштергән әлеге союзны халкыбызның насыйп язмышыннан берничек тә аерырга мөмкин түгел. Алар инде сигез дистә елдан артык үзара береккән уртак максатларга хезмәт итә. Гыйбрәт алырдай бердәмлек. Әмма бездә гасыр буена нәтиҗәле эшләп килгән социаль институтларның аерым структуралары, әйтик, илдәге иҗат берлекләренең үткән юлын өйрәнү төрле сәбәпләр аркасында үзагымга куелган. Дөрес, әледән-әле чыккалап торган махсус басмаларда ошбу тема өлешчә искә алына. Мәсәлән, 1917-1973 елларны иңләгән татар совет әдәбияты елъязмасында *(«Әдәбият баскычлары», Татарстан китап нәшрияты, 1976)* республика Язучылар союзы эшчәнлеге дә яктыртып узыла. Шулай ук «Татар әдәбияты тарихы»ның озак вакыт аралыгында дөнья күргән алты томлыгында да шушы оешмага кергән каләм ияләренең күмәк рәвештә башкарылган гамәлләре азмы-күпме мәгълүмати чагылыш тапкан. Бу мәсьәләгә берникадәр кагылышлы бүтәнрәк китаплар да бар. Әдәби хәрәкәтнең үзәгендә кайнаган берлек турындагы кайбер белешмәне көндәлек матбугатта басылган мәкалә яки истәлекләрдә табарга

мөмкин. Кызыклы расламалар теркәлгән хәтсез язмалар архив мәгарәсенең катлы-катлы киштәләрендә саклана... Аңлавыбызча, Язучылар оешмасы хакында ниндидер хезмәт әзерләр өчен, әүвәл тау-тау материалдан кирәкле мәгълүматлар туплау сорала. Максатчан эзләнүләр исә алай җиңелдән бирелми.

Зарурлыгы күренеп торган андый басма, ниһаять, киң җәмәгатьчелекнең даими кулланышына тапшырылды. Исеме бик анык куелган – әллә кайдан аңлап алырлык: «Татарстан Язучылар берлеге». Эчтәге титул битендә «Әдипләр берлеге» дип тә өстәлгән. Китапның авторы – Татарстанның халык шагыйре Равил Фәйзуллин. Ошбу үзенчәлекле хезмәттә публицистик уйланулар, тарихи фактлар, хатирә-күзәтүләр композицион бөтенлектә бирелгән. Анда тарихи әһәмияткә ия сирәк фоторәсемнәргә дә, безгә чагыштырмача якынрак чорларда төшерелгән сурәтләргә дә, кыйммәтле саналырлык документларның күчермәләренә дә урын табылган. Кереш сүз рәвешендә язылган «Чор таләбе» исемле мәкаләдә укучы өйрәнү юнәлешләре белән инде таныша да башлый. «Бу китап, нигездә, Татарстан Язучылар оешмасының үткән юлы турында, – диелә башлам өлешендә. – Иҗат союзлары соңгы бер гасырга якын вакыт аралыгында әдәбият һәм сәнгать үсешенә йогынты ясаучы мөһим фактор булды... Алар нинди максат белән төзелгән дә, нинди идеалга һәм нинди даирәгә хезмәт иткән? Профессионаллар берләшмәсен күздә тотсак, мәдәният, шул исәпкә язучылар да кергән аерым үзәк профсоюз системасы бар иде. Иҗат союзларының, бигрәк тә Язучылар берлегенең социаль функциясе бүтәнрәк, чынлыкта ул киңрәк һәм тирәнрәк. Аны аңлау, асылына төшенү өчен, объектны, мотлак, шул иҗтимагый чор идеологиясе аша карап анализлау мөһим. Чишмә чыганагын, тора-бара шуңа кушылган башка кизләү-инешләрне белсәң генә, елга-дәрьяның зурлыгын, аның агышындагы көч-куәтне чамалый аласың».

Аң-зиһенебезгә сеңдерелгәнчә, аерым билгеләрне чагылдырган иҗат төшенчәсенә мөстәкыйльлек мәгънәсе шактый мул салынган. Әйләнештә йөргән төрле аңлатмаларда да аның әлеге үзлегенә басым ясала. Сәнгатькә бәйле эшчәнлек, әйе, үзбаш алып барыла. Күпләр кистереп әйткәнчә, иҗатта бер баш яхшы, икенчесе кирәк тә түгел. Вәләкин адәм баласының табигатендә бергәлек хисе дә җитәрлек. Гомумән, кеше бары берләшеп яшәгән очракта гына үз тормышын һәрьяклап тәэмин итәргә мөмкин. Борынгы кытай философлары да шул хакта ассызыклап искәрткән. Бу дөньяда «мин» алмашлыгы аңлаткан мәгънәгә дә, шулай ук «без» төшенчәсенә дә урын бар. Гомер сөрүнең мондый хасияте, әлбәттә, әдипләргә дә бердәй кагыла. Газиз халкыңның чын хадиме булу өчен әсәр арты әсәр язу гына җитми. Милләтнең каләм әһелләре кайгыртуындагы көнүзәк мәсьәләләре, аларга йөкләтелгән җәмәгать эшләре санап бетергесез. Мәшһүр Бальзак язучыны үзенчә зурлап, аны хәтта «дәүләт кешесе»нә тиңләгән. Мондый өстәмә җаваплылык гомуми ихтыяҗдан килә. Шулар өстенә әдәби иҗат белән шөгыльләнүчеләр бердәмлекнең бихисап мөмкинлекләреннән дә файдаланырга тиеш. Бу җәһәттән Равил Фәйзуллинның игътибар үзәгенә алынган әлеге китабында Татарстан Язучылар оешмасы төзелү тарихы тулы эзлеклелектә яктыртылыш таба. Беренчел сәбәпләр дә бик тәфсилләп шәрехләнә. «Бөек әсәрләрне – шигырьме, көйме, рәсемме – талантлы шәхес ялгызлыкта, дөнья белән бергә-бер калып, серле тынлыкта иҗат иткән, – дип үзенчә раслый шагыйрь. – Үзалдыңа илһамланырга мөмкин, әмма ялгызың гына яшәп, тормыш кичереп булмый». Сүз дә юк, дәүләт ярдәмендә берләшү идеясе туганчы да каләм осталары үзара аралашу юлларын эзләгән. Аларны аерым әдәби агымнар да, уй-фикерләр уртаклыгын сиздерткән төркемнәр дә, кайнап торган мәдәни үзәкләр дә, милли әдәбиятка мөнәсәбәтле җәмгыятьләр дә, рәсмиләштерелгән ассоциацияләр дә үзләренә тарткан. Монография таләпләре югарылыгында башкарылган хезмәттә боларның барысы хакында да аңлатыла. Шул рәвешле, автор әдипләрне берләшүгә этәргән иҗтимагый зарурлыкка төрле яклап ачыклык кертә, озак елларга исәпләнеп корылган социаль институт структурасының җирлегендәге тарихи алшартларны күрсәтеп бирә. Урыннарда охшаш үрнәкләре барлыкка киләчәк СССР Язучылар союзы ничек төзелгән, аның алдына устав кысаларына сыймаган тагын нинди астарлы максатлар куелган? Файдаланыр өчен бик уңайлы

тәртиптә эшләнгән әлеге китапта бик күпләрне кызыксындырган андый сорауларга төпле җавап бирелгән.

Таләпчән укучы шикләнмәсен, алдагы битендә урнаштырылган кыскача белешмәдә беркадәр чуаррак мәгълүмат күрсәтелсә дә, бу җитди басма эчке бөтенлекне тәэмин итәр тотрыклы композициягә корылган. Төрле материалларның үзара ярашуы, әлбәттә, эзлекле фикер йөртүдән килә. Язуда мондый бәйләнешлелеккә ирешү өчен, ныклы кызыл җепләрнең булуы кирәк. Ә аерым оешманың узган юлын яктыртканда, кабатланып торган ниндидер күрсәткечләрне ачыклау шарт. Эзләнүчән Равил Фәйзуллин маяктай тезелеп киткән билге-укларны тапкан – алар Язучылар союзы тарафыннан үткәрелеп килгән корылтайлардан гыйбарәт. Гамәлдәге кануннар нигезендә төзелгән мондый җәмгать оешмасында съезд аның югары идарә органы булып санала. Гадәттә, әлеге зур җыенда иҗат берлегенең билгеләнгән вакыт аралыгындагы эшчәнлегенә хисап бирелә, төрле әдәби жанрлар буенча тәҗрибәле каләм ияләре әзерләгән этрафлы докладлар тыңлана, халык тормышының рухи-мәдәни өлкәсендә килеп туган көнүзәк мәсьәләләр уртага салып тикшерелә, иҗтимагый яшәештә гаять әһәмиятле урын тоткан әдәбиятның өстенлекле үсеш юнәлешләре билгеләнә... Саный китсәң, алар шактый. Еш кына мондый корылтайларның дәрәҗәле мөнбәреннән ил-дәүләт җитәкчелеге вәкилләре дә чыгыш ясый. Менә шулай эшлекле төстә уздырылган җыеннарның стенограммаларын укып та, сүз сәнгате үзәгендә торган оешма турында күпне аңларга мөмкин. Әмма болар белән генә чикләнгән очракта безгә кирәкле тарих тулы булмас иде. Язучылар союзының көндәлек эшләре әдәби хәрәкәт мәшәкатьләреннән аерылгысыз. Ә Равил Фәйзуллин моны иҗат тәҗрибәсе аша белә. Шуңа күрә ул дөрес юл сайлый. Сиксән еллык чамасындагы дәвер дүрт вакыт аралыгына бүленә: 1934-1945, 1945-1960, 1960-1990, 1990-2016 еллар... Әйе, аның китабында әлеге дә баягы съездлар шартлы ориентир итеп алына, ләкин шушы вакыйгалар тезмәсенә укучының аң-зиһенен баетырлык күптән-күп мәгълүмат өстәлә. Алай гына түгел, шагыйрьнең аерым чорлардагы гайре табигый сәяси вазгыятькә үзенең гадел мөнәсәбәтен белдереп баруы, кайбер рухи-әхлакый кыйммәтләр хакында гамьле аксакалларча уйланып алуы хезмәтнең бәясен бермә-бер арттыра.

Төртмә теллеләр тәкрарларга яратканча, тикшерелә торган мәсьәләләр һәркемгә аңлаешлы икән, җыен бик озак дәвам итәргә мөмкин. Ошбу кинаяле раслама әдәбият тормышының фарызына әверелгән корылтайларга, аерым алганда, Совет язучыларының I Бөтенсоюз съездына һичничек туры килми. Тарихи әһәмияте ягыннан тиңдәшсез саналырлык әлеге чара (1934 ел, 17 август) СССР башкаласындагы Союзлар йортының Колонналы залында ачыла. Күпләр гаҗәпләнеп куяр: корылтай 16 көннән (!) соң, 1 сентябрьдә генә тәгаллләнә. Аның болай сузылуын җиңел аңлатырга була. Беренче тапкыр үткәрелгән оештыру съездына берсеннән-берсе мөһимрәк хәтсез бурыч йөкләнә. Күптөрле кануни документлар кабул итәргә, өр-яңа тәҗрибәгә нигез салырга кирәк. Җыенның дәрәҗәсе ифрат югары. Анда 52 милләттән 591 делегат, чит илләрдән 40 язучы катнашкан. Котлаулар, докладлар, чыгышлар... Сүз әйтергә сусаганлыкны чагылдырган корылтайда исә 300дән артык кеше нотык тота. Теркәп барылган стенограмма гына да 50 басма табаклык тупламны хәтерләтә. Фикри үстерелеш нигезенә ятарлык мондый гыйбрәтле мәгълүмат Равил Фәйзуллинның тәфтишләп язылган хезмәтендә күпләп китерелә. Теләсә кайда чәчелеп яткан мөһим фактлар тематик уртаклык буенча затлы җепләргә тезелгән. Һәммәсе дә җиңел үзләштерелә.

Совет язучыларының беренче съездына киңрәк тукталып үтәсе килә. Китап авторы әлеге вакыйгага багышланган бүлекне тикмәгә генә «Тарихи җыен» дип атамаган. Аның әһәмияте нидән гыйбарәт? Әдәби хәрәкәттә мондый структураның барлыкка килүе, белгәнебезчә, турыдан-туры Максим Горький исеме белән бәйле. Берлек идеясен ул күтәреп чыга, корылтайның оештыру комитетын ул җитәкли, Бөтенсоюз съездын ул ачып җибәрә, төп докладны да ул ясый. Бу заманда аныкы кебек олпатлык таҗы, тере классиклык дәрәҗәсе кемдә булды икән?! Шушы урында безне, әлбәттә, бер сорау борчый: күп милләтле илнең каләм әһелләрен җыйган тәүге съездда гасырларны колачлаган татар әдәбияты нинди исәпкә кертелгән соң? Шул ук Максим Горький

чыгышында моңа ачык җавап бирелә – анда халкыбызның язма мирасы беренче «милли бишлек»тә тәкъдир ителә. Үзебезнең Казанда «тормыш университетлары»н үткән әдип татарларны әллә ничә тапкыр искә ала, хәтта безнең язучыбыз әйткән сүзләрне докладтагы фикри нәтиҗәләрнең берсен ныгыту өчен файдалана, менә шундый кайгыртучан мөнәсәбәте аша тирән тамырлы мәдәниятебезнең мөмкинлекләренә ихлас ышануын күрсәтә. «Үзебезнең күбрәк булуга карап кына милли азчылыкның әдәби иҗатын игътибарсыз калдырырга хакыбыз юк, – ди Алексей Максимович, этник тигезлекне яклап. – Мәдәни кыйммәтләр сан ягыннан түгел, ә сыйфат белән үлчәнә. Әгәр безнең үткәндә Пушкин зур кыядай калкып тора икән, бу әле әрмәннәр, грузиннар, татарлар, украиннар һәм башка кавемнәр әдәбият, музыка, сынлы сәнгать, архитектура өлкәләрендә бөек осталарны бирергә сәләтсез дигән сүз түгел».

Аңлашыла ки, Совет язучыларының I Бөтенсоюз съездында безнең әдипләр илтифаттан мәхрүм ителми. Чынлыкта, милли сүз сәнгатебез әйдәп баручылар исемлегенә кертелгән. Өйрәнүче вазифасындагы Равил Фәйзуллин үзенең китабында искәртеп үткәнчә, «...съездда милли әдәбиятлар буенча украин һәм белорус вәкилләреннән соң өченче итеп сүз Татарстан Язучылар союзы рәисе Кави Нәҗмигә бирелә, һәм ул татар әдәбиятының торышы турында зур доклад белән чыгыш ясый. Грузин, әрмән, азәрбайҗан, үзбәк, төрекмән, таҗикларның чираты арттарак була. Гомумән, милли әдәбиятлар буенча махсус рәвештә нибары 9 доклад ясала». Шунысы да бик гыйбрәтле: ошбу мәртәбәле корылтай утырышларының берсендә Кәрим Тинчурин да нотык сөйли. Партиясез делегат сыйфатында. Әлеге чыгыш хакында күпләр хәбәрдар түгел. Әлбәттә, хезмәт авторы аны эзләп табуга ирешә. Белергә тырышкан укучы ниләр әйтелгәнен аңлар – китапта драматургның фикерләре кыскача бәян ителгән. Анда игътибардан читтәрәк торган чыгыш кулъязмасының күчермәсен дә, съездга барган делегатларыбызның күмәк фотосурәтләрен дә күрә алабыз.

Мантыйк кагыйдәләрен саклаучы затлар шундый сорау бирергә мөмкин: ә республикабыз язучылары съезды төгәл кайчан үткәрелә соң? Сүз сөрешенең тәртибе чүт-чүт бозылды күк. Бераз сәеррәк тоелса да, урыннарда корылтай алданрак уздырыла. Безнеке 1934 елның 25 июлендә Татар академия театры бинасында башлана, рәсми рәвештә әйткәндә, әлеге җыен Совет язучыларының I Бөтен Татарстан съезды дип атала. Аннары аның эше Мәгариф хезмәткәрләре йортында дәвам иттерелә, чыгышлар һәм оештыру мәшәкатьләре 29 июльдә генә төгәлләнә. Шул чорларга хас үтә тантаналы рух. Вакыт мул бирелә. Беренче съезд күренекле язучы Кави Нәҗминең кереш сүзе белән ачыла, оештыру комитеты рәисе Гаяз Ризванов докладны өч сәгатьтән артыкка сузыла. Көннәр буена чыгышлар тыңлана. Соңыннан Татарстан Язучылар союзының 9 кешедән торган идарәсе сайлана, шулай ук Бөтенсоюз съездына 12 делегат җибәрергә карар кылына... Иҗат белән шөгыльләнүчеләрнең һөнәрдәшлек нигезендәге бәйләнешен рәсми беркетү эше яңа социалистик җәмгыять корган илдә менә ничек җанланып китә. Дөресен әйтергә кирәктер, бу елларда әлеге максатка омтылыш әдәби җәмәгатьчелектә шактый көчле булган. Эчке ихтыяҗны чагылдырган ихтыярда ашыктыру галәмәте дә сизелә. Татар-башкорт шагыйре Шәехзадә Бабичның чакыру рәвешендә әйтелгән сүзләрендәгечә, «Хакыңны ал хөр чакта, берләшеп кал форсатта!..» Мондый иҗат берләшмәләрен киләчәктә ни көтә? Моңарчы күрелмәгән чынбарлыкка язучылар ничек күнегер? Сорауларны Равил Фәйзуллин китабындагыча дәвам иткәндә, «Алдагы 10-15 елда нинди әсәрләр язарлар да, үзләренә нинди язмыш язылыр?..» Иртәгә нәрсә буласын сорама, дип кисәткән борынгы римлылар. Әмма шушы вакыйга үзәгендә әвәрә килгән каләм ияләре әдәбият тормышындагы тарихи үзгәрешләрне башлыча яхшы гамәлгә юраган. Һәрхәлдә, киләчәк барысын да үз тәртибенә кертәчәк.

Исәбең дөрес булсын, дип өйрәтә халкыбыз. Иҗат әһелләрен берләштерү идеясен гамәлгә ашыру, билгеле, унитар дәүләткә хас мәҗбүрияттән генә тормаган. Ул күптәннән килә. Еракта калган кадим заманнарда да уртак мәнфәгатьләр буенча аерымлану күзәтелгән. Барлык акыллы кешеләргә үзара бәйләнештә эш итү лазем – әнә шундый эрелек катыш таләп куючылар да табылган. Ошбу зирәк затлар төркеменә, шәт, язучылар да керәдер инде. Мәдәният белгече Борис Парамонов та үзенчә хаклы:

«Әдәбият безнең илдә күмәк невроз сыман күзаллана». Гаммәви авыру хакында, әйе, шактый образлы әйтелгән. Әмма иңгә-иң иҗтиһат кылырга омтылу шәхси тормыштагы иҗтимагый башлангычның көчәюеннән, кулына каләм алган затның үзеннән-үзе җәмгыятьче вазифасына керешүеннән киләдер. Ә совет заманында аерым хуҗалык булып яшәү, олуг максатларга ялгыз ирешү мөмкин түгел иде.

Сүз дә юк, әдипләрнең халыкка гаять зур дан-шөһрәт китерүен дәүләт хакимиятенең фәһемле катламы тирәнтен аңлый. Шуңа күрә Октябрь инкыйлабы юлбашчысы да талантларны кадерләргә, аларга саклык белән даими рәвештә ярдәм күрсәтергә чакыра. Җитәкчеләр кабатларга яратканча, уңайлы иҗтимагый шартлар тудырылган очракта сәләтле шәхесләр һәркайда калкып чыгучан. Чыннан да шулай. Кемдер төрттереп әйтмешли, иҗатка мәхәббәт матди яктан баетмаса да, бу дөньяда күпләр әдәби эшчәнлеккә тартыла. Шушындый көчтән нигә файдаланмаска! Алар җәмгыять үсешенә йогынты ясарга тиеш. Һәм әле «бозылырга» өлгермәгән совет хакимияте язучылык хезмәтенә тиешле мөмкинлекләрне ача да. Гаделлек йөзеннән хәтергә төшерик. Илдә колач җәйгән культура революциясенең беренче казанышлары, әлбәттә, әдәбиятның җанланышына да бәрәкәтле җирлек барлыкка китерә. Нәшрият эшчәнлегенең моңарчы күрелмәгән дәрәҗәдә күтәрелеш алуы иҗатның нәтиҗәлелеген арттыруга аеруча куәтле этәргеч биргән. Язучы белән укучы арасын якынайту галиҗәнап китапның тормыштагы урынын ныгыта. Чынлыкта ул мәдәниятнең нигез ташына, өстәп әйтсәк, идеологик төзелешнең мөһим өлешенә әверелә. Ә үзгәрешләр бөтенесен иңли, чөнки сәнгать күпкырлы бит. Шагыйрь Равил Фәйзуллин ап-ачык төстә аңлатканча, «Язучы икәнсең – әсәреңне китап итеп чыгарасы, кешеләргә ирештерәсе килә, рәссам икәнсең – эшләреңне җыеп, күргәзмә ясап күрсәтәсе, артист икәнсең, сәхнәдә шаулатып уйныйсы килә... Еллар хроникасына күз салсаң, татар җәмәгатьчелеге өчен күңел булырлык гамәлләр кылына башлый. Ниндидер стимул бар!»

Яңа җәмгыять хакимиятенең прәннек өләшүе озакка сузылмый – күпләрнең башын кыячак зәһәрле камчылар эшкә керешә. Канлы репрессия сәгате суга. Тикшерелә торган китапта күрсәтелгәнчә, тәүге съезд докладларында макталган язучыларның яртысыннан күбрәге беркайчан да акланмаслык мәгънәсез залимлек корбанына әверелә. Безнең ише тырыш халыкта арттырып үтәү гадәте бар: яхшысын да, яманын да. Казанда Октябрь кораллы күтәрелешен дә Пётр каласыннан алданрак әзерләргә өлгергәннәр. Каләм ияләрен эзәрлекләү дә бездә иртәрәк башланып киткән. Әйтик, Гадел Кутуй, Нәкый Исәнбәт кебек әдипләр тарихи съездда катнаша алмый, чөнки алар уйдырма «җидегәнчелек»тә гаепләнү аркасында әдәби хәрәкәттән бөтенләй читләштерелә. Беркадәр тукталыбрак әйткәндә, артык төпченмичә, яшерен оешма төзүче итеп «билгеләнгән» Гадел Кутуй илкүләм золымның һөҗүмнәрен язучылар арасында беренчеләрдән булып кабул итә. Гаепсезгә 10 ай төрмәдә утыру аның гомерлек кара сакалына әйләнә. Һәртөрле нахак каныгуларны аңарчы Һади Такташ та байтак кичерә, әдәбият тормышындагы үзгәрешләрне күрмичә, утыз яшьлек шагыйрь «үз үлеме» белән дөньядан китеп котыла. Күрәсең, тәкъдир каләме аны аяган – репрессиягә кадәр китереп җиткермәгән.

Кирәгеннән артык хисләнеп язылган тәкъбиргә, иртәме-соңмы, ташламасыз вакыт тарафыннан төзәтмә кертелә. Фикри образ өчен, янәсе, җәза бирелә алмый. Рәсми вәхшәтлек елларында хаксыз рәвештә «кызыл күлмәк» кидертелгән каләм ияләре җирдәге тормышка салават күпереннән карап әйтелгән әлеге сүзләрне расларммы икән?! Сталин заманында ирекле шигырь дә үзен хокуксыз итеп тойгандыр шикелле. Кызганыч, шулай фикер йөртер өчен, кире кагылгысыз җирлек бар. Дәлилләр дә бик ишле. Җәберле тарихыбызга тартылган Равил Фәйзуллин репрессияне мәгълүм шәхесләргә бәйләп күрсәтә. «Ил тарихының шомлы 1937-1938 еллары. Аңларга һәм аңлатырга кыен чор, – ди автор гаҗизанә хәлдә. – Язучылар союзын оештырып йөргән яки бу башлангычны күңеле һәм гамәле белән хуплаган байтак әдипләр зинданга озатылган. Әле күптән түгел генә 25 еллык иҗат бәйрәме үткәрелгән Кәрим Тинчуринябылуда, Галимҗан Ибраһимов төрмәдә... Вакыт аралыкларында бераз аерымлык булса да, шул ук язмышка дучар ителгән Ибраһим Салахов, Шамил Усманов, Гомәр Толымбай, Гомәр Гали, Мәхмүт Галәү, Галимҗан Нигъмәти, Фәтхи Бурнаш, Гали

Рәхим, Җамал Вәлиди, Фатих Кәрими, Сәгыйть Сүнчәләй, Фатих Сәйфи-Казанлы, Кави Нәҗми, Фатих Кәрим, Мирсәй Әмир, Мин Шабай, Сөббух Рәфыйков, Ләбиб Гыйльми, Хәсән Туфан... Исемлекне дәвам иттерергә мөмкин. Кайсылары юкка чыгарылган, кайсылары алтын гомерләре мәхбүслектә үткәч кенә кайта алган, кайсылары фәлән ай гына утырып куркытылган, кушканны күндәм үтәүчеләр сафына баскан...»

Иреген җуйган каләм әдипнең авызлыгына әйләнә. Әлбәттә, язучылар арасында чарасызлыкка ихтыярсыздан җайлашып яшәүчеләр дә, хокук чикләнгәнлегенә ризасызлык белдерүчеләр дә байтак булган. Буйсынырга теләмәүчеләрне сындырырга тырышу исә ул чорда җәзалау конвейерына куелган. Менә шундый киеренке шартларда тайпылышсыз иҗат кылып кара! Борынгы һиндлар образлы искәрткәнчә, патшага хезмәт итү кылыч йөзен ялауга, арысланны кочаклауга, еланны үбүгә бәрабәр. Өстәвенә әлеге илбаш залимлеген күрсәтә башласа... Татарның күп язучысы барыбер баш бирмәгән. Йөз төрле җәберләүдән өзлексез интексә дә, кылыч йөзен һичничек яларга теләмәгән мәгърур Шамил Усманов каләмне миенә үтеп керерлек көчтә күзенә китереп кадый. НКВД хезмәткәрләре әйтерсең «уйлап табучылар» булган – алар нинди генә җәзалау алымын кулланмаган: гаепләнүченең башын һичбер сәбәпсез сейф почмагына җенләнеп бәрүләр, кыйнаудан соң хәлдән таеп егылганның өстенә пес итүләр, «дөреслеккә туры килмәгән» беркетмәләрне мәҗбүри төстә тиз-тиз ашатулар... Хөкемдар явызлыгын гәүдәләндерүче арысланны кочаклауга каршы килгән Җамал Вәлиди сорау алу бинасының өченче катындагы ачык тәрәзәсеннән аска сикерә... Тиранлык хөкем сөргән заманда тоткыннар шыплап тутырылган баржаны, ут төртелгән хәлдә, Төньяк диңгездә садистларча күрәләтә батыру әмәле гамәлгә кертелгән. Менә шундый үлем судноларының берсеннән нибары ике кеше исән котыла. Һиндлар ишарәләгән мәрхәмәтсез еланны үбүдән ваз кичкән Фатих Кәрим бозлы суда сөргендәше белән ярга кадәр йөзеп чыгуга ирешә.

Каләм изгегә тартыр – элгәрләребез тәгаен хаклы. Әмма кызыл террор тегермәненең туктаусыз эшләп торуы язучылык хезмәтен шактый куркыныч вазифалар рәтенә кертә. Акыл ирешә алмаслык хәлләр җәһәтеннән мантыйкый төгәл җавап табып булмый. Дәүләт хакимиятенең турыдан-туры катнашы белән илдә иҗат союзы төзелә, шул ук вакытта аның әгъзаларын диктаторларча эзәрлекләү башланып китә. «Чистарту» гына дияр идең... Аяныч расламалар күрсәткәнчә, гаммәви репрессия көчәеп барган елларда Совет язучыларының I съездында катнашкан барлык каләм ияләре дә кулга алына, тора-бара ТАССР Язучылар берлеге идарәсенең өч составы да хәтта газраилнең зиһенен чуалтырлык ачы язмышка дучар ителә. Иксез-чиксез империянең башка төбәкләрендә дә чын талантларны «сирәкләү» галәмәте күзәтелә. Съездлар уздыру ихтыяҗы үзеннән-үзе әһәмиятен югалта. Кәрван артка әйләнсә, аксак алда булыр. Бабаларыбызның зирәкләрчә кисәтеп әйтелгән әлеге нәсыйхәтен Равил Фәйзуллин сүзләре белән дәвам иткәндә, «әдәби фигураларның байтагы кулга алынгач, көчләр таркатылгач, табигый, Союзның нәтиҗәле эшчәнлеге турында сөйләү кыен. Чор таләбе буенча оешма җитәкчелегендә дә яңа «лидерлар» пәйда була: Т.Имаметдинов, И.Вахитов, Х.Җәмил... Бу исемнәрне өлкән буын язучыларның да бик азы гына ишетеп беләдер. Архив хисабында бар саналсалар да, әдәбиятта алар юк». Гаделлек өчен өстәп әйтсәк, югарыда санап үтелгән җитәкчеләрнең берсе әдәбият елъязмасына гына түгел, шагыйрь Хәсән Туфанның мәсхәрәле көлү өслүбендәге дүртьюллыгына да кертелгән. Эпиграмма белән танышыйк. Автор аңа исем куймаган.

*Бар иде заманнар, бар иде,*  
*Без яза башлаган елларда:*  
*Хәбәрче Хан Җәмил хан иде*  
*Бездәге әдәби дөньяда.*

Корбаннарның гаепсезгә түгелгән каны башка афәтне тартып китерүчән. Гөнаһ шомлыгына каршы, репрессия фаҗигасенә ялганып киткән Бөек Ватан сугышында милләтнең алыштыргысыз алтын баганалары янәдән киселә башлый. Дөрес, әлеге кырылыш бөтенләй аерылып тора – монысы илең өчен көрәшеп үлү. Әмма теләсә

нинди очракта халык авыр югалтулар кичерә. Санлы расламаларга күчсәк, 72 мәмләкәтне үзенә тартып керткән олы сугышта җәмгысе 1215 язучы катнашкан, шуларның 460ы Көнбатыш Европагача сузылган дәһшәтле яу кырында мәңгелеккә ятып калган. Орышлар тарихы төрлесен хәтерли. Фронтовик әдибебез Габдрахман Әпсәләмов үзенең истәлегендә бәрелешләрнең берсенә әзерләнүне болай искә төшерә: «Без дошманны корал көченнән битәр, саныбыз белән җиңәргә тиеш булачакбыз». Әйе, шәһитләрнең ишлелегенә ис-акылың китмәле! Халык саны буенча процентлар белән исәпләп карасак, татар әдәбияты күргән зыян зуррак килеп чыга: сугышка киткән 124 язучының 34е туган җирләренә кире әйләнеп кайтмый. 460 һәм 34. Беренчесе – бөтен дөнья күләмендәге корбаннар, икенчесе – безнең милләткә генә караганы. Бүтәнчә ничек күзалларга? Фашистлар Германиясенең Икенче империя суды карары нигезендә «немец рейхының хәрби куәтен какшатулары өчен» 1944 елның 25 августында Муса Җәлил һәм аның көрәштәшләре Плетцензее төрмәсендә җәзалап үтерелә. Нибары 30 минут эчендә гильотина 11 башны кисә. Милләтнең мөбарәк тәсбихендәге мәрҗәннәр шушындый җәһәтлектә юкка чыгарыла. Яшерен оешма әгъзаларының бишесе язу эшчәнлеге белән шөгыльләнгән. Алар арасында балалар әдәбияты классигы Абдулла Алиш та, үз халкының горурлыгын гәүдәләндерүче башка талантлар да була.

Гыйбрәтле батырлык кылып, чын фидакарьлек күрсәтү... Татар әдипләренең Икенче Бөтендөнья сугышында каһарманнарча көрәшүе ватанның героик анналларына аерым бүлек рәвешендә керерлек. Бу уңайдан Равил Фәйзуллинның «Татарстан Язучылар берлеге» дигән китабында да шундый белешмә-кулланманың махсус мәкаләләре нигезенә ятарлык мәгълүматны күпләп табарга мөмкин. Гомумән, әлеге хезмәттә иҗат оешмасының сугыш чорындагы эшчәнлеге дә, милли мәдәниятебез тормышының төрле тәэсирләр тудырган хәл-халәте дә, ил хакимиятенең идеологик гамәлләре дә тәфсилле төстә яктыртыла. Ошбу сәхифәләрне горурланып та, чиксез гаҗәпләнеп тә укыйсың. Татар язучыларының сугышта күрсәткән гаярьлеге инде ничә еллар сокландырудан туктамый. Күз алдына китереп үтик. Җәлилчеләр Берлинда бөтен «Идел-Урал» легионының восстаниесен әзерләсә, Хәйретдин Мөҗәй Мюнхенда әсирләрнең яшерен оешмасын төзешә. Алар да Дахау концлагерен бердәмләшеп баш күтәрүгә хәстәрли... Совет режимының сәяси тоткыннар лагереннан фронтка җибәрелгән Фатих Кәрим, Украина, Белоруссия, Карпатны азат итүдә катнашып, Мәскәү янындагы позициядән Көнчыгыш Пруссиягә кадәр утлы чакрымнар уза. Ике тапкыр яраланган взвод командиры хәлиткеч бәрелешләрнең берсендә һәлак була. Аның иҗаттагы баһадирлыгы да чын мәгънәсендә хәйран итә. Алгы сызыкның гаять хәтәр шартларында шулхәтле әсәр язып кара әле: 100дән артык шигырь, 9 поэма, 2 повесть, 1 пьеса... Икенче Бөтендөнья сугышында шәһит киткән 460 язучы арасында андый күләмдәге фронт мирасы калдырган каләм әһеле юктыр. Гиннесс рекордлар китабына кертерлек... Татар әдипләре шулай көрәшкән. Немецчага күчерелгән «Без – сталинградчылар» нәсере прокламация сыйфатында камалыштагы армиясе өстенә самолёттан яудырылганы өчен Вермахт нәфрәтенә юлыккан Гадел Кутуй Кызыл мәйдандагы Җиңү парадының аллы-гөлле фейерверклары күкне балкытыр чакта Польшаның Згеж шәһәрендәге госпитальдә якты дөнья белән галибанә хушлаша. Мондый гыйбрәтле мисаллар китерүне моңланып дәвам иткәндә, «Европада татар шагыйрьләре» тезмәсе фаҗигале мәгънә ала. Шаккатмалы хәлләр бездә җитәрлек. Сугыш алдыннан озак елга Себергә сөрелгән Хәсән Туфан, яуда үзләренең кыюлыгын раслаган каләмдәшләре сафына басарга теләп, хәрби җайга корылган югары хакимият органнарына үтенеч юллый. «Мин... атып үтерүгә хөкем ителгән идем, – диелә анда. – Илбасарларга каршы аяусыз көрәшкә күтәрелгән халкыңнан читтә торудан да авыррак җәзаның булуы мөмкин түгел... Сездән мине сугышның иң канкойгыч урынына җибәрүегезне, яки миңа үлемнән берничек тә котыла алмаслык эш кушуыгызны, гранаталарга уралып, самурайларның сугышчан машинасы астына ташлану, йә булмаса, торпеданың руль тоткычы сыйфатында, дошман корабленең йөрәгенә бәрелеп шартлау, яисә шуңа охшаш бүтән берәр максатка юнәлешле бурыч бирүегезне сорыйм... Шагыйрь намусы белән ант итәм: сезгә биргән сүземне һичшиксез үтәрмен».

Тикшеренүче вазифасын башкарган Равил Фәйзуллин, сугыштан соңгы сынау

чорын күзаллап, 1945-1960 елларда ил-көн тормышына тотрыклылыкның әйләнеп кайтуын мисалларда ачып күрсәтә. Әлбәттә, җәмгыятьтәге даими ышанычлылык билгеләре китапның IV бүлегендә колачланган вакыт аралыгында да, ягъни үзгәртеп кору дәверен үз эченә алган 1960-1990 елларда да күзәтелә. Дөрестән дә, туплар тынып калгач, музалар телгә килә. Әмма моның өчен үзгә шартлар сорала. Зур афәттән соң халыкның көнкүрешен азмы-күпме җайга салырга мөмкин, мәдәни тормышны җанландырып җибәрү исә күбрәк көч таләп итә. Канлы репрессиянең һәлакәтле базында черетелгән, сугышта кырылган талантлар инде терелми. Ә бит аларны саклау тиеш иде. Безнең хакта мәңгелектән торып кайгыртучы Габдулла Тукай, әнә, теләсә кайсы заман илбашларына яраклы киңәш бирә. «Бездә мөхәррирләр тәмле хыялларга корбан булырга түгел, кирәк эшләремезгә дә аздыр, – дип искәрткән пәйгамбәрдәй зат. – Әгәр... кыйбатлы мөхәррирләремез һәлак булып бетсәләр, дөньяда тик корчаңгы мөхәррирләр генә калачактыр». Күрәбез, ул хөрмәт казанган олуг язучыларның кадерен белергә куша, тик «халыклар атасы» мондый тәкъдимнәргә колак салмаган шул.

Алдарак әйтеп үтелгәнчә, автор аерым иҗат оешмасы тарихына багышланган китабында съездлар үткәрүне ниндидер эзлеклелек факторы итеп саный. Чыннан да, әлеге олы җыеннар тәртибен билгеләүдә тормыштагы тотрыксызлыклар да ачык чагыла. Гәрчә устав буенча корылтайлар өч елга бер уздырылырга тиеш булса да, СССР язучыларының чираттагы II съезды нәкъ 20 елдан соң гына җыела. Безнекеләр бу очракта да өлгерлек күрсәтә – Татарстанда ул 4 елга иртәрәк оештырыла. Шагыйрь Равил Фәйзуллин сүзләрен кабатлап әйткәндә, «үзенчә эшләүче үзәк кушуы беләнме, әллә җирле башлангыч өстенлек иткәнме? Мөгаен, соңгысыдыр». Озак көтеп алынган ошбу вакыйга 1950 елның 13-15 июнендә була. Съезд барган залда элекке олпат әдипләр, берләшүдә башлап йөргәннәрнең байтагы күренми инде. Күптармаклы сәнгать дөньясын кумәклек гәүдәләнеше – биниһая олы остаханә итеп күрүчеләр бар. Әгәр шулай икән, безнең каләм әһелләре цехындагы буш урыннар кырыгынчы еллар ахырында күзгә бәрелеп торган. Бер-бер артлы ябырылган ике һәлакәт югалтулары, һичшиксез, әдәбият үсешенә дә кире йогынты ясаган. Нишлисең, нәкъ менә шушы чорда саллы әсәрләргә кытлык сизелү күпне кичергән зур биографияле язучыларның кимүенә турыдан-туры бәйле. Шөкер, татар халкының генофондында яңарыш омтылышы көчле. Милли әдәбиятыбызның чын талантларга байый башлавы икенче корылтайда да шактый ачык тоемлана. Мәдәни яшәешкә рух-дәрт кайта. Әлеге дә баягы китапта дикъкатьле төстә билгеләп үтелгәнчә, «...съездлар үткәрү дә бер тәртипкә салына». Яңа күтәрелеш заманы килә.

Минем яшьрәк чакта алып барылган көндәлек дәфтәремдә теркәлүе үземчә кирәк саналган бер өземтә саклана. Ул юк-бар әйтелмә түгел – рәсми телдә язылган сүзләр. Карасана, КПССның өченче Программасыннан фикер-кәлимәләр күчереп алганмын. «Партия әдәбият, сәнгать, мәдәниятнең гөрләп үсүе, һәрбер кешенең шәхси мөмкинлекләрен бөтен тулылыгында күрсәтүе өчен һәммә шартларны тудыру, барлык хезмәт ияләрен эстетик тәрбияләү, халыкта югары сәнгатьчә зәвык һәм мәдәни күнекмәләр булдыру турында өзлексез кайгыртырга бурычлы». Мондый пафослы юллар белән танышкач, кемдер мыек астыннан елмаеп куяр. Әмма мин шушы өзекне укыган саен, төрле чорларны күзаллаган хәлдә уйга талам. Юк, партия программасының югарыда китерелгән өлеше күңелне иркәләрлек риторикадан гына тормый. Тантаналы төстә белдерелгән әлеге ният илдә мөмкин кадәр гамәлгә ашырылган. «Татарстан Язучылар берлеге» дип исемләнгән китапта бу юнәлештәге эшчәнлекнең уңай нәтиҗәләре җентекләп яктыртыла. Гадәләтчә танырга тырышыйк, сугыштан соң мәдәният тормышын җайга салу өчен, совет хакимияте үзенә күрә әһәмиятле эшләр башкарган: Мәскәүдә Татар әдәбияты һәм сәнгате декадасы үткәрелә; күренекле әдипләр югары органнарга депутат итеп сайлана; яшьләрнең «Үсү юлы» дигән альманахы чыгарыла башлый; Матбугат йорты комплексының яңа куәтләре сафка кертелә; Татарстанның Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт бүләге булдырыла; башкаладагы Союзлар йортының Колонналы залында юбилейларыбыз уздырыла; Муса Җәлилгә Советлар Союзы Герое исеме бирелә, аның «Моабит дәфтәре» Ленин премиясе белән бәяләнә; «Татар поэзиясе антологиясе» укучылар кулына барып ирешә;

милләтара әдәби тәрҗемә алмашу химаяле нигезгә корыла; республика китап сәүдәсе оешмасы үзенең мөмкинлекләрен киңәйтә; газета һәм журналларның тиражы күзгә күренеп арта; каләм ияләренә чагыштырмача әйбәт кенә гонорар түләнә; СССРның аерым төбәкләрендә иҗат йортлары файдалануга тапшырыла... Кыскасы, елъязмачы кебек бөтенесен тезеп чыксак, әлеге мәгълүмати хроника озынга китәчәк. Күренә ки, совет чорында җитәкчелек иткән партия халыкка биргән вәгъдәсен үтәргә омтылган. Сугыштан соңгы елларда башланган җанланыш җәһәтеннән, Равил Фәйзуллин хаклы рәвештә билгеләп үткәнчә, «...Ач-ялангач чор бит, әмма китаплы чор! Шул заманда ачлы-туклы яшәп, тырышлык белән белем алган, китаптан аерылмаган буын XX гасыр ахырына кадәр дөньяның терәге булды да».

Җәмгыятьтәге мөһим иҗтимагый вакыйгаларны беркадәр йөгертеп күздән кичергәндә, ахыры күренмәгән үзгәртеп коруга ялганып киткән болгавыр дәвердә халык тормышыннан аерылгысыз әдәбият та зур кыенлыкларга юлыкты. Вакыт үткән саен, әйберләрнең әһәмияте үзгәрә. Борынгы философларның әлеге гыйбарәсендә игътибарга алынган нәрсәләр арасына рухи-мәдәни кыйммәтләрнең килеп керәчәгенә берничек тә ышанасы килми. Кызганыч ки, яшәешне иңләгән күңелсез метаморфоза җилләре сөекле китабыбыз язмышына да кагылды. Беренче карашка реформалар белән яшәгән Россиядәге гайре табигый үзгәрешләр «белем чишмәсе» кебек мөһим төшенчәләрнең дә астын өскә китерде. Гасырлар дәвамында сыналган мәдәни ориентирларның отыры югала баруы, эстетик зәвыкның бозылуы тискәре нәтиҗәләрен инде күрсәткәләп тора. Атаклы Матбугат йортыннан каләм хезмәтенә бәйле барлык оешмалар сөрелде, элегрәк «иң күп укыган» илдә китап сәүдәсе подвалга төште. Башта озак еллар сүз ирегендә даулаштык. Инде хәзер ирекле сүзнең дә кадере бетте – җитәкчелек хәтта тәнкыйть язмасына да игътибар итми. Белүебезчә, китап тармагын үстерүнең бердәм концепциясен эшләү бүген бездә көн тәртибенә бөтенләй куелмый.

Дөрес, сөенерлек яңалыклар да сирәк кенә ишетелгәли. Әнә, Казандагы Шәриф Камал музей-фатиры җирлегендә «Татар китабы» йорты эшләнә икән. Монысы бик тә яхшы. Әмма кешелекнең иң бөек казанышларыннан саналырлык китапка мөнәсәбәт, гомумән алганда, аның бәһаләп бетергесез могҗизалы асылына муафыйк югарылыкта түгел. Ул белем бирү учреждениеләрендә дә үзен ятим итеп тоя күк. Күреп торабыз, «формаль» мәктәп «креатив»ка әверелде, виртуаль яссылыкка авышу көчәйде, зомбига түнтәрелү куркынычы артты. Әхлагы тотрыксыз җәмгыятьтә компьютер иблис коралына әйләнер. Хәзер социаль челтәрдән террорчылар да файдалана, аннан хәтта яшүсмерләрне үз-үзләрен үтерергә өйрәтәләр. Яшь дәвамчыларыбыз бары үз ихтыяҗларын гына канәгатьләндерүдән битәр, юкны иҗтиһат белән барлыкка китерүче булып үссен иде. Рухи тигезләнешне җую шәхси бөтенлекне җимерә. Болар дәүләтнең ныклыгына сугарга мөмкин. Каләм ияләре бергәлегенең тарихын төрле яклап өйрәнгән Равил Фәйзуллин да үз хезмәтендә әлеге мөһим мәсьәләләргә гамьле карашын даими белдергәләп бара. Шагыйрь борчылуын да сиздерә, өмет өзмәвен дә белгертә. «Хәзер Россия халкының 35 проценты елына бер китап та кулына алып карамый икән, – дип гаҗәпләнә ул. – Искитмәле, бүтәнчә әйтсәк, коточкыч хәл!.. Ә бит бүген кибетләрдә нинди генә хикмәтле китаплар юк. Эстетик кыйммәте ягыннан дисеңме, тарихи тирәнлеге, күзне иркәли торган полиграфик бизәлеше җәһәтеннән дисеңме!.. 60-70 нче елларда берәр яхшы басма кулга төшсә, без, кош тоткан кебек, биһуш кала идек. Заманалар үзгәрде. Ләкин әле бу затлы Китапка ясин чыгу түгел».


Үзеннән-үзе аңлашылганча, рухи азык сыйфатындагы китапка ихтыяҗ саклансын өчен, безнең җәмгыятьтә язучының абруе югары булырга тиеш. Зур әдәбиятка таянмаган милли идеяләр халыкның генетик зиһененә сеңдерелә алмый. Әдипнең элек-электән дәүләт кешесенә тиңдәш итеп каралуы хакимият эшчәнлегенең максатчанлыгын ныгытуда турыдан-туры чагылыш тапкан. Бу бәйләнешнең торышы хәзер ничегрәк соң? Чынын әйтергә кирәк, гадәти инженерларга тиешенчә кадер-хөрмәт күрсәтелмәгән илдә «кеше рухы мөһәндисләре»н олылау зарурлыкка әйләнерме? Бүгенге көндә каләм иясенең һөнәри хокуклары да ил күләмендәге бердәм кануннар нигезендә рәсми теркәлмәгән. Иҗтимагый мөнәсәбәтләрне тәртипкә сала торган нормаларның җитешмәве Язучылар берлеге эшчәнлеген оештыруда да һәрдаим

сиздертә. Тик менә «Россия Федерациясендә мәдәният турында»гы закон проектының 2011 елдан бирле кабул кылынмавы, мәдәни тормышыбызны көйләргә булышырдай башка кирәкле кануннарның гамәлгә куелмавы күңелдә сәерсенү тойгылары уята. Шуның аркасында Әдәбият фонды да һич кирәкмәгән ясалма киртәләргә очрый. Гаҗәпкә калырлык, кешелекнең тәрбиячесе булып саналган әдип илдәге профессияләр исемлегенә нигәдер кертелмәгән. Төгәлрәк аңлатканда, «Профессиональ союзлар, аларның эшчәнлек хокуклары һәм гарантияләре турында»гы федераль законда да, шулай ук «Россия Федерациясенең хезмәт кодексы»нда да язучылык иҗаты телгә алынмаган. Бик сәер килеп чыга: безнең шартларда «закон кысаларындагы карак» бал-май гына ашап тора, ә җитәр-җитмәс хокуклы әдип гаиләсен кайдадыр эшләп туйдырырга мәҗбүр. Череп баеган Көнбатыш кинаяләп искәртергә яратканча, әгәр дә язучылар яхшы эшкуарлар булса, аларның язучылыкны сайламаска акыллары җитәр иде. Кагыйдә буларак, каләм иясенең дәрәҗәсен күтәрүгә китермәячәк мондый вазгыять әдәби алмаш әзерләүгә дә кире йогынты ясый. Гадәттә, язар өчен азмы-күпме уңай шартлар тудырылган чакта, күпләр раслаганча, хәтта сәләтсез назымчы да үзенең шөгыленнән оялмый. Без сүгәргә күнеккән совет чорында менә шундый мөнәсәбәт – күктән иңдерелгән талантың белән ихлас горурлану күзәтелә иде. Ә хәзер... Һәрхәлдә, шәхсән үземнең ачыктан-ачык халыкка хезмәт итүче, ягъни законлы язучы булып каласым килә.

Мәгълүм ки, сүз сәнгате остасы тарафыннан язылган яхшы китапка автор күзаллаганнан да күбрәк эчке мәгънә салына. Гадәттә, андый басмалар укучыны иксез-чиксез уйлануларга этәрә, үзгәрәк фикри сөземтәләр чыгарырга зәмин бирә. Үз чорының мәдәни биеклегендә калу өчен, әйе, акыл сәләтеңне һәрдаим баетып тору шарт. Бу җәһәттән Равил Фәйзуллинның «Татарстан Язучылар берлеге» дигән китабы югарыда игътибар үзәгенә алынган гаять әһәмиятле максатларга хезмәт итә. Алдарак искәртеп үтелгәнчә, әлеге оешма тарихына мөнәсәбәтле кайбер хезмәтләр бар, әмма алар теләсә кайсы урында чәчелеп ята. Сибелгән хәлдәге мәгълүматларның күплеге исә кайчак фикер тупларга комачаулык ясый. Ә яңа тикшеренмәдә, әйткәнебезчә, һәрнәрсә дә бар: Язучылар берлеге турында белешмәләр дә, төрле чорлар вазгыятенең тасвирламалары да, әдипләр хакында гыйбрәтле фактлар да, иҗадият күренешләренә баглы шәрехләүләр дә, рухи-әхлакый үзгәрешләрне күрсәткән күзәтүләр дә... Съездлар барышын җентекләү дә бер мантыйкый эзлеклелектә башкарылган. Бик җайлы бит. Әдәби хәрәкәтебездәге хәлләрне инәсеннән җебенә кадәр белергә теләгән кешегә әлеге хезмәт үзенә күрә энциклопедия рәвешендә дә кулланылырга мөмкин. Һәркем сизәр, гомере дәвамында гыйльми эшләргә тартым йөзләрчә тәнкыйть мәкаләсе язган, җитди докладлар ясаган шагыйрь үзенең зур тәҗрибәсеннән маһиранә файдаланган. Татар әдәбияты тарихының XX-XXI гасыр башы аралыгындагы дәверен галимнәрчә өйрәнүдә Равил Фәйзуллин Татарстан Фәннәр академиясенең шәрәфле академигы булуын да гамәлдә раслый. Һәрбер китапның язмышы җәмәгатьчелек бәһасенә бәйле. Тирәнтен ышанып әйткәндә, рухи-мәдәни яшәешебез сәхифәләрен гамьле күңел аша яктырткан ошбу басма олуг максатларыбызга ирешүдә озак вакытка исәпләнгән ярдәмлек вазифасын үтәячәк.

**Зиннур МАНСУРОВ**

# КЕМ УЛ – НОБЕЛЬ БҮЛӘГЕ ЛАУРЕАТЫ ҺЕНРИК СЕНКЕВИЧ?



Язучы һәм галим Һенрик Сенкевич (1846-1916) – әдәби тәнкыйтьтә һәм әдәбият белемендә «поляк реалистик прозасының классигы», дворян әдәбияты вәкилләренең берсе, «зур эпик полотнолар һәм новеллалар тудыру остасы», «поляк әдәбиятына иң югары дәрәҗәдәге әдәби сүз үрнәкләре» биргән иҗаты исә «милли тенденцияләр, патриотик омтылышлар» *(Мальков М. Романтическая биография польской новеллы // Польская новелла XIX-XX веков. – М.: Художественная лит-ра, 1988. – С.9)* белән сугарылган иҗат буларак бәяләнә. Бер үк вакытта ул – тамырларында әтисе ягыннан татар һәм әнисе ягыннан белорус каны аккан шәхес буларак та билгеле.

Гомер буе туган җире Польша мәдәниятенә хезмәт иткән бу олы шәхесне без ничек кабул итәргә тиеш? Без аны үз мәдәниятебез тарихына урнаштыра алабызмы? Гомумән, башка телләрдә татар кешеләре тарафыннан иҗат ителгән әдәбиятка нинди мөнәсәбәттә булырга? Бу сораулар гел калкып чыгып тора. Охшаш сорауларга башка милләт галимнәре дә җавап эзли. Төрле халыклар мәсьәләне төрлечә хәл итә.

Методологик яктан, миңа, шәхсән, күренекле рус әдәбиятчысы Н.Л.Лейдерман фикере уңышлы тоела. Ул рус телле әдәбиятның рус әдәбиятыннан аермасын билгеләү бурычы куя һәм болай дип белдерә: рус әдәбиятының рус телле әдәбияттан аермасы шунда: соңгысының текстлары структур яктан рус һәм башка милли тормыш моделе арасындагы сөйләшүгә (диалогка) корыла *(Лейдерман Н.Л. Русскоязычная литература – перекресток культур // Русская литература XX-XXI веков: направления и течения. Вып.8.–Екатеринбург, 2005.– С.48-59)*. Димәк, иҗатында мондый сөйләшү булган язучыларны милли мәдәният кырына кертү, урнаштыру мөмкин дигән сүз.

***

Һенрик Йосыф улы Сенкевич 1846 елның 5 маенда Белоруссия-Польша чигендәге Воля-Окшейск имениесендә туган. Язучының бабалары Витовт (1350-1430) хакимлеге вакытында Җәләледдин җитәкчелегендә Бөек Литва кенәзлегенә килгән татар шляхтичларыннан (шляхта – сугышчыларның морза (дворян) сословиесе: шляхтичларның гербларында рун язуы сакланып калган) була. XVIII гасырда Сенкевичлар мөселман диненнән католик диненә күчә.

Әнисе – Белоруссия-Литвадагы танылган белорус дворяннары Цецишовскийлар нәселеннән.

Һенрик Сенкевич Варшавада гимназия тәмамлый һәм 1866-1870 елларда Варшава университетының медицина һәм тарих-филология факультетларында укый. Студент вакытында ук «Атналык күзәтү» («Przegląd Tygodniowy») журналында басыла башлый (тәхәллүсе – Литвос), журналист-публицист булып таныла. 1873 елдан – «Польша газетасы»нда («Gazeta Polska») фельетонист, 1874 елдан «Niwa» журналында әдәби бүлекне җитәкли, 1882 елдан – «Сүз» («Słowo») газетасының редакторы.

1881 елда ул, кызның әти-әнисе матди хәле тотрыклы булмаган язучы белән туганлашуга каршы булсалар да, Мария Шеткевич белән гаилә кора. Әмма хатыны 1885 елда, ике баласын (улы Генрик-Юзеф һәм кызы Ядвига) ятим калдырып, үпкә авыруыннан вафат була. 1888 елда, иҗатына мөкиббән бер кешенең матди ярдәме, Сенкевич хатыны исемен йөртә торган фонд ача һәм туберкулёз белән авыручы мәдәният әһелләренә ярдәм итә башлый. 1893 елда Одесса шәһәре кызы Мария Володкович белән гаилә корып, Италиягә китәләр. Әмма бу никах 1895 елда аерылышу белән тәмамлана. 1904 елда өченче тапкыр – Мария Бабскаяга өйләнә.

Журнал заказы буенча Америкага сәяхәт итеп (1876-1879), Сенкевич «Сәяхәттән хатлар» дигән юлъязмаларын бастыра. Европага кайткач, бераз вакыт Парижда яши, Венециягә һәм Римга бара, төрле җирләрне иңли (Австрия, Англия, Италия, Литва, Франция, Швейцария, 1886 елда – Румыния, Болгария, Төркия, Греция, 1891 елда – Мисыр, Занзибар һ.б.). 1900 елда, әдәби иҗатының 25 еллыгы уңаеннан, Сенкевичка Обленгорек (Oblęgorek) имениесен бүләк итәләр.

Сенкевич әдәбият белеме белән дә шөгыльләнә. Барокко эпохасы шагыйре Миколай Семпе-Шажинский турында, әдәбиятта натурализм юнәлеше, тарихи романнар хакында зур хезмәтләр авторы ул. Петербург Император Фәннәр академиясенең мөхбир-әгъзасы (1896 елдан) һәм аның шәрәфле академигы (1914 елдан) да.

Беренче Бөтендөнья сугышы башланганнан соң, Сенкевичлар гаиләсе Швейцариягә күчә. Һенрик Польшада Сугыш корбаннарына ярдәм комитеты оештыра. Веве шәһәрендә 1916 елның 15 ноябрендә вафат була. 1924 елда җәсәде Варшавага күчерелә.

Һенрик Сенкевич иҗатының үзенчәлекләрен, популярлыгы серен барлап, Б.Стахеев болай дип яза: «Аның иҗатына хикәяләүнең кызыклылыгы, маҗаралар күплеге, сюжетның тиз үсеше, тел осталыгы һәм образларның сыгылмалылыгы хас. Соңгы сыйфат бигрәк тә әһәмиятле: Сенкевич укучыны мавыктырып кына калмый (мавыктыргыч китаплар башка авторлар тарафыннан да языла), ул аны өйрәтә, тәрбияли, камилләштерә. Күренекле язучының романнары безне гадәти булмаган, әкияти, әмма әхлакый яктан укучыга якын кешеләр белән таныштыра. Тугрылык һәм рух көче, куркусызлык, бәла-казалар алдында нык булып калу, югары максатларга хезмәт итүне шәхси мәнфәгатьләрдән өстен кую, туган илгә мәхәббәт, тормыштагы активлык – Сенкевич китапларындагы уңай геройларга, ул яратып һәм яратуын яшермичә сурәтләгән геройларга хас сыйфатлар менә шулар» *(Стахеев Б. Генрик Сенкевич // Сенкевич Г. Собрание сочинений. Том 1. – М.: Худож. лит-ра, 1983. – С.5.)*. Сенкевич иҗатындагы төп сыйфатлар буларак, без эчтәлектә әхлакый бәяләүнең алга чыгуын, туган җирне ярату һәм аңа тугрылыкның иң мөһим кыйммәт итеп күтәрелүен, мәхәббәтнең гаять зур, кешене каһарман да, җинаятьче дә ясый торган көч булуын раслауны, маҗаралылыкның әсәрләрнең укылышын тәэмин итүен, геройларның идеаллаштырылып һәм психологизм алымнары кулланып сурәтләнүен күрсәтер идек.

Сенкевич әдәбиятка 1872 елда, кечкенә хикәяләре, новеллалары белән килеп керә. «Воршилла портфеленнән юморескалар» дигән баш астына тупланган беренче әсәрләре мәгърифәтчел идеяләр белән сугарылып, иҗтимагый яңарыш яклылар белән иске фикерлеләр яки битарафлар арасындагы каршылыкка корылган (мәсәлән, «Үз илеңдә пәйгамбәр булу авыр»). Бу әсәрләр яшь авторны уңышлы детальләр ярдәмендә сурәт тудыру остасы итеп күрсәтә.

Шулай да Сенкевичка уңыш китергән әсәр дип автобиографик төсмерле өч әсәрне – «Карт хезмәтче» (1875) хикәясе, «Ганя» (1876) повесте яки күләмле «Сәлим Мирза» (1877) хикәясе – берләштергән цикл санала. Әсәр сюжеты ике яшүсмер егет Һенрик белән Сәлимнең егетлек чорына аяк басуы, гашыйк булулары, шул мәхәббәтне югалтулары һәм Сәлимнең үлеме кебек үсә. Малай-егетләр күрше утарларда яши. Һенрик шляхтичлардан булса, Сәлим – татар мирзалары нәселеннән. Хикәяләү «мин» – Һенрик исеменнән алып барыла, бу исә әсәрнең тирән психологик анализга корылуын тәэмин итә.

Әсәр яшүсмерләрнең гаиләләре, Варшавада гимназиядә укулары, университетка имтиханнар тапшырулары кебек язучы биографиясеннән танылa торган детальләргә

бай. Һенрик һәм Сәлим характерлары гаять югары дәрәҗәдәге осталык белән иҗат ителгән. Тиз кызып китүчән, куркусыз, хәтта башсыз, ачык күңелле, чибәр, кыю, талантлы Сәлим һәм шундый ук кыю, әмма үз эченә йомылган, хисләрен йөрәгеннән читкә чыгара алмый торган, шуңа да каршылыклар, коточкыч газаплар белән яшәүче Һенрик – икесе дә Ганяга гашыйк була. Ганя – карт хезмәтче Миколайның кызы, әтисе үлгәч, Һенриклар гаиләсендә тәрбиягә калдырылган һәм панилар кебек белем-тәрбия алган. Кызга чын-чынлап гашыйк булса да, Һенрик аңа да, үзенә туп-туры сораулар биргән дусты Сәлимгә дә серен ачмый. Киресенчә, күршеләре Устжицкийларның кызы Лёляга тәкәллеф күрсәтә. Ә инде Сәлим белән Ганя арасында саф хисләр кабынуны төшенүгә, Һенрикның күңелендә ачу-нәфрәт хисләре кайный башлый. Язучы аның кичерешләрен барлык ваклыкларында күзәтеп бара, ул кичергән каршылыклы хисләрне укучы да үз йөрәге аша уздыруга дучар ителә.

Ганя белән Сәлим качып китә, әмма карт мирза бу никахка ризалык бирми, шул ук көнне Ганяны гаиләгә кайтара. Сәлим белән Һенрик дуэльдә сугыша, каты яраланалар, чак кына бер-берсен үтермичә калалар. Ганя чәчәк чире (оспа) белән авырып китә.

Психологик анализ ярдәмендә язучы чак үлемнән калган Һенрикны һәм Сәлимне бу хәлләрдә үзләрен гаепләү ноктасына алып килә: егетләр үз хисләрен алга куюларын, кыз мәнфәгатьләре өчен түгел, мәхәббәтләрен яклап көрәшүләрен, шул мәхәббәтне үзләрен ярату корбанына әйләндерүләрен төшенәләр.

Кыз терелгәч, аның авыру ямьсезләгән йөзен, кулларын күргән Һенрик сөю хисенең «кош кебек эзсез югалганлыгын» аңлый. Әмма әтисенә аңа өйләнергә әзер икәнлеген әйтә. «Мин бакчага чыктым һәм әлеге, Ганя белән Сәлим беренче тапкыр мәхәббәт аңлашкан, үрмә гөлгә уралган беседкада сөйгәннәре үлгәч елаган кешеләр кебек елап җибәрдем. Чыннан да, элеккеге Ганя минем өчен үлгән, дөресрәге, минем мәхәббәтем үлгән, аның урынына йөрәктә бушлык, төзәлмәслек җәрәхәттән яра авыртуы һәм күзгә яшьләр китерә торган хатирәләр генә калган иде» *(Ганя // Сенкевич Г. Собрание сочинений. Том 1.: Повести и рассказы. – М.: Художественная лит-ра, 1983. – С.136.),* ди ул.

Шул кичтә Һенрик Ганя белән Сәлимнең күрешүенең дә шаһите була. «Чынлап та, эңгер-меңгер төшкәндә, Сәлим килде. Ганяны күреп, ул кызарды, аннары агарды. Йөзенә карап, аның күңелендә бу мизгелдә хис белән намус көрәше барганлыкны күрү авыр түгел иде. Димәк, аның йөрәгеннән дә мәхәббәт дип атала торган әлеге канатлы кош очып киткән. Әмма киң күңеллелек өстен чыкты, ул Ганя янына килде, аңа кулларын сузды, аннары тезләнде дә кайнар итеп пышылдады:

– Ганя, кадерлем! Мин шул ук, мин һичкайчан, һичкайчан сине ташламам!

Ганяның йөзеннән яшьләр акты, ул Сәлимне акрын гына этеп куйды:

– Мин ышанмыйм, ышанмыйм, мине хәзер ничек итеп яратып булсын, – диде, аннары йөзләрен каплап кычкырды: – О! Сез бик мәрхәмәтле! Ә мин һәммәгездән дә начаррак һәм гаеплерәк, ләкин болар барысы да артта калды, мин үзгәрдем!

Һәм, карт Мирзаның үтенүләренә, Сәлимнең ялынуларына карамыйча, егетнең тәкъдимен кире какты. Беренче тормыш давылы бу гүзәл, әле генә ачылган чәчәкне сындырды» *(136-137 бб.)*.

Циклдагы икенче әсәр Ганяның шәфкать туташы булып китүе, шунда тынычлык табуы хакындагы хәбәр белән тәгәлләнә. Сәлимнең прототибы гаярь татар егете 1863 елгы баш күтәрүдә һәлак булса да, өченче әсәрдә язучы героен француз-прусс сугышына җибәрә (цензура таләпләре белән бәйле), шунда батырларча үлүе турында сөйли. Шулай итеп, әсәрдә татар темасы, татарларның холкы, яшәү рәвеше, менталитеты шактый киң алып тасвирлана.

Сенкевичның беренче чор иҗатына караган әсәрләрдә («Күмер белән ясалган рәсемнәр», 1877; «Янко-музыкант», 1879; «Ипигә барганда», 1880; «Фәрештә», 1880; «Маякта фонарь кабызучы», 1881; «Бартек-җиңүче», 1882 һ.б.) үз чорында Ләхестан (Речь Посполитая) җирендәге тормыш, кешеләр арасындагы мөнәсәбәтләр әхлакый бизмәнгә салып күрсәтелә. Боларда инде трилогиядәге кебек милли проблематика яки геройлар күзгә бәрелеп тормый.

1876-1878 елларда Америкада яшәү Сенкевич иҗатына чит җирләр тормышын алып керә *(«Прериядә», 1878; «Орсо», 1879; «Сахем», 1889 һ.б.)*.

Әмма 1879 елда Варшавага әйләнеп кайткан язучы кабат үз туган җире, шушы төбәктә булган тарихи вакыйгаларны сурәтләүгә керешә. «Татар әсирлеге» (1880) хикәясе XVII гасырдагы сугыш хәрәкәтләре турындагы зур романнар өчен уйланманың нигезе булып санала. Тарихи трилогия («Ут һәм кылыч белән» (1883-1884), «Ташу» (1884-1886), «Пан Володыевский» (1887-1888)) 1647 елдан алып 1673 елга кадәрге вакыйгаларны колачлый. Беренче романда Ләхестанда Украинаны бүлеп чыгару хәрәкәте, Б.Хмельницкий казаклары белән көрәш үзәккә куела. Икенче китапта полякларның 1655-1656 елларда шведлар басып керүенә (язучы бар дөньяны каплаган язгы ташу белән чагыштырып, образны әсәр исеменә чыгара) каршы милли-азатлык сугышы сурәтләнә. Өченче романда төрек басып алулары чорында (1672-1673) поляк сугышчыларының батырлыклары бәян ителә. Романтик идеаллаштыру, геройларны тудырганда һәм вакыйгаларны тергезгәндә, героик эпос алымнарына мөрәҗәгать әсәрләрнең мавыктыргыч стилен, укылышын тәэмин итә. Бер үк вакытта язучы шул чор вакыйгаларын теркәп калдырган бик күп тарихи чыганакларны, шәхси көндәлекләрне, язмаларны файдалана. Мифлар, легендалар, фактлар, бергә укмашып, әсәрләрдә әлеге җирләрнең бердәм тарихы булып калка.

Бу чор Ләхестан тарихында иң авыр заманнардан, ил һәм дәүләтчелек язмышы кылыч очына менгән вакытлардан санала. Икътисади торгынлык белән янәшә сәяси торгынлык, төрле йогынтылы төркемнәрнең үз мәнфәгатьләрен алга сөрүе, Кырым, Швеция, Пруссия, Төркия, Россия мәнфәгатьләренең бәрелешүе илне җимерелү чигенә китереп җиткерә. Әмма Ләхестан мөстәкыйльлеген саклап кала. Сенкевич шушы вакыйгалар фонында телне, мәдәниятне, динне, милли үзаңны саклау мәсьәләсенә мөрәҗәгать итә, шуларны дәүләтчелекне тоту өчен мөһим кыйммәтләр дип белдерә. Әйтик, Богдан Хмельницкий җитәкчелегендәге казакларның Украина мөстәкыйльлеген яклап баш күтәрүе дә язучы тарафыннан бердәм дәүләтне таркату буларак бәяләнә. Крестьян бунтлары да бердәмлекне җимерү омтылышы кебек карала. Язучы дәүләтнең көчен, ныклыгын беренче урынга куя, тарихи вакыйгаларны шәрехләүне патриотик башлангычка буйсындыра. Морзалар, өстен катлау гына түгел, крестьяннар да, хезмәтчеләр дә – бердәм халык, үз җирен яклап көрәшкә чыккан бер йодрык кебек күзаллана.

Безнең өчен язучының өченче – «Пан Володыёвский» романы аерата кызыклы, чөнки әсәр татар хәрбиләре тормышына шактый зур урын бирә. Бер яктан, язучы шляхта гаскәрләрен һәм Урда (Алтын Урда җимерелгәч, аерым төркемнәр хасил итеп, әмма кабат оешу өметен җуймыйча яшәгән татар отрядлары) хәрбиләрен аерып куя. Урда хәрбиләре Ләхестанны җимерергә, җирләрен басып алырга, шунда урнашырга омтыла. Икенче яктан, язучы идеаллаштырып тасвирлый торган шляхта гаскәриләре арасында да татарлар күп, алар югары чиннар арасында да бар, аерым отрядлар булып Урдага каршы да көрәшәләр.

Төп каршылык язучының идеалы дәрәҗәсендә сурәтләнгән поляк рыцаре, тарихи билгеле шәхес Михал Володыёвский белән татар сугышчысы, хан улы Азья Тугай-Беевич арасында күрсәтелә. Поляк панының үзен татар белән тигез куймавы бик вак детальләрдә үк күренеп тора. Мәсәлән, мәхәббәт аңлашканда, ул кызга «мине курыкмыйча тыңла, мин скиф та, татар да, явыз да түгел», дип эндәшә һ.б. Бер үк вакытта Володыёвскийның бер хатында мондый юллар бар: «Безнең бөтен татарларыбыз – шляхта, дин ягыннан христиан булмасалар да. Литвада мин авыллар булып яшәүче татарларны күрдем. Аларны анда липеклар дип атыйлар, ә мондагыларын чирмеш, диләр. Алар озак еллар Ләхестанга икмәк өчен рәхмәт йөзеннән тугры хезмәт иттеләр, әмма крестьян чуалышлары вакытында күпләре Хмельницкийга авышты, ә хәзер, ишетүемчә, Урда белән уртак тел тапканнар» *(Пан Володыёвский: роман // Сенкевич Г. Собрание сочинений. Том 5. – М.: Художественная лит-ра, 1984. – С.140.)*.

Әсәр бүген дә укучыны гаҗәпләндерә, сокландыра торган күп сыйфатларга ия. Шул заман маҗаралы тарихи әсәрләре таләпләренә җавап биреп, язучы тормышны ак

һәм карага аера: төп героен идеаллаштыра, аның дошманы Тугай-Беевичны тискәре буяулар ярдәмендә сурәтли. Ләкин бер үк вакытта әсәрдә Азьяның холкы һәм үз-үзен тотышы, аның сәбәпләре белән бәйле кызыклы күзәтүләр урын алган. Бөтен даланы тетрәтеп торган Тугай-Бәйнең (Азьяның әтисе) хәрәменә эләккән сеңлесен коткару, алыштырып алу өчен, шляхтич Ненашинец ханның яраткан улы – өч яшьлек Азьяны урлый. Әмма үзенә ярдәм иткән юлбасарлар белән каршылыкка кереп, малайны югалта. Тагын бер шляхтич – Нововейский Азьяны далада табып, кем икәнен белмичә, хезмәтче итеп һәм кыйнап, түбәнсетеп үстерә. Азья явызлыклар кылганда, һәрчак үзенең канга батырылган аркасын хәтеренә китерә – язучы моны роман буенча гел кабатлап килә. Нәтиҗәдә, акыллы, киң карашлы, чын хәрби җитәкче кебек фикерли торган, батыр Азья үчле һәм эчкерле булып формалаша. Язучы, мохитеннән, тамырларыннан аеру кешенең психикасын үзгәртүгә китерә, дигән нәтиҗә ясый.

Хан улы булуын белгәч, татарлар гына түгел, шляхта да егетне хөрмәт итә башлый. Язучы бу мәсьәләдә дә поляклар һәм татарларны чагыштыра: поляклар теләсә кайсы этнос вәкиленә, акылына һәм кыюлыгына карап, шляхта титулы бирә, бу дәүләтне ныгытырга ярдәм итә. Татарларда исә бары тик нәсел җебе буенча гына титул тапшырырга мөмкин. Әлеге үзенчәлек бу кавемгә каршы эшли. Мондый чагыштырулар роман буйлап сибелгән.

Сенкевичның тарихи әсәрләренә хас булганча, романда мәхәббәт өчпочмагы туа. Азья Володыёвскийның хатыны Басяга гашыйк була, башын югалта: аны урлап качу омтылышы ясый, Рашков крепостен яндырып, татарларны үз артыннан ияртеп, Урдага китә, төрек солтаны гаскәренә кушыла. Солтан гаскәре Ләхестанга яу белән килә. Ләкин җиңүгә ирешә алмый.

Әлеге романнар дөнья күрүгә, Сенкевич Польшада иң билгеле язучыга әйләнә. Аның китапларын соратып алып, эзләтеп укыйлар, иҗаты мәктәп һәм югары уку йортлары программаларына кертелә.

1880 еллар ахырында язучы тарихтан заман проблематикасына әйләнеп кайта, психологик роман жанрына мөрәҗәгать итә («Иманусыз», 1889-1890). Сенкевич үзе бу әсәрендә катлаулы һәм психик авыру, әмма, авыру икәнен аңлап та, терелергә омтылучы түгел, шунда казынучы кешенең күңел дөньясын ачу максаты куюы турында язып чыга.

Көндәлек формасында язылган әсәр психологик анализның үзанализ төренә өстенлек бирә. Аның герое 35 яшьлек граф Леон Плошовский – эстет-аристократ, тирән белемле, матурлык колы, әтисе белән Римда яши. Әмма тормыштан һәм үз-үзеннән канәгатьлек таба алмаучы егет яшәүнең мәгънәсен күрми. Апасы аны Анеле исемле кыз белән таныштыра һәм өйләнергә үгетли. Егет кызга гашыйк була, әмма төпле карар кабул итә алмый. Ахыр чиктә Анеле спекулянт Кроницкийга кияүгә чыгарга мәҗбүр була. Шуннан соң Леон аны кайтару өчен көрәшә башлый. Әмма ире үз-үзен үтергәннән соң, авырлы Анеле дә тормыш белән хушлаша. Леон да соңгы сәхифәләрдә үз тормышына үзе нокта куючы булып аңлашыла.

Яшәү көче таба алмаучы, мәхәббәтен, бәхетен җуйган егет «урталыктагы» яки «артык кеше» тибына туры килә. Шунысы кызык: геройның бу халәтен язучы аның милли җирлектән, традицияләрдән аерылган булуы белән дә бәйләп куя. Аның сөйгәне Анеле, Леоннан аермалы буларак, бу көчне диндә, иманда таба. Плошовский исә философиянең, фәннең, техник алгарышның кешегә ышанычлы нигез була алмавы, киресенчә, әхлакый ышанычын җимерүе турында сөйли. Аның монологлары Ф.Әмирханның «Урталыкта», Г.Ибраһимовның «Мәрхүмнең дәфтәреннән», Г.Гобәйдуллинның «Юлдаш эзләгәндә» әсәрләрен хәтергә китерә. Роман ахырына мәхәббәтен югалту, сөйгәненең үлеме фаҗигасен кичергән, үзенең беркайчан да бәхетле була алмаячагын аңлаган герой башкалар кайгысына һәм кичерешенә сизгер шәхескә әверелә. Ул үкенми, язмышын үзгәртергә омтылмый, киресенчә, үз теләге белән дөньядан үтә. Бу финал Плошовский кебек геройларның кичәге көн кешеләре булуына ишарә кебек тә яңгырый.

Язучының аннан соң иҗат ителгән «Поланецкийлар гаиләсе» (1893-1894) романын тәнкыйтьчеләр «Иманусыз» әсәре белән бер бәйләмдә карыйлар һәм, автор тарафыннан

кире кагылган Плошовский белән чагыштырганда, бу әсәрнең төп герое язучының идеалын – гаилә кыйммәтләренә, җиргә, милли тамырларга әйләнеп кайтуны күрсәтә, дип язалар.

Бу романнан соң Сенкевич кабат тарихи темага борыла һәм борынгы Рим империясенә, Неронның христианнарга каршы көрәше вакыйгаларына багышланган «Кая барасың?» (1894-1896) роман-эпопеясын иҗат итә. Шунысы кызык: Сенкевич әсәрдәге тарихи вакыйгаларны, христиан рухының матди омтылышларны җиңүен Польшадагы рухи яңарыш, күтәрелеш белән аваздаш итеп сурәтли. Бу роман авторга дөньякүләм дан алып килә. Ул тиз арада төрле телләргә тәрҗемә ителә, Америкадан Япониягә кадәр тарала.

Шундый ук дан язучының тагын бер тарихи әсәрен – «Тәре йөртүчеләр» (1897-1900) романын озата бара. Әсәр XIV йөз ахыры – XV йөз башында полякларның тевтон орденын җиңү вакыйгаларына багышланган. Урта гасырларда яшәүчеләрнең тормышка карашын, инану-ышануларын, гадәт-йолаларын сурәтләү ягыннан әсәргә тиңнәр юк.

Тарихи теманы дәвам итеп, язучы «Дан кырында» (1903-1905) романын яза. «Чоңгыл» (1909-1910) романы 1905-1907 еллар рус революциясе вакыйгаларына багышланган. 1910-1911 елларда балалар өчен маҗаралы «Африка чытырманлыкларында» повестен иҗат итә. Полякларның Наполеон сугышларында катнашуы турындагы «Легионнар» (1913-1914) романы төгәлләнмәгән килеш кала.

1905 елда Сенкевич әдәбият буенча («Эпик әсәрләр тудыру өлкәсендәге күренекле хезмәтләре өчен») Нобель премиясенә лаек була. Польшада һәм бүтән кайбер дәүләтләрдә аның истәлегенә музейлар, һәйкәлләр, урамнар ачылган. Китаплары бүген дә яратып укыла, төрле телләргә тәрҗемә ителеп басыла тора, алар буенча фильмнар төшерелә, картиналар иҗат ителә...

Әлбәттә, бүген дөнья әдәбиятында Һенрик Сенкевич исеме поляк язучысы буларак билгеләнгән. Иҗатына күзәтү ясау әсәрләрендә без искәртеп киткән мәдәниятара сөйләшүнең дә юк дәрәҗәдә булуын күрсәтә. Язучы әсәрләрен поляк шляхтичы буларак иҗат итә, үз иленең, поляк халкының патриоты төсендә күренә! Әмма Сенкевичның биографлары аның әтисе ягыннан татар булуын һәрдаим ассызыклыйлар, әсәрләрендә дә татар тамырлы шляхтич икәнлеге сиземләнә. Аерым новелла-хикәяләрендә татар характерын тудыру омтылышлары ясала. Күләмле тарихи әсәрләрендә исә татар тарихына караган күзәтүләр, татар сугышчылары образлары шактый урын алып тора. Тарихи романнары Польша, Литва татарларының урта гасырдан – XIX йөзгә кадәрле катлаулы, фаҗигале тарихын әдәби чаралар ярдәмендә тергезгән сәхифәләре белән дә кадерле. Бу сәхифәләр гасырлар дәвамында барган этносара мөнәсәбәтләрне эмоциональ бәяләргә ярдәм итә. Сенкевич шәхесе, биографиясе башка халыклар арасына сибелеп яшәгән татарлар язмышы, телләрен, аерым бер очракта диннәрен дә югалткан милләттәшләребез фаҗигасе турында да уйлануларга этәрә. Идел буендагы татар әдәбияты дәүләтчелеген югалту сөременнән арынырга омтылышлар гына ясаган бер вакытта, XIX гасырның икенче яртысында, чит телдә элитар эпос үрнәкләре тудырып, дөньякүләм дан алган язучының үз әсәрләрендә татарларның Кыргый Даладагы тарихын теркәп калдыруы яссылыгында аның исеме милли мәдәниятебез тарихында телгә алынырга хаклы тоела миңа.

**Дания ЗАҺИДУЛЛИНА**

# ҮСМЕР ГЕРОЙЛАР САГЫНДЫРА

Тарихы гасырлар катламы астына яшерелгән милли сүз сәнгатебезне баетуга алыштыргысыз үз өлешен керткән классик әдипләребез бик күп. Шулар арасында «Саф җилләр», «Язгы аҗаган» кебек әсәрләре белән күңелгә үтеп кергән Мәхмүт Хәсәнов та лаеклы урын алып тора. Аның тууына бу айда 90 ел.

Язучы-прозаик, драматург Мәхмүт Максуд улы Хәсәнов 1927 елның 21 декабрендә Татарстан Республикасының Саба районы (хәзерге Теләче) Югары Кибәхуҗа авылында туа. 1937 елда гаиләләре белән Яшел Үзән шәһәренә күченәләр. Шунда Мәхмүт Хәсәнов 5 нче номерлы татар урта мәктәбенә укырга керә, Ватан сугышы чорында һөнәр училищесын тәмамлап, берникадәр вакыт заводта эшли, аннары янә урта мәктәптә укуын дәвам итә. Әдәбиятка, театр сәнгатенә балачактан кабынган мәхәббәт 1944 елда уналты яшьлек эшче егетне Мәскәүгә – А.Луначарский исемендәге Театр сәнгате институтына алып килә. Биш елдан соң, институтның актёрлык факультетын тәмамлап, Мәхмүт Хәсәнов Казанга кайта һәм Яшь тамашачылар театрында актёр булып эшли башлый. Бер елдан аны Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрына эшкә чакыралар. Шул чорда (1949-1961) Мәхмүт Хәсәновның исеме мәкаләләр, очерклар, хикәяләр авторы буларак та газета-журнал битләрендә еш күренә башлый.

Өч төбәкнең – Саба, Теләче, Яшел Үзән районнарының могтәбәр шәхесе булган Мәхмүт Хәсәнов язучылык юлына һәммәбезгә мәгълүм әлеге катмарлы елларда килә. Репрессия, сугыш, сугыштан соңгы авыр еллар егетнең әдәбиятка кечкенәдән булган мәхәббәтен вакыйгаларга бай, маҗаралы, урыны-урыны белән трагик әсәрләр иҗат итү биеклегенә күтәрә. Ниһаять, Бөек Ватан сугышы бетеп, илгә тынычлык килгәч, 1952 елда, Мәхмүт Хәсәновның тәүге китабы – «Беренче хикәяләр» дөнья күрә. Алты хикәяне үз эченә алган, нибары 48 биттән торган бу җыентык «Таткнигоиздат» нәшрияты (хәзер – Татарстан китап нәшрияты) тарафыннан бастырылган. «Урта яшьтәге балалар өчен» дип баш куелган, 1950-1951 елда иҗат ителгән хикәяләр Мәхмүт Хәсәновның, аның чордашларының малай чагында узган бар авырлыкларны вакыйгаи тулылыкта үз эченә ала. Әлеге санда тәкъдим ителә торган «Герой» хикәясе дә ун-унике яшьлек малайларның, колхоз үсешенә өлеш кертү, сугыштан соңгы еллардагы ач-ялангач гаилә иминлеге өчен тырышып-тырмашып яшәү максатында, төнлә болында ат саклау күренешенә корыла. Тыйнак, ипле, әтисе сугышта һәлак булган Хаҗинур белән кыланчык, мактанчык, тәкәббер Харис арасында җиңелчә конфликт килеп чыга. Карлыгач кушаматлы атта җилдерүче Харис һәрвакыт чабышта беренче килә, тик тышауланган Карлыгач күлдә бата башлагач, аны паникёр Харис түгел, Хаҗинур коткарып кала. Чапаев белән бергә хезмәт иткән Зиннәт абзый мәсьәләне гадел хәл кыла: моннан соң җитез Карлыгачны куркак Харис түгел, ә этисе кебек герой Хаҗинур иярләячәк.

Әлеге җыентыкка кергән «Ташландык күлдә», «Дулкыннар арасында», «Һәрвакыт хәзер!» хикәяләре дә Совет иле иминлеге өчен җанын да бирергә әзер, патриот үсмер малайларның нәни генә, ләкин бик тә әһәмиятле батырлыкларын сурәтләүгә багышлана. «Корея малае» хикәясе исә партизаннарга мәдхия булып яңгырый. Америка генералы Биббс – ачкүз атакасыннан Еню Чен авылын, аның халкын саклап калган, күз алдында әнисе үтерелгән, соңыннан партизанлык юлына баскан Чан Хай исемле үсмер малай батырлыгы сокландыра. Виртуаль дөнья «геройлары» – бүгенге үсмерләр бу вакыйгаларның уңай чишелешенә өлеш кертә алыр иде микән?!

Шул рәвешле, зур прозаик Мәхмүт Хәсәновның тәүге китабына кергән кечкенә хикәяләренең берсен искә төшерик – «Әдипнең тәүге китабыннан»... Яңа сәхифәгә ак юл!

**Рамил ХАННАНОВ**

Мәхмүт
Хәсәнов



# ГЕРОЙ

хикәя

Сабан туендагы кебек, тузан өермәсе уйнатып чабышып килгән атлар кинәт кенә Олы күл буендагы болынлыкка борылдылар. Үсмер малайларның кычкырына-кычкырына атларын кууларыннан ук аларның бер-берсен узарга теләүләре күренеп тора иде.

Иң алда – җылкылдап торган кара ат килә... Аннан бераз гына калышып, башын болан кебек артка ташлап, көрән ат чаба.

Атлар, болынлыкка төшү белән, финишка килеп җиткәндәй, үзләреннән-үзләре туктадылар.

– И-и, Хаҗинур!.. – диде беренче булып килгән малай. – Тагы калдың бит! Юкка гына син минем белән узышасың...

Өченче малай сүзгә кушылды.

– О-о... «Карлыгач» белән, билгеле...

– Эш «Карлыгач»та түгел.

– Әллә синдәме? – дип куйды көрән атка атланган Хаҗинур.

– Ә кемдә соң?..

– Әйдә алайса, узыштан йөгереп карыйк.

– Узыштан?! Юк, а лай узышмыйм. Аягым авырта...

– О-о... Курыкты.

Һәрвакытта да диярлек өстенлекне үз ягында калдырырга яратучан Хариска җитә калды.

– Кем курыкты?.. Минме?.. Әйт әле, минме? Беләсең икән!.. Курыкты... Куркырга, мин бит син түгел...

Малайлар шулай үзара бәхәсләшеп торган арада, болынлыкка тагы бер көтү атлар төште. Кулына озын чыбык тотып, атларны куалаучы Зиннәт абзый да күренде. Колхозда һәм якын-тирәдә аны «Чапай Зиннәт» дип кенә йөртәләр. Чөнки ул, яшь Совет илен ак интервентлардан саклаган елларны, Чапаев дивизиясендә хезмәт иткән. Зиннәт абзыйның бөтерелеп килгән җирән мыегын, бераз кырын салып кигән папахасын күргән кешеләр аны һәрвакытта да Чапаевка охшаталар иде.

– Зиннәт абзый, – дип кычкырды Харис. – Иң элек «Карлыгач»ны тышаулагыз. Мин бүген дә беренче булып килдем.

– Шулаймы? «Йомран» бүген дә калыштымыни?..

– Калышмыймы соң! Мин Хаҗинурны әллә кайда калдырдым...

– Кая инде әллә кайда калдырдың?.. – диде Хаҗинур. – Синең артыңнан ук килеп җиттем ич.

Минут эчендә бөтен болынлык шау-шу белән тулды. Якында гына анасын югалткан тай кешнәп куйды. Шунда ук анасы да аңа җавап кайтарды. Атларның күбесе, пошкыра-пошкыра, кимерчәк чәйнәгән аваз чыгарып, ашарга керештеләр.

Зиннәт абзый, иртә белән тотарга җиңел булсын өчен, малайлар атланып килгән атларны тышаулый башлады. Ул иң элек «Карлыгач»ны тышаулады, йөгәнен салдырып, Хариска бирде...

Әкренләп, кояш баер вакыт җитте. Сирәк кенә булып үсеп утырган агачларның, печән кибәннәренең һәм ашап йөрүче атларның озынайганнан-озыная барган күләгәләре бөтен болынлыкны каплады. Бая гына әле, яфраклары саргаюдан, әкияттәге алтын агач кебек булып утырган яшь каен агачы, батып килә торган кояшның соңгы нурларында, ялкынланып ут капкандай, кызгылт төскә кергән иде. Үләннәр өстенә кичке чык төште. Тыныч кына яткан күл өстен аксыл төстәге томан каплады. Көзге кебек ялтырап яткан су өстен бары тик балыклар уйнавы гына тынгысызлый иде. Күлнең су астыннан тырпаеп тамырлар чыгып торган бу ягында (кайчандыр ул урында таллык булган) балыклар аеруча күп уйныйлар. Чөнки тамырлар арасына яшеренгән балыкны ятьмә белән дә, кармак белән дә тотып булмый иде. Биредә, зуррак алабуга эләктерергә хыялланып, кемнәр генә кармакларын өздермәде?!. Печән кибәнен бастырыклап куйган колга башында утырган саескан да, кояш батуны сизенеп куанган кебек, көлгән тавыш чыгарып шаркылдап алды да күлнең аръягындагы урманга таба очып күздән югалды. Җир өстенә сөт кебек ак йомшак яктылык чәчеп, ай калыкты...

Малайлар, Зиннәт абзыйның әйтүен дә көтеп тормыйча, утын хәзерләп, ут ягып җибәрделәр. Зиннәт абзый, протезлы аягын сузып утырды да алып килгән камытын ямый башлады. Малайлар, авызларын ачып, аның нәрсә турында булса да сөйләвен көтәләр иде. Чөнки Зиннәт абзый, һәр кичне диярлек, аларга ак бандаларга каршы көрәшеп йөргән еллары турында, Чапаев турында сөйли. Ә малайлар дөньяларын онытып тыңлыйлар-тыңлыйлар да, утырган җирләрендә үк авып, кыштырдап торган хуш исле печән өстендә йокыга китәләр... Алар төшләрендә, Чапаев кебек, яшендәй ялтырап торган кылычларын айкап, «Ура!» кычкырып, дошман явы өстенә ташлануларын күрәләр...

Берничә минутка сузылган тынлыкны сөяк саплы кечкенә пәкесе белән ниндидер агач кисәге юнып утырган Харис бүлде:

– Зиннәт абзый, – диде ул. – Ни өчен әле сезгә Чапаев «Молодец!» дип әйткән?

Үткән төнне генә Зиннәт абзый аларга Чапаевның сугышның иң кызу вакытында да сугышчыларын ничек күрә белүе, күңелләрен күтәрә һәм җиңүгә рухландыра алуы турында сөйләгән иде.

Зиннәт абзый:

– Кирәк чагында, каушап калмыйча, ике куллап (бер кулга кылыч, икенчесенә наган тотып) сугышкан өчен, – дип җавап кайтарды.

Чапаевны үз күзе белән күргән, аның белән бергә хезмәт иткән карт сугышчының сүзләрен герой булырга хыялланучы Харис аеруча яратып тыңлый иде. Әле дә инде, ул үзен «герой» дип йөрттерер өчен, ниләр генә эшләмәде. Үткән елның көзендә хәтта авылдагы иң биек келәт өстеннән дә

сикерде. Шулай да аны герой дип йөртмәделәр. Бары тик кызгандылар һәм тиргәделәр генә. Чөнки Харис шулай дуамалланып аягын имгәтте һәм ике айга якын урын өстендә ятты. Шуның аркасында ул мәктәпкә дә бер елга соңга калып керде...

Зиннәт абзыйның сөйли башларга ашыкмавын күреп, малайлар үзара сөйләшә башладылар.

– Юк, Хаҗинур, – диде Харис. – Син герой була алмас идең...

– Әйе!.. Була алмас иде менә!..

Малайларның бәхәсләшүен тыңлап утырган Зиннәт абзый да сүзгә кушылды:

– Алай димә, Харис энем. Ни өчен Хаҗинур герой була алмасын ди?.. Аның бит әтисе дә герой исеме алып һәлак булды. Ул Рейхстагка Җиңү байрагы кадарга менүчеләр арасында булган...

Зиннәт абзый тыныч кына утырган Хаҗинурга карап алды. Малайның җитди йөзе, зурлар кебек сабыр һәм тыйнак булуы Зиннәт абзыйны күптән гаҗәпләндерә иде инде.

Зиннәт абзый, тезе өстендә яткан камытны алып ташлады да, тәмәке тартудан саргайган мыегын бөтереп, тамагын кырып куйды. Малайлар аның нинди булса берәр вакыйга сөйләргә җыенуын Зиннәт абзыйның күзләре очкынланып китүеннән үк белделәр...

Тик шулвакыт күл ягыннан ниндидер сәер тавыш белән ат кешнәве ишетелде.

Бөтенесе дә, бер кешедәй, тавыш килгән якка борылдылар. Тик, ай болытлар арасында булганлыктан, тирә-як караңгылыкка чумган иде. Шунлыктан малайлар бернәрсә дә күрә алмадылар. Ат яңадан кешнәде. Шунда ук кемнеңдер суны чупырдаткан тавышы да ишетелде...

– Нәрсә булган соң ул атка?.. – дип куйды Зиннәт абзый. – Барыгыз әле, кайсыгыз булса да карап килегез...

– Мин барам, – диде Харис, урыныннан сикереп торып, һәм ул, үзенең геройлыгын күрсәтергә теләгән кебек эре-эре атлап, күл буена таба төшеп китте.

Күп тә үтми, су буеннан аның үзәк өзгеч тавыш белән кычкыруы ишетелде.

– Әй!.. Әй... Тизрәк! Ат бата... Тизрәк... «Карлыгач» ба-та!..

Ут янында утырган малайлар сикерешеп тордылар да, этешә-төртешә, күл буена йөгерделәр. Харис әле һаман да кычкыра иде.

– Әй!.. Тизрәк!.. «Карлыгач» ба-та-а!..

– Ни булган аңар?.. – дип куйды беренче булып йөгереп килгән малай.

– Коткарырга кирәк!

– Ул тора алмый...

– Бәлки, аның тышавы су астындагы тамырга эләккәндер.

– Әнә, әнә... Бөтенләй батты...

– Зиннәт абзый!.. Тизрәк... Ба-та-а!..

Кояш баер алдыннан гына тып-тыныч яткан күл өсте хәзер тынычсызланган иде инде. Караңгы булганлыктан, әле генә сукаланып үтелгән буразналар кебек булып күренгән кап-кара дулкыннар, бер-берсен узарга теләгәндәй, каядыр ашыгалар... Судан чыгып торган тамырлар, зәһәр еланнар кебек хәрәкәт иткәндәй, тырпаеп торалар, һәм алар, «Карлыгач»ны гына түгел, теләсә кемне бөтереп алырга хәзерләнгәндәй, тезелешеп утыралар иде.

Берничә тапкыр бөтенләй диярлек дулкыннар астында калган «Карлыгач»,

тагы бер тапкыр тыпырчынып, башын калкытты һәм, «коткарыгыз!» дип әйтергә теләгәндәй, балалар ягына борылып кешнәмәкче булды... Тик бу юлы кешнәү урынына авыр сулау һәм ниндидер ыңгырашу авазы гына ишетелде, һәм «Карлыгач» яңадан дулкыннар астында калды...

– Батты... – дип кычкырды кемдер, елаган тавыш белән.

Харис, кулларын болгап, һаман да әле ярдәмгә Зиннәт абзыйны чакыра иде.

Шулвакыт Хаҗинур Харис кулында ялтырап киткән пәкене күрде, һәм ул, тиз генә аның кулыннан пәкене тартып алып, әле генә «Карлыгач»ны күмеп киткән дулкыннар арасына сикерде дә юк та булды...

Беренче булып су астыннан тышавы киселгән «Карлыгач» атылып чыкты һәм, малайларны бәреп ега язып, яр өстенә сикерде...

«Карлыгач», читлектән ычкынган кош кебек, юеш ялларын җилфердәтеп, пошкыра-пошкыра, яр буенча чабып китте.

Шул арада, чатанлый-чатанлый, Зиннәт абзый да йөгереп килеп җитте. Ул, баштанаяк чыланган һәм пычракка буялган Хаҗинурны күрү белән, эшнең ничек булганлыгын аңлап алды.

– Рәхмәт!.. – диде ул, Хаҗинурны кочаклап. – Менә хәзер Чапаев, һичшиксез, сиңа «молодец» дип әйтер иде.

...Тирә-як тып-тын. Бары тик ашап туйган атлар гына пошкыргалап куялар. Бер кәйгә генә янган учак янында малайлар бер-берсенә елышып, төшләр күрә-күрә йоклыйлар. Зиннәт абзый Хаҗинурның күлмәкләрен киптереп куйды да тагы бер тапкыр атларны карап килергә китте.

Сызылып аткан таң беленде...

– Йә, геройлар, – диде Зиннәт абзый, малайлар янына килеп. – Торыгыз!.. Таң атты...

Малайлар, хәрби тревога вакытындагы кебек, сикерешеп тордылар. Зиннәт абзыйның гимнастёркасын киеп йоклаган Хаҗинур беренче булып сикереп торды.

Зиннәт абзый, малайлар атланып кайтырга тиеш булган атларны тотып, йөгәннәрен кидерә башлады. Ул беренче булып «Карлыгач»ны тотты.

– Кая, бир, – диде Харис, Зиннәт абзый янына йөгереп килде дә, – мин үзем дә атлана беләм...

– Юк инде, Харис энем. Бүгенге көннән «Карлыгач»ка Хаҗинур атланып йөриячәк...

Яңадан чабыш башланды. Иң алда, әкияттәге канатлы ат кебек, «Карлыгач» килә... Ул озын күпер өстеннән, барабан каккан тавыш чыгарып, ике генә сикереп үтте дә авылга да кайтып җитте.

Шул ук көнне колхоз председателе бөтен колхозчылар алдында пионер Хаҗинурга рәхмәт әйтте һәм аны герой дип атады.

Бу турыда хәтта район газетасына да язганнар иде.

*1951 ел*

# УЙ БУЕНЫҢ УЙЛЫ УРАМНАРЫ

Татар тарихының бик күп сәхифәләре Чиләбе өлкәсенең Троицк шәһәре белән бәйле. Ул – танылган рәссамнар, шагыйрь һәм әдипләр, галимнәр ватаны. Монда М.Гафури, Г.Тукай йөргән эзләр саклана, әлеге калада Тукай вафаты алдыннан гына – 1912 елның августында – атаклы галим, монументалист рәссам, портретчы, миниатюралар остасы Ч.Әхмәрев туган. Монда бормаланып, ярларына тулышып, безгә шомлы, данлы ерак гасырлар авазын да, гамен дә җиткергәндәй, уйлы Уй елгасы ага... Уйның җирле тарихчылары хәтерендә Чалла татар (Ярам татар), Кара туры егет тәхәллүсләре белән билгеле һәм милли сүз сәнгатебез тарихында чынбарлыктагыдан лаеклырак урын табарга тиешле Галимов Әкрәм Миннегали улының (1892-1913) кадерле исеме саклана. Дөрес, гади халык арасында онытылуына борчылып, Чиләбе өлкәсе шагыйре Басыйр Рафиков аның турында «хәтердән чыгарылган шагыйрь», дип яза *(Поэт из забвенья // Вперёд. – Троицк, 1993. – 16.01)*. Шулай да Ә.Галимов турынданиндидер мәгълүмат табарга була, чөнки исеме берничә белешмәлеккә, шул исәптән Татар энциклопедиясенә һәм Чиләбе өлкәсенекенә кертелгән.

Ә.Галимов иҗаты, әдәби-мәдәни бәйләнешләре, бигрәк тә шагыйрьнең Тукайга мөнәсәбәтен ачу һәм бу исемне пропагандалау эше белән төп шөгыльләнгән кеше – Троицкида яшәгән рус кешесе А.А.Шмаков[1]. Казакъ галимнәре дә Ә.Галимов иҗатын өйрәнүне туктатмый. Безнең өчен шунысы сөенечле: алар да Ә.Галимов иҗатын милли багланышлар кысаларында яктырта[2] , чөнки ул – XX гасыр башында казакъча һәм татарча иҗат иткән шагыйрь, драматург, журналист; тәрҗемәче; кардәш төрки халыкларга мәгърифәт тараткан татар мөгаллиме. Аны казакълар, татарлар гына түгел, гадәттәгечә, нәсел бәйләнешләре булмаса да, аларча язмаса да, башкортлар да үз язучылары саный. Ә.Галимовның этисе – татар, әнисе – кыргыз. 1913 елда Кустанайда туса да, ул, белем алу максатыннан, Көньяк Җаекта бик мәртәбәле булган «Рәсүлия» мәдрәсәле Троицк шәһәренә күченә. Бу уку йорты аны ныклап торып татар-башкорт һәм казакъ мәдәниятенә алып керә, чөнки егет, анда укыганда ук, бик күп каләм ияләре белән аралаша. Дөрес, ул берара туган җирендә балалар укытып ала, әмма, үз мөмкинлекләрен ныграк ачар өчен, әдәби-иҗади тирәлекле Троицкига әйләнеп кайта.

XX гасыр башында Ә.Галимов әсәрләре «Шура», «Кармак», «Акмулла», «Идел» һ.б. вакытлы матбугат битләрендә дөнья күрә, ул Троицкида чыга торган «Айкап» журналының сәркатибе, «Акмулла»ның әдәби хезмәткәре булып эшли. 1912 елда Казанда Кәримовлар типографиясендә чыккан «Яшьлек җимешләре» («Джегетен джимесдяри»; «Җастык җимесдәре») җыентыгы Тукай язган «Сөткә төшкән тычкан» әсәренең казакъчалаштырылган варианты белән ачыла. Ә.Галимовның бу вакытка исеме төрки халыклар арасында гына түгел, яшь рус язучыларына да яхшы билгеле була, шуңа да карамастан аны русча бастыру мәсьәләсе көн кадагына куелмый. Уночение елның август аенда язган мәкаләсендә Чиләбе шагыйре А.Туркин мөселман әдәбиятының, шул исәптән Ә.Галимов шигырьләренең тәрҗемә ителмәвенә, русларның алар белән үз телләрендә таныш булмавына үкенеч белдерә һәм: «Ул безнең янәшәбездә яшәгәнгә һәм иҗат иткәнгә, үз халкы гамендә булганга, аны бездән яхшырак белгәнгә, бигрәк тә кызганыч. Аның фикерләре нәкъ менә күпне кичергән һәм утлары шәүләләнгән халык улы булганга оригиналь дә», – ди.

Ә.Галимов вафаты матбугатта, бигрәк тә җирле газеталарда киң чагылыш таба[3]. Аның үлеменә хәтта башкала газеталары да битараф калмый. Санкт-Петербургта чыга

[1] Шмаков А.А. Урал литературный: крат. биобиблиогр. слов. / А.А.Шмаков, Т.А.Шмакова. – Челябинск: Юж.-Урал. кн. изд-во, 1988. – 366 с.; Шмаков А. Троицкое литературное гнездо // Урал. – Свердловск, 1967. – №12. – С.170-173; Шмаков А.А. На литературных тропах: [ист.-лит. очерки]. – Челябинск: Юж.-Урал. кн. изд-во, 1969. – 184 с.

[2] Исмаилов Е.К. К вопросу казахско-татарских литературных связей // В поисках нового: [сб. ст.]. – Алма-Ата: Жазуши, 1967. – С.115; Искаков Б. Этапы развития казахско-татарских литературных связей // Казахская литература и её интернациональные связи: [сб. ст.]. – Алма-Ата: Наука, 1973. – С.127-155.

[3] Хроника: Сообщение о смерти У.Галимова // Голос Приуралья. – Челябинск, 1913. – 10 август.

торган «Мөселман газетасы»нда аның үлеме яңарыш, яктылыкка хәрәкәт юлындагы авыр сынауларның берсенә тиңләнә. «Шура» журналы хушлашу сүзе янәшәсендә *(Гафифи С. Шагыйрь Әкрәм Галимовның вафаты // Шура. – 1913. – №17)* шагыйрьнең үз әсәрен дә бастыра. Журналистлар, җирле тарихчылар әдәбият тарихында гаять талантлы, халык зур өметләр баглап, әлеге талантның ачылганын көтеп торган Ә.Галимов онытылганны язса да, аның «Май мәсьәләсе» («Май мәсәдеси») комедиясе, фольклор әсәре сыйфатында, узган гасыр ахырынача халык театрлары, үзешчән артистлар тарафыннан уйналган[4] . Үз заманында әлеге әсәр гаять тә популяр була. 1918 елның 25 гыйнварында, мәсәлән, Уфаның «Новый клуб» залында «Галия» мәдрәсәсендәге «Милли көй, сәхнә һәм әдәбият түгәрәге» файдасына өч бүлектән торган зур кичә үткәрелә, һәм аның беренче бүлегендә Әкрәм Галимовның «Май мәсьәләсе» дигән бер пәрдәлек комедиясе куела, әсәрне тотып торган Гариф мулла ролен С.Кудаш башкара. Икенче бүлектә Ә.Галимов иҗаты яхшы таныш милләт вәкилләреннән – татар, башкорт, казакъ, кырым татарларыннан мәдрәсәнең музыка укытучысы Вильгельм Клименц аерым хорлар оештырып җырлата.

Ә.Галимов шигърияттә Акмулла, Гафури һәм Тукай традицияләрен дәвам итүче санала, Тукайны татарның иң бөек шагыйре һәм үзенең остазы дип хисаплый. Вакытлы матбугатта даими басылган мәкалә һәм фельетоннарын аның калыбында язарга тырыша, казакъ халкының артта калганлыгы, аңа мәгърифәткә юл ачарга кирәклек турында сөйли. Ул сатирик иҗатында иске карашлы, байларга тәлинкә тоткан ишаннарга каршы рәхимсез көрәшә. «Айкап», «Акмулла» журналларында эшләгәндә, шагыйрь үз чорының җитешсезлекләрен, социаль гаделсезлеген, тормыш контрастларын тасвирлый. Аның шул юнәлештә эшчәнлек алып баруына Тукай иҗаты турыдан-туры тәэсир итә. Чалла татар шигырьләре «Шура» журналында, Хаҗитарханда чыккан «Идел» газетасында да дөнья күрә. Ә.Галимов рус телен яхшы белә, Тукай йогынтысында рус әдәбияты белән дә ныклап таныша. Г.Тукай да Ә.Галимов иҗатын даими күзәтеп бара һәм бервакыт сатира-юмор калыбындагы язмасын *(Гөмберт. Матбугатымызның «фәсахәт нәмүнәләре // Ялт-йолт. – 1913. – 15 март)* аңа адреслый. Бу язма Ә.Галимовның Тукайга булган уңай мөнәсәбәтен үзгәртми. Үзенең дә икътисади хәле, сәламәтлеге шәптән булмаган егерме яшьлек егет Ә.Галимов Тукайның вафатын авыр кичерә һәм, хәсрәте чирен көчәйтеп, озак та үтми үлә. Аны җирләү Тукайны күмүне хәтерләтә – шагыйрьне бакыйлыкка озатучылар агымы урамнарны тутырып җыелган яшьләрнең манифестациясенә әверелә. Ә.Галимовны күмәргә дип рус журналистлары да килә. Вафатыннан соң иҗатын анализлаган һәм югары бәя биргән язмалар чыга.

Ә.Галимов, Тукай кебек үк, бик авыр һәм ярлы тормышта, һичбер ялсыз эшләп яши, үзе хезмәт иткән редакциядә төннәр буе утыра, журнал саннарының чыгуына башыннан ахырына кадәр үзендә җаваплылык сизә. Әйтик, «Айкап»ның номерын тапшыру көннәрендә ахыргача өенә кайтып китми торган була. Шагыйрь хәтта гонорар сорарга кыенсына, кайбер журналларга бушка гына яза.

Сәйфи Кудаш «Яшьлек эзләре буйлап» хезмәтендә *(1964. – Б.49-51; 66-68)* Ә.Галимовка да туктала, әмма аның турындагы сүзләре гел Тукайга мөнәсәбәтлеләре белән кушылып китә. Ул 1911 елда Кустанайда Хәлил Абзалимов, Рәсүл Мөхәммәдиев исемле приказщиклар һәм яшь шагыйрьләрдән Вәлиулла Хәлили белән Әкрәм Галимовның һәвәскәр труппа төзүен, ә режиссураны рус артисты Павел Сысинга тапшыруларын сөйли. Труппа «Казанга сәяхәт» тирәсендә оешкан бер актлы комедия уйный һәм программаның икенче өлешенә кертелгән шигырьләр арасында Г.Тукайныкылар да була.

Ә.Галимов – бәхәссез, Уй буе шәһәрләренең урамнарын уйлы иткән, бу төбәктә Тукай иҗатын таратуга көч куйган һәм иртә үлеме әдәбиятыбыз өчен гаять үкенечле булган шагыйрь. Һич югы яшьтәш әһле каләм белсен өчен, кулларына алып карарга китапханәләрдә җыентыгы да юк шагыйрьдер.

**Рифә РАХМАН**

[4] Метелева Н.Ф. Галимов Укрем Минлегалимович // Календарь знаменательных и памятных дат / сост.: Э.А.Абхаликова, Л.А.Величкина, И.Н.Пережогина. – Челябинск, 2011. – С.144-146.

Зәки
Вәлиди Туган

# ХАТИРӘЛӘР

## Әстерхан сәяхәте вә Гомәр углы Гадеррахман

Мин Нәби углы Муса хажи белән Закир Рәми бай биргән акчама иң башта Әстерханга, соңыннан Казанга барыр өчен Орынбурдан йөк поезды белән киттем. Юлда Бозаулык шәһәрендә төшеп, Галиәсгар Чагатай исемле имам вә мөхәррир белән күрештем. Бу зат либеральлек максаты илә пәйгамбәребезнең хатыны Гайшәне яманлап, бер әсәр чыгарган иде. Әңгәмәбездән бу мәүзугка кагылышлы язганнарын урыс миссионерларының әсәрләреннән алганлыгын әйтте, өендә Ислам тарихи чыганакларының берсен дә күрмәдем. Самарада «Икътисад» исемле бер журнал чыгарырга уйлаган имам Фатих Мортазин белән күрештем, зыялы бер зат иде ул. Аның белән милли тормышыбызга кагылышлы бик күп ихлас әңгәмәләр узгардык. Ул миңа икътисад белеме алу, мөгаллимнәр мәктәбен тәмамлау белән генә чикләнеп калмыйча, университетка керү юлларын карарга кирәклеге турында әйтте. Самарадан пароход белән Әстерханга киттем. Әстерханга баруымның бердәнбер сәбәбе: «Идел» исемле гәзитәне чыгара башлаучы Габдеррахман Гомәров белән күрешү иде. Каранугай түркләреннән булган бу зат Казанда Мәрҗани мәдрәсәсендә агам Хәбиб Нәҗҗарның шәкерте булган, мин кечкенә чакта берзаман остазын эзләп, авылыбызга килгән иде, агам Вәли мулла белән дә атам белән бөтен югары Агыйдел, Җаек буйларын гизеп, борынгы Нугай дастаннарында искә алынган җирләрне, Ирәмәл, Шыкмамай вә башка җәйләүләрне күреп кайттылар. Мулла агам, атам белән гел хат алыша торганнар иде. Бу зат Әстерханның читендә, «Тирәк» дип аталган җирендә яши икән. Ул мине өендә кунак итте. Әстерхан тирәсендәге нугай авылларын күрсәтте. Бу шәхес борынгы түрк дастаннарына муеннан гашыйк кеше иде. Шул турыда әзерләгән әсәрләре дә бар икән. Бер өлешен рисалә шәкелендә бастырып та чыгарган. Ул гарәп теле вә әдәбиятын су кебек эчкән, белеме мөкәммәл. «Кафия» исемендә гарәп теле грамматикасын тәрҗемә итеп бастырып чыгарган. Мин аңа укырга теләгем турында әйттем. Ул минем язма эшләрем турында белгәч, үз нәшриятында мөхәррир сыйфатында Әстерханда калуымны үтенде, өйләнергә дә тәкъдим итте. Ләкин мин Казанга барып, бары тик уку эшләре белән генә шөгыльләнәчәкмен, дигәч, мине пароходка утыртып җибәрде.

Бу пароходның йөкләре арасында ярымкачак хәлендә Казанга менеп киттем. Казанга җиткәнче, бер пристаньда төшеп, акча эшләп алырга иде. Саратовны узгач, Балаков пристанендә төшеп калдым. Пароходтагы кешеләрнең киңәше белән, мин Прохоров атамалы бер урыс авылына җәяү киттем. Аркамда Әстерханда тектереп алган кышкы кием, китапларым бар. Утыз чакрым юл, бара-бара аякларым кабарды, ахшам өсте бу авылга килеп җиттем. Бер чәйханәгә кереп, Ибраһим Качкынбайга, анама хат яздым. Нинди кыен хәлгә төшкәнемне аңлаттым. Укырга дәртем аркасында бу кыенлыкларны күрергә әзермен, дидем. Атама хат язарга җөрьәт итмәдем, чөнки аның миңа үпкәсе бар. Бу хуҗалыкта ашлык суктыру машинасында мин 15 көн эшләдем. Бу эшем шактый күңелле иде. Бәлки, 25 көнгә калып эшләрмен, дидем, суктыру машинасы сафтан чыкты, хуҗалык идарәсе мөдире (управляющий) машинаның көйсезләнгәнен миннән күрде, ачулана башлады. Миңа кыен булды, җаным кысылды. «Тырышып

*Дәвамы. Башы 7, 8, 10нчы саннарда.*

эшләгән акчам харам булсын!» дип, мин, нахакка рәнҗетелгән кеше буларак, хакымны түләп, араны өзүләрен теләдем. Мөдир үз хатасын аңлап, уналты көн эшләгәнемә акча бирде. Хәләл көчем белән тапкан акчам исраф булмасын, дип, Балаков пристинена тагын җәяү киттем. Бер көн пароход көтәргә кирәк иде. «Кәмәлек» ыруыннан бер башкорт кешесе үз авылына кайтырга тора икән.

– Мине алырсыңмы? Минем Кәмәлекне күрәсем килә, чөнки борынгы дастаннардан Иштуган шунда вафат булган, – дидем.

Ул шатланып риза булды. Без «Чулак» исемле бер җиргә килеп җиттек. 1917 елда Башкортстан хәрәкәтендә Кәмәлек башкортларыннан күп зыялылар безнең хәрәкәттә катнаштылар. Бу сәфәрем моннан тугыз ел соңыннан булачак вакыйгалар өчен бик файдалы булачак. Иртәгесе көн тагын пристаньга баручы бер агайга утырып, Балаковага юл алдым. Пароходка өлгермәдем, башка бер көймә көтәргә туры килде. Шушы форсаттан файдаланып, мин анам вә Ибраһимга урыс авылында эшләвемне, Кәмәлек сәфәремне аңлатып, озын-озын хатлар яздым. Минем бер шигырь дә язганым булмады, әмма бу маҗараларымны мин шигырь белән язганмын икән. Соңыннан белдем, минем бу шигъри хатымны кулдан-кулга йөртеп күчереп алганнар. Пароходта Пушкинның «Пугачёв гыйсъяны» исемле әсәренең тәрҗемәсе белән шөгыльләнә башладым.

## Мәрҗани вә аның әсәрләре

Казанга килеп җитәр-җитмәстән, агамның остазын эзләп табар өчен, Мәрҗани мәдрәсәсен, аның углы Борһан мулланың йортына киттем. Мәдрәсәсендәге мөдәррис Сафи хәзрәт вә хәлфәләре белән сөйләштем. Мәрҗани, чыннан да, соңгы гасырларда Русия мөселманнары арасыннан үсеп чыккан иң бөек галим. Ул – урыс шәрекъчылары (востоковеды) арасында да танылган шәхес. Аларның гыйльми конгрессларында катнашып килә. Ләкин аның мәдрәсәсендә идарә эшләрен башкаручы Сафи хәзрәт мине ошатмады. Касыйм хәзрәт, аның иярченнәре белән минем мөнәсәбәтем яхшы иде. Әмма агамның тәрбия күргән урынын, Мәрҗани мохитен үз мохитем кебек хис иттем. Аның углы Борһан мулланың вә казанлыларның бөеге Галимҗан Барудиның китапханәләрендә Мәрҗанинең басылып чыккан «Вафият әл-Аслаф» исемендә сигез томлык гарәпчә тарих китабын укып чыктым. Бу әсәрнең тәкъдим сүзе генә дә үзе бер том хасил итә. Гарәп фәйләсүфе ибн Халдунга баш орып язган бу «Мөкаддимә»сендә Мәрҗани бераз либераль фикерләрен уртага ташлый. Мәрҗани бу бөек әсәрен 1881 елда бастырып чыгарган «Мунтаһаб әл-Вафия» исемле гарәпчә аңлатмасында да белгерткәне кебек, хәлифәләр тарихына, Ислам галимнәренең тәрҗемәи хәлләренә йөз тотып эшләгән, соңгы томнарында Идел буйлары, Төркестан вә Госманлы галимнәренең тарихын язды. Бу бөек әсәр хакында бала чагымнан бирле бер шәйләр ишеткән булсам да, кулыма алып уку минем өчен чиксез ләззәт иде. Бүген бу бөек әсәр урыс телендә Казан университеты китапханәсендә саклана, ләкин аның кыскача эчтәлеге дә, хәтта аның күрсәткечләре дә тәртипкә китерелмәгән. Бу әсәрнең фотокүчермәсен Истанбул университетына китертү эшен Төркиянең Мәскәүдәге илчесе профессор Гали Мозаффар бәй аша йөретсәк тә, тиешле нәтиҗәләргә ирешә алмадык. Мин 1908-1909 елларда бу сигез томлык әсәрне баштанаяк укып, бер томының эчтәлек күрсәкечен эшләп куйдым. 1915 елда Мәрҗанинең 100 еллыгы бәйрәменә Казан университетының Археология җәмгыяте минем аннотациянең эчтәлеген чыгарды, анысы да урысча басылган иде. Көнчыгыш төркләре арасында узган гасырда шушы бик тә мөһим әсәрне – культура тарихын – өйрәнүче кеше табылмаганына хәйран каласың. Һәрхәлдә, Казан татарлары арасында соңгы заманнарда гарәпчәне тирәнтен белгән тарихчы шәхес тәрбияләнмәгән, күрәсең, ни кызганыч.

## Казан ислахчылары (реформаторлары)

Казан татарлары арасында бу араларда милли мәйданнарда киң реформаларга сусаган яшьләр, мәктәпләрнең заманча үзгәртелүен теләүче егетләр мохите барлыкка килде. Чынлыкта мин Казанда күп кеше белән аралашмый идем. Алар «Әл-ислах» дигән гәзитә дә чыгара башладылар. Мин бу ислахчылар белән көрештем. Ләкин

аларның төгәл планы юк, фикерләрен дә нигезсез дип таптым. Болар үзләре укыган татар мәдрәсәләрен һәм гимназиягә, инженерлар әзерләүче мәктәпкә яки университетка әверелдерү теләге белән яна. Минемчә, хакыйкатән, искергән татар мәдрәсәләрен бары тик ике тип урта мәктәпкә әйләндерергә кирәк. Берсе христианнарда булганы кебек, «теологик семинарияләр» (дини мәктәпләр), икенчесе – «мөгаллимнәр мәктәбе» шикелле уку йортлары. Шушы турыда «Бәянелхак» исемле татар гәзитенә бер мәкалә яздым. Бу фикер зыялы ислахчыларның башка бер төркеменең хушына китмәде. Шагыйрь Габдулла Тукай бу мәкалә мөнәсәбәте илә бер шигырь, Фатих Әмирхан атлы мөхәррир бер-ике мәкалә бастырды. Ләкин алар бу мәкаләмне Габдулла Гыйсмәти кушаматы белән башка берсе язган, дип уйладылар. Мәкаләләре тупас тел белән язылган иде. Габдулла Тукай исә минем язмамны мыскыл итү максаты илә: ул зыялыдыр, беләмсең, мәгърифәт хикмәт сата, дип бер каһкаһә язган иде. Бераз вакыт узгач, бер шагыйрь мине Тукай белән таныштырды. Габдулла Гыйсмәти түгел, ул мәкаләне мин язганны аңлагач, Тукай үз шигыренең уңышсыз чыкканлыгын әйтте. Бу шагыйрь әгъза булып саналган төркем, Фатих Әмирхан төркеме хәмер эчә, азгын уеннар уйный икәнен белгәч, мин алар белән бик аралашмадым. Габдулла Тукайның шәхсән Болгар кунакханәсендә тормыш кичерүен белгәч, мин аның янына бик еш бара идем. Габдулла «Әл-ислах» гәзитендә басылган шигырендә минем максатымны ялгыш аңлаганы турында мәкалә язган икән. Гәзитә хуҗасы Фатих Әмирхан тәкәббер вә мәгърур бер кеше булганлыктан, минем тәнкыйтьләремә ачуы чыккан вә Тукайның бу мәкаләсен бастырмаган. Соңыннан үзләре дә аңлады: мәкаләнең ялгыш аңлашылуының сәбәбе – «Бәянелхак» гәзитәсе минем мәкаләнең бер өлешен төшереп калдырган булып чыкты.

## Катанов, Ашмариннар белән танышуым

Исеме телгә алынган Емельянов мине «Урыс булмаганнар өчен урыс теле укытучылары әзерләү мәктәбе»ндә дәрес бирүче, мөгаллим-шәрекъче (ориенталист) Николай Ашмарин белән һәм, ниһаять, профессор (ориенталист) Н.Ф.Катанов белән таныштырды. Шул сәбәпле, мин Казандагы шәрекъчеләр мохите белән дә аралашып киттем. Николай Ашмарин үзе чуваш кешесе икән. Николай Катанов исә Алтайның «Сагай» төркләреннән булып чыкты. Һәр икесе дә – Рус шәркыять институтын бетереп, рус ориенталистлары мохитенә килеп кергән затлар. Мин бу ике шәхестән бик күп файда иттем. Шул елда Ашмаринның «Рус мәгариф Вәкиллеге» («Министерство народного образования») журналында чыккан «Татар әдәбияты» атамалы мәкаләсен урысчадан татарчага тәрҗемә иттем. Бу тәрҗемә соңыннан Орынбурда «Вакыт» матбагасында аерым бер әсәр буларак басылып чыкты. Гомумән, мин Казанда бик мәшгуль идем. Күп укыдым, фәкыйрь тормышта яшәдем. Март аенда атамнан 70 сум акча алдым. Ибраһим да 40 тәңкә акча салган. Анам да, Ибраһимның анасы да бик күп кирәк нәрсәләр, эчке кием-фәлән җибәргәннәр. Бик куандым. Китап сатып алу, мөгаллим имтиханнары өчен түләү мөмкинлеге ачылды. Ашмарин да миңа Глухарёв исемле бер укытучыны табып бирде. Мин урыс әдәбияты, математика, педагогика дәресләр алуымны дәвам иттем.

## Авылымда җәйге татил (каникул)

Май аенда (1909) пароходка утырып Уфага киттем. Анда мәдрәсә ачып, милли дәгъвалар юлында көрәшкән хәлфә Зиятдин Кәмали һәм башка зыялылар белән көрештем. Бу минем губерна шәһәребезне беренче тапкыр күрүем иде. Мин монда башкортларның тарихы белән җитди сурәттә мәшгуль булган Филопенко исемле урыс мөгаллиме белән таныштым. Бу зат берничә еллардан соң үзенең эзләнүләрен, тапкан материалларын аерым китап итеп бастырып чыгарды. Авылыбызга кайттым. Атам да, агам да миңа булган үпкәләрен күптән оныткан. Атам – өйдә абруйлы хөкемдар. Аннан куркып, аны санга сугып торалар, ләкин сорауларына иплӛп җавап биргәндә, канәгать кала иде. Минем Казанда Исламиятне өйрәнеп ятуыма ышанмый, урысча гына укый, дип уйлый.

– Урысларның яхшымы, әллә начармы икәнен өйрәнгәннәреңне сөйлә! – диде.

– Урысның яхшысы аягы астына чаптырыр, яманы муеныбызга камыт тактырыр, – дидем.

Бу сүземне атам бик ошатты. Чөнки атамның уенча, безнең тормыш итүебез вә мәдәниятебез шулкадәр мөкәммәл иде ки, урыслардан вә ауропалылардан техникадан башка һичнәрсәгә өйрәнеп булмас.

Тәмәке тартканымны алар киемемә сеңгән истән белделәр. Урысларга охшаган кием кигәнем дә аларга ошамады. Тәмәке исе атам белән анамның күңелен болгата иде. Алар бу киемнәремне чормага менгезеп элделәр һәм алар күзгә чаклы, авылдан аерылып китәнемә кадәр, шунда эленеп торды. Өйгә кайткан көнне иртән, яраткан кола атыма атланып, тирә-якны карап йөрдем. Кире кайтканда, өй яныннан гына агып ятучы кечкенә инештә электән сөйгәнем мишәр кызы Ләйлибәдәрнең кер чайкаганын күреп алдым. Аның ярәшелгән икәнен ишеттем, бу гүзәл мине күрүгә үк качты. Минем аңа булган самими гыйшкым һич үзгәрмәде. Шушы эчтәлектәге халык такмагын язып, кызның төпчек энесенә бирдем.

*Су буенда керләр чайкый,*
*Талмый микән беләге;*
*Күрше торып, күрә йөреп,*
*Янмый микән йөрәге!*

Ул да миңа язу күндерде.

*Күтенә кигән чалбарының*
*Балаклары тар икән,*
*Коръән өе мәдрәсәдә*
*Тәмәке тарта икән.*
*Кигәне сасык, шул исенә*
*Күрше-күлән төчкерер,*
*Авызы янсын корагорның,*
*Ил янмасын, ди микән?!*

Ул вакытта тәмәке тарту бездә нәҗес эш санала иде. Кыз шул турыда минем йөземә бәрде. Шулай итеп, шушы елның җәй татилендә кызны ара-тирә күрүем миңа ләззәт бирә иде. Ләйлибәдәрнең тәнкыйте тәэсирендә бу татил вакытында, хәтта яшереп булса да, тәмәке тартмадым.

## Күзлек кияргә мәҗбүр итте

Берничә көн өйдә торганнан соң, кола атыма атланып, Яру вә Карагач җәйләүләренә, Ибраһим Качкынбайларга киттем. Ибраһимга никадәр тирән бер мәхәббәт белән бәйле булганымны бер ел аерылып торгач кына аңладым. Юлда барганда, Нәваиның «Чәһрәсе фәрештә кеби вә инсаннар арасында тиңе булмаган бер егет күңлемне биләде, мәгънәсендәге шигырьне яттан сөйләдем. Мин «Карагач йорты»на килгәч, Ибраһим куй чалып, дусларымны чакырды. Болар минем яшьтә (кордаш) иде, аларның барысы да өйләнгән, һәрберсе хатыны янына кайтмыйча, минем бер ел эчендә күргәннәремне, нәрсәләргә өйрәнгәнем турында тыңлап утырдылар. Тукранга ау оештырдык, биләмәләрне карау өчен ат өстендә тауларга каршы ат чаптырдык вә төрле җәйләүләргә йөреп, кымыз эчеп, вакытыбызны бик шәп уздырдык. Бер җайсызлык килеп чыкты. Төнен Нөгеш елгасында шәм белән һәм чатал сәнәк белән салкын суда балык тотканда, суык тидердем. Үпкәм кабармасын, дип курыктым, мине мендәр-ястыклар белән төреп, арбага утыртып, җәйләүдән алып кайтып киттеләр. Бер ай, бәлки, артык тадыр, чирләп яттым. Авырып ятканымда «Биржевые ведомости» гәзитәсенең кушымтасы буларак, чыгарыла торган романнарны укып ятам. Морат Рәмзинең югарыда искә алынган ике томлык тарихи әсәрен, Русиянең Исламга каршы рәнҗетүле гамәлләре хакында

кискен сүзләр белән ачынып язылганына күрә, Рус хөкүмәте ул китапны сатудан алган. Әсәрне бастырып чыгарыр өчен акча бирүче Троицкиның Зәйнулла ишан иде. Зәйнулла хәзрәт китапның тентүдән яшереп калган нөсхәләренең бер өлешен безгә вә агама күндерде. Бу китапларны тарату эше белән атам шөгыльләнде. Мин килешмәгән кайбер урыннары булса да, мине түрк кавемнәренең тарихы белән тирән кызыксынуы илә мәшгулъ булырга мәҗбүр иткән бу әсәрнең байтак урыннарын, патша хөкүмәтенең ачуын чыгарганга, мин кат-кат укыдым. Хаста килеш китап укып ятакта ятканымда, күзләрем бозылды. Моны ятактан торгач, ук ату уенында катнашканда аңладым. Укны өебезгә якын мәчет манарасының һилалыннан (аеннан) чыгарып уйный идек. Мин бу囗 эштә иң алдынгы мәргән (төз атучы) идем. Бу юлы ук атарга дип калкынсам, манара башындагы һилалны күрмәдем. Соңыннан урманга барып, кош аулаганда да, күземнең ерактан яхшы күрмәгәнен аңладым. Шуның нәтиҗәсендә мин өч-дүрт айдан соң, күзлек тагу мәҗбүрендә калдым, гәрчә мин күзлек кияргә яратмый идем.

## Әстерханга икенче сәяхәтем

Көз җиткәч, атам мине тимер юл ыстансасына хәтле озата барды. Агам исә быел Әстерханга кит, дип киңәш итте. Габдеррахман Гомәровка тапшырыр өчен, кайбер бүләкләр белән бер тәпән бал бирде. Быел атам белән Ибраһим Качкынбай берәр ат сатып, акчасын миңа бирделәр. Анам да акча бирде, бу җәһәттән Әстерханга сәяхәтем әйбәт булды. «Идел» гәзитенә мәкаләләр яздым. Болар, гәзит мәкаләсе булулары белән бергә, минем беренче фәнни хезмәтләрем дә иде. Иң башта мин Морад Рәмзинең югарыда аталган әсәрен җентекләп өйрәнеп, тәнкыйть итеп, бер мәкалә бастырдым. Бу язучы Мәрҗанигә хаксыз ябырылган иде. Мин Мәрҗанине алдынгы фикерле дин галиме, Морад Рәмзине исә бер кадимче санаганыма күрә, Мәрҗанине бик каты яклады м вә мәкаләмне «берәүсенең хәрәкәтләре хуш күрелсә, аның гаепләренә дә күз йомалар, берәүсенә ачулары чыкса, аның керле киемнәрендә казына башлыйлар», дип, бер гарәпчә шигырь белән тәмамладым. Бу язмамны Мәрҗанинең шәкертләре вә дуслары бик яхшы каршылады.

Габдеррахман мулла янә Әстерхандагы Габдеррахман Иләков вә Мәхмәт Садыйк исемле башка ике имам белән берлектә «Мәгариф» исемле бер журнал чыгара башладылар. Мине бу журналның нәшер эшләрен башкаручы итеп куярга теләделәр. Беркөнне Садыйк белән Габдеррахман муллалар мине Әстерханга якын бер җирдәге «Соңгыр Түбә» исемле бер тарихи урынны күрсәтәбез, дип каядыр алып киттеләр. Бер бай Нугай хаҗиның өендә мөкәммәл Нугай милли ашлары әзерләп куйганнар. Бу затның бик гүзәл бер кызы бар икән, кызны күрсәтәчәкләр икән вә шуңа игътибар итәргә куштылар. Бераздан мин утырган ачык тәрәзә каршыннан ике тәгәрмәчле, өсте каплаулы, «кимә» дип аталган, матур итеп бизәлгән арбадан милли Нугай киемнәре кигән, бик гүзәл бер кыз төште. Бу гадәттән тыш бер манзара иде. Җанымны тартучы гүзәл бер кыз иде бу.

Әстерханга кайткач, мине «Мәгариф» журналының идарәсен үз өстемә алырга һәм Әстерханда торып калырга бик нык кыстадылар. Кыстау гына түгел, бу боерык, фәрман кебек яңгырады. Мин бу тәкъдимне кабул итмәдем, арабызда салкынлык урнашты. Мин дә Габдеррахман мулла өеннән бер кунакханәгә күчендем. Мулла Әстерханнан киткәндә, пароходка билет алу эшен дә оештырмады һәм озатырга да төшмәде. «Идел» гәзитәсенә язган мәкаләләрем өчен дә түләмәде. Ул минем фәкыйрьлегемне белә иде, юкса, мохтаҗлыкта булганыма күрә, алар мине бу эшкә ялларга булганнар. Гәрчә, мин Әстерханда «мөхәррир» буларак, берәр урынга кереп оялау ниятендә түгел идем. Әстерханнан киткәч, Габдеррахман муллага язган озын хатымда мин боларның барысын да аңлаттым. Баш мөхәррир вазифаларыннан баш тартуымның сәбәбе – журнал наширләренең дини мәүзуглар белән артык кызыксынуы һәм бу мәсьәләдә аларның кире фикерле бәндәләр булуы иде вә кайбер четерекле мәсьәләләрдә артык кычкырып бәхәсләшүебез, аларның каткан фикерләрен үзгәртә алмаячагын аңлаганга күрә булды. Гомәровның миңа боерык биреп сөйләшүендә иде ул сәбәп, дидем.

Габдеррахман белән Мөхәммәд Садыйк муллаларның Әстерханга якын Нугай авылында бер бай хаҗиның өендә күрсәткән кыз һич акылымнан чыкмый. Баштанаяк

Нугай милли киемнәргә төренгән, бизәнгән, гадәттән тыш гүзәл кыз, төркчә укый-яза белә торган бу гүзәлгә хат язарга вә киләсе елда Әстерханга тагын киләчәгем турында әйтергәме-юкмы дип, бик җитди уйладым. Ләкин гарәпләрнең мәшһүр хәрби җитәкчеләреннән Мухалләб ибн Аби Суфрадан: «Сугышта син ничек җиңү яуладың?» дип сорагач, ул: «Һәр эштә алдан күрүчәнлегем һәм дәртемне, алгысуымны җиңүем аркасында», – дип җавапланган, диләр. Бу сүзләр шулкадәр хушыма китте ки, мин гүзәлгә хат язудан ваз кичтем. Миңа, белем алып, алга барырга кирәк, һич тә өйләнергә түгел, дидем.

Әстерханга икенче сәфәремнең башка бер кызыклы нәтиҗәләре дә булды. Анда Җәмил исемле авыл имамының кулында борынгы Ислам тарихына кагылышлы милади 889 елда вафат иткән ибн Котәйбә исемле бер затның танылган «Әл-имама вәлсиясәт» атлы әсәренең язма нөсхәсен табып, «Идел» гәзитәсенә мәкалә яздым. Бу әсәрдә «яман хөкемдарлар» дип саналган Әмәви хәлифәләре күккә чөеп мактала, исемнәре изге саналган кайбер сәхәбәләр тәнкыйть ителә, бу әсәрне мин бик ошаттым. Шул заманның бөек галиме сыйфаты илә югарыда искә алынган Ризаэддин Фәхреддин бу мөһим әсәрнең Әстерханда табылганына ышанырга теләмәде, бәлки, башка бер әсәрне ялгышлык белән әсәр буларак кабул иткәнмендер, дип шикләнде. Китапның нөсхәсен аңа күрсәттем. Җентекләп тикшерде вә минем дөрес сөйләгәнемне аңлады. Әсәрдә имамәт хакындагы фикерләрне дә, «Идел» гәзитәсендә дөрес язганымны күргәч, миңа карата арабызда һичбер вакыт какшамаган бер ышаныч хасил булды. Бу турыда ул үз теле белән, 1926 елда Истанбулга килгәч, өемдә кунак булганда әйтте. Чыннан да, бу ике мәкаләм, бер тарафтан, төрк кавемнәре тарихына, икенче яктан, Ислам тарихына кагылышлы эзләнүләремнең башлангычы иде.

## Пароходыбызның капитан ярдәмчесе

Мин Әстерхан сәфәремне һәм Мәрҗанинең шәкертләре арасыннан чыккан бөек галимнең заманына кагылышлы хатирәләрне тыңлап кичердем. Идел суы буйлап Казанга китеп барышымда Мәрҗанинең Ислам гыйлеменә кагылышлы бөтен фикерләрен бергә туплап язылган «Бөек юл» (әл-Тарикать әл-Мутхла) атлы әсәрен укып вакыт уздырдым. Җәйге айларда укыган урысча әсәрләрдән Җ.В.Дрэперның «Дин белән фәннең каршылыклары», профессор Овсянико-Куликовскийның «Урыс интеллигентлары тарихы» исемле әсәрләре.

Суыклар бик иртә башланды. Кар яуды һәм пароходыбызны боз тотты, ул төнлә йөри алмый иде. Ярый әле, бу әсәрләрне юлга алганмын. Дрэперның әсәрләрендәге либераль фикерләр миңа электән, Төркиядә Әхмәт Мидхәт әфәнденең нәшрияты мәйданга чыгарган китапларыннан ук таныш иде. Бу юлы урысчасын өйрәнеп чыктым. Төрекчәсе җентекле тәрҗемә иде, урысчага тәрҗемәсе исә католик дошманлыгы белән сугарылган иде. Бу китап вә Овсянико-Куликовскийның әсәре тормышымда миңа бик нык йогынты ясаган хезмәтләр булды. Юлда Царицында (хәзер – Сталинград) сатып алган бер сандык «әнис» дип аталган кечкенә баллы алмалар эшкә ярап куйды. Мин бара торган өченче классның бүлмәләре юк, суыктан карыш-карыш калтырап утырам. Пароход капитаны ярдәмчесе, минем яннан узып барганда, кулымдагы китапка күз ташлаганын сиздем. Беркөнне ул мине югарыга, үз каютасына чакырды.

– Мөселманнардан бу китаплар белән кызыксынган беркемне дә күргәнем булмады, биредә кал, – дип, мине бер матросның җылы бүлмәсенә урнаштырды. Мишкин исемле бу капитан ярдәмчесе бик тә зыялы, укымышлы кеше булып чыкты. Бу китаплар анда да бар икән, укый икән. Сембер каласыннан, андагы татарлардан Акчуриннарны бик яхшы белә. Укый торган гарәпчә әсәрнең ни турында икәнен дә сорады. Адресын бирде. Соңыннан миңа Р. Милюковның «Рус мәдәниятенең тарихы» китабын вә Дрэперның «Аурупа зыялылары хәрәкәтенең тарихы» атлы әсәренең урысчага тәрҗемәсен вә Чернышевскийның бер-ике китабын бүләк итте. Бу зат минем Сембердәге Ибраһим Акчурин исемле зыялы зат белән танышуыма да арадашчы булды. Советлар дәверендә вафат иткән Ибраһим бәй урысчадан башка алманча, чагатайча, уйгырча да белә иде. Бер ел соңра мин, Сембергә барып, Ибраһим бәйдә кунак булдым. 1923 елда Русиядән

киткәнчегә чаклы күрешеп, уйгыр хәрефләре белән хатлар алыштык, Ибраһим бәй вә гаиләсе миңа иң нык тәэсир иткән инсаннардан булды. Бу гаилә белән таныштырганына күрә, капитанга һәрчак миннәтдар (канәгать) булып калдым. Пароходыбыз, бозларны вата-вата, мең бәла белән, Казанга килеп җитте. Без дусларча хушлаштык. Кызганыч ки, без кабат күрешә алмадык.

## Казандагы мөгаллимлегем вә урыс мохите

Бу 1909-1910 уку елында мине «Касыймия» мәдрәсәсенә төрк тарихы вә гарәп әдәбияты тарихы укытырга куйдылар. Казанның урыс мәхәлләләрендә зур авыл хуҗалыгы җирләрендә урнашкан пансионда бер бүлмә алдым, бу пансионның хуҗасы Шалыгин атлы кеше иде. Гаиләсендә кеше бик күп. Аның улы Николай (Коля) белән дуслашып алдым. Ул табиблыкка укый. Икебез бер бүлмәдә яшибез. Алар миннән көләләр, дуңгыз ите ашатмак булалар, ләкин аларның бу эшләре барып чыкмый иде. Мин аларга күчтәнәчкә килгән җылкы итен ашатырга телим, каз ите дип ялганлап, тәки ашаттым бит, дип куандым, ләкин мин биргән җылкы казысын алар ат ите икәнен белеп ашаганнар икән. Анам миңа кышын почта аша бик күп итеп катырган пилмән җибәрә торган иде. Мин бу гаиләдә ике ел тордым. Бик тату яшәдек. Болар Казанда бары тик кышын балаларын укытыр өчен генә яши. Мин, дәрес китабы буларак, «Төрк тарихы» атлы әсәремне яза башладым. Тарихи эзләнүләр һәм материалларны туплап, тарих язу ысулын профессор Кареевның шушы мәүзугка кагылышлы бер әсәреннән өйрәнеп, дәресләр бирәм. Соңрак өйрәнгән бу әсәр Алман профессоры Е.Бернхейм белән француз тарихчысы Сейнобосның тарих методологиясенә кагылышлы әсәрләрдән сөземтә (мәгълүмат) генә булган икән. Соңыннан, тарихны өйрәнү ысулы турында китап язганда, бу ике галимнең китапларыннан мин нык файдаландым. Һәм мин профессор Кареевка бу ике галимне 40 ел әүвәл танытканлыгы өчен һәм миңа күп вакытымны янга калдырырга ярдәм иткәне өчен бик тә рәхмәтлемен. Кареев тарихны дөрес аңлаткан икән. Петербургта яшәүче мәшһүр шәрекъче, профессор Бартольдның Урта Азия тарихына кагылышлы таш басма язмаларын укыйм. Бу юлы милли тарихыбызга кагылышлы мәгълүматны туплаган Карамзин вә Соловьёвларның урыс тарихына кагылышлы әсәрләрен вә урыс елъязмачыларын өйрәнгәнем кеби, француз галиме Леон Каюнның вә инглиз галиме Генри Ховорсның төрк вә монгол тарихына кагылышлы әсәрләрен урыс телендә укыдым. Леон Каюнның әсәре Е.Лависс Рамбауд тарихына караган кыска өлешенең урысчасы Ташкентта «Урта Азия» мәҗмугасында басылып чыкты. Тулысы белән башкорт арасыннан күтәрелгән адвокат Галиәсгар Сыртланов тарафыннан урысчага тәрҗемә ителеп чыкты. Бу китапны мин Уфада генерал Шәехгали гаиләсеннән алган идем. Ховорс әсәренең Чыңгыз ханга кагылышлы өлешенең урысчасы Ташкентта «Урта Азия» журналында басылып чыкты. Боларны укып чыкканнан соң, төрк кавемнәренең тарихын өйрәнүдә мин дөрес юлда булганымны аңладым. Профессор Катановның ярдәме илә – Гареп, Лондон, Лейденнан, башка бер тарафтан – Ташкентта, Бакуда шәрекъ китаплары сата торган китапчылардан тарихка кагылышлы чыганаклар алдыра башладым. Катановның ярдәме илә мин Лондондагы китапчы Люзактан фарсыча Мирхонд вә Хантимер тарихларына вә Бабур мирза хатирәләренең төп нөсхәләрен алдырдым. Д-Оссон вә Ховорсның монгол тарихына кагылышлы әсәрләреннән урысча чыгарылганнарын укысам да, бу әсәрләрнең төп нөсхәләрен үзем укыр өчен, французчамны ныгыту вә инглиз телен шәпләп өйрәнү зарурлыгында калдым.

Мәдрәсәдә мөгаллим буларак эшләвем өстенә «Урыс булмаганнар өчен мөгаллимнәр мәктәбе»ндә һәм дә лицейның программаларына күрә, имтихан тапшыру өчен әзерлек дәресләренә йөрүемне дәвам итәм. Лицейга имтихан бирәлмәсәм, һич тә булмаса, урыс теле укытучысы булырмын, дидем. Имтихан әзерлеге дәресләре бирүче латинча, алманча вә математика өйрәтүче ике зат (Рыклицкий белән Арбеков) мине урыс зыялылары мохитенә алып керде. Шулай итеп, мин еш кына урыс шәһәр театрына йөри башладым. Бу минем өчен яңа бер галәм иде. Бер тапкыр операга бардым, Шаляпин башкаруында «Король Лир»ны тыңладым. Соңыннан бу бөек

сәнгатькәрне 1934 елда Австрияда Кицбюэльдә очраттым да мин аның җырлавын беренче тапкыр Казанда тыңлаганымны сөйләп бирдем. Өйләрендә кунак булганым бар, Шаляпинның гаиләсе байтак кына урыс зыялылары белән танышуыма сәбәпче булды. Бу гаиләнең кызлары белән мәҗлесләргә, танцаларга йөрим. Кызлары Татьяна белән, боз каткач, Кабан күле өстендә тимераякта бергә шуабыз. Шаляпин гаиләсенең бөтен әһелләре дә мине бик хуп күрәләр. Ләкин арабыздагы дин аермасы бу дуслыкны һәрдаим бер чиктә тота иде. Мин аракы эчмим, алар мине һичбервакыт аракы эчәргә кыстамады. Боларның китапханәсендә урыс классикларының китаплары бик күп иде. Мин аларны йотлыгып укыйм. Мәдрәсәбездә миннән әүвәл төрк тарихы да, гарәп теле-әдәбияты да дәрес буларак укытылмаган. Әмма мин алып килгән яңалык һәр шәкертнең күңеленә ята, барысы да канәгать. Шәкертләрем бик күп, алар шәкерт кенә түгел, алар минем ярдәмчеләрем дә иде. Шәкертләремнең берсе үзенең авылыннан Тимер угыллары заманында яшәгән Сәмәркандлы төрекмән бәге Дәүләтшаһның фарсыча «Шагыйрьләр тәзкирәсе» әсәрен миңа бүләк итте. Әстерханда ибн Кутэйбәнең гарәпчә һәм Дәүләтшаһның фарсыча әсәрләренең монда табылуы миңа мәмләкәтебезнең Ислам, аеруча Урта Азия мәдәнияте әсәрләренең «эзләсәң, табарсың» мәкален исемә төшерде. Миндә язма әсәрләрне эзләп табу уе ныгып бара иде. Татар галиме Шиһабетдин Мәрҗани белән Казанда яшәгән алман шәрекъчесе Готвальд узган гасырга кагылышлы берничә мөһим әсәр тапкан. Мин шәкертләремә: шуның кебек әсәрләрне авылыгызда күрсәгез, миңа хәбәр итегез, дип үтендем вә «Касыймия»дә дүрт ел сөргән мөгаллимлегем вакытында бик күп әсәрләр турында хәбәрләр алдым һәм аларны барып күрдем яки аларны китерттем.

Шәрекъче Френ 1840 елда ук Ислам өлкәләрендә эзләнергә тиешле Ислам мәдәнияте тарихы чыганакларын санап, бер әсәр бастырып чыгарган. Бу китап миңа юл күрсәтүче булды.

Бу елда алманча өйрәтүче мөгаллимем Рыклицкийның алманчаны гарәпчәдән яки фарсыча вә төрекчәдән алманчага тәрҗемә ителгән әсәрләрне, хикәяләрне чагыштыру юлы белән өйрәнүемнең күп файдалы булачагын әйтте. Чагыштыру ысулы урысчамны яхшыртуга бик файда итте. Профессор Катанов та миңа бу ысулның файдалы булачагын сөйләде вә тюрколог Радловның «Төрк кабиләләренең халык әдәбияты үрнәкләре» вә «Котадгу белек» китапларын кулга төшерергә киңәш бирде. Бу мине турыдан-туры төрк кабиләләренең дастаннары белән мәшгуль булырга мәҗбүрләде. Шул ук вакытта профессор Позднеевның «Монгол кабиләләре халык әдәбияты үрнәкләре» китабын өйрәнеп чыктым. Бу эш тикшеренүләремне бары тик төрк кабиләләрен генә түгел, монгол кавемнәрен дә өйрәнүемә сәбәп булды. Тырышуым нәтиҗәсендә «Төрк кавемнәрендә дүрт мисраглы халык җырулары» мәүзугына кагылышлы гыйльми әсәрем барлыкка килде. Быел бу тикшеренүләремнең нәтиҗәләрен «Шура» журналында бастырып чыгардым. Профессор Катанов минем тырышуларымнан бик канәгать калды.

## Динне кабул итүемдә үзгәрешләр

Мин, ике ел дәвамында атам-анамнан еракта булсам да, намазымны ташламадым, тормышта вә фикри хәятемдә, уемда, гамәлләремдә атам-анамның тәэсирендә яши идем. Бу хосус Коръәндә (5: 104; 43: 21), гарәпләр әйткәнчә: «Җаһил вә гафил булсалар да безгә бабаларыбыздан өйрәнгәннәребез бик җитә». Янә Инҗилдә (Иоанна, 8: 41) үзләрен Ибраһим нәселеннән санаган яһүдләрнең ана юлы белән түгел, аталарының ялгыш юлыннан киткән кавемнең ахмаклыгын тасвирлый. Әл-Мәгарри: «Инсаннар аталары артыннан сукырларча ияреп, үз араларына дин пәрдәсе корып куйдылар», дип язды. Бер бүлмәдә яшәүче Коля Шалыгин белән әңгәмәләребездә безнең фикеребез уртак иде: «Аталарыбыздан мирас итеп алган дини догматик ышануларыбыз булмаса, безнең арада аеры-чөере килүгә һич сәбәп табылмас иде». Коля христианлыктан һаман суына бара иде. Ул миңа Шишков исемле бер урыс язучысының Гайсәнең (Иисус) тарихы турындагы яшерен рисаләсен (брошюрасын) укырга бирде. Анда Иисусның тарихи шәхес түгеллеге, ул бары тик попларның уйдырмасы икәне турында язылган

иде. Мин дә аңа әл-Мәгарринең «Мин Брахман падишаһларының вә тарафдарларының йөзләрен сыер сидеге белән юганнарын күреп, шаккаттым, христианнарның да, башка инсаннарның да, хачка кадакланган кешегә берсе дә ярдәмгә килми, бер бичара бәндәгә «Аллаһның углы» дигәннәренә аптырыйм, башка бер кавем «шайтанга таш атам», дип, ерак-ерак илләрдән Мәккәгә җыелалар, гаҗәп, бу кешеләрнең күзе сукырмы? Иса (Христос) килде вә Мусаның шәригатен тыйды, Мөхәммәд биш вакыт намаз укуны кертте, диләр вә үзеннән соң башка бер пәйгамбәр килмәячәген сөйли, шулайдыр, кешеләр иртә белән ахшам арасында адаштылар (юлларын югалттылар)», дип, мин Коля Шалыгинга бу сүзләрнең урысчасын әйттем.

Бу зиһенле кешеләрнең бөтенесе дә бергә җыелып, уртак бер дин табачаклары турында уйлана башладым. Борынгы төркләр токымындагы шаманизм милли дин була алачакмы, дип уйлыйм. Ихтимал, аның табигать дине икәнен искә алсак, «китап диннәре»ннән шаманлыкның бик яхшы яклары бар. Ләкин семит халыклары кебек алга киткән әдәбиятка хуҗа булмаганга, бу башлангыч инанулар төзек бер дини шәкел булып оеша алмаганнар. Шаманизмга кагылышлы Радлов, Михалов, Вербитский вә башкаларның, аеруча Чокан Вәлихановның эзлекле хезмәтләрен укыйм. Чокан Солтанның төпләмәләре кулымнан төшми. Ул да шаманизмны идеаллаштыра, аеруча бу диннең асылы: гамәлләрдән ваз кичеп, тынычлыкка омтылу һәм табигатькә мәхәббәт, минем хушыма китә. Алтай төркләренең вә казакъларның шаман догаларын гарәпчә ислами догаларга караганда мин күп беләм. Ләкин бу башлангыч ышануларның миллионлаган төрк халыкларының зыялыларын бер җиргә туплап, тартып китерерлек кодрәте, магниты юк. Шаманлык төзек бер система шәкелен алалмаган.

1908 елдан бирле Тәүрат вә Инҗилне укыйм. Мин бу динне яратмадым (кабул итәлмадым). Ләкин явызлыкка каршы пассив булырга өйрәтүче буларак, ышанучыларына, бигрәк тә мин белгән урысларга карата хөрмәт уятмады. Инкарь итүчеләрне, хәттин ашканнарны җәзага тартырга гаҗиз калган дин мине канәгатьләндерә алмый. Инҗилдә (Иоханна, 8:1-15) иренә хыянәт иткән фахеш хатынны канун буенча җәзага тартырга кушкан, хәтта Иисус: «Сез бары тик җисеменә (җенесенә) күрә хөкем итәсез, мин исә беркемне дә хөкем итмим», – дигән сүзләрен укыгач, миңа болар бер рыякярлык (ихлассызлык) әсәре, бичара җәмгыятьнең бичара фәлсәфәсе кеби күренде. Христианлык, Дрэперның әйткәне кебек, башта романлыларның золымы астында ыңгырашкан бер төркем яһүдләрнең тоткан дине иде. Инҗил хикәяләр тупламасыннан гыйбарәттер, ул кешенең эчке, тышкы тормышын сурәтләгән мәҗбүри тәгълиматны эчендә тотмый. Һәм Исламият – инсанның эчке-тышкы тормышын төзекләндерүне максат иткән бер диндер. «Җанга – җан, күзгә – күз, колакка – колак, тешкә – теш» принцибы көрәшче, сугышчы бер милләтнең рухиятен чагылдыручы буларак, миңа якын иде. Исламият куәтле хәрби җәмгыятьнең дине буларак барлыкка килде, торабара ул кешенең ихтыярын чикләде, дөньяга карашын тарайтты, гаугаларда үҗәтлек өстенлек ала иде. Ислам белән христианлыкны чәкәштергән швед Пфандерның «Мизан эл-Хак» вә Һиндстанлы Рәхматулла Дәһләвинең «Изһар эл-Хак» исеме белән нәшер ителгән әсәрләре шуңа бер манзара кеби иде. Болар кебек мөтәгассыйплар (фанатиклар) атамның пирләренең пире Ваһаетдин Нәкышбәнд (в.1389) вә Һератлы дин белгече Гали әл-Кари (в.1605) кулларына корал төшсә, Папа Пий Икенчедән дә артык дәһшәт белән сугышкан булырлар иде.

Минем фәлсәфә мөгаллимем Давыдов алып килгән Социал Демократик Партия нәшрияты чыгарган басмаларда Алланы, динне тулысы белән инкарь иткән әсәрләре дә бар иде. Әсманның, галәмнең төрле шәкелләргә керүче аңлы-зиһенле бер Барлык тарафыннан яралтылганын һәм табигый кануннар белән идарә ителгәнен инкарь итүче язулар мине бервакытта да җылытмады. Алла һәм диннең халыклар белән идарә итүе – чынбарлык. Моны инкарь иткәннәр милләтеннән ваз кичеп, үз башына яшәү мәҗбүриятендә калачаклар. Ислам мәмләкәтләрендә милләтенә иҗтимагый вә сәяси мәйданнарда файдалы булырга теләгән дәүләт адәмнәре, дингә формаль гына булса да хөрмәт күрсәткән шәхесләрне, үзләре вафат булгач, үз халкы аны хөрмәтләп, мәрасим итеп, гүргә иңдерәчәк. Бу хәлдә бик мөһим бер мәсьәлә калка: үзеңнең Аллага ышанмаганың турында халыкка әйтергәме, юкмы, әйтеп, хөкүмәт вазифасыннан баш тартыргамы яки,

халкың белән бергә булып, аңа файдалы гамәлләр кылыргамы? Бу хәлдә ихлас сөйләсәм, минем динем нинди дин? 1910 елда, майның берендә, мин шулай уйлап утырам. Шул көнне минем янга килгән шәкертем Госман белән, инде исеме онытылган тагын бер шәкертем бу сорауга җавап бирүемне бик тели иде. Җавабым минем шундый иде: инсан галәмнең барлыкка килүенә шакката, бу яки башка диннең мәрасименә туры килгән бер сурәттә инсан ул йолаларны үти. Мөшкеллеккә төшкәч, ул Аллага сыена, моны атам-анам өйрәткән мәрәсим белән башкарырга кирәк. Ләкин дини йолаларны үтәү дини мәүзуглар хакында хөр уйларны тыймаска тиеш. Дин тотам дип, кеше артыгын кыланмаска тиеш. Дин кешенең ихтыярын алмаска тиеш. Ислам дине рухи азык буларак кабул ителергә тиеш. Минем дингә тартылуым доктор Дрэперныкы кебек. Мөселманлыгым Коръәннең «мәхлук»[1] булганын белгән Габбаси хәлифәсе Мәэмүннеке вә либерал мүтәззиләрнеке[2] кебек.

Дин һәм Исламият хакында бу шәкелдә фикерләсәм дә, мин үземне диннең киң катнашуыннан үземне катгый рәвештә саклау турында да уйлыйм. Намаз белән ураза минем өчен авыр йөк була башлады. Шушы елда мин май аеның унынчы көнендә Казанның «Ташаяк ярминкәсе» дигән базарына киттем. Базарда йөргән чагымда мин бу йөкне өстемнән алып атып, аннан котылырга булдым. Моңа кадәр һич кермәгән урыс мәйханәсенә кердем, бу көнгә чаклы харам санаган ризыклар китерттем, исерткеч тә алдым. Шалыгиннарның «Суконное» мәхәлләсенең өске тарафында югарыда булган өйләренә көчкә кайтып җиттем. Үрне менеп җиткәндә, мин егылыр хәлдә идем. Бүлмәмә керүгә үк, ятакка аудым. Яныма дәрес алыр өчен, минем иң яраткан шәкертем Госман килергә тиеш иде. Ул «шәһәр мәктәбе» дигән урыс мәктәбендә укый һәм авыл хуҗалыгы мәктәбенә кергән бер егет иде. Урыс мәктәбеннән чыгып, Исламча белем алыр өчен, Касыймия мәдрәсәсенә күчте. Тарих дәресләреннән башка минем өйгә килеп, гарәп әдәбиятыннан өстәмә дәрес ала. Ул да, минем кебек белем алыр өчен, Бәйрутка китәргә җыена иде. Дәрес алыр өчен килгәч, мине уңайсыз рәвештә, чишенмичә аунап ятканымны күргән һәм, бакчага чыгып, мин айныганны көтеп утырган. Ул миннән хәлемне сорады, мин дөресен сөйләп бирдем дә Нәваидан бер шигырь сөйләдем:

*Еллар буе шәехнең сүзләрен тыңладым,*
*Фәкать бу сүзләр нә күңлемә бер зәвык,*
*Нә дә рухыма бер ләззәт бирде;*
*Фәкать шәраб сатучы кяферулы бер йотым биргәч,*
*Күңлемә җыр салды, җанымны дәртләндерде.*

Бу ахшам һәр икебез китапларыбызны бер янга куеп, динебез тыйган нәрсәләр турында сөйләшеп, зәвык белән сафа кордык. Госман бу мәсьәләдә минем белән бер фикердә иде. Без бер үк кыенлыкларны күргән икәнбез. Хәзер Госман минем карарымны хуплады. Мәдрәсәдә татар теле укытучысы буларак, мин аны кисәтеп куйдым: беркемгә дә үземнең дини кануннарны бозганымны әйтмәячәкмен. Без аның белән ата-ана үзләштергән дини кануннар белән генә яшәргә ярамаганлыгы турында сөйләштек, тормыш киңрәк, аны өйрәнергә кирәк, кешеләрне фикер (идея) коллыгыннан коткарырга кирәк, кыланып гамәл кылу (подражание) бары тик фән юлына гына буйсынырга тиеш, дигән фикергә килдек. Без Госман белән май аеның унберенче көнендә Идел өстендә пароход белән сәяхәткә чыгарга булдык һәм бергәләп безнең якка – Урал тауларына китәчәк идек. Самара вилаятендә, Мәләкәс исемле салада яшәп ятучы, гарәп теле грамматикасына кагылышлы «Әлфия» исемле әсәрне төркчәгә тәрҗемә итү белән мәшгуль Гатаулла мулла илә хәбәрләштек. Аннан бу китапны юлда укырга-өйрәнергә алачак идек. Бергәләшеп Самарага юл алдык. Юлда Иске Болгар шәһәре хәрабәләрен зиярат иттек. Мәләкәстә Жлобин исемле бер урыс гаиләсенә кунарга кердек. Һәм Гатаулла мулладан бер ай дәрес алдык. «Әлфия» исемле бу әсәрнең бер өлешен әүвәлендә Әхмәд Шинкитидән өйрәнгән идем инде, монда калган өлешләрен мулланың үзеннән өйрәнеп, күңелдән ятладык.

[1] Мәхлук – Коръән Алла тарафыннан төшерелмәгән, кеше кулы белән язылган.
[2] Мүтәззиләр – Алла кешене яралткан, әмма ул адәмнәре язмышына битараф, дип әйтүчеләр.

Урал якларына юлга чыгар алдыннан, бер-ике көн алдан монда бер вакыйга булып алды.

Карт Жлобин улы, хатыны вә килене белән өерелешеп эчәләр. Углы Степан әхтәри уеннарында катнаша (картёжник). Эчәргә акчалары беткәч, болар әйберләрен чыгарып сата. Бу юлы Степан үз әйберләре белән минем Казанда сатып алган яхшы күнитекләремне дә шуыткан. Углына караганда шактый көчле күренгән Жлобин килене белән йоклаган. Боларны өсләрендә тоткан углы атасы белән сугышты. Без Госман белән әхтәри суга идек. Бу хәлләрне күргәч, әхтәриләребезне ташлап, Госман белән карашып алдык. Ни уйлаганыбызны икебез дә аңладык: «Атабыз вә анабыз тарафыннан алга сөрелгән инанычлар буш булса да, без мөселманлыкта калырга тиеш!» дип уйладык без шул чакта. Боларның ата-аналары өйрәткәне үзләренә булсын, дидек. Безнең мохиттә була алмый торган вакыйгаларга шаһит булдык. Мин карар кылдым: бу йорттан тиз чыгып китәргә һәм башка урынга күчәргә яки Мәләкәстән Башкортстанга китәргә! Чөнки шәһәрдә яшәүче урыс халкына караганда, авылда яшәүче урыслар диндар кебек күренә. Ләкин болары да Тәңре каршында җаваплылык вазифасын тәгәл үтәргә күнекмәгән. Христианлык та Исламият кебек, кеше яңадан терелергә вә Тәңре каршында хисап тотарга тиеш, дип өйрәтә, ләкин христианнарда ул төгәллеккә җиткезелмәгән: «инсан бу дөньядан аерылганнан соң үзен йөгәнсез, авызлыксыз иркендә яшәргә хаклы, дип саныймы әллә?» һәм шуңа күрә, христиан дине кешенең рухи (эчке) дөньясына йогынты ясый алмый. Минем бу фикерләрем белән барысы да килешә кебек, хәтта мондагы поп та.

Беркөнне тәрәзә янында утырганымда Галишер Нәваиның шушы шигырен гел кабатлыйм икән, Госман игътибар иткән:

«Һәй, күңел, ярыбыздан аерылдык, без аны рәнҗеттек, башка бер яр эзләек, тауларны, далаларны гизәек, яңа бер дус, яр табаек, Фәкать... эзләнүдән ни чыгар? Эзли-эзли кемне табарсың? Иң яхшысы, иске дустыбызны яңадан табаек та аның күңелен табарга тырышаек».

Госман бу парчаны бик ошатты, өйрәнеп алды, мәгънәсен дә белә. Һәм әйтте:

– Һәй, күңел, дип, син, чыннан да, мине күз алдында тотып әйттеңме? Иске дустыбыз ул – Исламият. Бу җирәнгеч эшләрне күргәч, Исламиятне яңадан эзли башладыңмы? – диде. Мин дә:

– Әлбәттә, – дидем. – Әмма алай гына түгел шул, чөнки Исламият безгә инде иске рәвешендә кайтмаячак!

Бу сүзем Госманны бик кызыксындырды. Исламиятне яңача аңлавымның ниләргә китереп чыгарасы турында ул кат-кат сораштырды. Безгә кайтканнан соң, Урал тауларына менеп йөргәндә, шул турыда тагын кабат-кабат сорады. Аңладым, мине кызыксындырган мәсьәләләр аны да шул ук дәрәҗәдә кызыксындыра икән, ләкин ул аларга җавап табалмый интегә, хәзер ул сорауларга җавапны миннән алырга тели. Ул да, минем кебек, диннәргә карашларны әл-Мәгарринең вә урыс язучысы Шишковның әсәрләреннән өйрәнде: борынгыларның догматик инанулары башкаларга сукырларча иярүдән гыйбарәт икән. Зыялы кеше болардан котылырга тиеш, ул башка дин һәм башка догмалар, сүзләрдән башка – яңа мәгънә эзләргә бурычлы. Безнең эзләнүләребез ике ай буена дәвам итте. Гамәлләребез заяга булмады: без Исламга тугры калдык. Фәкать, без үзебез аңлаганча, аңа бәйле булып калачакбыз. Моннан соң азгын уен – әхтәрине кулыбызга да алмаячакбыз. Хәмерне бары тик аз микъдарда гына кулланачакбыз, намазны бары тик күңелебез кушканча гына укыячакбыз. Мин бу антымнан беркайчан да ваз кичмәдем. Госман да минем кебек антына тугры калгандыр, дип уйлыйм.

Без Мәләкәс саласыннан август башларында киттек, Самара юлы белән минем Ватаныма йөредек. Китәр алдыннан Гатаулла хәзрәтне күреп, җәй көнне эссе вакытларда эшен-көчен ташлап, вакытын безгә дәрес бирүгә сарыф иткәне өчен рәхмәтләр әйттек. Жлобин гаиләсендә күргәннәребезне сөйләп, хәзрәтнең шушындый бер мохиттә, бер авылда яшәвенең никадәр кыенлыгы турында сораштык. Ул әйтте:

– Без аларның мохитеннән тулысы белән аерым яшибез, – диде.

Чыннан да, мөселман-төрк вә христиан-урыс мохите арасындагы бу кадәр контрастны үз гомеремдә минем беркайчан да, бер җирдә дә очратканым булмады.

Һавалар чалт аяз тора, пароход белән Самарага киттек. Бер көн узгач, Шафран пристанена килеп җиттек. Моннан өебезгә 150 чакрым. Каты җилдә, туфракка хәтле иелеп, янә баш калкыткан бодай, арыш басулары арасыннан барабыз. Кайтып җиттек. Өйдә беркем юк. Атамның печән чабу өчен һәр елда күрше авыллардагы кешеләрне чакырып эшләтә торган өмә көне булып чыкты. Өмә булган җиргә – Ирәмәл буйларына киттек. Һәр тарафтан атамның дуслары, туганнары кымыз вә куй ите китерделәр, атам да берничә үгез суйдыртты. Яшь егетләр йөзләрчә башкорт җырларын җырлап, уйнап-шаярып печән чабалар. Икенделәргә печән чабу бетте. Суелган куй вә үгез ите пеште. Аштан соң мәйданны җырчыларга, көрәшчеләргә калдырып, атам йокларга дип, китеп барды: без төн уртасына чаклы уйнадык, биедек, бу – Госман күрмәгән, һич ишетмәгән бер тамаша иде. Ләкин аның бөтен халыкның итне, салманы, токмачны бармаклары белән тотып ашаганнарына исе киткән иде.

Өйдә иртәнге намазга уяттылар. Атамның өйдә юклыгыннан фадаланып, намазны казага калдырдык. Өебездә берничә көн яшәгәннән соң, Госман белән бергә башка авыллардагы туганнар, дуслар янына киттек.

## Фикер инкыйлабының сызланулар китерүе

Бу айларны гел бәхәсләшеп уздырдык, Госманның сорауларына җавапларымны мин аңа хат рәвешендә кыягазга язарга мәҗбүр булдым, Госман киткәч, бу хатларым гаиләбез эчендә зур бер тетрәнү китереп чыгарды. Госман үзенә язып биргән бу хатларны бер китап эченә кыстырып куйган да, шуны Эстәрлетамактагы «Каләм» китапханәсе хуҗасының өендә онытып калдырган. Орынбурдан кунакка килгән һәм Мисырда яки Бәйрутта белем алучы бер татар мөгаллиме Сөнгатуллин Бикбулат белән бергә бу язмамны укыганда шунда бер чит кеше аларны тыңлап торган, ул чит кеше минем турыда башкаларга сөйләгән һәм минем хакта гайбәт таралган. Бер мәҗлестә минем Ислам диненнән чыгуым турында атама сөйләп, атамның кәефен кырганнар. Шул сәбәпле, атамның миңа булган мөнәсәбәте кинәт үзгәрде. Сәбәбе турында һәм язманың «Каләм» китапханәсе хуҗасының кулында булуы, язманы юкка чыгарырга кирәклеге турында миңа анам сөйләде. Атка атландым да җан-фәрманга чаптырып Эстәрлетамакка киттем. «Каләм» китапханәсе мөдиреннән язмамны алдым. Бу язманы укымадым да, күрмәдем дә, дип башкаларга сөйләвен үтендем, ул шулай әйтергә сүз бирде. Өйгә кайттым. Хәлләрне анама аңлатып бирдем һәм атамны тынычландырырга куштым. Ләкин эш болай гына бетмәде. Мин бер ялгыш җибәрдем: язманы юкка чыгардым, димәдем. Атам: язу кайда, дип сорауга ук, ялганлый алмадым, язмамны чыгардым да атама сондым. Арабыз бөтенләе белән бозылды. Минем белән һич сөйләшмәс булды. Иртәнге намазга да мине уятмый башлады. Анам еш кына җылый. Кардәшләремә берни дә әйтмәделәр, әмма алар арабызда ниндидер аңлашылмаучылык булганын һәм гаиләбездә минем ят кешегә әверелүемне сизәләр иде. Атам берничә тапкыр Үтәк авылына барып килде. Әлбәттә, агам белән ни кылачаклары турында карарланырга баргандыр.

1920 елда агам бу язмаларымны табып, истәлеккә булсын дип, миңа тапшырды.

Исеме телгә алынган Әхмәтсанины агам бик тә ярата иде. Агам минем язмамны укырга Әхмәтсанига биргән, монысы язмамны күчереп алган һәм язманы үзе белән Истанбулга алып киткән дә Өскедарда яшәүче Казанлы доктор Сибгатулла Дәүләткилдиевка биргән. Соңыннан Әхмәт бу заттан алып, миңа бирде. Бу минем өчен бик зур шатлык иде, чөнки агам 1920 елда миңа биргән нөсхә Башкортстандагы әврагымда (архивта) калган иде. Җиде сәхифәдән торган бу язмадагы фикерләрнең сөземтәсе шушы иде:

«Белеме булган инсаннар өчен дин – инанудан гыйбарәттер: галәмнәрдә зиһенле (кодрәтле) бер хаким булганына, әсманның, бөек галәмнең зиһниятле бер Барлык (Асыл, Мәгънә) шул зат тарафыннан идарә ителүенә, инсанның җаны үзенең тәне эчендә кичергән дәвердә чикләнеп калмыйча, рух сыйфаты белән вакытлы тәненнән (фани вөҗүдтән) башка да, аерым бер тормыш булачагына ышану «дин» дип атала. Инсаният бу югары Барлык (Асыл) белән элемтәгә керү юлларын эзли. Гавам исә

Аллаһны үз телендә сөйләшүче бер инсан кебек, дип фараз кыла, хәтта үз телендә яки Ибраһим яки Сүрьяни телләрдә сөйләшкән сүзләрне Аллага хас, дип уйлый. Гавам дөньяда күтәреп йөргән вөҗүден (бәдәнен, тәнен) сөякләре белән бергә кабереннән кубарылачак һәм хөкемгә тартылачагына, Аллаһ тарафыннан сорау алыначагына инана. Хәлбуки, Җир кебек ничә миллиардлар, бәлки дә һич санаусыз галәмнәрне яралткан вә алар белән идарә иткән Аллаһның вәгазь кануннары, табигать төзеклеге бар. Кырмыскаларның мәш килүе, Әхмәтнең, Мәхмәтнең эшләре белән маташу Алланың эше түгел, бу Аның вәгазь иткән табигать төзеклегенең эшедер. Инсаннар арасыннан чыккан пәйгамбәрләр хәятнең вә галәмнәрнең башлангычы һәм бетүе, әхлак вә киләчәк дөнья тормышы мәсьәләләре тирәсендә күп уйлау нәтиҗәсендә, башка инсаннар белмәгән бик күп нәрсәләргә өйрәнгән, галәмнәрнең серенә төшенгән вә Аллаһка якынаерга тырышучы өске катлам кешеләре барлыкка килә. Борынгы кавемнәрдә безнең төркләрдә дини йолаларны үтәүчеләр «Кам» белән «Шаман» кебек дини рәһбәрләр пәйда булган. Башка кавемнәр белән чагыштырганда мәдәни булган Семит (яһүд) кавемнәрендә болар пәйгамбәрләр катлавын тәшкил итәләр. Күбесе укый-яза белгән вә халык арасыннан чыккан вә мәдәният дәрәҗәсе белән гавамга күп якын булган бу дини рәһбәрләр инсаннарның миенә фикер вә идеялар сеңдереп, тарихи хикәяләрне халык аңлаган телдә сөйлиләр һәм шуларга ышанырга мәҗбүр итәләр. Кешеләрнең нинди гайрәткә ия икәнен раслар өчен, Коръән җиһангир Зөлкарнәен (Александр Македонский) кыйссасын китерә. Чынлыкта исә, Мәгърип (Көнбатыш) белән Мәшрикны (Көнчыгышны) берләштергән бөек җиңүче (җиһангир), турындагы бу кыйсса, бары тик Македония короле Филиппның углы Александрга кагылышлы дастанның гарәпчәгә күчерелгән бер риваятендәге каһарман гына. Дөресе шулдыр, кем, Коръәнгә байтак кына халык мәсәлләре, мәкальләр, әйтемнәр һәм тарихи вакыйгалар да кергән, Бакара сүрәсендә булган кебек, башка сүрәләрдә дә болар 24 тапкыр кабатлана. Әлбәттә, пәйгамбәрнең үз заманында вә үзеннән бер гасыр әүвәл булган Йеменнең Хабәши үзәнендәге вакыйгаларда катнашкан Әбрәхәгә кагылышлы мәгълүмат, хәтта Гайсә пәйгамбәр турында «Яһүдләр аны үтермәде дә, асмады да, фәкать (үтерелгән бәндә) аларга Гайсә (Иисус) булып кына күренде» дигәне кебек сүзләр, әлбәттә, әкият түгел, тарихтыр. Галимнәр арасында бәхәсләр байтак: «Коръәнне Алла хәрефләр вә сүзләр белән иңдергәнме, әллә, бары тик мәгънәсен генәме?» Шул җөмләдән мөтәззилләр: Аллаһ мәгънәсен генә иңдерде, диләр. Чынлыкта исә бары тик хәрефләр вә сүзләр генә түгел, Коръәндәге пәйгамбәр кыйссаларының вә мәсәлләрнең мәгънәләрен пәйгамбәр заманындагы гарәпләргә яхшылап аңлатыр өчен кулланылган алымнан гыйбарәттер. Ягъни, максат: вакыйгаларның мәгънәләрен гарәпләргә кыйсса, дастан вә мәсәлләр аша аңлату. Коръәндәге кыйссаларның барысын да фәнни чагыштыру ысулын кулланып тикшерсәк, кайсы хикәяләрнең бары тик аңлату өчен генә кулланылганы, кайсыларының чынбарлыкта булган вакыйгалар икәнен исбатласак, борынгы Исраил риваятьләрен чынбарлык, дип кабул иткән христиан миссионерларының Иске Васыять (Ветхий Завет), Яңа Васыятьтәге (Новый Завет) сүзләренең буш булганы үзеннән-үзе аңлашылыр шәт».

Изге китапларыбызда, җөмләдән, Коръәндә кулланылган кыйссаларга кагылышлы 20 яшемдә чакта язган бу фикерләремнең дөреслегенә бүген тагын бер мәртәбә ышандым. Чөнки Семит кавемнәренең аңлавында бүген Баалбекның аякта торган өч нәсел баганасы вә терәкләреннән торган «Ирәм кыйссасы» Коръәндә гарәпләр белгән, аңлаган телдәге киңәшләрдән гыйбарәттер. Коръәндәге «Ибраһим белән Исмәгыйль Кәгъбәнең нигезен корганда» шәкелендә катгый рәвештә аңлаткан вакыйга саф алар (гарәпләр) дастанының бер парчасыдыр. Максат: пәйгамбәребез тәкъдим иткән диннең вә мөселманлыкның бик борынгы булганлыгы, ягъни пәйгамбәрнең үзе тарафыннан уйлап чыгарылган нәрсәләр түгеллеге турында сөйли. Коръәнне бу шәкелдә аңлаганнан соң Исламият минем өчен тагын да ныграк сөекле бер дин рәвешен алды. Гади халык кебек, зыялылар да бу кыйссаларга тарих кебек инансыннар, teләсәләр, хәреф – сүз янында гына торып калмыйча, мәгънәсе тирәсендә дә уйлансыннар, шул чакта бу ике төркем берсе өстенә икенчесе гаеп ташламас иде. Сәләхетдин Руми Коръәннең төрле сурәтле, астарлы гыйбарәләрен бик яхшы белгәнгә күрә, үзенең «Мәснәви»ләренә

яңадан-яңа хикәяләрен керткән. Ләкин бу хикәяләрнең тарихи хакыйкатькә туры килү-килмәве турында ул үзе һич уйламый. Безнең түркләребез арасыннан да пәйгамбәрләр чыккан булса иде, һичшиксез, Коръәндә төрек дастаннарындагы каһарманнар турында да хикәяләр урнашкан булыр иде. Түрк дастаннарында, мәсәлән, хаин булган кешеләрне танытыр өчен, Угыз дастанындагы Көләркин Ябгуның хатынына кагылышлы кыйссалары, гаделлек турында бәян иткән Идегәй дастанындагы «Идегәйнең дөясе»н, «Куркур»ның ихласлыгын түркләрнең инанычы шәкелендә күчереп була иде. Соңгы заманнарда инглиз галимнәреннән Кеннет Краггның «Заман мөселманына кагылышлы дәресләр» исемендә бастырган әсәрләре Коръәндәге кыйссаларның гарәп галәмендә һәм Көнбатышта байтак галимнәрне томнарча әсәр язарга этәргәне турында укыгач, 1910 елдан бирле бу мәүзуглар тирәсендә баш ватам, бу мәүзуглар белән булашу мөмкинлеге чыкканга шөкер итәм. Ләкин атам бу мәсьәләдә башка төрле фикердә тора. Уйларымны белгерткән язмамны укыганнан соң, атам минем мөселманлыктан тәмам ваз кичкәнемә ышанды. Әмма гаиләбез эчендә бер фаҗига шәкелен алган бу мәүзуг турында беркемгә дә сөйләмәде, миңа булган нәфрәтен дә беркемгә дә әйтмәде. Намазга уятмас булса да, башкалар намазга басканда, минем дә намазда катнашуымны тели иде. Бу эшләрен ул фәкать анам аша йөртә иде. Унбиш көнләп булыр, тормышымда атамнан һич ишетмәгән авыр-авыр сүзләр ишетеп, аның нәфрәтен аркамда тоеп яшәдем. Казанга китим, дип уйладым, ләкин бу гамәлем анамның бәгырен өзәчәк иде, гаиләм белән элемтәләрне кисү булыр иде, сабыр иттем, бәлки агам берәр чарасын күрер, дидем. Беркөн атам миңа «калык, агаң янына киттек» диде. Мине үз янына арбага утыртырга теләмәде, «син җайдак барырсың», диде. Үтәк авылына килеп, агам Хәбиб Наҗҗарның өенә кергәндә бөтен туганнарым, анамның Ташбүкән, Ялгызкаен, Яңарыш авылларыннан вә Үтәк авылының үз мәхәлләләрендә имам торучы олы-кече бәрадәрләр вә кияүләре, хатыннары килгән иде. Болар миңа хөкем чыгарырга җыелганнар, дип уйладым. Ләкин сөйләшүләреннән, килгәннәрдән бары тик кайберәүләр генә мәсьәләне аңлаган булырга тиешләр. Кайберләре минем белән бик салкын исәнләште, бәгъзеләре минем белән бик шат әңгәмә корды. Ахшам намазыннан соң кичке аш ашадык. Моннан соң гаиләм миңа хөкем оештырды. Атам бик кырыс сүз башлады. Ул кереш сүзен бетергәч, мин әйттем:

– Ләгыйн лам тантаһи лә-ерҗуманәккә? Бу фикердән ваз кичмәсәм, сине таш атып үтертәчәкмен, дип әйтергә телисеңме? – дидем.

Коръәннән алынган бу гарәпчә сүз, атасы янагач, Ибраһим пәйгамбәрнең атасына әйткән сүзе иде. Атам:

– Юк, улым! – диде. – Сине үз күргәнемә шулай сөйлим, син галимсең, менә каршыма Коръәнне куй! – диде дә җылый башлады, ул сөйли алмас дәрәҗәдә үкси иде. Җизнәм Кәбир мулла сүзгә кушылды:

– Бу язма бер кыягаз гына бит ул, багып карыйк, бу сүзләрнең барысы да аның фикерләреме? – дип мине якларга алынды. Агам Хәбиб Наҗҗар миңа карап әйтте: – Энем, чит-ят мохиттә болганасың вә күп укыйсың, әлбәттә, фикерләреңдә үзгәрешләр булачак, бу турыда атаңа да сөйләдем, синең мөселман булып калырыңа без ышанабыз, ләкин бер нәмә бар: милләтне сакларга комачау иткән һәм башыңа килгән бер гарип фикерне бу илдә һичберкемгә сөйләмә, фикерләреңне һич тә кыягазга язма, моны дошманнарыбыз файдаланачак, бу сүзләр тулганып йөреп, атаңа, миңа, бөтен гаиләбезгә әйләнеп кайтачак. Әнә Шаһшәриф Метинов (иске Дума әгъзасы) синең урысчаны бу кадәр дә яхшы белгәнеңә, адвокат кебек гаризалар яза белүеңә хәйран калган. Без барыбыз да: яшең җиткәч, синең «земство»га (җирле идарәгә), хәтта Думага бу төбәктән әгъзалыкка сайлануыңны телибез.

Соңыннан ястү намазы булды. Намазда бөтен гаиләбез катнашты. Агамның ике хатыны да бик гүзәл иде. Һәр икесе дә укымышлы. Әбием мөбарәк галимә бер хатын иде. Агам имам буларак, безгә намаз укытты. Бу – гаилә намазы, зыялы инсаннарның намазы иде. Коръәнне аңлаган, гарәпчәдән хәбәре булган затлы нәселнең намазы иде. Бу намаздан мин бик мәмнүн калдым. Башка намазларны укыр өчен җамига китәбез. Фәкать ястү генә өйдә укыла. Агам намазда укылмый торган Коръәннең «Әл-Хиҗр» сүрәсен китерде. Шушы сүзләрне салмак кына укыды.

– Боерылганнарны яхшы аңлат вә (Аллаһка) тиң (дип ташка, потка) табынганнардан ерак тор. Сине мыскыллаганнарга каршы көрәшергә Безнең ярдәмебез җитәр. «Аллаһ белән бер дәрәҗәдә», дип алар башка бер уйдырма тәңрегә табына башладылар. Озакламый барысы да ачыкланачак. Син бүгеннән Раббыңа мәдхия укып, тәсбих әйт вә сәҗдә иткәннәр сафында бул. Әҗәлең килгәнгә чаклы Раббыңа гыйбадәт кыл!

Икенче рәкәгатьтә «Фуссиләт» сүрәсеннән ул:

– Раббыбыз, Аллаһ – бер дигәннәргә, дин юлында нык торганнарга фәрештәләр үзләре иңәр, алар курыкмасын вә кайгырмасыннар. Фәрештәләр аларга дөнья вә ахирәт тормышында дус вә аларны саклаучы булачаклар. «Мин, әлбәттә, мөселман» дигән вә Тәңресенә дога кылган кешедән тагын да гүзәлрәк сүзле кем бар? Игелек белән яманлык икесе бер түгел, яманлыкка игелек белән җавап бирсәң, дошманнарыңны тагын дус буларак күрерсең»,– дип дога кылды.

Агамның бу аятьләрне укуы миңа төбәлгән иде. Чөнки ул атам белән чагыштырганда тагын да либеральрәк фикерле шәхес иде. Намаздан соң ул миннән сорады:

– Истикамәт ул ни? – диде дә үз соравына үзе җавапны әйтте. – Үҗәт рәвештә алга бару! Алгысау! Тәвәккәллек, дигән сүз. Хак дип белгән юлыңны шикләнүсез дәвам итмәктер, истикамәт ул буш эшләрне бер кырга ташлап, бөек юлдан югарыга таба менә белү, дигән сүз. Исламда истикамәт вөҗданың, акылың белән дөрес тормыш юлын табу булыр. Син дә югары белем алу юлында иман белән һәм истикамәт белән укуыңны дәвам итсәң, максатларыңа, иншаллаһ, ирешерсең.

Соңыннан тормышта максатыңны белеп, һичкемгә бакмастан, юлыңны дәвам итүнең файдасы, читкә тайпылуларның зарары турында гарәпчә шигъри парчалар, хәдисләр сөйләде. Намаз, дога, үгет-нәсихәтләр беткәч, атам әйтте:

– Менә шулай агаң бөтен мәсьәләләрне хәл итте, – диде.

Агам әйтте:

– Ислам тарихында иң бөек шәхесләрдән Әмәви Вәлид ибн Муавия Коръәнне ертып ата, һәм ертык китапка мөрәҗәгать итеп: бар, кит! Кыямәт килгәч, хуҗаң –Аллаһка сөйлә, Вәлид мине ертып ташлады, диген... Әмәви Мәрван ибн Мөхәммәд белән халифә Мәэмүнне хөр фикерләре өчен «зыйндыйк» дигәннәр. (Мүтәзиләр – дин рәһбәрләренең артыннан сукырларча ияреп баруны инкарь итәләр. Шикләнүләрне дөньяны танып белүдә беренче шарт, дип карыйлар. Гаделлекне һәм Аллаһны бер дип саныйлар.) Әмир Тимер мүтәзилләрне якын күргән. Шамлылар риза булмаган көе, Тимер мүтәзилләрне дүрт мәзхәпкә имам итеп куя. Шуңа күрә, Шамлылар Тимерне «кяфер» дип игълан итәләр. Безнең улыбыз болардан да яманрак мөселман түгелдер, шәт. Аның башына гарип фикерләр килгән икән, андый фикер һәр уйлый торган башка килергә тиеш. Мөселман галимнәре арасында Зөлкарнәеннең Юнан (Грек) хөкемдары Искәндәр-и Кәбир икәнлеген сөйләүчеләр бар, – дип агам сүзен тәмамлады.

Атам әйтте:

– Ләкин углыбыз Әхмәт Мидхәткә түгел, гяур Дрэперга, христиан гарәпләргә вә һәр укыган урыс китабына инана вә фикерен үзгәртә, – диде.

Агам аңа каршы:

– Фикер үзгәрмәсен дип, китап укудан качып та булмас! – диде.

Бу сүзләрдән һәм намаздан соң бөтен гаиләбезнең кальбендәге киеренкелек уздыкитте. Агам әйтте:

– Солтаннарның остазы Хызыр бәй углы Синанэтдин дә шулай булган, икеләнгән, шикләнгән, фәкать шәех Вафаның ярдәме белән тугры юлга төшкән вә Фатих Солтан Мәхмәткә мөгаллим булган. Иншалла, Әхмәт Зәки дә үз юлын табар, – диде.

Атам әйтте:

– Бары тик аның шәех Вафасы христиан яки денсез булмасын! – диде.

Агам:

– Юк! Ул нәрсә булмас! Монда бер хата бар, башына килгән фикерләрне кыягазга язган вә гайбәтләргә юл ачкан. Моннан соң фикерләреңне кыягазга язмассың! – диде.

Мине яргулаган (хөкем иткән) гаиләбездә бимазалар тудырган бу мохитне бер намаз дәвамында, Коръәннән мисаллар китереп, арабызны татулаштыру гадәттән тыш бер вакыйга булды. Монда беренче тапкыр буларак, катгыян мәгълүм булды ки: агам

төгәл мәгънәсендә либераль фикерле шәхес икәне ачыкланды. Ул минем фикерләрем белән эчтән килешә, аларны фикер буларак кабул итә. Ләкин монда иң мөһим нокта – ул тактикада үзенең маһарәтен (осталыгын) раслады. Ләкин ул минекенә охшаш үз фикерләрен башкаларга әйтеп, минем сыман, үз башына бәла алмый. Атамның хәтере өчен, ул мине хөкем итәргә чакырган, ә чынлыкта ул мине яклады-саклады. Ул яклау эшен Коръәнгә кушты. Һәм атамның башын идерде. Коръәннән укыган аятьләре белән атамны җиңде. Атам тынычланды. Агам алган юлымны дәвам итүемә теләктәш иде. Бу мохитнең тагын да күп игелекләре бар иде. Ул бер-беренә самимилек, ихласлык тәрбиясенә бәйле, тырыш хезмәт кешеләре, һәр эшендә тәвәккәл, җанлы, гамәлләре фәкать үлчәүле, бөтен әгъзалары кимчелексез, артык үҗәтлектән (фанатизмнан), сәрхушлыктан, һәр төрле әхлаксызлыктан тулысы белән ерак торган бер мохит иде ул. Һич булмаса, миңа пәйгамбәрнең «тормыш юлында инсаннарга зарар вә кыенлык тудырырдай гамәлләр кылмау иманның бер өлеше», дигән фикерен сеңдерде, без урманда юл өстенә ауган агачны күрсәк, аны читкә алып куябыз, юлда таш ятса, алып куябыз, үләксә күрсәк аны күмеп куябыз, юлда машиналарның тәгәрмәчләрен тишәрдәй мал мөгезе, кадак, шешә ватыкларын күрсәк, читкә алып ыргытабыз. Шуннан канәгать калабыз. Мине тәрбияләгән мохит һичбер кешегә кыенлык тудырмады, без кешеләрнең хәтерен калдырмадык. Бу мохит киләчәктә байтак абруйлы шәхесләр тәрбияләр әле. Ләкин урыс инкыйлабының милләт өстенә китергән афәте моңа юл куймады. Кызыл урыслар: башкаларны укырга, язарга без өйрәттек, дип дөньяга кычкырдылар, хакыйкатьтә исә югары культурага хуҗа булган мохитне төбеннән–тамырыннан корыттылар. Бу вакыйгаларга чаклы кунакка килгән шәкертем Госман белән бергә төрле авылларга таралып утырган гаиләбез әгъзаларын зиярәт иткән идек. Агам Госманны игенчелек мөһәндислегенә (инженерлыкка) укуын хуплаган-тәбрик иткән иде. Ул Госманга:

– Гаиләбез мөгаллимнәр, имамнардан гыйбарәт, милләтебезгә бары тик патшаның фәрманын (указ) алгач кына хезмәт итәбез. Син күргән балаларыбызның күбесен мөһәндис, хокукчы буларак үстерәсебез килә, берничәсе Әхмәт Зәки кебек тарих, әдәбият вә фәлсәфә, Гарп вә Шәрекъ гыйлемен өйрәнсен. Шул вакыт гыйлем вә белем мәркәзе ачачакбыз, – диде. Максаты – үз авылында заманча игенчелек мәктәбе ачу иде. Бу хәбәр Госманның да күңеленә хуш килде. Менә, мәктәбеңне тәмамлап, бәлки бер көн монда мәктәп ачып, бу эшне үз кулыңа алырсың, «земский нәчәлник» Солтанов та моңа тарафдар, диде.

Икенче тарафтан агам Әхмәтсани белән Мансур Кылычның Төркиядән Ватаннарына кайтып, бер «көллият» ачарга теләүләрен бик хуплап каршы алган иде. Бер матбага ачу турында да уйлана иде. Шулай булганда Үтәк бер культура мәркәзе хәленә киләчәк иде. Мин хәзер Әхмәтсани белән сөйләшүләремдә, атамның хозурында:

– Коръән ул – инсанга тәэсир итәр өчен иңдерелмеш тәгълимат, Аллаһның сүзе, бер инсан (Пәйгамбәребез) тарафыннан бер милләтнең телендә, аның фольклорын вә культура дәрәҗәсен югарыга менгезгән мәңгелек әсәр буларак, ул пәйгамбәр сүзе! – дидем.

Атам канәгатьсезлеген сиздермәде. Үтәктә үткәрелгән «гаилә хөкеме» атама бик яхшы тәэсир иткән булып чыкты. Үзем теләгәндә генә намаз укырга хокук яулавым шул булды. Атам иртәнге намазга мине уятмый башлады. Минем хакта башкаларга атам:

– Ул инде үз иҗтиһаты белән гамәл кыла, үсеп җитте бит инде, үзе беләдер, – ди.

Атам белән дини, фәлсәфи мәүзугълар турында һич бәхәскә керми идек. Моннан соң мин дә шушындый мәүзугълар турында беркем белән дә бәхәскә кермәдем, беркемнең дә дини ышанычларына кагылмадым, Пәйгамбәребез әйткәнчә, «сөйләшкәндә акылларына сыйдыра алган микъдарда гына сөйләшә» идем.

*Төрекчәдән* **Рабит БАТУЛЛА** *тәрҗемә итте.*

**Редакциядән:**

*Хөрмәтле укучыларыбыз! Зәки Вәлиди Туганның «Хатирәләр» дип аталган хезмәтенең журнал вариантын шуның белән төгәллибез. Төрекчәдән тәрҗемә итеп, басмага әзерләүче Рабит Батуллага рәхмәтебезне җиткерәбез һәм әлеге хезмәтнең тулысы белән китапта басылып чыгуын телибез.*

# КАРЛЫ ТАУДА – КАРАЧУН

Без ел саен Яңа ел бәйрәмен билгеләп үтәбез. Аны көтеп алабыз. Йортка чыршы агачы алып кайтабыз, аны бизибез, балаларга, бер-беребезгә бүләкләр таратабыз. Яңа елны каршы алуның төп персонажы – Кыш бабай инде, әлбәттә. Безгә аңлатуларынча, Яңа елны каршы алу – Раштуа бәйрәме, ягъни христианнарның Гайсә пәйгамбәренең туган көнен билгеләп үтү бәйрәме икән. Ә Яңа елга чыршыны бизәү безгә Ауропадан кергән икән. Аны, ауропалылардан күреп, Пётр I патша махсус указ белән керткән, имеш. Шулай итеп, бездәге рәсми версия буенча, Яңа ел – христианнарның Раштуа бәйрәме, ә аны бизәлгән чыршы каршында каршы алу – ауропалылардан безгә кергән йола, аңа кадәр бездә Яңа елны каршы алу да, аның өчен чыршыны бизәү дә булмаган икән.

Яңа елны каршылаганда, чыршыны бизәүне Пётр I керткән дигән сафсатага бераз гына тукталып китик. Указның үзен алып укыганда, шул күренә: Пётр I патша Рәсәйдәге ел исәбен генә алыштырган, аңынчы бу илдә елларны Дөнья Яратылудан (от Сотворения Мира) исәпләгән булсалар, ул аны, Ауропадагы кебек, Гайсә пәйгамбәрнең тууыннан (от Рождества Христова) исәпләтә башлаган. Һәм шул яңа исәп уңаеннан, ул Яңа ел алдыннан капкаларны, трактир түбәләрен, урам-юлларны нарат, чыршы, артыш агачлары ботаклары белән бизәргә киңәш иткән. Әлеге указны юньләп үтәгән кеше булмаган, ә Пётр патшаның вафатыннан соң, бу турыда, гомумән, онытканнар. Ә аның бу фәрманыннан Рәсәй дигән илдә кызыклы бер йола торып калган. Түбәгә ылыслы агач кадап кую трактир хуҗаларына ошап киткән. Ни дисәң дә, ул ерактан ук күренеп, менә монда эчәргә аракы бар, дип кычкырып торган. Түбә башына кадап куелган ылыслы агач ботагы, шулай итеп, Рәсәйдә кабаклар символына әйләнгән. Ә Яңа елны чыршы бизәп каршы алу Рәсәйдә фәкать XIX гасыр урталарында гына күренә башлый. Аны чынлап та бу илдә яшәгән ауропалылар эшли. Александра Фёдоровна атлы патшабикә Кышкы сарайга чыршы утыртып куйгач, әлеге йола аеруча популярлашып китә.

Сүз уңаеннан әйтеп китик, П.Кампанелли раславынча, Яңа ел алдыннан чыршыны бизәү иң башта алман-роман халыкларында түгел, ә фин-угыр халыкларында булган. Һәрхәлдә, иң беренче язма чыганаклар шул турыда сөйлиләр. Яңа елны чыршы бизәп каршы алу турында табылган иң беренче язма чыганакта латышларның чыршы бизәүләре, аңа төрле уенчыклар тагулары һәм аның тирәли әйлән-бәйлән йөрүләре турында сөйләнә.

Урысларның Дед Морозына килик. Бусын инде рус галимнәре бик хаклы рәвештә үзләренең мәҗүси аллалары Карачун (Корочун, Чернобог) белән бәйлиләр. Карачун рус һәм кайбер башка славян халыкларында караңгылык, салкынлык, теге дөнья – Җир асты дөньясы, үлемне символлаштырган мәҗүси алла.

Хәзер инде Яңа елны каршы алуның да, аның өчен чыршыны бизәүнең дә бернинди дә ауропалылардан түгел, ә татарлардан алынуын дәлилләп китик. Моның өчен, иң беренче чиратта, билгеле тарихчы, язучы Морат Атчыга (Мурад Аджига) мөрәҗәгать итик. Ул үзенең «Кыпчаклар. Төркиләр һәм Бөек Даланың борынгы тарихы» китабында татар-төркиләрдә борынгы заманнарда ук булган Ёлка бәйрәме турында яза. Бу бәйрәм борынгы татарларның төп мәҗүси аллаларының берсе – Җир-су алласына багышланган булган. Татарлар аны инде моннан 3-4 мең ел элек үк билгеләп үткәннәр (алга таба «татарлар» сүзе генә кулланылыр, чөнки, «татар» этнонимы «төрки» сүзенә караганда күпкә борынгырак һәм күпкә киңрәк (Паркерны укыгыз), Идел-Урал сөйләшендә начар аңлашылган урыннарда гына «татар-төрки» термины кулланылыр). Автор әлеге

бәйрәм турында шулай яза: «Бу бәйрәм вакытында татарлар тау башындагы зур чыршы агачын бизәгәннәр, аңа төрле уенчыклар такканнар, тасмалар бәйләгәннәр, агач төбенә мәҗүси аллаларга бүләкләр куйганнар, балаларга да бүләкләр таратканнар. Бәйрәм кышның иң кызган вакытында, 25 декабрьдә билгеләп үтелгән. Ни өчен чыршы агачы сайлап алынган соң? Морат Атчы фикеренчә, чыршы Җир-Су алласының яраткан агачы булган, ул туры булып, биек булып үсеп, башы белән икенче бер мәҗүси алла – Ульген атлы алланың күктәге сараена тиеп торган. Бу алланы алтай һәм себер татарлары затлы кызыл кафтан кигән куе ап-ак сакаллы карт рәвешендә күз алдына китергәннәр. Ульген – Идел-Урал татарлары сөйләшенә күчергәндә, Үлгән кебек булып яңгырый, ләкин аның русчага тәрҗемәсенә караганда, бу сүзне Идел-Урал сөйләшендә Өлкән дип әйтергә кирәктер кебек. Өлкән, ягъни мәҗүси рухлар арасындагы өлкән рух. Өлкән алла тугызынчы кат күктә (кайбер чыганакларда – 16нчы кат күктә) яши икән, аның анда алтын сарае, алтын тәхете бар икән һәм дә аның хозурлыкларына алтын капка аша үтеп керәсең икән.

Бәйрәм төн буена, таң атканчы барган. Борынгы татарлар «Корачун! Корачун!» сүзләрен кычкырып, чыршы тирәли әйләнгәннәр, бу әйлән-бәйлән аларда «индербай» (китапта, русча транскрипциядә шулай, татарча, бәлки, «иңдербай» була торгандыр) дип аталган. Аларның түгәрәк ясап басулары кояшны символлаштырган, шул уеннары белән алар Кояшны кире кайтырга чакырганнар. Чынлап та, бу төннән соң Кояш күбрәк күренә, төннәр кыскара, көннәр озая башлаган. Татарлар бу төнне төрле теләкләр теләгәннәр, алар бу вакытта теләнгән теләкләр мотлак чынга аша дип ышанганнар.

Морат Атчы русларның «ёль» сүзе татарның «юл=йул» сүзеннән алынган дип аңлата. Ягъни тау башында үсеп утырган мәһабәт, биек чыршы агачы – Күккә, Өлкән алланың сараена илтүче юл.

Автор Эрлик атлы алла (рух) турында да искә ала. Ул – аныңча йә Өлкәннең бертуганы, йә икенче кыяфәткә кергән шул ук Өлкән рух. Тик анысы беренчесенең капма-каршысы икән. Беренчесе игелеклелек, яктылыкны символлаштырса, Эрлик явызлык, караңгылык рухы булган. Борынгы татарларның, тау башына менеп, шул келәүләреннән Яңа елны чыршы янында каршылау башланган да инде, дип дәлилли Морат Атчы. Ә татарлар келәү белән мөрәҗәгать иткән Өлкән рух – урыс һәм башкаларның Дед Морозы булып киткән. Үз фикерен дәлилләү өчен, ул Дед Морозның куе ак сакалы һәм бар гардеробы да: бүреге, киез итеге, кызыл кафтаны, кушагы Өлкән алладан, ди, болар барысы да борынгы татарларның өс киемнәре, ди. Борынгы татар курганнарында табылган кеше калдыклары нәкъ менә шундый киемнәрдә җирләнгәннәр дә.

Хәзер инде Өлкән һәм Эрлик рухларга тукталып китик. Борынгы татарлар, әлбәттә, Мәңгелек Зәңгәр Күккә – Тәңрегә табынганнар, аларның төп аллалары шул булган, тик алар аннан башка табыну культларына да ия булган: ата-бабалар культы, бүре (Бүрехан) культы, таулар-елга-күлләр ияләре культлары, атаклы камнар культлары һ.б. Иң борынгы мәҗүси культлардан галимнәр Өлкән (Өлкән, Өлкән хан, Өлкән кахан, Өлкән бай, Өлкән би) һәм Эрлик (Эрлик, Эрлик хан, Эрлик кахан, Эрлик бай, Эрлик би) культларын күрсәтәләр. Алар Себер һәм Үзәк Азиянең бар татар кавемнәрендә дә (себер татарлары, алтайлылар, тубалар, шорлар, хакаслар, бурятлар, монголлар һ.б.) бар, тик төрле төркемнәрдәге культлар бер-берләреннән бераз аерыла. Шулай да бу культларның төп эчтәлекләре уртак: Өлкән рух – якты көчләр, игелеклелек, җылылык, җәй, Кояш, көн, яктылык, яшәеш, тереклек, бәрәкәт, уңыш, нигъмәт белән символлаштырыла, ул Җирне һәм Күкне, йолдызларны, Кояш һәм Айны яралткан, аларның хәрәкәте белән идарә итә. Аның яшәгән урыны да – күктә. Ә Эрлик исә кара көчләр, явызлык, салкынлык, караңгылык, кыш, ачлык, уңыш булмау, йот, кытлык, михнәтләр, теге дөнья, үлем белән ассоциацияләшә, ул Җиргә төрле михнәт-афәтләр, чирләр җибәрә, кешеләрнең җаннарын ала да аларны тугыз кат Җир астындагы үз патшалыгында тота. «Эрлик» теонимын Идел-Урал сөйләшенә күчергәндә, бу сүзне рус авторлары ничек тәрҗемә итүләрен һәм Себер татарлары сөйләше үзенчәлекләрен искә алырга кирәктер. Себер татарлары җирне «йер-йир», диләр. Морат Атчыда да «йер» сүзе кулланылган. Шуңа күрә дә бу сүзне Идел-Урал сөйләшенә – «җирлек» («йирлек-йерлек»), ягъни җир эчендә яшәгән рух, җир асты алласы дип күрсәтергә

кирәктер. Бу – мәкалә авторының үз версиясе генә, авторның моңа 100 % ышанычы юк, төгәл итеп аңлату өчен, татарның бар диалектларын да яхшы белергә кирәк, шуңа күрә дә бу теоним мәкаләдә русча чыганакларда күрсәтелгән транскрипциядә бирелер.

Алтай татарларының ышануы буенча, Өлкән алланың алтын капкалы, алтын тәхетле күктәге алтын сарае нәкъ менә Алтын күл (Телецкое озеро) буенда урнашкан Алтын тау өстендә икән (Алтын тау – Алтайдагы иң биек тауларның берсе). Ә «Алтай» топонимын аңлатуның төп варианты да: «Алтын+тай (таг=тау)». Алтай татарларының ышанулары буенча, борынгы татарлар, нәкъ менә шул тау башындагы чыршыны бизәп, Яңа елны каршы алганнар да инде.

Китабында кулланган «Корачун» сүзен Морат Атчы борынгы Алтай татарлары телендәге «Кими барсын!» (Пусть убывает!») сүзе дип аңлата. Идел-Урал сөйләшендә «Корачун» сүзен «Кими барсын» белән бәйләү кыен. «Корысын!» вариантын гына карамаганда. Шуңа күрә бу сүзне аңлатуның башка төрләрен дә карап китәргә кирәк. Ә аның чыгышы татардан, мотлак татардан.

Русларда «карачун» дигән сүз бар. Андый сүз яки шуның кебек үк сүзләр башка славян халыкларында да бар. Аңлатмалы сүзлекләр аны «үлем», «вафат булу» мәгънәләре белән аңлата («карачун пришёл», «карачун тебе (ему)» һ.б.). Бар яңгырашы белән татарча булган «карачун» сүзен рәсми чыганаклар башка телләргә бәйләргә тырышсалар да, бәйсез гыйльми чыганакларда, интернеттагы бәйсез форумнарда аның татарча булуына, татардан алынган булуына шик белдерүчеләр аз. Тик версияләре генә төрлечә. Берәүләре, Морат Атчы кебек үк, бу сүз борынгы татар телендәге «Кими барсын!» гыйбарәсе, дип күрсәтәләр; икенчеләре «Карачун» – башка берни дә түгел, ә борынгы болгардагы – «Кара җан» («Чёрная душа», караңгылык җаны, үлем җаны), дип дәлиллиләр, җанны болгар татарлары һәм аларның замандашлары булган башка татарлар «чун» дигәннәр икән; өченчеләре бу сүз татарчадагы «Кара үлем»не аңлата, диләр; дүртенчеләре «Карачун»ның украиннарда «коротун» дип аталуыннан чыгып, бу сүз татарларның – «Кара+төн»е, «Караңгы төн» алласы, дип аңлаталар; бишенчеләре бу сүз татардагы «Кара+чоң»нан барлыкка килгән диләр, «чоң» – Урта Азия татарларында (мәсәлән, кыргыз татарларында) «галәмәт зур» дигән сүз; алтынчылары «Карачун» Карачурын атлы татар ханыннан алынган, дип аңлаталар (тарихта шундый атлы татар ханы билгеле) һ.б.

Карачун атлы топонимнар (авыллар, бистәләр, таулар, табигый урыннар һ.б.) бик күп. Рәсәйдә дә, Украинада да, Белоруссиядә дә, хәтта көнчыгыш славян илләрендә дә. Тарихчылар аларның атамаларын татарча аңлаталар, нигездә, югарыда искә алынган вариантларда. Яки аларның мәгънәләре Карачун атлы мәҗүси алла аша аңлатыла. Ә Карачун аллага без алда тукталып китәрбез, бу сүзнең этимологиясе дә шул ук «карачун» сүзенеке кебек үк. Топонимнарга берничә мисал да китереп китик. Донецк өлкәсендә Карачун тавы бар. Элек анда хәрби ныгытма булган, каравыл дозорлары торган. Тигез урында калкып торучы бердәнбер биек тау буларак, бу тау элек-электән үк зур стратегик әһәмияткә ия булган. Җирле халык тауның «Карачун» атамасын татарча – «Кара үлем» («Чёрная смерть»), дип аңлата.

Воронеж өлкәсендәге Карачун авылы – өлкәнең иң борынгы авылларының берсе. Авыл атамасы барлыкка килүе буенча тарихчыларда шундый версияләр бар: Карачар атлы татар морзасыннан атамасын алган бу авыл, җирле риваятьләр буенча, авыл янындагы елгада әлеге морза батып үлгән булган; татарчадагы «Карасу» сүзеннән; Алтын Урда вакытындагы ваба кизүе (эпидемиясе) вакытыннан калган авылның атамасы, ул вакытта авылның күп халкы кырылып беткән дә шуннан соң авыл «Карачун» дип аталып йөртелә башлаган; татар-төркичә «Кара+чан»нан, монда «Кара» – чёрный, «чан» – «яма», «сторона»ны аңлата икән. Авылдан ерак түгел ике Карачан елгасы бар (Юеш һәм Коры Карачаннар), аларның этимологиясе дә нәкъ менә шулай аңлатыла. Аннан тыш, шул елгалар буенда Карачан атамалы авыллар да бар. Сүз уңаеннан әйтеп китик, татарның кайбер сөйләшләрендә «җ» авазы урынына «ч» авазы әйтелә, ул шивәләрдә «Карачан», чынлап та, «Кара+җан»ны аңлата.

Тагын бер мисал. Кривой Рог шәһәрендәге «Карачун» бистәсе. Шәһәр халкы бу атаманың барлыкка килүен нәкъ менә татарлар белән, ул гына да түгел, Запорожье

татарлары белән бәйли. Андагы риваять буенча, шәһәргә Запорожье Сече татарлары һөҗүм иткән, хәзер Карачун дип аталган бистәдә көчле сугыш булган, ләкин татарлар шәһәрне ала алмаганнар, күп кешеләрен югалтканнар. Шуннан соң бу урынны татарлар яман җир, карачун җире дип атый башлаганнар, Кривой Рогка һөҗүм итәргә тырышмаганнар. Бистәнең Карачун атамасы шул татарлардан торып калган. Монда игътибарга лаек урыны шул: Запорожье Сече кешеләре риваятьтә татарлар дип атала, ә безгә аларны крепостнойлыктан качкан урыс крестьяннары, дип аңлаталар. Запорожье Сечен – татарлар нигезләгән, Олы урда татарлары. Сарай алынып, талангач, аның халкы далага качкан, Кырым ханлыгы белән Бөек Литва кенәзлекләре чикләрендә үзенең качаклар дәүләтен төзегән. «Казак-кацак» татарның «качак» (беглец) сүзеннән барлыкка килгән. Шул вакытлар Европа хәритәләрендә (карталарында) бу җирләр Малая Татария, Казацкая (Казакская) орда дип күрсәтеләләр дә. Запорожье Сече дә тарихи чыганакларда бернинди дә Сечь дип түгел, ә Запорожье Кошы (Коошы) итеп күрсәтелә, ягъни, далага казаклыкка (качаклыкка) китәргә мүҗбүр булган татарларның вакытлы яшәү урыны, вакытлы куышы, дип.

Сүз уңаеннан әйтеп китик, Олы урда шактый зур җир биләгән, Белгород (Аккирмән), Воронеж – Олы урданың татар шәһәрләре булган. Ул урыннардагы бик күп топонимнар татарча аңлатыла. Воронеж өлкәсендәге алда искә алынган Карачун авылы янындагы башка күп борынгы авыллар татар атамалылар: Айдар, Ертиль (Йорт-ил), Хава (авыл һәм елга, Һава – татарда хатын-кыз исеме), Усмань, Байгора, Чамлык, Карамыш, Телелюй, Елань, Емань (Яман), Еманча һ.б. Туган якны өйрәнүче белгечләр бу авылларның барлыкка килүләрен һәм үз атамаларын алуларын нәкъ менә татарлар, Олы урда татарлары белән аңлаталар да.

Инде алда әйтеп кителгәнчә, Карачун урысларда һәм күп кенә славян халыкларында мәҗүси алла итеп күрсәтелә. Ул – теге дөнья, үлем, суыклык, караңгылык алласы, явыз рухларның патшасы. Карачун алла аларда кафтан кигән, билен кушак белән буган ак сакаллы карт итеп тасвирлана. Аның карашы җанөшеткеч, ул бер карауда кешене үтерергә мөмкин. Карачун зәмһәрир суыклар, кайгы-михнәтләр алып килә, көннәрне кыскарта, төннәрне озайта. Галимнәр раславынча, рус һәм башка славян халыкларының Дед Морозы нәкъ менә шул явыз Карачуннан килеп чыккан да инде. Тик аңа христианнарның Изге Николай (Санта Клаус) культы тәэсир иткән һәм ул дәһшәтле үлем алласыннан бүләкләр таратучы киң күңелле Яңа ел картына әйләнгән. Ә «Карачун» исә – татар сүзе, татардан алынган теоним (теоним – төрле аллаларның исемнәрен аңлатучы термин), ул гына да түгел, ул – борынгы татар культы, татар персонажы, татарларның явызлык, суыклык, кыш һәм үлем алласы – Эрлик. Славяннарның Карачун алласы белән татарларның Эрлик алласы арасында бернинди дә аерма юк. Чынлап та, элекке вакытта Дед Мороз дигән персонаж (чынбарлыкта – шул ук Карачун), хәзерге замандагы кебек, балаларга бүләкләр таратып йөргән киң күңелле юмарт карт булмаган. Ул зәмһәрир суыклар, бураннар, караңгы төннәр алып килүче, бар дөньяга кайгы-михнәт таратып, уңга-сулга үлем чәчеп йөрүче усал, явыз, дәһшәтле карт булган. Некрасовның «Дед Мороз, красный нос» поэмасында ул шулай сурәтләнә дә. Утынга дип урманга барган бер гаепсез мескен Дарьяны катырып үтерә ул карт. Ә ул Дарьяның әле генә ире үлгән була, балалары ятим кала. Поэмадан аңлашылганча, салкын йортта үзләре генә торып калган ул балаларны да шул ук тәкъдир көтә. Шулай итеп, татарның Эрлик алласы русларда һәм башка славян халыкларда Карачун алла булып киткән. Ә Карачун, үз чиратында, соңыннан Дед Морозга әйләнгән. Ә «үлде», «вафат булды» мәгънәсендә йөргән «карачун» сүзе Карачун алладан, нәкъ менә шул Эрлик алладан, борынгы татарларның үлем алласыннан алынган. Сүз уңаеннан, тагын бер фактны күрсәтеп китик, татарның игелеклелек, җылылык, җәй, яктылык, Кояш, Күк, нигъмәт, уңыш алласы Өлкән рус һәм башка славян халыкларында Даждьбог (Дажьбог, Дажбог) булып киткән. Татарның Өлкән мәҗүси алласы белән славяннарның мәҗүси Даждьбог аллалары арасында бернинди дә аерма юк.

Урыс һәм башка славян халыкларында элек Карачун төнен билгеләп үтү йоласы булган. Ул 21еннән 22сенә каршы төндә, ягъни кышның иң озын төнендә билгеләп үтелгән. Карачун төненә алдан ук тәм-томнар әзерләгәннәр, өйне, йорт тирәсен

тазартканнар, чистартканнар. Үзләре дә чистарынганнар, юынганнар. Зур-зур учаклар якканнар, өйләрен якты итеп яктыртканнар. Төн буена учак тирәли уеннар оештырып, күңел ачканнар, бер-берләренә кунакка барганнар, ачуланышкан кешеләре белән татулашканнар.

Алман халыкларында Йоль дигән мәҗүси бәйрәм булган. Ул да нәкъ менә Кояш борылышы белән, табигый Яңа ел белән бәйләп билгеләп үтелгән. Йоль дигән ул бәйрәм алманлыларда 12 көн (төн) буена барган. Бәйрәмнең төп символы, караңгылыкны, суыкны, кышны җиңүче – учак, яктылык булган. Алар зур учак ягып аны 12 көн буе сүндерми тотканнар.

Хәзер инде алда язылган мәгълүматларны берләштереп, Яңа елны каршы алу, аның өчен чыршы бизәү, явыз Карачун карт һәм башкаларның русларда, шулай ук бүтән халыкларда ничек барлыкка килүен язып китик. Алар барысы да, татардан, безнең ата-бабаларыбыздан алынган йолалар һәм персонажлар. Татардан алынганнар, татардан үзләштерелгәннәр, татардан урланганнар.

Татарларда исә бу шулай булган: мәҗүси динле борынгы татарлар якты көчләр һәм явыз көчләр рухларына ышанган. Кыш, суыклар, көннәрнең кыскаруы, аларның ышануларынча, шул явыз рухлар эше булган. Шуңа күрә дә татарлар аларны куып җибәрү йолалары үткәргән. Һәм дә бу чара кышның иң озын төнендә 21еннән 22сенә күчкән төнне үткәрелгән. Моның өчен алар алдан ук үзләре яшәгән җирдәге иң биек тауны сайлап алып, андагы чыршыны бизәгәннәр, аның төбенә рухларга бүләкләр куйганнар, өйләрен, яшәгән җирләрен чистартканнар, үзләре дә мунчага барып юынганнар, төрле тәм-томнар пешергәннәр. Бар пычраклыклардан, яман уйлардан, яман гадәтләрдән арынганнар, бер-берләренә үпкәләрен, рәнҗешләрен кичергәннәр. Алар барысы да иске елда калырга, куып җибәрелгән яман рух – Эрлик белән китеп барырга тиеш булган. Кич җитү белән, өйләренә шәмнәр утыртып, аларны яктыртканнар, зур учаклар якканнар, аның аша сикергәннәр (татарларда ут аша ыргып чыгу – тазарыну процедурасы булып саналган), аның тирәли әйләнгәннәр, җырлаганнар, биегәннәр, төрле сүзләр кычкырып (Морат Атчы язуынча, «Карачун» дип кычкырып), келәүләр әйтеп, караңгы көчләрне куганнар. Ул кадәр дә яктылыктан, ул кадәр дә эссе-җылылыктан һәм татарларның шул кычкыру-келәүләреннән куркып, борынгы татарларның ышануларынча, кара көчләр качып китәргә мәҗбүр булган. Һәм дә иң куркыныч рух – Эрлик алла, җәй җитә икән дип, үзенең Җир асты патшалыгына чумган.

«Карачун» сүзенең килеп чыгышы да шуннан ук дип исәпләргә кирәк. Монда бу сүзнең килеп чыгышының, гомумән, башка вариантын да карап китү зарур. Карачун ул вакытларда, бәлки, Карачум (Кара+чум!) рәвешендә булгандыр, татарлар «Карачум! Карачум!» дип кычкырып, шул караңгы көчләрне куганнардыр («Кара» рух, бар үзеңнең җир асты патшалыгыңа кире кереп «чум!»). Карачум, бәлки, шул ук Эрлик алланың икенче исеме генәдер. Юкка гына татарның Эрлик алласы русларда Карачун дип атала башламаган бит инде. Бу версиянең дөреслеккә якынлыгын «Карачун» сүзенең русларда элек «Карачун бабай» рәвешендә кулланылуын әйтеп китәргә кирәк («карачун бабай пришёл», «карачун бабай ему»). Гади халык сөйләшендә әле бүгенге көнгә кадәр «Карачум бабай» гыйбарәсен дә очратырга була. Карачум атлы топонимнар да җитәрлек. Бу мәкалә авторының фикеренчә, ул башта «Карачум!» рәвешендә булган, тора-бара татарның «м» авазы русларда һәм башка халыкларда «н» авазына әйләнгән. Ә, бәлки, шул ук вариантта ул «Караңгылык, чум!» (караңгылык алласы, бар кире үзеңнең Җир асты патшалыгыңа чум!» рәвешендә булгандыр. Бәлки, борынгы татарлар «Кара+чумың!» яки «Кара+чыгың!» дип кычкырганнардыр. Тик шунысы хак: татарлар моны учак тирәли әйләнгәндә дә, чыршы тирәли әйләнгәндә дә кычкырганнар һәм бу сүз кара көчләрне, караңгылык, суыклык, үлем, теге дөнья рухларын кууны, якты көчләрне, җылылык, яктылык, тереклек рухларын чакыруны символлаштырган. Борынгы татарлар исәпләвенчә, шулай итеп, шул төннән башлап, яңа ел, яңа тормыш башланган, табигать уянуга, яңарышка таба йөз тоткан. Татарларның ул кадәр тырышлыгы бушка китмәгән, шул төннән соң Кояш иртәрәк чыга, соңрак байый, төннәр кыскара башлаган. Эрлик алла чигенеп, Өлкәр алла өскә чыгуга юл алган.

Төн буе яман көчләрне кугач, таң атар алдыннан татарлар тауга менгән һәм анда, Морат Атчы язган рәвештә, Җиргә иң беренче нурлар төшүен, таң атуын каршылаган, чыршы тирәли әйләнгән, җырлаган, биегән, рухларга, мәҗүси аллаларга келәүләр әйткән. Татарларның ул келәүләренең кайберләре русларда һәм башкаларда өлешчә сакланып та калган. Мәсәлән, Карачун төнендә руслар: «Зло, уходи туда, откуда явилось!», ә алманлылар Йоль бәйрәме вакытында, үзләренең изге агачлары тирәли әйләнгәндә: «Священное дерево, надели меня силой!», – дип келәү әйтә торган булганнар.

Ни өчен иң биек тауга менгәннәр соң татарлар? Беренчедән, Кояшның иң беренче нурларын иң биек тауга менеп күзәтергә мөмкин булган. Икенчедән, татарларның иң югары культлары, иң олуг аллалары – Тәңре булган. Тауга менү Тәңрегә якынлашу саналган. Чыңгыз ханның да, хәлиткеч карарлар кабул итү алдыннан, Бүрхан (Бүрехан) тавына менеп келәү әйтүен искә төшерегез. Ә иң биек таудагы иң биек чыршы агачы исә Тәңрегә тагын да якынрак торучы булып исәпләнгән. Өлкән алланың яшәгән урыны да, шулай ук – күктә, тауга менү аңа якынлашу да булып торган. Татарларның Сабан туенда, биек багана утыртып, аңа менүдә ярышулары да шул мәҗүси заманнардан, Тәңрегә якынлашырга тырышудан калган. Кайбер галимнәр Сабантуйны, гомумән, язгы кыр эшләрен тәмамлау бәйрәме дип түгел, ә күчмәләрнең саба (саба – бөрдекнең башка исеме) бәйрәме, күчмәләрнең җәйләүгә күчү, беренче кымыз бәйрәме, дип аңлаталар да. Андый бәйрәмнәр себер татарларының кайберләрендә бүгенге көнгә кадәр сакланып калган.

Татарлар яман кара көчләрне куып җибәргәч, татар илендә Яңа ел, яңа Кояш туган. Ул аларда Нардуган дип аталган. Нардуган – татарча Кояш туган, нур туган дигән сүз. Бәйрәмдә татарлар тәм-томнар пешергәннәр, бер-берләренә кунакка йөрешкәннәр, бүләкләр бирешкәннәр, ә яшьләр исә, танымаслык итеп төрле киемнәргә киенеп, төрле битлекләр (аю, бүре һ.б. битлекләре) киеп, өйдән-өйгә йөргәннәр, өйдәгеләрне Нардуган белән котлаганнар, алар алдында җырлаганнар, биегәннәр, аларга яхшы теләкләр теләгәннәр. Бу визитлар яшьләргә хас уен-көлкеләр, шуклыклар белән бергә барган, Нардуган бәйрәме татарда бүгенге көнгә кадәр керәшеннәрдә сакланып калган. Нардуганда киләчәкне юраганнар, кияүгә чыкмаган кызлар, булачак ирләрен юрап, фал салганнар. Бу бәйрәм берничә көн, атналар буена барган.

Шулай итеп, татарның мәҗүси Эрлик алласы, теге дөнья алласы русларда һәм башка славян халыкларында Карачун алла булып, ә аннары Дед Мороз булып киткән. Борынгы татарларның, тау башына менеп, Кояшны, Яңа елны каршылаулары – русларда, башка славян һәм славян булмаган халыкларга да күчкән, ә татарның Нардуганы – русларда һәм башка славяннарда Колядага әйләнгән (предрождественские (зимние) святки, сочельникларның чыгышы да шуннан ук). «Коляда» сүзен Морат Атчы татарчага «вымаливать благополучие», дип тәрҗемә итә, ягъни, келәү дип, Тәңрегә яки башка бер рухка мөрәҗәгать итеп, бәрәкәт келәү, дип. Коляда, авторның аңлатуынча, «Келәде», «Келәү әйтте», «Келәү башкарды» була инде. Чынлап та, славяннарның Коляда бәйрәме татарның Нардуган бәйрәменнән берние белән дә аерылмый, шул ук төрле битлекләр киеп киенүләр, шул ук өйдән-өйгә йөрүләр, шул ук фал салулар, шул ук уен-көлкеләр һ.б. Ә аю, бүре һәм башка затлар булып киенү – Эрлик алланың ярдәмчеләреннән килә. Татарларның ышануларынча, зәмһәрир суыкларны өненнән уянып чыккан аю (шатун) китерә, ә бураннарны бүре алып килә икән.

Бу бәйрәмнәрнең, бу персонажларның, бу йолаларның христиан диненә, Гайсә пәйгамбәрнең туган көненә (Раштуага) бер катнашы да юк. Ул – Кояш борылышын, табигый Яңа ел килүен билгеләп үтү белән бәйләнгән. Гайсә пәйгамбәрнең дөньяга килүе татарча Яңа елга туры килүе аркасында гына (якынча туры килүе аркасында гына) христиан дине татарның тарихи бу ядкарьләрен үзенә үзләштергән, аны үзенеке иткән, татарның Яңа елын Раштуа бәйрәме дип игълан иткән. Ә татарның бу бәйрәмнәре, бу йолалары бик борынгы, Морат Атчы язганча, аларга 3-4 мең ел. Ул кельтлар заманнарына ук барып тоташа. Чөнки алманлыларның «Йоль» бәйрәме кельтлардан алынган, дип исәпләнә. Ә бу исә Морат Атчының «ёль» сүзен татарның «юл=йул» сүзе белән аңлатылуын да дәлилли. Алманнарның ул Йоль бәйрәме

борынгы татар Яңа елы кебек үк, шул ук учаклар, шул ук агач утырту һәм бизәү, шул ук аның тирәли әйләнү, шул ук кунакка йөрешү һ.б. Борынгы ул кельтларга бу бәйрәм татарлардан, нәкъ менә борынгы татарлардан кергән, дип исәпләргә кирәк.

Христианнарның (рус һәм башка халыкларның) татардан үзләштергән тагын бер йоласына туктап китик. Ул – Пасха бәйрәме. Төгәлрәк итеп әйткәндә, Пасхага йомыркалар буяу. Бу бәйрәм дә бар асылы белән – татардан. Татарда бик борынгы заманнардан ук Йомырка бәйрәме булган. Йомырка – тормышның мәңгелек яңарышын, алмашынып торуын, мәңгелек тереклекне символлаштырган татарларда. Кыш бетеп, таулар (тау башлары) кардан арыну белән, Йомырка бәйрәме үткәрелгән. Татарлар моның өчен йомыркаларны пешергәннәр, төрле төсләргә буяганнар, аларга төрле рәсемнәр, бизәкләр төшергәннәр. Аннары якындагы биек тауга менеп, аларны таудан тәгәрәткәннәр (бу йола татарның күп кенә төркемнәрендә бүгенге көнгә кадәр бар). Кемнең йомыркалары аска таба күбрәк тәгәрәвендә ярышканнар. Йомырка бәйрәме Кояш борылышы көнендә, көн белән төннең тигезләшкән вакытында билгеләп үтелгән. Татарлар бу көнне тәм-томнар (гадәттә, күп итеп йомырка, көлчәләр) пешергәннәр, бер-берләренә кунакка йөрешкәннәр, яшьләр өйдән-өйгә йөреп, төрле такмаклар әйткәннәр, җырлаганнар, биегәннәр, күңел ачканнар. Татар бәйрәмнәренең барысына да хас булган учак ягу һәм аның аша сикерүләр, әйлән-бәйлән эшләүләр дә Йомырка бәйрәменең төп атрибутларының берсе булган. Фарсылар тәэсирендә татарның Йомырка бәйрәме соңыннан Нәүрүз дип аталып йөртелә башлаган. Шулар тәэсирендә үк татарның кышның иң кыска көнендәге Яңа елы язга күчкән. Ә христианнарның Пасхасы якынча татарның Йомырка бәйрәменә туры килгән, шуннан инде аларда да йомырка сырлау, йомырка буяу, йомырка бизәү йоласы таралыш алган.

Пасханың куличларын да татардан, татарның көлчәсеннән дип исәпләргә кирәк. Ни өчен? Беренчедән, русларның «кулич» сүзе, грекларның «коулликиов» (κουλλίκιον) сүзенә караганда, татарның «көлчә» сүзенә ныграк яңгырашлы (ә рәсми чыганаклар «кулич» сүзенең этимологиясен грекларның нәкъ менә шул сүзе белән бәйләргә тырышалар да). Икенчедән, руслардагы һәм башка славян халыкларындагы Пасха бәйрәме борынгы заманнарда Яз җитүнең мәҗүси бәйрәме булган, ул Кояш борылышы көне буларак билгеләп үтелгән. Моны бар белгечләр дә таный. Ә бу бәйрәм исә татарның Йомырка бәйрәменнән кергән аларга. Башта алар татарлар кебек үк Йомырка бәйрәменә төче камырдан көлчә пешергән булган, ә аннары, христиан динен кабул иткәч, ул көлчә христианнарга борынгы греклардан кергән коулликиов ризыгы рәвешен алган. Ә ул коулликиов исә – борынгы грекларның мәҗүси Орлык йөртү алласының (бог Плодоношения) ирлек мәртәбәсен символлаштыручы ризык. Аның бар төзелеше, бар формасы шуның рәвешендә эшләнгән. Тарих күзлегеннән караган вакытта, куличның христианлыкка бер катнашы да юк, ул – мәҗүси диндәге греклар ризыгы. Ул гына да түгел, шактый негатив эчтәлекле мәҗүси ризык.

Мәкаләбезне шундый юллар белән тәмамлыйсы килә:

*Дед Мороз да безнеке,*
*Карачун да безнеке, –*
*Коляда дигән бәйрәм дә*
*Безнең үзебезнеке!*
*Яңа елны Чыршы бизәп*
*Каршы алу – безнеке,*
*Яңа ел дигән бу бәйрәм –*
*Безнең үзебезнеке!*

**Айрат ЧАНЫШЕВ**

## А

- Акыл камилләшә – дөнья бәхилләшә.
- Акча – сатылганны, бакча – чокынганны, урыс – чукынганны, дәрес – укыганны... ярата.
- Акылда «а» хәрефе – кыл өстендә.
- Аш тозы да… тәм.
- Ак аракы йөз каралта.
- Акча киендерә дә, чишендерә дә.
- Адашканнан юл сорамыйлар.
- Акылыңны ат итеп җигеп, ишәк булма.
- «Атом-матом» сөйләшкәндә, ат мат куя.
- Ай югары булса да, җиргә иелгән.
- Аракы – телне, караңгы күзне ача.
- Алтын – табылган, шагыйрь күмелгән җирендә кадерле.
- Акланганда… күңел таплана.
- Авызына су капкан халык судагы балыкка әйләнә.
- Адәм баласын алдау имезлектән башлана.
- Аяк белән эшләгәндә, баш ял итә.
- Алама – бирәчәген ялган белән түли.
- Аламаның сакалы – өскә калыккан сай акылыдай, сирәк кыллы.
- Аламаның – алачагында тозак, бирәчәгендә йозак.
- Аракы – кесә карагы.
- Артык картлыкның пенсиясе арту гына шатлык.
- Астан казу шахтёрга гына килешә.
- Ат – солы колы.
- Акылга таман – зарга саран.

## Б

- Банкрот илне домкрат та күтәрәлми.
- Базарда – фәкыйрь күзе арзанда.
- Бал корты аюдан да кыю.
- Бабайның күргәне бай.
- Баш бирмәгән – илгә терәк.
- Бай яр бояр санында йөри.
- Бүләк түләп алына.
- Белешмә алганда телләшмә.

**Наилә МИҢНЕХАНОВА**

# ХУШЛАШЫП КИТТЕ...

Ул туып, атна-ун көн узуга, аның әнисе югалды. Күзләре ачылып, йөри башлаган гына көннәре иде әле. И юксынды, и елады инде ул чакта бәләкәч. Бик жәлли идек үзен. Ләкин аңа безнең жәлләү түгел, әнисе кирәк иде шул. Башта ятсынып кача иде бездән. Тора-бара кулга ияләшә башлады нәни песиебез.

Әнием дә исән иде әле ул чакта. Песиләрне бигүк өнәп бетерми иде ул. Ә бу песине әни дә ничектер аерым бер ярату белән яратты. Гел кочагына алып сөя, аның белән сөйләшә-сөйләшә иркәли торган иде. Әллә без шулай артык яратып иркәләгәнгәме, әллә табигате белән шундый иде инде – ул бик тә ягымлы, назлы булып үсте. Бик матур да үзе. Соры төстә, юллы-юллы кара сызыклары бар. Кайчак мин аңа: күрче, бигрәкләр дә матур инде син, пескәебез, дип сокланып карыйм. Шулчак елмайгандай була, әллә аңлый инде?! Кәефе шәп чагында гел янда сырпаланып йөри. Башыннан сыйпасаң, ул да безнең кулны ялый башлый. Аннары аяк очына ятып, «юынырга» тотына.

Көн артыннан көн узып, песиебез дә матур гына «егет»кә әйләнде. Барыбыз да улыбыз кебек яраткангадыр инде, аңа чын малайлар исемен – Самат дип куштык.

Пескәйнең дә үз дөньясы бар шул. Ул һәрчак безнең янда гына буталмый, чын авыл мәчесе буларак, үзенең кичке «очрашулары»на да чыгып киткәли. Һәм ел саен ике як күршеләрнең берсендә песиебезнең үзенә охшаган балалары дөньяга килә. Ә алар тугач, аның өчен яңа тормыш башлана. Ул мәш килеп шулар янында бөтерелә. Аның чын күңелдән уйнавын, яратып иркәләвен күрсәң, шаклар катарсың. Кайбер кешеләр үзләренең балаларын да шул дәрәҗәдә ярата белмидер, мөгаен. 80 яшьлек әти дә, исе китеп: «Шушы яшемә җитеп, үз балаларын шулкадәрле яраткан, кайгырткан ата песине күргәнем юк иде әле», – диде. Бер елны хәтта, кызып китеп, күршедәге нәниләрен берәмтекләп безнең өйгә үк ташый башлаган иде. «Ситуацияне» көчкә көйли алдык.

Еллар узу белән, Саматыбыз чын мәгънәсендә безнең гаилә әгъзасына әйләнде. Әниебез вакытсыз бу дөньядан китеп баргач (апа да, мин дә шәһәрдә яшибез бит инде), песиебез әти өчен чын бер иптәшкә,гаиләдәшкә әверелде: әти бакчага эшләргә чыкса, аңа ияреп чыга; әти ятып торса, ул да ятып тора; әти үзе нәрсә ашаса, Самат та шул ризыкны ашый. Шөкер, ризыкка да  әллә ни нәзберек түгел үзе, өстәлгә без өйдә юк чагында да менмәс. Авылга кайтканда исә, песиебезгә махсус күчтәнәчләр кыстырып кайтабыз. Кайтып керүгә, чабып килеп, сумкадан «тәмлүшкә» чыкканны сабыр гына көтә белә ул.

Әллә шулай артык сыйлагангамы, песиебез кышка тазарыбрак китә. Безне дә идән уртасына хуҗаларча сузылып яткан килеш кенә озата. Бөтен кыяфәте – авылга ешрак кайтыгыз, безне онытып бетермәгез, ди гүя.

Узган ел әтиебез авырып китте. Атна-ун көнгә өйне бикләп, больницада ятып чыгарга туры килде аңа. Октябрь ае булганлыктан, песиебез сарайда яшәп калды. Күршебез Гөлшат апа, һәркөнне кереп, аны ашатып йөрде. Больницадан да әти туры өйгә кайтмады, айга якын апаларда, Түбән Камада яшәде.

Әти анда киткәч, мин, өйне карап килим дип, авылга кайттым. Кайтсам, Самат беркайда да күренми. Аптырап, күрше-тирәләргә дә кереп эзләдем – юк, күренми. Инде әбәд вакыты да узып китте.

Сәгать өчләр тирәсендә күрше апа белән чәй эчәргә утырдык. Кинәт абзар ягыннан берьюлы биш-алты мәче «елаган» тавыш ишетелде. Нәрсә булды икән дип, йөгереп

чыксам, аптырап киттем, бернинди биш мәче юк, каршыда, өйалды тупсасында Саматыбыз утыра. Мине күрүгә, башын тупсага салды да елый-елый сөйли, сөйли-сөйли елый башлады пескәем. Мондый хәлне үз гомеремдә беренче тапкыр күргән кеше – мин нишләргә белмим... «Ник берүземне ташлап киттегез?!» дия-дия, озак елады әле ул. Хәтта аның: «Башка болай эшләмәгез, үземне генә калдырып китмәгез!» – дигән ялваруын да ишеткән кебек булдым. «Без гаепле. Зинһар, гафу итә күр!» – дип тынычландырып, көчкә алып кердем үзен.

Өйгә керүгә, ул бөтен бүлмәләрне йөреп чыкты. Әтине эзләде бугай. Аннары карават астына кереп качты. Үпкәләгән. Сигез яшенә җитеп, беркайчан да аның үзен генә калдырып киткәнебез булмаган иде шул... Бераз вакыт узгач, бик ялындырып кына ашарга чыкты. Аннары инде өйдән гел чыкмады.

Мин инде әти терелеп кайтканчы һәр атнаның ял көннәрендә авылда булдым. Песием дә, моны белеп, көтеп тора иде. Башка еламады, аны ташламавыбызны, вакытлыча гына калдырып торуыбызны аңлады, ахры.

Быел җәен, июль урталарында, һич көтмәгәндә, Саматыбыз югалды. Башта без аны кайтыр, дуслары белән бәйрәм итеп кенә йөридер дип уйладык. Андый гына шаярып алулары булгалый иде. Ләкин ул бүтән күренмәде. Бәхетсезлеккә юлыктымы, авырып чыгып киттеме, берәр җирдә бикләнеп калдымы – әллә ниләр уйлап бетердек. Каенлыктан, амбар тирәсеннән, су буйларыннан эзләдек, якын-тирә күршеләрдән сораштырдык. Юк, Саматыбыз табылмады инде, сер булып югалды... Җәебезнең яме булмады диярлек. Сөйләшергә утырсак та, сүзебез гел Саматка барып тоташты.

Инде сентябрь азаклары да җитте... Әти ул көнне алма бакчасында ял итеп утыра икән, берзаман песи елаган тавыш ишетелгән. Һәм шундук бәрәңге бакчасы буйлап, елый-елый, Саматыбыз кайтып килүен күргән: ябыккан, кечерәйгән, көч-хәл белән генә атлый икән үзе, мескенкәй...

Бу яңалыкны ишетү белән, мин тизрәк авылга ашыктым. Юлда кайтканда да, күңелем алгысынды. Тизрәк аны күрәсем, сөеп-яратасым килде... Кайтып кергәндә, песием мин йоклый торган караватның түрендә утыра иде. Аны күргәч, чүт елап җибәрмәдем. Йөгереп килеп, янына утырдым. Алдыма алып, сыйпый-сыйпый иркәләп сөйдем. Хәле бик мөшкел булса да, сагышлы күзләре җылынгандай булды. Мин алып кайткан күчтәнәчләрне дә яратып ашады.

...Өйгә кайткач, бер атна яшәде ул. Хәле авыр икәнлеге бөтен кыяфәтенә чыккан иде. Уң яңагында шеш үсеп чыккан иде шул аның. Бик еш, тыела алмыйча, су эчте. Өйдән бөтенләй чыкмый диярлек. Чыкса да, безгә ияреп кенә чыгып керә. Күбрәк ятып кына торды. Ничек ярдәм итәргә дә белмәдек инде үзенә... Ветеринар да чакырып караган идек, ул да ярдәм итә алмады...

...Соңыннан, мәңгелеккә күчкән Саматыбызны өй артындагы сәрби куаклары янәшәсенә җирләдек. Хушлашырга гына кайткан булган икән, дип юатты күршеләребез...

Юксынабыз соры песиебезне. Бигрәкләр дә акыллы: ярата һәм яраттыра белә иде шул ул үзен.

**Лилия ГАТАУЛЛИНА**

---

**Хата төзәтү:**

Мөхәммәтгали Арслановның 10 нчы санда басылган «Зыялы режиссёр иҗаты» мәкаләсендәге «Бәлки, шуңа күрәдер дә П.Исәнбәт, ГИТИСның режиссура бүлегенә шушы ук югары уку йортының актёрлык осталыгы буенча Татар театр студиясен тәмамлап, Казан Яшь тамашачылар театрында һәм Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрында берничә ел эшләгәннән соң, шактый тәҗрибә туплап, 1952 елда гына укырга керә», дигән җөмләне «...1951 елда гына укырга керә», дип укырга.

# 2018 елда дини бәйрәмнәр
# һәм истәлекле көннәр

## МӨСЕЛМАН АЙ КАЛЕНДАРЕ БУЕНЧА 1439-1440 ҺИЖРИ ЕЛЛАР

**19 март** – мөселман календаренда изге саналган Рәҗәб аеның беренче көне. Бу айда Ибраһим пәйгамбәрнең, Гайсә пәйгамбәрнең туган көннәре һәм башка истәлекле көннәр билгеләп үтелә. Шулай ук кече хаж, гомрә хаҗы кылына.

**22 март** – Рәҗәб аеның беренче җомгасына каршы кич – Рәгаиб кичәсе дип атала. Мөхәммәд пәйгамбәрнең әти-әнисе Габдуллаһ һәм Әминәнең бергә кушылуын искә алу кичәсе дә.

**13 апрель** – Мигъраҗ кичәсе. Мөхәммәд пәйгамбәрнең Мәккә шәһәреннән Иерусалимга һәм аннан җиде кат күккә – Аллаһы Тәгаләнең тәхете янына кылган могҗизалы сәяхәте. Мигъраҗ уразасы 100 төн ураза тотуга тиңләнә.

**30 апрель** – Бәраәт кичәсе, ягъни «ләйләтул-Бәраәт». Бәхет һәм һәртөрле уңышлар, изгелекләр иңә торган изге көн. Нәкъ шушы төнне Аллаһы Тәгалә, һәркемнең изге гамәле һәм догаларында ялварып сораган үтенечләрен исәпкә алып, кешеләрнең язмышы турында карар кабул итә.

**16 май** – изге Рамазан ае һәм Ураза башланган көн.

**21 май** – Идел Болгарстанында Ислам динен рәсми рәвештә кабул иткән көн (310нчы һиҗри, 922нче милади ел).

**15, 16, 17 июнь** – Гайдел-фитыр. Ураза бәйрәме.

**20 август** – Гарәфә көне. Хаҗ кылучылар тарафыннан Мәккә янындагы Гарәфә тавына бару һәм тау итәгендә намаз уку көне.

**21 август** – Гайдел-Әдъхә, Корбан бәйрәме. Мөселманнарның иң зур бәйрәме. Ураза тәмамлангач, нәкъ 70 көннән соң башлана торган Корбан чалу бәйрәме, ул 3 көн дәвам итә. Бу көн Татарстан Җөмһүриятендәге барлык календарьларда кызыл төс белән билгеләнгән.

**22, 23 август** – Тәшрикъ көннәре. Бу көннәрдә мөселманнар, фарыз намазларын укыганнан соң, Аллаһы Тәгаләне мактап махсус сүзләр әйтәләр.

**11 сентябрь** – 1440 ел, яңа мөселман елы һәм Мөхәррәм ае башланган көн. Бу айда күп итеп хәер (зәкят) бирелә, изге гамәлләр кылына.

**20 сентябрь** – Гашура бәйрәме. Сөнниләр – Аллаһы Тәгаләнең ун пәйгамбәренә күндерелгән изгелекләре хөрмәтенә, ә шигыйлар, Мөхәммәд пәйгамбәрнең оныгы Гали хәлифәнең улы Хөсәенне (626-680) җәзалап үтерү көнен мөбарәк, изге вә хөрмәтле санап, ураза тота.

**4 ноябрь** – Сәфәр ае башланган көн.

**20 ноябрь** – Мәүлид бәйрәме. Иң зур бәйрәмнәрнең берсе – Мөхәммәд пәйгамбәрнең туган көне. Әлеге изге бәйрәм нәкъ бер ай дәвам итә. Бу вакытта мәчетләрдә вәгазьләр укыла, хәер, садака (зәкят) өләшенә. Күп кенә мөселман илләрендә факеллар һәм фонарьлар кабызып, тантаналы мәрәсимнәр уздырыла.

*Төзүче-мөхәррир –*
**Хаҗи Абдулла ДУБИН.**

# 2017 елда «Казан утлары» журналында басылган әсәрләр исемлеге


**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ**

2017 елда Татарстан Республикасының Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт бүләкләрен бирү турында. №6

**БАШ МӨХӘРРИР СҮЗЕ**

Ибраһимов И. Яңа елның яңа әдәби бизәкләре. №1

Ибраһимов И. Рухыбыз учагы – «Казан утлары» журналына – 95 яшь. №5

**ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР**

Абдуллин Ф. Күрәсен күрде... *Бәян*. №12

Ахир. Мөхлис һәм иблис. *Рок-н-роллы бәян*. №3

Әмирханов М. Тәхетсез патша. *Кыйсса*. №4

Батулла Р. Илбашы. *Татарстан Республикасының Беренче Президенты, татар халкының олуг шәхесе Минтимер Шәймиев турында хикәяләр*. №№1, 2

Бәйрәмова Ф. Һиҗрәт. *Тарихи роман*. №7

Васыйлова Г. *Нәсерләр*. №11

Вәлишина Л. Серле күгәрчен. *Хикәя*. №6

Галиев М. Тимә, яшәсен! *Роман-новелла*. №№1, 2

Галиев Ф. Үтерелгән мәхәббәт кайтавазы. *Хикәя*. *(Р.Хәйретдинова тәрҗемәсе)*. №6

Галиуллин Р. Боссоойко. *Хикәя*. №3

Галиуллин Р. Әдрән. *Бәян*. №11

Гыйматдинова Н. Үлмәс. *Бәян*. №9

Гыйльманов Г. *Хикәяләр*. №2

Гыйсметдин Д. Асылташ. *Сатирик маҗара*. №7

Закиров Р. Җилкәнсез диңгезче. *Бәян-хатирә*. №9

Зарипов Р. Әниләр. *Бәян*. №12

Зәйдулла Р. *Хикәяләр*. №10

Иксанова И. *Хикәяләр*. №6

Исмәгыйлев Х. Исәр. *Хикәя*. №1

Имамов В. Карабәк. *Тарихи роман*. №№5, 6

Нуриев В. Мәһдиев һәм... *Бәян-хатирә*. №5

Садриев Ф. Кышкы яшен. *Повесть*. №8

Хәлим А. *Хикәяләр*. №2

Хәмзин А. ...дисәң дә була. *Шаян әңгәмә*. №9

Хәсәнов А. Өстемдәге затлы җиләнем... *Хикәя*. №12

Хәсәнова К. Сандык биге. *Хикәя*. №3

Шаһиев Р. *Хикәяләр*. №4

Яһудин Н. Атлы казаклар. *Роман*. №11

**ШИГЪРИЯТ**

Аймәт Р. Кыяларсыз калган дөньялар. *Шигырьләр*. №12

Әюп Х. Нәсел агачы. *Шигырь*. №8

Бәйрәмова Г. Хак-бәһасен вакыт үзе әйтер. *Шигырьләр*. №6

Бәшәр Р. И җанымның садә чаклары. *Шигырьләр*. №5

Биектаулы И. Чын дусларым – сүзләр. *Шигырьләр*. №2

Бу – минем тарихи кыйммәтем! (Р.Миңнуллин, А.Хәлим, Р.Рахмани, Н.Сафина, Р.Низами, Р.Шәрипов, Л.Шәех *шигырьләре*). №7

Вәлиев Р. Яңа елның яңа таңы ата... *Шигырь*. №1

Вәлиев Р. Тамырымда мәңге калырмын. *Шигырьләр*. №3

Вәлиулла И. Мең төсмерле җиһан үзе... *Шигырьләр*. №3

Габидуллина Ф. Вакыт ага үз иркенә. *Шигырьләр*. №3

Газизов Р. Татар моңы булып агыла. *Шигырьләр*. №4

Гарифуллина Р. Минем күңелемдә яңа яз. *Шигырьләр*. №2

Гыйләҗев И. Чын исемен тарих саклаган. *Шигырьләр*. №10

Гыйләҗев Ф. Иске Казан – Кирмән нигезе. *Лирик поэма*. №5

Дәрзаман Ж. Төшләремә кереп сагындыра. *Шигырьләр*. №10

Дәүләтбаев Ф. Сагындырганы – яшьлек еллары. *Робагыйлар*. №11

Җамалетдинова Ф. Тарих борылмаган еллар юк. *Шигырьләр*. №10

Җиһангирова Ш. Яратам туган телне! *Шигырьләр*. №8

Зәйдулла Р. Очкын бар каләм очында. *Шигырьләр*. №5

Зыятдинов Ф. Яз җырчысы – тургай моңы. *Шигырьләр*. №6

Ибушев Г. Читтә өзгәләнгәч аңлыйсың. *Шигырьләр*. №10

Идиятуллин Р. Еракларга җилде болытлар. *Шигырьләр*. №7

Йолдыз. Мин ихлас ышанам. *Шигырьләр*. №4

Корбан Р. Килә җырлар язып калдырасы. *Шигырьләр*. №1

Мансуров З. Чияләнде башымдагы бар уем. *Шигырьләр*. №2

Мәхмүдов Ә. Бәхет мизгелләре вакытлы. *Шигырьләр*. №6

Мирза М. Сабырлык сорыйм ялварып... *Шигырьләр*. №12

Мөҗәһит. Бездә бар да элеккечә кебек. *Шигырьләр*. №8

Мөслимова Ф. Дөнья шундый тиз үзгәрә. *Шигырьләр*. №11

Мөхәммәтша Р. Догада кузгалырбыз... *Шигырьләр*. №1

Нәгыймуллина Д. Офыкларда ал таң ата... *Шигырьләр*. №3

Низами Р. Хәтер үзәнендә тора сакта. *Шигырьләр*. №11

Рахман Р. Шигырь аша телне өйрәттем. *Шигырьләр*. №9

Рахмани Р. Күкрәк тулы моң калган... *Шигырьләр*. №11

Рәхим Г. Монда аклык кына хөкем сөрә. *Шигырьләр*. №4

Рәхмәтулла С. Чорлар узгач – дөнья беләчәк. *Шигырьләр*. №2

Сабиров И. Яшәсен иде халкым... *Шигырьләр*. №7

Садриева Л. Халык җаны белән тоташкан. *Шигырьләр*. №8

Саттар Ә. Шигъриятькә бирдем гомеремне. *Робагыйлар. (Ф.Хуҗинның кереш сүзе белән)*. №12

Сафин Ф. Җанга саксыз кагылмагыз. *Шигырьләр*. №8

Ситдыйкова Ә. Вакыт – җитез болан *Сонетлар*. №9

Суфиянов А. Өзек өметемнең ак тыны. *Шигырьләр*. №6

Тарханова Ф. Моң таралды ачык тәрәздән. *Шигырьләр*. №5

Харис Р. Уба. *Поэма*. №12

Хәйруллин Д. Күккә бага, кулларына дога алып. *Шигырьләр*. №9

Хәлим А. Син милләтне иттең Тукайлы. *Шигырьләр*. №1

Шагыйрьҗан Л. Туган телгә мәдхия. *Шигырь*. №7

Шәех Л. Дәвер аша килә татар. *Шигырьләр*. №4

Шәрифуллина Э. Без – Тукайлы халык мәңгегә. *Шигырьләр*. №6

Юнысова А. Моң агыла нурлы Казаннан. *Шигырьләр*. №9

Янсуар Л. Тузганак таҗларын көрибез. *Шигырьләр*. №12

**ДРАМА ӘСӘРЛӘРЕ**

Әхмәтгалиева А. Сагынган чакларымда... *Драма*. №3

Сафиуллин Ю. Йосыф һәм Зөләйха. *Мюзикл*. №10

**ГАМЬЛЕ ӘҢГӘМӘ**

Тарих һәм заман. *Тарих фәннәре докторы Д.Исхаков белән Р.Юныс әңгәмәсе*. №1

Тарих – сабак, тарих – гыйбрәт. *Академик Р.Хәкимов белән И.Ибраһимов әңгәмәсе*. №2

Бердәм милләт мәңге яшәр! *Бөтендөнья татар конгрессының Башкарма комитеты рәисе Р.Закиров белән И.Ибраһимов әңгәмәсе*. №7

Милли мәгарифне үстерү – заман таләбе. *ТР Премьер-министры урынбасары, ТР мәгариф һәм фән министры Э.Фәттахов белән И.Ибраһимов әңгәмәсе*. №8

Халкыбыз яшәгәндә, сәнгать яшәр! *Сәнгать фәннәре докторы, язучы М.Арсланов белән И.Ибраһимов әңгәмәсе*. №10

Бер гасыр милләт сагында. *Казанның*

*Г.Тукай исемендәге 1нче татар гимназиясе директоры Г.Шәмсиева белән Р.Ханнанов әңгәмәсе*. №12

### «ТҮГӘРӘК ӨСТӘЛ»

Хак тарихны кайтару юлында *(Д.Исхаков, Ф.Хуҗин, И.Заһидуллин, Җ.Мөхәммәтшин, Р.Ханнанов, К.Кәримов, В.Имамов катнашында)*. И.Ибраһимов алып барды. №10

XX гасырның иң зур тарихи вакыйгасы… Иртәгә безне ни көтә? *(И.Таһиров, Р.Хәкимов, И.Заһидуллин, Л.Гобәйдуллин катнашында)*. И.Ибраһимов алып барды. №11

### «ИҢ ШӘП ХИКӘЯ» КОНКУРСЫНА

Даутов Г. Дөрес яшә. *Хикәя*. №8

Ибраһимова Л. Мизан бураны. *Хикәя*. №3

Кәримова Р. Майра. *Фантастик хикәя*. №10

Мөхәммәтша Р. Тырыйк. *Хикәя*. №8

Рахман Р. Бәйрәм. *Хикәя*. №4

Төхбәтуллина Н. Сөйли, җырлый, сагына торган материя. *Хикәя*. №12

Фәттахова Л. Җир астыннан юллар бар. *Хикәя*. №6

Харисова Н. Кыйбла. *Хикәя*. №8

Якупова С. Уран. *Хикәя*. №9

### ПУБЛИЦИСТИКА

Морат Г. Ирек дигән татлы сүз... №3

### ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

Галиуллин Т. Моң шагыйре... *(Рәмис Аймәт иҗаты турында уйланулар)*. №9

Галиуллин Т. Шагыйрь эзлим. *(2016 ел поэзиясенә бер караш)*. №3

Заһидуллина Д. Кем ул – Нобель бүләге лауреаты Һенрик Сенкевич? №12

### ТАРИХ

Өнәр М. Тарихтагы татар сурәте турында язмалар. №7

Фәйзрахманов Ә. Арча музейлары. №№4, 5

Хәмидуллин Л. Беренче мөфтиләрне биргән төбәк. №№9, 10

### ФӘН

Мансуров З. Каләм бергәлектә көчле. №12

Хаҗиева Г. Татар кушаматлары. №3

### СӘНГАТЬ

Алмазова А. Иҗатында – шәхес язмышы *(Ренат Еникеевка 80 яшь)*. №6

Арсланов М. Зыялы режиссёр иҗаты *(Празат Исәнбәтнең тууына 90 ел)*. №10

Әхмәтгалиева А. Яшәү җыры. №2

Батулла Р. Тулганай тотылганда. №7

Бәйрәмова Г. Тормыш чынбарлыгы *(Юныс Сафиуллинга 70 яшь)*. №10

Бәйрәмова Г. Тугрылык *(Рәшидә Җиһаншинаның тууына 100 ел)*. №10

Сафиуллин Ю. Сиксәндә дә җегет! *(Наил Дунаевка 80 яшь)*. №4

Юнысова А. Юллар һәм җырлар. №7

### МӨХӘРРИР СОРАУ БИРӘ

Әдәбиятыбызда «Казан утлары» яктысы *(Р.Рахман, Н.Юсупова, Л.Җамалиева, Ә.Закирҗанов, Ә.Мотыйгуллина, Г.Мулласалихова )*. Р.Ханнанов әзерләде. №5

Рухың саумы, Милләтем? *(Колесникова Л., Зәбиров Р., Алмаев Ә., Сафин Р., Гыйбатдинов Ф.)*. Р. Ханнанов әзерләде. №7

Милләт киләчәген кайгыртып... *(Мостафина Ф., Карпова Н., Гарипова Г., Гарипов Р., Вәлиуллина Р.)*. Р. Ханнанов әзерләде. №8

### МӘГАРИФ ХЕЗМӘТКӘРЛӘРЕНЕҢ АВГУСТ КИҢӘШМӘСЕ

Муллин Р. «Иң зур теләгем – район халкының тормышын тагын да ямьлерәк, уңайлырак итү». №8

### МӨГАЛЛИМ МӨНБӘРЕ

Тимергалиева Э. Әдәбият укытучысы – бала күңеленә әхлак кануннарын язучы. №8

### ГАБДУЛЛА ТУКАЙ ИСЕМЕНДӘГЕ ДӘҮЛӘТ ПРЕМИЯСЕНӘ КАНДИДАТЛАР

Әбүдәрова Л. Яңа заманның бәхет өчен көрәшүче каһарманнары. №4

Әхмәдуллин А. Тормыш сабаклары сынавында *(Т.Галиуллинның «Сәет Сакманов» трилогиясенә яңа караш)*. №4

Бикмуллина А. Гаффар Тукае! №4

Галимуллин Ф. Замандашларны аңлау юлында. №4

Заһидуллина Д. Факил Сафин шигърияте *(Романтизм поэтикасы һәм индивидуаль үзенчәлекләр)*. №4

**ТУКАЙ ҺӘМ ТАТАР ӘДӘБИЯТЫ**

Рахман Р. Ачы тәҗрибә авазы: Мөхәммәт Мәһдиев. №1

Рахман Р. «Зур тәрәзә бар дип аңла дөньяга күкрәктә син». №2

Рахман Р. Шагыйрьләр солтаны. №3

Рахман Р. Тукай җырларының очкыны чәчрәсә. №4

Рахман Р. Тукай кулын кысар иде. №6

Рахман Р. Тел дигән дәрья бар, дәрья төбендә мәрҗән бар. №8

Рахман Р. Уй буеның уйлы урамнары. №12

Рәмиев Р. Тукай энциклопедиясен төзү тарихыннан. №4

**100 нче БИТ**

Бәйрәмова Г. Хуш киләсең, Рамазан! №6

Кәримов К. Күтәрергә ярамый төшерергә. №2

Латыйпова Р. Ана теле «Әлифба»дан башлана. №9

Морат Г. Миңкәйдән – Бабайгача. №1

Мөхәммәтшин Г. Татар моңы. *Шигырь*. №11

Нәҗми Н. Татар теле. *Шигырь*. №10

Сабиров И. Ана теле сүзлеге. *Шигырь*. №7

Уразай Ф. Рух ныклыгын милли аң билгели. №4

Фәйзуллин Р. Һәр саны бәйрәм. №5

Фәтхуллова К. Ана теле сагында. №3

Фәхреддин Р. Остаз вә мөгаллим (укытучы). №8

Хуҗин Ф. Туган телем. *Шигырь*. №12

**ӘДӘБИЯТЛАР ДУСЛЫГЫ – ХАЛЫКЛАР ДУСЛЫГЫ**

Вәлиев М. Һич бетмәс бу тарихи уртаклык. №6

Иванов К., Сеспель М., Ухсай Я., Лукин А., Давыдов-Анатри В., Айдаш Ю., Сениэль М., Семендер Ю., Енеш В., Афанасьев П., Сарби Р., Тургай В. шигырьләре. №6

**КАРДӘШ ХАЛЫКЛАР ӘДӘБИЯТЫ**

Корбан Р. Татар иленә рәхим ит! №10

Кулиев К. Мин җырладым яшәү турында. *Шигырьләр*. №10

Макатаев М. Шифа эзлим җаныма, телгә – терәк. *Шигырьләр*. №9

Миңнуллин Р. Казакъларның йөз аклыгы. №9

**ӘДӘБИ ХӘЗИНӘЛӘРЕБЕЗ**

Вәлиди Туган З. Хатирәләр. *(Р.Батулла тәрҗемәсе)*. №№7, 8, 10, 12

Мөхәммәтҗанова Л. Пар гына күкеләр чакырганда... №3

Мөхәммәтҗанова Л. Самара татарлары һәм замана фольклоры. №7

Хасавнех А. Мәшһүр вә укымышлы булган Фәрһад белән мәгъшукасы Ширин хикәясе *(кереш сүз белән)*. №2

**ТАТАР ХИКӘЯЛӘРЕ ХӘЗИНӘСЕННӘН**

Гази И. Югалган Мәрзыя. *Фронт дәфтәреннән*. №2

Латыйфи Ф. Себер хикәяте. №8

**ӘДИПНЕҢ ТӘҮГЕ КИТАБЫННАН**

Хәсәнов М. Герой. *Хикәя. (Р.Ханнановның кереш сүзе белән)*. №12

**ЮБИЛЕЙЛАР**

КӘРИМ ТИНЧУРИННЫҢ ТУУЫНА 130 ЕЛ

Арсланов М. Фидакарьлек. №9

ЯКУБ ЗӘНКИЕВНЕҢ ТУУЫНА 100 ЕЛ

Сәйфуллина Ф. Иртештә таң атсын өчен... №4

ӘХСӘН БАЯННЫҢ ТУУЫНА 90 ЕЛ

Кәримов К. Һәркем яшьлеген эзли. №12

РӨСТӘМ МИНГАЛИМНЕҢ ТУУЫНА 80 ЕЛ

Мирза М. Ул – киләчәк шагыйре. №8

Мингалим Р. Иртәгә... *Поэма*. №8

КОЯШ ТИМБИКОВАНЫҢ ТУУЫНА 80 ЕЛ

Маликова М. Күңелем яктырткычы. №11

ЗИННУР НАСЫЙБУЛЛИННЫҢ ТУУЫНА 80 ЕЛ

Насыйбуллин З. Моңнар белән шуңа чигелгән. Шигырьләр. №11

КАДЫЙР СИБГАТУЛЛИННЫҢ ТУУЫНА 75 ЕЛ

Фәйзуллин Р. «Пристаньнар ярга ятып кала... №2

ЗӨЛФӘТНЕҢ ТУУЫНА 70 ЕЛ

Сафин Ф. Зөлфәтлек. №1

З ө л ф ә т. Томырылдым тирән үткелгә мин... *Шигырьләр*. №1

НАИС ГАМБӘРНЕҢ ТУУЫНА 70 ЕЛ

Ю с у п о в а Н. «Яшәүдән соң яшәү бармы? Бардыр...» №8

Г а м б ә р Н. Кайтсам... *Шигырьләр*. №8

ӘНВӘР ХӘЙРИНЕҢ ТУУЫНА 70 ЕЛ

Л е р о н Л. Әнвәр әзи. №12

**КОТЛЫЙБЫЗ!**

«КАЗАН УТЛАРЫ» ЖУРНАЛЫНА – 95 ЕЛ

«Безнең юл»: Байчура Ш. Патша хөкүмәте вакытында Төркестанда татар мөгаллимнәре. №5

«Яңалиф»: Я у ш е в М. Боз кузгалды. №5

«Атака»: И р т у г а н о в Җ. Донбасста татар матур әдәбияты. №5

«Совет әдәбияты»: К а м и л о в Г. Фронт газеталары. №5

«Казан утлары»: Д ә ү л ә т Н. Татар диаспорасы һәм Тукай. №5

Әдәбият һәм сәнгать яңалыклары. №5

Безне котлыйлар: Р.Ратникова, М.Өнәр, Д.Салихов, Р.Кинйәбаев, Д.Осман. №5

Г а л и м у л л и н Ф. «Безнең юл» журналы һәм Галимҗан Ибраһимов. №5

Мәшһүрләр мөнбәре *(Х.Туфан, Г.Кашшаф, Ф.Хөсни, М.Госманов)*. №5

С о л т а н б ә к о в Б. Татарлар һәм Игънатьев. №5

Ш ә р и п о в М. Нинди җир ул Суслонгер? №5

Ю н ы с М. Соңгы сулыш №5

Ю н ы с Р. Сер саклаучы фотолар. №5

Фотомизгелләр. №5

МӨСӘГЫЙТ ХӘБИБУЛЛИНГА 90 ЯШЬ

Г а л и м у л л и н Ф. Бүгенгедән – тарихка таба. №12

ЛИРОН ХӘМИДУЛЛИНГА 85 ЯШЬ

М а н с у р о в З. Рухият югарылыгына чакыру. №11

РЕЗЕДА ГАНИЕВАГА 85 ЯШЬ

З а һ и д у л л и н а Д. Галимә ачкан дөньялар. №11

НУРМӨХӘММӘТ ХИСАМОВКА 80 ЯШЬ

А х у н о в А. Галим, остаз, шәхес. №3

АЙДАР ХӘЛИМГӘ 75 ЯШЬ

С в е р и г и н Р. Кыйблага кайту. №1

РӘФКАТЬ КӘРАМИГӘ 75 ЯШЬ

З а һ и д у л л и н а Д. Татар әдәбиятында реализм: Рәфкать Кәрами прозасы. №2

РАЗИЛ ВӘЛИЕВКӘ 70 ЯШЬ

Г а л и е в а Л. Уртак хаклык. №1

ФЛЁРА ТАРХАНОВАГА 70 ЯШЬ

Г а л и м у л л и н Ф. Сизгер күңел – нәзберек каләм. №5

ЭЛЬМИРА ШӘРИФУЛЛИНАГА 70 ЯШЬ

М а н с у р о в З. Гыйбрәтле күңел галәме. №6

РИФӘ РАХМАНГА 55 ЯШЬ

М ө х ә м м ә т ш и н З. Рифә Рахман прозасының иҗади үзенчәлекләре. №9

**ШӘХЕСЛӘРЕБЕЗ**

Ф ә й з у л л и н Р. Юксыну. №7

**ХӘТЕР**

М о с т а ф и н Ш. «Безнең нәсел – көчле рухлылар токымыннан!..» №6

**ИСТӘЛЕКЛӘР**

К ә р и м о в а Г. «Менә шундый Зәйнәб инде мин...» №№6, 7

Т а һ и р о в И. Азатлык юлында. №7

Х а р и с о в М. Укытучы иртә чалара. *Автобиографик сәхифәләр*. №№5, 6, 8, 10

Х а т и п о в Ф. Балачак хатирәләре. №3

Ю н ы с Р. Татар күге якты, бик якты! №7

**ЯҢА ИСЕМНӘР**

Ә х м ә т җ а н о в С. Ул хакыйкатьне белгән... *Шигырьләр*. №12

Г а б д р а х м а н о в а Л. Өметтән нәзек җеп эрләдем. *Шигырьләр*. №1

З а к и р о в а М. Күпсенмәсен күкләр генә... *Шигырьләр*. №11

Х ә с ә н о в а К. Сандык биге. *Хикәя*. №3

Х ө с н у л л и н а А. Язмыш кайтавазы. *Бәян*. №12

**АК ҖИЛКӘН**

Г ә р ә е в а Э. Басым. *Әкият*. №8

М а н с у р о в а А. Яратам мин. *Шигырь*. №8

Н у р е т д и н о в Н. Бәхет алмагачы. *Хикәя*. №8

Н о г м а н о в а  Р. Иң кадерле... *Шигырь*. №8

Х ө с н у л л и н а  Г. Йөнтәс. *Хикәя*. №8

Хикәя яза аласызмы?  №№1, 3, 6

**БӘЛӘКӘЙЛӘР**

Ш а к и р о в  Ә. Бәләкәй Әзһәр. №3

**ПЕЧӘН БАЗАРЫ**

Ш ә р и п о в  Р. Сары йортка әтәч килә. *Хикәя*. №1

**ЮБИЛЕЙГА  БАРЫШЛЫЙ**

Татар мәдәниятенең көндәлек дәфтәреннән. №2

Әдәбият һәм сәнгать яңалыклары. №4

Ә м и р  М. Игътибар җитми! №1

Ш а м о в  А. Журналның бер нөсхәсе. №3

**ФИКЕР**

Ч а н ы ш е в  А. Карлы тауда – Карачун. №12

**ТАБИГАТЬ ҺӘМ МИН**

Г а т а у л л и н а  Л. Хушлашып китте... №12

Д и н д а р о в  И. Матуркай балык тота. №3

**УКУЧЫЛАРЫБЫЗ ИҖАТЫ**

С а т т а р о в а  Н. Йөгерә җәяүле буран. *Шигырьләр*. №4

Х ә с ә н  Г. Алтыннан да асыл телем. *Шигырьләр*. №7

**КАЛӘМ ТИБРӘТҮЧЕЛӘР**

А б л е е в а  Л. Елама, төн... *Шигырь*. №8

А л л а я р о в а - С а б и р җ а н о в а  Л. Халык әйтсә, ни әйтә. *Хикәя*. №8

Ф ә й з у л л и н а  Г. Шигыремдә – барлык хисләрем. *Шигырь*. №8

**КАЙТАВАЗ**

Г ы й л ә җ е в а  Н. Күңелемә хуш килгән әсәр. №3

К ә р и м о в а  Р. Йөрәк аша үткәреп. №7

Х ә б и б у л л и н а  С. Якты әсәр. №7

**ЮМОР-САТИРА**

А р и ф у л л и н  Р. Колхоз кассиры Кәүсәрия һәм банкомат. №11

М и р з а  М. Ант эчкәндәге ысылдаулар. №11

Х у җ и  Р. Маймыл. *Хикәя*. №8

**ШАЯН СӘХИФӘ**

Ә х м ә д и е в  Н. Сине алырга килдем. №4

В ә л и д и  Т у г а н  З. Хатирәләреннән өземтәләр. №7

В и л д а н о в а  Н. Балалы өйдә бур ятмас. №8

Г а л и е в  М. Язгы кыз, көзге кыз... №6

М и ң н у л л и н  Р.  Шаян Юзәй. №6

Р ә х и м  Г. Илле бер. №3

С а д р и е в  Ф. Ике өлешле чыгыш. №8

Ю з е е в  И. Бутыйлар... №6

Бөтендөнья татар конгрессының VI съезды резолюциясе. №10

Халык бердәмлегендә – милләтнең көче! Татар халкына Бөтендөнья татар конгрессының VI корылтаеннан мөрәҗәгать. №10

«Рухи тормышыбыз энциклопедиясе». №5

Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы белән Татарстан Республикасы Язучылар берлеге игълан иткән конкурсның низамнамәсе. №5

Сәфәрләр, очрашулар, тәэсирләр... №5

Мәкаль өмәсе. Н.Миңнеханова мәкальләре. №12

«Танымыш дәресе». №3

2018 елда дини бәйрәмнәр һәм истәлекле көннәр. *Абдулла Дубин әзерләде.* №12

«Казан утлары» архивыннан.*Сәхифәне Р.Фәйзуллин әзерләде*. №№1-12

Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан. *Сәхифәне В.Нуриев әзерләде*. №№1-12

Яңа китаплар. №4

Хушлашу сүзе. Л.Шагыйрьҗан. №2; Ә.Авзалова. №7

## ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ СЕССИЯСЕ

Татарстан Республикасы Дәүләт Советының 33нче сессиясе татар телен өйрәнү мәсьәләсе аркасында ябылмыйча калган иде. Ул эшен дәвам иттерде. Бу мәсьәләдә ТР вице-премьеры – мәгариф һәм фән министры Энгель Фәттахов доклады тыңланды. Фикер алышуларда татар телен өйрәтү методикасын үзгәртү зарурлыгын искәрттеләр. Сессиядә Татарстан Республикасы Президенты Рөстәм Миңнеханов катнашты һәм чыгыш ясады. «Милли хисләргә кагылырга кирәкми. Уйламыйча әйтелгән теләсә нинди сүз аянычлы нәтиҗәләргә китерергә мөмкин», – дип кисәтте ул.

29 ноябрьдә сессия эшен тагын дәвам иттерде. Анда ТР прокуроры Илдус Нәфыйков доклад белән чыкты. Аның әйтүенә караганда, дәүләт телләрен өйрәнергә мөмкин, әмма моның өчен ата-аналарның язма рәвештә ризалыгы кирәк. Киләчәктә татар теле дәүләт теле буларак ихтияри рәвештә ике сәгать укытылачак.

## ЯҢА МӘКТӘП

Арчада 500 укучыга исәпләнгән яңа мәктәп ачылды. Казан арты милли мәгариф белем үзәге ул. Монда укучылар федераль дәүләт белем бирү стандартлары кысаларында беренче сыйныфтан тугызынчыга кадәр татар телендә белем алачак. Мәктәп ачу тантанасында ТР Президенты Рөстәм Миңнеханов, ТР Президенты аппараты җитәкчесе Әсгать Сәфәров, ТР вице-премьеры – мәгариф һәм фән министры Энгель Фәттахов катнашты.

## КУРГАН ӨЛКӘСЕНДӘ ТАТАР МӘГЪРИФӘТЕ КӨННӘРЕ

Курган өлкәсендә татар мәгърифәте көннәре үткәрелде. Анда катнашырга Казаннан ТР вице-премьеры – мәгариф һәм фән министры Энгель Фәттахов җитәкчелегендә зур делегация килде. Э.Фәттахов Курган өлкәсе хөкүмәте бинасында Губернаторның беренче урынбасары Виктор Сухнев, Губернаторның социаль сәясәт буенча урынбасары Александр Карпов, Татарстанның Свердловск өлкәсендәге даими вәкиле Ринат Садриев, «Курган өлкәсе татар конгрессы» төбәк иҗтимагый үзәге рәисе Марат Юнусов, социаль сәясәт идарәсе җитәкчесе Елена Баева, мәгариф һәм фән департаменты директоры Наталья Бобковалар белән очрашты.

Татарстан делегациясе өлкәнең Сафакүл, Әлмән, Шатровск, Шадрин районнарындагы мәктәпләрдә, балалар бакчаларында, мәдәният йортларында, китапханәләрдә, музейларда булды, хакимият башлыклары, мәгариф идарәләре, милли-мәдәни иҗтимагый оешмалар җитәкчеләре белән очрашты, халык иҗаты белән танышты. Сәфәргә йомгак өлкәнең мәгариф һәм фән департаментында «түгәрәк өстәл» утырышында ясалды. Мәгариф тармагында Курган өлкәсе белән Татарстан Республикасы арасында икеяклы килешү имзаланды.

## БЕР КӨНДӘ – ӨЧ БӘЙРӘМ

Актанышта бер көндә өч вакыйга – өч бәйрәм булды. Сәнгать һәм мәдәният паркында бөек татар шагыйре Габдулла Тукайга һәйкәл ачылды. Район Мәдәният йортына Россиянең атказанган, Татарстанның халык артисты, шушы туфракта туып-үскән Әлфия Авзалова исеме бирелде. «Актаныш таңнары» газетасының 85 еллыгына багышланган кичә булды. Шунда ук Татарстанның халык шагыйре Гамил Афзал премиясенең быелгы лауреатын игълан иттеләр. Бу олуг бүләккә драматург, прозаик Данил Салихов лаек булды. Премияне район башлыгы Фаил Камаев тапшырды. Актанышта булып узган чараларда Россия Федерациясе Дәүләт Думасы депутаты Әлфия Кагогина, шушы районнан чыккан язучылар Илфак Ибраһимов (шагыйрь Мөхәммәт Мирза), Вахит Имамов, Ләбиб Лерон, Ягъсуф Шәфыйков, Айгөл Әхмәтгалиева, Әлфия Ситдыйкова һ.б. катнашты.

## ОЧРАШУ

Әтнәдәге Г.Тукай исемендәге Татар дәүләт драма театрының зур залында Татарстанның халык шагыйре Разил Вәлиев районның мәгариф һәм мәдәният хезмәткәрләре белән очрашты. Халык белән күзгә-күз карап аралашу, ихлас күңелдән фикер алышуга әверелгән бу очрашуда тамашачылар шагыйрьнең җырларын, шигырьләрен тыңладылар, кунакка шәхси тормышына, иҗади һәм сәяси эшчәнлегенә кагылышлы сораулар бирделәр, туган телебез, милләтебез язмышы турында уйландылар.

## «ТҮГӘРӘК ӨСТӘЛ»

Татарстан Язучылар берлегендә оештырылган «түгәрәк өстәл»дә сүз бүгенге татар прозасы, аның үсеш тенденцияләре турында барды. Анда ТР Фәннәр академиясе вице-президенты, әдәбият галиме Дания Заһидуллина, КФУ доценты Гөлфия Гайнуллина, «Казан утлары» журналының проза бүлеге мөхәррире, язучы-прозаик Камил Кәримов докладлар белән чыкты. Фикер алышуда язучылар, галимнәр, Казан шәһәре китапханәчеләре катнашты. «Түгәрәк өстәл» утырышын Татарстан Язучылар берлеге рәисе урынбасары Рәмис Аймәт алып барды.

***

Арча педагогия көллиятендә «Арча. Туган тел, гореф-гадәтләр: киләчәккә караш» темасына «түгәрәк өстәл» үткәрелде. Районның мәгариф һәм мәдәният хезмәткәрләре алдында филология фәннәре докторы, профессор Рүзәл Юсупов, шагыйрь һәм галим Рифат Җамал, Татарстан Язучылар берлеге рәисе урынбасары Рәмис Аймәт, Татарстанның атказанган артисты Шамил Әхмәтҗанов, шагыйрь, галим Хәнәфи Бәдигый, «Казан утлары» журналының җаваплы сәркатибе, язучы-прозаик Вакыйф Нуриев, журналист Риман Гыйлемханов, «Яңа Гасыр» телерадиокомпаниясе алып баручысы Фәридә Төхвәтуллина, «Белем.ру» оешмасы директоры Раил Гатауллин һ.б. чыгыш ясады. «Түгәрәк өстәл»нең пленар утырышында Арча районы хакимияте башлыгы Илшат Нуриев катнашты һәм үзенең фикерләре белән уртаклашты.

## ЯЗУЧЫ ДӘРЕС БИРӘ

Г.Тукай исемендәге Арча педагогия көллияте өч ел элек «Язучы дәрес бирә» дигән проект башлап җибәргән иде. Быел да бертөркем язучылар – Илфак Ибраһимов (шагыйрь Мөхәммәт Мирза), Сания Әхмәтҗанова, Илсөяр Иксанова, Нәҗибә Сафина, Йолдыз Шәрәпова, Рифат Сәлах һәм җырчы Миңгол Галиев үзләрен укытучы ролендә сынады.

## ЮБИЛЕЙЛАР

К.Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма театрында шагыйрь, прозаик, публицист, Гаяз Исхакый, Һади Атласи исемендәге әдәби премияләр лауреаты Айдар Хәлимгә 75 яшь тулуга багышланган «Кайсыгызны юатыйм» дип аталган әдәби-музыкаль кичә булды. Театрның фойесендә А.Хәлимнең китапларыннан күргәзмә оештырылды. Кичәгә кадәр, көндез әдипкә ТР мәдәният министры Айрат Сибагатуллин Татарстан Республикасының «Фидакарь хезмәт өчен» медален һәм ТРның беренче Президенты Минтимер Шәймиевнең Рәхмәт хатын тапшырган иде. Кичәдә ТР Президенты каршындагы мәдәниятне үстерүгә ярдәм фонды җитәкчесе Нурия Һашимова ТР Президенты Аппараты җитәкчесе Әсгать Сәфәровның котлау хатын укыды. Бәйрәмдарны Татарстан Язучылар берлеге рәисе Данил Салихов, Бөтендөнья татар конгрессы рәисенең беренче урынбасары Данис Шакиров, каләмдәшләре Равил Фәйзуллин, Гәрәй Рәхим, Г.Камал театры артистлары Әзһәр Шакиров, Равил Шәрәфиев, Башкортстаннан, Омск, Оренбург шәһәрләреннән килгән кунаклар котлады.

***

Язучы, галим Фарсель Зыятдиновка 80 яшь тулды. Шул уңайдан Татарстан Язучылар берлегенең Г.Тукай клубында әдәби-музыкаль кичә үткәрелде. Бәйрәмдарны Татарстан Язучылар берлеге рәисе Данил Салихов, Татар энциклопедиясе институты директоры Искәндәр Гыйләҗев, ТР авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры урынбасары Илдус Габдрахманов, Бөтендөнья татар конгрессы исеменнән шагыйрә Шәмсия Җиһангирова, Казан шәһәре мәдәният идарәсеннән Рузилә Камалова, якташлары исеменнән Актаныш районы мәдәнияте бүлеге җитәкчесе Илшат Габделхәев, язучы Айгөл Әхмәтгалиева, сабакташлары исеменнән галимнәр Рүзәл Юсупов, Фоат Галимуллин котлады. ТР Мәдәният министрлыгы вәкиле Рәшит Фәтхуллин Фарсель агага «Мәдәнияттәге казанышлары өчен» күкрәк тамгасы тапшырды.

***

Шагыйрә, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, Абдулла Алиш исемендәге әдәби премия лауреаты Йолдыз Шәрәпованың юбилее уңаеннан, Татарстан Язучылар берлегенең Г.Тукай клубында әдәби кичә үткәрелде. Бәйрәмдарны Татарстан Язучылар берлеге рәисе Данил Салихов, Татарстанның халык шагыйре Роберт Миңнуллин, шагыйрьләр Ркаил Зәйдулла, Шәмсия Җиһангирова, якташлары – Буадан һәм шушы районның Яңа Тинчәле авылыннан килгән делегацияләр һ.б. котлады. Йолдыз Шәрәповага ТР Министрлар Кабинетының Рәхмәт хаты тапшырылды.

## МУЗЕЙДА – СӘНГАТЬ ТӨНЕ

ТР Милли музееның әдәби салонында «Сәнгать төне» дип аталган мәдәни чара кысаларында күренекле язучы, якташыбыз Василий Аксёновның иҗатына багышланган әдәби кичә булып узды. Анда әлеге шәхеснең 75 яшьлек юбилее уңаеннан төшерелгән «Визит пожилого джентльмена» дигән фильм күрсәтелде. Кичәдә Татарстан Рәссамнар берлеге рәисе Зөфәр Гыймаев, язучы Маргарита Небольсина чыгыш ясады. Кичәне әдәби салонның хуҗабикәсе Флүрә Дәминова алып барды.

# В ЭТОМ НОМЕРЕ:

*«Проза и поэзия»: повести Ф.АБДУЛЛИНА «Видел всё, что суждено», Р.ЗАРИПОВА «Матери»; рассказ А.Хасанова; поэма Р.ХАРИСА «Уба»; стихи М.МИРЗЫ, А.САТТАРА (с предисловием Ф.ХУЗИНА), Р.АЙМЕТА, Л.ЯНСУАРА.*
*«Лучший рассказ»: Н.ТУХБАТУЛЛИНА. «Материя, которая говорит, поёт и тоскует».*
*«Новые имена»: повесть А.ХУСНУЛЛИНОЙ «Эхо судьбы», стихи С.АХМЕТЗЯНОВА.*
*«100-я страница»: Ф. ХУЗИН. «Мой родной язык».*
*Интервью Р.ХАННАНОВА с директором 1-ой татарской гимназии г.Казани Г.ШАМСИЕВОЙ.*
*«Наши юбиляры»: Статья Ф.ГАЛИМУЛЛИНА, посвящённая 90 летию М.ХАБИБУЛЛИНА.*
*«90 лет со дня рождения А.БАЯНА»: статья К.КАРИМОВА «Каждый ищет свою молодость».*
*«70 лет со дня рождения А.ХАЙРИ»: статья Л.ЛЕРОНА «Анвар ази».*
*«Наука»: З.МАНСУРОВ. «Сила пера в единстве».*
*«Литературная критика»: Д.ЗАГИДУЛЛИНА. «Кто же он, лауреат Нобелевской премии Г.Сенкевич?»*
*«Из первой книги писателя»: рассказ М.ХАСАНОВА «Герой» (с предисловием Р.ХАННАНОВА).*
*«Тукай и татарская литература»: рубрику ведёт Р.РАХМАН.*
*«Литературное наследие»: З.ВАЛИДИ. «Воспоминания».*
*«Мнение»: А.ЧАНЫШЕВ. «Карачун в снежной горе».*
*«Природа и я»: Л.ГАТАУЛЛИНА. «Ушёл, попрощавшись...»*
*Библиографический список произведений, опубликованных в 2017 году.*
*Дневник общественно-культурной жизни.*
*На наших обложках: «Зимушка». Картина Газиза Губайдуллина; памятник Г.Тукаю (автор – уроженец села Новое Алимово Актанышского района Халит Минлегалиев) в парке культуры и искусства в Актаныше. Фото Вахита Имамова.*

# IN THIS ISSUE:

*«Prose and poetry»: stories by F.ABDULLIN «I saw everything that meant to be», R.ZARIPOV «Mothers»; story by A.KHASANOV; poem by R.KHARIS «Uba»; poems by M.MIRZA, A.SATTAR (with a foreword by F.HUSIN), R.AYMET, L.YANSUAR.*
*«Best story»: N.TUKHBATULLINA. «The matter that talks, sings and longs».*
*«New names»: story by A.KHUSNULLINA «Echoes of destiny», poems by S.AKHMETZYANOV.*
*«100th page»: F. HUSIN. «My native language».*
*Interview by R.KHANNANOV with G.SHASSIEVA, the director of the 1st Tatar gymnasium of Kazan.*
*«Our jubilees»: article by F. GALIMULLIN devoted to the 90th anniversary of M.KHABIBULLIN.*
*«90th anniversary of A.BAYAN»: article by K.KARIMOV «Everybody is looking for youth».*
*«70th anniversary of A.HAYRI»: article by L.LERON «Anwar Hazi».*
*«Science»: Z.MANSUROV. «The power of the pen is in unity».*
*Literary criticism: D.ZAGIDULLINA. «Who is he, Nobel Laureate G.Senkevich?»*
*«From the first book of the writer»: story by M.HASANOV «Hero».*
*«Tukay and Tatar literature»: section is led by R.RAHMAN.*
*«Literary heritage»: Z.VALIDI. «Memories».*
*«Opinion»: A.CHANYSHEV. «Karachun in the snow mountain».*
*«Nature and I»: L.GATAULLINA. «Left saying goodbye...»*
*From the photo archive of the magazine.*
*Bibliographic list of works published in 2017.*
*Diary of social and cultural life.*
*On our covers: «Zimushka». Picture by Gaziz Gubaidullin; monument to G.Tukay in the park of culture and art in Aktanysh (the author is Khalit Minlegaliev, a native of the village of Novoye Alimovo of Aktanyshsky district). Photo by Vakhit Imamov.*

*Тышлыктагы сурәтләр*

*Тышлыкның беренче битендә:* «Кыш». *Газиз Гобәйдуллин картинасы.*

*Тышлыкның дүртенче битендә:* Актанышның мәдәният һәм сәнгать паркындагы Г.Тукай һәйкәле (авторы – Актаныш районы Яңа Әлем авылыннан Халит Миңлегалиев). *Вахит Имамов фотосы.*